# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр. ....3
Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Иблис коткысы. *Кыйсса.* ....13
Руслан СӨЛӘЙМАНОВ. Без – мең үлеп, мең терелгән милләт... *Шигырьләр.* ....61
Рафис КОРБАН. Артык кешеләр. *Роман-эссе.* ....66
Гөлнур АЙЗАТ. Сынаулар бирә Раббыбыз... *Шигырьләр.* ....123
Вакыйф НУРИЕВ. Нәби Дәүли йөз кызарта. *Хикәяләр.* ....127

ЯҢА ИСЕМНӘР

Люция ӘБЛИЕВА. Җиде нота гына җитми икән... *Шигырьләр.* ....135

«СЕЗ ИҢ ГҮЗӘЛ КЕШЕ ИКӘНСЕЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Әнисә ЗӘЙНУЛЛИНА. Очрашу. *Хикәя.* ....138

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Бикә КОЛЫНЧАКОВА. Үкенеч. *Хикәя. (Ногайчадан Рафис КОРБАН тәрҗемәсе.)* ....142

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Равил РАХМАНИ. Шагыйрь гомере. ....149

*Фотоархив.* Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинга 80 яшь. ....161

ФӘН

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. «Ут бөтерчеге». ....163

ХӘТЕР

Айгиз БАЙМӨХӘММӘТОВ. «Курай булып кайтырмын...»
*(Роберт Миңнуллинның тууына – 75 ел).* ....167

ПУБЛИЦИСТИКА

Рухия АХУНҖАНОВА. Сөббух Рәфыйков ядкяре. *Документаль бәян.* ....171

ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП

Марсель ГАЛИЕВ. Күңел кушуы. *(Мостай Кәрим, Кояш Тимбикова,*
*Наҗар Нәҗми хатлары).* ....184

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Тәүге йолдыз *(Асия Измайлованың тууына – 120 ел).* ....188
Милләт бакчасы тәрбиячесе *(Ләбибә Ихсанованың тууына – 100 ел).*
*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 8 (1210) 2023*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.


---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 28.07.2023, график буенча 28.07.2023, басылып чыгу вакыты 03.08.2023
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-1943. Тираж 5483.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2023 ел



Равил
Фәйзуллин

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

## И Казансу!..

*(фрагментлар)*

*Бар атаклы башкалалар –*
*Истанбуллар, Парижлар...*
*Алардан да өстенрәк,*
*безнең өчен Казан бар!*

Казан – Казан була аламы –
Кирмәнсез, Колшәрифсез,
Болаксыз, Кабаннарсыз...
Безнең ачы язмышларны
сыйдырган Казансусыз?

Идел суына кушылып,
тоташасың диңгезгә.
Син – чишмә дә, син – инеш тә,
дәрья да син безгә!
И Казансу, Казансу!..

* * *

Йөрәк тамырлары кебек
тармаклы үзәннәрең.
Гавам хәтерендәме соң
Тарихта күргәннәрең?

Әллә инде оныткanмы
данлы, шанлы чакларын?
Яңа буыннар үсәме
Ватаныңны сакларлык?
И Казансу! Казансу!..

---

Равил ФӘЙЗУЛЛИН (1943) – *Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Алты томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

* * *

Син бит ул – Сөембикәне
сыктап озаткан елга.
Офыкларда рәшә булып
эреде Алтын Урда...

Мәңге яшәргә теләсәк,
гыйбрәт алып үткәннән –
югалтмыйк иманны!
Үстерик үзаңны!
И Казансу! Казансу!..

* * *

Яшәү көче тоеп синдә
тирә-як ярларыңда
күпме халык көн итә!
Әле дә ярый ил пычрагын
агымнарың юк итә!..

Тулышасың. Саегасың –
кемнәр хуҗа ярыңа?..
Акчарлаклар ятып елый
Идел каскадларында.
И Казансу, Казансу!..

* * *

Соң чорларда булды хәлләр
Казансу тамагында!
Үзәнеңне үзгәртүләр,
Болак-улакны томалап,
Кабаннан аерулар...
Бакалтай болынлыклары
әйтерсең, булмаган да...
И Казансу, Казансу!..

* * *

Казансуда бар бер һәйкәл –
Империя өрәге,
Зөядәге чиркәүләрнең
Казандагы терәге...

Яр буенда уйнап-көлеп
сәйран кыла халыклар.
...Эче көеп, чума алмыйча
бәргәләнә дулкыннарда
селитёрлы балыклар.
И Казансу, Казансу!..

* * *

Күбебезне сагындыра
Синең табигый чаклар!
Ярың буенда гөр килеп
тергезелгән учаклар!

Җәннәткә тиң утраулар!
Яшеллек. Җиләк-җимеш.
Җыр. Дуслар. Уен-көлеш.
Син – илаһ дәрья-инеш!
И Казансу, Казансу!..

* * *

Хәзер килсәм, бетон-кыршау
диварларга абынам.
Комлыгында яланаяк
йөргән чакны сагынам!

Әрәмәлекләр кырылгач,
кунмый былбыл баласы.
Су чигенгәч, ачыла шул,
ләмле утраулар булып,
үзәгеңнең ярасы.
И Казансу, Казансу!..

* * *

Яшь чакларда йөзеп-очып
тибрәндек дулкыннарда!
Күкрәкләре тулышканнар
зарыгып көтте ярда...

Ничә мең кабат чыгылган
Миллениум күперләрен!
Подлужныйдагы камышлар
кемнәрнең хәтерендәдер?
И Казансу, Казансу!..

Казансуның чишмә башы –
Арча Иле туфрагы.
Синең суны эчеп үскән
күпме мәшһүрләр ягы...

«Иделгә җитәм!» дигәндә
Казансуны «кысты»лар.
Күпер, Арена, заводлар...
Өстәлде Вамин тагы!..

* * *

Казансуның тарихында
Сабак алыр еллар бар!
Җир астында юллар бармы?
Таш кузгатыр юллар бар!
Явыз Иван гаскәрләре
дары мичкәләре йөрткән
«метро»лы юллар, бар...
И Казансу, Казансу...

Кемнәрдер сөйләнгәли гел:
«Татар барда хәтәр бар!»

Сөйләнсеннәр... Безнең исә
әйтер сүз бар! Хәтер бар!

* * *

«Казан – безнеке!» дисәк тә,
катмарлы аның даны...
Бер якта – азан аһәңе,
бер якта – чиркәү чаңы...
Алармы күтәрә аңны?

Шөкер, хәзер балкып тора
ярында Китапханә!
Төрле милләт яшьләре өчен
ул – гыйльми шифаханә!
И Казансу, Казансу!..

* * *

Җир астыннан выжлап узса,
пассажирлы вагоннар
Өстән канат юлы үтәр диләр,
алдагысы елларны!

Ничек хикмәтле димисең
мондый мәшһүр елганы!
Һава тарантасларында
йөриселәр бар әле!
И Казансу, Казансу!..

* * *

Булды заман... Канда актың
баскын белән алышта...
...Шөкер, хәзер синдә үтә
бар дөнья сокланырлык
халыкара ярышлар.
И Казансу, Казансу!..

* * *

Булсын җәе, булсын кышы –
син һәрчак хәрәкәттә!
Су өсләп тә, боз өсләп тә
җилдерәләр җилкәннәр!

Яр буенда моңсуланып,
карап тора өлкәннәр –
яшьлекләре үткәннәр...
И Казансу, Казансу!..

* * *

Үзең тирән, үзең сайсың,
үзең киңсең, үзең тарсың...
Тарихларның безгә язган
язмышларыбызга парсың.

Шәрык дип тә агасың,
гареп дип тә агасың.
Синең хакта чыгар әле
дастаннарның яңасы!
И Казансу, Казансу!..

## Дулкыннар кочагында

Егылсам да, торып йөгерсәм дә,
туфрактан – җирдән көч алам.
Кошлар нәселеннән булсам да, тик
дәрьяларда гына оча алам!

Бу кулларым Җирдә эш майтара:
казый, юа, ярлар коча ала...
Болытларга карап сузылсам да,
дулкыннарда гына оча алам!..

Дулкыннарда чакта куллар – канат.
Чалкан ятып талпын, кагын син!
Зәңгәр күктә очып барган кошлар
күзләреңне назлап чагылсын!

Су өстендә куллар – таянычым!
Җир-Күк өчен – алар кул гына...
Кош күк оча кеше! Оча!.. Түбәнендә –
һава урынына су гына!
Аермалар бары шул гына...

Кемнәр әйтә Күктә оча! – диеп,
Кеше фәкать суда оча ала!
...Әнә, күрегез, ничек кагына
су читендә нәни бер бала!

## Туган халкым

*Бөтендөнья татар конгрессының*
*беренче җитәкчесе Индус Таһировка*

Бу дөньяда һәркем лаек ихтирамга,
раслый алса яшәвенең олылыгын.
Туган халкым! Ышанычны, илне, телне
бүгенгәчә югалтмавың – горурлыгым!

Матурлыкка, гаделлеккә, тынычлыкка
хезмәт итсәң – намусың пакь, иҗатың чын.
Туган халкым! Сынауларда сабыр булып,
җиңүләрдә батырлыгың – таянычым!

Кайда гына яшәсә дә, һәрбер кеше
милләтенең кабатланмас бер чәчәге.
Туган халкым! Иманына тугры калган
игелекле балаларың – киләчәгең!

* * *

*Айдар Фәйзрахманов исеменнән*

Мәңгелеккә китеп барышында,
әй, ялвардым: кире борыл, дип...
Сабырлыктан Ходай аермасын,
кемдер: «юк!» ди. Ә мин: «бар ул!» дим.

Күпме генә йолдыз атылса да,
күк йөзе сүрелеп каламы?
Кешеләр күңелендә саклансаң,
Үлем дә Яшәүнең дәвамы!

Шатлык-кайгылар, туу-үлемнәр...
Барсы да бер гомер эчендә.
Камил яратылган Кешелек:
Яшәү ул – мәңгелек күченү!

* * *

Безнең чорда, малдан бигрәк,
рухи байлык – баш иде.
Без – китапка, хәзергеләр –
интернетка баш ия.

Виртуаль дөньяда яши
хәзер кайбер бәндәләр.
Башлар түнә кирәксез
информацияләрдән.
Күрәсең, кайчак прогресс та,
регресска әйләнә!

...Моңарчы Тарих – ташларда,
тире-пергаментларда,
кәгазьләрдә язылган!
Нинди имляда булса да,
аерылмыйк язудан!

Без яшәдек һәм яшибез
ирешелгән хак белән.
Бакыйлыкка да күчәрбез
иманлы китап белән.

* * *

*«Кеше кешегә дус»*
*Ишегеңне эчтән биклә!..*

Күгәргән күңелләр.
Тимер ишекләр.
Халыкара чикләр.
Кирәкмәгән шикләр.
Ишек саен бикләр...

Ачыл син, Дөнья!
Күк капусы кебек!

Балкысын Җиһан!
Нурлансын күңел!
...Йомылып яшәүләр
яхшылыкка түгел.

Ясалма җыеннар,
хәйләле уеннар,
«демократ» сайлаулар, –
алыштырамы соң
самимилекне,
күршелекне,
кешелеклелекне?

Бик тә йозак,
бик тә йозак...
Үзебезгә тозак.

* * *

Этләрнең дә була төрлесе:
бар өрә торганнары,
бар тешли торганнары.

Кешеләрнең дә (эт дусты бит!)
бар сөйли торганнары,
бар эшли торганнары...

Этләрнең йә тышта була,
йә абзарда оясы.
...Аларның да киләдер ул
кәнәфигә утырасы.

* * *

Кара урманмы, дала-чүлме ул –
адашып калырга язмасын!
Янәшәдә яшәп, якыннарын
ятим калдырганнар азмы соң?!
Кайчак синнән күпкә түбән җаннар
хәл итәләр Кеше язмышын...

...«Заманалар авыр, еллар ябык»...
Карурманны бергә кичәр өчен
таянырлык дуслар бармы соң?

* * *

*Кеше ник дип кисә икән*
*үзенең иң газиз кылын?*

Алдагысын Алла белә.
Ул беләдер... Ә без?
Алдана – ялмана
ни чиккә җитәбез?

Явызлыклар бишегенә
әйләнмә, Җир-Ана!

Имин яшәү була ала
тик әхлак булганда!

Уртак йорт-планета
һаман сугыш, күз яшь...
Күбрәк игелек кыл,
азрак сөйләш.

## Каршылык

Кемдер ала миллионнар.
Кемдер – ташка үлчим!..
Хезмәт хакы аермасы –
котып белән котып арасы!
Күпләрнең гаделсезлектән –
җанында йөрәк ярасы...

Җыела нәфрәт, җыела үч!..
Беркөн килеп бәреп чыга.
Гавам-халык ташкын булып
инкыйлабка барып чыга.

Ә сугышка кирәк яшь кан.
Яшь кан аңа тансык, таныш...
Ә халыкның күңелендә
мәңге өмет, мәңге сагыш.

## Хәл

Җир җимерткән аягым!
Күккә тигән аягым!
Ярда ярлар күргән чакта
дулкын өсләреннән генә
йөгереп йөргән аягым!

Хәрәкәтне бәрәкәт дип
туймый хәзер аягым...
Туганнан да якын кебек
кулымдагы таягым...

* * *

Иң яшь идем... Иң карт булдым...
Язучылар рәтендә.
Кемгәдер күренәм бугай
аксакал сурәтендә.

Сакал да юк. Чәч тә сирәк.
Хәтер дә шәптән түгел.
Күп нәрсәләр югалтсам да,
һаман яшь калды күңел.

Төштә яңа тешләр чыкты.
Көләм дә елыйм икән!

Балачактагы көйләрне
кабатлап җырлыйм икән...

Шулайдыр ул. Тартынмыла
балалар-оныкларга.
Якынлашам карт көнемдә
сабыйлык дигән ярга.

БАЛАЛАР ӨЧЕН ШИГЫРЬЛӘР

## Гөлүсә

Тәрәзә төбендә
бер матур гөл үсә.
Кадерләп карый аны
Гөлүсә.

Килгән һәр кешенең
күзе гөлгә төшә.
Шуңа бик сөенә
Гөлүсә.

Чәчәкләрен күргәч,
күңеле дә үсә.
Җиргә ямь өсти бит
Гөлүсә!

Тәрәзә төбендә
бер матур гөл үсә,
үзе дә гөл кебек
Гөлүсә!
Гөлләр белән бергә
ул да үсә!

## Өч тиен

*(Газиз улым белән язган шигырь)*

Урманда өч тиен
тапканнар өч тиен.

Утырып танкка,
киткәннәр банкка.

Акчаны салганнар
Бик зур процентка!

Телиләр, янәсе,
Миллион эшләргә!

...Ә безгә нишләргә?!

Ә безгә –
акчага баш ими,
аңлашып,
бергәләп эшләргә!
Эшләргә!

Бу якты дөньяда
Гөрләшеп,
кешечә яшәргә!
Яшәргә!
Яшәргә!

## Тау

Газиз белән, тотынышып,
икәү тауга менәбез.
Менгән саен Туган якның
киңлекләрен күрәбез.

Адым саен без үсәбез,
ә тау – тәбәнәгәя...
Менә-менә башларыбыз
болытка тимәгәе!

Безнең күләгәләр төшә
кошларның канатына.
Утырганбыздыр шикелле
хыялның ак атына!

Уенчык күк өстән – йортлар,
күлләр, поезд юллары...
Ә без гүя әкияттәге
Алып батыр уллары!

...Газиз белән тотынышып,
икәү таудан төшәбез.
Аяк асларына карап,
таштан ташка күчәбез.

Арттан тау зураеп кала.
Кошлар очалар өстән.
Күләгәләр, кечерәеп,
аяк астына күчкән.

Тылсымлы кебек күренми
сукмак та, тирә-юнь дә.
Газиз арып кунаклады
әтисенең иңенә.

Ә шулай да, күңелләр шат.
Өйдә – әни, алда – юл.
Тауларга менгән кешеләр
кечерәя алмый ул!



Галимҗан Гыйльманов

# ИБЛИС КОТКЫСЫ*

КЫЙССА

*«Күктән Иблис төшә» дигән хәбәр*
*килеп ирешкәч, Җир тетрәнеп куйды.*
XIX гасыр кулъязма китабыннан

*Шуның өчен бирелгәнме бу Җан –*
*Иблис теләкләрен үтәр өчен?*
*Тәңре сүзләренә колак салмый,*
*Ишетмәгән булып китәр өчен?*
Фирая Зыятдинова «Мин гөнаһлы»

**1**

Ап-ак чәчле, ак сакаллы, шулай ук актан киенгән бер карт аңа нидер әйтмәкче була. Күз карашлары белән үтәли карап, болай да җыерчыклы йөзләрен тагын да ныграк чытып, сакал-мыек астында күпереп торган калын иреннәрен ямьсез бөрештереп, җан тавышы белән кычкырмакчы була, нидер хәбәр итәргә тели. Тик ничек кенә көчәнсә дә, һич тавышы чыкмый, тамак төбендә кысылып, өзелеп кала. Бераздан аның йөзе дә, күз карашлары да төссезләнә, юыла башлый, аннары күксел томан эчендә бөтенләй юк була.

Менә өченче көн инде Мәүлет төшендә бер картны күрә. Кем ул? Бер изге затмы? Илаһи образмы? Пәйгамбәрме? Әллә?.. Әллә Аллаһы Тәгаләнең үземе? Ходайның үзе үк булмаса да, ким дигәндә, Хозыр-Ильястыр.

Кем генә булса да, Мәүлеткә нидер әйтергә тели ул. Нәрсәдер хәбәр итмәкче була. Әйтергә теләгәне бик мөһимдер шул – әнә бит йөз җыерчыклары соң чиккә җитеп калтыранып тора, күз алмалары кан сауган шикелле көннән-көн алсулана, кызара бара.

* Журнал варианты.

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ (1957) – *шагыйрь, язучы, тәнкыйтьче, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе; Абдулла Алиш, Фатих Хөсни, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты; «Тозлы яңгыр», «Албастылар», «Оча торган кешеләр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Юкка түгел бу. Нindидер мөһим сүз, илаһи ым-ишарә бар монда.

Мәүлет тиле түгел, барысын да аңлый: бу сәер төш иң элек аның үз тормышына, үз язмышына ишарәли. Яхшыгамы бу? Әллә түгелме?

Начарга булмас. Болай да тормышының мактарлык җире юк. Авылдан качып диярлек китте. Анда эш юк. Шәһәрдән дә качты. Анда эшләргә кирәк. Бүген ул шәһәр белән авыл арасына урнашкан бер бистәдә мунча каравылчысы булып эшли. Ни өченме? Анда торыр почмак бирәләр. Бушлай юынып чыгарга була. Мунча эшчеләре эчеп исереп, эшкә килми калганда, алар урынына мунчачы булып та эшләп ала. Монысы инде өстәмә эш хакы дигән сүз...

Менә шул мунчада төнге каравыл торганда төшенә керде дә инде теге ак сакаллы карт. Хозыр-Ильяс. Шул-шул! Кешеләрнең төшләренә кереп, аларның алларына чыгып, бик мөһим әйберләр әйтеп китә, ди, бит ул. Тик авыл картлары аны нурлы йөзле, мөлаем карашлы, изге зат итеп сөйлиләр. Төшкә кереп бимазалаган карт исә бик усалга охшаган – кеше күзенә ярсынган, борчылган кыяфәттә генә күренә... Шулай да күңел аны үз итеп, якын итеп кабул итә. Мәүлетне кисәтергә, нindидер бәладән саклап калырга тели ләса ул.

Күңелен бимазалап йөдәткән уйлары белән үзенең тәрәзәсез-нисез тар бүлмәсендә аунап ятты-ятты да Мәүлет, күңеленә тынычлык эзләп, урамга чыгып китте. Гөнаһ шомлыгына, урамга атылып килеп чыгу белән ул ишеккә ышкылып диярлек үтеп баручы бер ир кешегә барып бәрелде. Бәхеткә, алтын кысалы күзлек кигән бу бәндә бик тәрбияле, зыялы булып чыкты: мөлаем генә елмайды да гафу үтенеп, ары китеп барды.

Җыештыручы Шәмси карт көзнең соңгы яфракларын себереп йөри иде.

– Нихәл, Шәмси бабай?

– Хәлләр синдәдер инде, миндә менә бер өем яфрак.

– Каян белдең миндәге хәлләрне, Шәмси бабай? Әүлияме әллә син?

– Йөзеңдәге борчуны күрер өчен гөнаһлы җир кешесе булу да җитә, балакай.

– Нинди җир, нинди гөнаһ? Ни сөйлисең син, Шәмси бабай?

– Үзем турында гына әйтәм, башкаларда эшем юк...

– Шулкадәр күпмени гөнаһың?

– Җитәрлек. Ахырзаманда күп мәшәкатьләнергә туры киләчәк миңа...

– Шулай укмыни?

– Шулай. Ә хәзер сөйлә – нәрсә борчый сине? Минем гөнаһларым хакында сорашырга чыкмагансыңдыр бит?

– Гөнаһлар хакында түгел, изгелекләр хакында сөйләшергә чыктым мин синең белән.

– Изгелекләр дисеңме? Анысы миңа түгел. Изгелекләр хакында сөйләшү өчен башка адәмнәр эзлә.

– Юк ла, аңламадың син мине, Шәмси бабай, әйт әле: син төшләргә ышанасыңмы?

– Тукта, тукта... Нигә әле бу хакта сорашасың? Төшләр хакында сөйләшергә ярамаганын беләсең бит? Илаһи ишарә бит алар. Ходай ихтыяры. Аллаһы Тәгалә өлешенә кермә, балакай, ай-һай, кермә.

– Шәмси бабай, туктале, тыңлап бетер башта! Әллә нинди сәер төш керде миңа. Миңа аны ничек тә аңларга кирәк. Юкса...

– Нәрсә – юкса?

– Юкса бәла-каза килүе бар.

– Шулай укмы?

– Алайса, сөйлә. Тик белеп сөйлә: авырлыгы үзеңә булачак.

Шәмси карт кулындагы себеркесен юкә агачына сөяп куйды да чүп ташый торган кул арбасының читенә килеп утырды.

– Хикмәт шунда: менә өченче көн инде төшемә Хозыр-Ильяс керә.

– Тукта! Шунда тукта! Хозыр-Ильяс кергән төш – шаукымлы хәбәр. Кисәтү төше. Шуңа күрә дә син аны миңа сөйләргә тиеш түгел. Миңа ачылмаячак ул, чөнки мин изгеләр белән дус түгел. Минем тирә-якта Иблис токымнары гына... Җыен эчкече, бозык, түбән җаннар... Мәхлук бәндәләр...

– Нишләргә соң миңа? Төшкә кергән Хозыр-Ильяс өченче көн инде миңа нидер әйтергә тели. Ләкин мин аны ишетмим.

– Ә син имчегә бар. Юраучыга.

– Кемгә? Имчегә? Юраучыга? Андыйлар әле дә бармыни?

– Бар. Имчеләр дә, төш юраучылар да, фал ачучылар да бар. Сиңа бу шаукымлы төшең белән шулар янына барырга кирәк, балакай.

Шәмси карт бит-йөзенә үтә дә җитди кыяфәт чыгарып, болай да җыерчыкка чорналып беткән маңгаен тагын да ныграк җыерып, эчкә баткан төссез күзләрен күккә төбәп, бераз тын калып уйланып торды да, дәррәү торып, урам читендә тузгып яткан яфрак өемнәрен лакандай зур чиләгенә тутыра башлады.

Мәүлет акрын гына кузгалып, олы юлга таба китте. Ләкин бер-ике адым атлауга, кире борылды да ах-ух килеп, яфрак җыючы Шәмси картка кычкырды:

– Каян табарга соң ул имчене? Төш юраучыны? Ә?..

Мәүлетне тәмам аптырашта калдырып, җыештыручы карт бу сорауны күптән көткән кебек бик теләп җавап бирде.

– Урам башында ике катлы йорт торамы? Әле күптән түгел генә шунда бер имче хатын килеп яши башлаган. Менә шул хатынның кызымы, сеңлесеме бар, имеш. Менә ул төшләрне аңлата ала, диләр. Тик кара аны, ипләп сөйләш, зыяны тия күрмәсен... Ышан син аларга...

## 2

Мәүлет бераз таптанып торды да кабат бүлмәсенә керде. Хөкүмәт мунчасының бер ягына урнашкан тынчу фатиры бу юлы тагын да шыксызрак булып күренде аңа. Күңеленә кереп оялаган шомлы уйлардан шулай икәнен Мәүлет аңлый, әлбәттә. Гомердә булмаган хәл бит: йөрәге ярсынып тибә, күңеле тынгысызланып борчыла. Җаны елый. Бәгыре өзгәләнә. Теге сәер төш кенә сәбәпчеме моңа? Анысы да бардыр. Ләкин ул гына да түгелдер.

Ныклап уйлап карасаң, тормышы бер дә рәтле түгел бит аның. Кешеләргә зыяны тимәсә дә, файдасы да тигәне булмады кебек. Әллә ничек кенә килеп чыкты аның гомере – рәхәтләнеп искә алырлык бер генә сөенече-шатлыгы да юк бит, ичмасам.

Авылдан киткәненә ун ел, аның әле аякка басканы, юньле-башлы тормыш кора алганы юк. Колхозлары таралып, авылдан киткәч, баштарак завод тирәсендә эшләштереп йөрде, аннары Казанда көч ала башлаган милли хәрәкәткә катнашып китте. «Азатлык!» дип кычкыра-кычкыра, яшел әләмнәр,

акыллы сүзләр, лозунглар язылган плакатлар күтәреп, шәһәр урамнарында күп йөрде, җыелышларда ялкынлы чыгышлар ясарда өйрәнде, фикердәшләре, көрәштәшләре барлыкка килде. Ләкин бердәнбер көнне милли хәрәкәттән гайрәте чикте аның. Милли азатлык көрәше башында торган кешеләр аларны ярымҗимерек урамнар уртасында ташлап калдырдылар. Яңа фатирлар, депутат таныклыклары, чиновник вазифалары, һич булмаса, бай фирмаларның, базарларның, банкларның матди ярдәмнәре бәрабәренә көрәш идеалларыннан баш тарттылар. Урамда калганнарның кайберләре – дингә, икенчеләре аракыга, әфьюнгә, башка төрле шайтан вәсвәсәсенә бирелде. Берничә мәхлук җан гына, демагог битлеге киеп, һаман әле урамда йөри. Ләкин аларны инде беркем дә ишетми. Алар хәтта үз-үзләрен дә ишетми. Теге төшкә кергән картны Мәүлет ишетми бит, нәкъ шулай.

Ачлы-туклы шәһәр тормышыннан туеп, бердәнбер көнне Мәүлет менә шушы бистә мунчасына килеп төпләнде. Үткәндәге урам вазгыятеннән, вакыт җиленнән җете төсләре уңа башлаган, бер буш, караңгы почмакка сөяп куелган Татарстан флагы гына торып калды.

Монда тыныч. Җаныңа замана юшкыны утырган булса да, тәнең чиста. Мунчаның бөтен пычрагын юарга туры килә килүен, аның каравы тук тормыш белән яшәрлек җай чыгып тора. Клиентлар арасында акча исәбен оныткан байлар җитәрлек – бераз күңелләрен күрсәң, акча кызганмыйлар. Кемгәдер әйбәт номер кирәк, кемгәдер сый өстәле әзерләп куярга туры килә. Чабыныр өчен хуш исле себерке, сыланыр өчен бәлзәм сулары, бал-майлар хакында әйтеп тә торасы юк.

Бу кайгысыз, әмма кызыксыз тормышында бернинди кискен үзгәреш тә көтелми иде, югыйсә. Һәм менә сәер төш. Бәлки шушы урында оныттыргадыр аны? Онытырга тырышыргадыр? Беркая да бармаскадыр? Шайтан шаукымы гына булса? Иблис коткысы?

Теге карт бүген тагын төшенә керсә? Ю-у-ук! Тагын бер күренсә, Мәүлетнең йөрәге түзмәячәк, урталай ярылачак, билләһи!..

Булган акчасын алды да Мәүлет бистәнең аргы башында яшәүче имче хатынны эзләп китте. Сорашып мәшәкатьләнергә туры килмәде, дүрт-биш йорт узуга, ике катлы йорт ишеге төбендә җыелып торган халыкны күреп алды. Сәер, әлбәттә – Мәүлет шунда ук күңеленә иләс-миләс, хәтта бераз шаукымлы хисләр иңә башлавын тойды. Шуңа күрәме, ул бу йортта имче хатын яшәгәнлегенә шикләнмәде дә, хәтта эченнән генә: «Шушында!» – дип, үз-үзен җөпләп куйды.

– Нихәл, апалар! Шушында торамы сихерче кыз?

– Абау! Тәүбә-тәүбә диген, балам. Изге кеше хакында андый сүзләр сөйлиләр, димени?!

Ишек катындагы озын эскәмиядә соңгы кеше булып утыручы, гайрәтне чигерерлек дәрәҗәдә ямьсез, йөз-битен тирән җыерчык баскан карчык, шелтә сүзләре белән генә чикләнмичә, алдына кулларын кушырып куеп, сихер догалары укырга тотынды.

Мәүлет әлеге «җен карчыгы» янына килеп басты. Җиргә чүгәләде. Дога иясенә ияреп, учларын алдына кушырып куйды. Ниндидер дога укырга уйламады да, дөресен генә әйткәндә, белми дә ул изге Коръән сүзен. Дога укыган кыяфәт чыгарып, чиратта торучыларны күзәтә башлады. Җыелган

кешеләр арасында яшәр гомерләрен тәгәлләп килүче карт-коры да, әле яши генә башлаган яшь-җилкенчәк тә бар. Чиратның урта бер җирендә, башкалардан кыенсынган кебек бер-берсенә сыенышып, яшь пар утыра. Ир белән хатын – әллә каян күренеп тора. Барсының да йөзләре җитди. Һәркемнең үз борчуы, җан ярсуы бардыр, күрәсең. Әнә теге карт көч-хәл белән сулыш ала, ютәлли башласа, озак кына тынычлана алмый интегә. Ә бу карчык, аяк балтырларын угалап, бертуктаусыз сызланып утыра. Әнә теге яшь кыз кулына кемнеңдер фотосурәтен тоткан. Җиту чәчле егет төшкән бу фотоны имчегә күрсәтеп, аның язмышын белергә телиме ул?

Менә бервакыт подъезд ишеге ачылып китте дә иңенә ап-ак шәл япкан хатын-кыз шәүләсе килеп чыкты. Мәүлет аның йөзен, үзен шәйләп өлгергәнче, җыелган халык аны сырып та алды. Баксаң, озын су буе эскәмиядә Мәүлет берүзе утырып калган икән.

Баштарак аңышмыйча торса да, ишек катыннан килгән мөлаем тавышны ул аермачык ишетте:

– Төшен юратырга килгән кеше керсен!

Мәүлет атылып-бәрелеп килеп җиткәндә, баягы хатын кереп киткән иде инде. Җыелган халык, як-якка тайпылып, аңа юл бирде. Ишеккә кадәр ачылган аралыктан барганда Мәүлетнең күңеленә баягы сәер тойгы кабат ургылып килеп керде. Гүя бу гамәлләрнең барысы да аның өчен генә, аны шушы имче хатын белән очраштыру өчен генә эшләнә иде. Гүя ул инде үз ихтыярында түгел, теләсә дә, кире борылып китә алмаячак, шушы йортның кайсыдыр фатирында аны көтеп утыручы хатын белән очрашмыйча кала алмаячак иде...

Подъезд ишегеннән керүгә баягы хатын каршы алды. Мәүлет аның үзен күрмәде, йомшак, җылы кулларын гына тойды. Бу куллар аны җитәкләп, дөм караңгы коридор буенча алып китте. Шактый бардылар. Нindидер текә баскыч буйлап өскә менделәр, аска төштеләр. Торган саен Мәүлетнең күңелендә дә шом арта барды, йөрәге ешрак типте, тәненә салкын тир бәреп чыкты. Ул үзен җир астына төшеп баргандай хис итте. Ләкин аң-зиһене гомер булмаганча ачык, якты иде. Шул ачык, якты аң-зиһенендә бәргәләнгән бердәнбер сораудан һич котыла алмады: «Бу имче хатын ничек күрә икән мондый гүр караңгылыгында?» Гомумән дә, бармы соң ул? Әллә берәр сихри, зәхмәти көч, җен-пәри алып барамы аны? Әнә бит – аяк тавышы да, сулыш алуы да ишетелми. Бары тик кул җылысы гына, шул кулындагы кан тибеше генә тоемлана.

Менә бервакыт Мәүлет каршында нindидер ишек ачылып китте, алда якты, хәтта нурлы ачыклык пәйда булды. Җитәкләп барган кул аны шул ачыклыкка кертеп җибәрде дә үзе сәер генә юкка чыкты.

Мәүлет гаҗәеп дәрәҗәдә якты, нурлы һәм татлы хушбуй исләре аңкып торган бүлмә эченә килеп керде. Күзләрне чагылдырырлык бу нурланыш һәм тәмле ис аны һич кенә дә сискәндермәде, киресенчә, шомлы караңгылыктан соң тынычландырды гына. Түрдәге тәбәнәк өстәл янында ак япмага төренеп утырган кызыйны күргәч, Мәүлет тәмам тынычланып җитте. Хәтта бөтен йөз-чырае белән елмаеп: «Мине чакырган идегезме?» – дияргә батырчылык итте.

Кызый да елмаеп җавап бирде. Ләкин урыныннан тормады, хәтта озын керфекләрен кагып куярга да кирәк тапмады.

– Сине...

Шулай алар бераз вакыт елмаешып, бер-берсенә карашып тордылар. Мәүлетнең бу кадәр чибәр, мөлаем йөзне күргәне юк иде әле. Кояш кебек балкып утыручы бу сихри зат фәрештәләрдән бер дә ким түгелдер... Әллә? Әллә фәрештә кешеләр шундый була микән? Юктыр. Фәрештәнең үзедер бу! Шулай булмаса, бу кадәр рәхәт тойгылар кичермәс иде Мәүлет, бу кадәр бәхетле булмас иде... Әллә бу кызның йөзеннән, тәненнән аңкып торган татлы хушбуй исе аны шулай исертәме, зиһенен томалыймы?

– Төшеңне сөйлә!..

Мәүлет сискәнеп, айнып киткәндәй булды. Аның бая гына бәхетнең үзенә тарган иләс күңеле кабат шомлы хисләргә, тирән борчуларга дучар ителде... Чынлап та, ул бит монда бәхет эзләп килмәде, бары тик сәер төшен юратырга, шул төшендәге серле картның әйткәннәрен ишетергә килде.

Мәүлет өч көн рәттән күргән төшен сөйләргә кереште.

Имче кыз аны шулкадәр бирелеп тыңлады, Мәүлет сөйләп бетергәнче керфек тә какмады, хәтта сулышын да алмый торды, ахры.

Имче дигәннәре күп сөйләшми торган зат булып чыкты. Тыңлап бетергәч, шунда ук эшкә кереште.

– Бир кулларыңны. Күзеңне йом.

Мәүлет, күзен йомып, кулларын алга сузды. Кызга якынрак барырга теләп, түргәрәк омтылды. Ләкин бер карыш та кузгала алмады. Ниндидер көч аны баскан урынына беркетеп куйган иде.

Шулвакыт ул үз учларында кызның кул җылысын тойды. Тойды да аңын югалтырлык дәрәҗәдә сихри халәткә тарды. Бу халәтне илаһи хиссият яки татлы бер төш белән генә чагыштырырга мөмкиндер.

Төш шул. Әнә ул таныш карт – ап-ак сакаллы, ап-ак озын чәчле, ак йөзле, ак күңелле. Күзләрендәге алсулык кына шомлы, хәтта куркыныч! Әйткән сүзләре дә шомлы. Җир йөзенә, кешелек тормышына килгән хәтәр афәт, зур бәла, бетмәс-төкәнмәс кайгы хакында хәбәр итә иде ул.

– Илаһи күк кануннарын бозган Газазил җәнаплары «Иблис мәлгунь» дип игълан ителде һәм Аллаһы Тәгалә катыннан сөрелде. Ул инде Аллаһ катыннан бер тапкыр куылып, мең тәүбә бәрабәренә аның мәрхәмәтенә ирешкән иде. Хәзер илаһи сынау итеп гөнаһлы Җиргә җибәрелде. Сиңа, Исхак улы Мәүлеткә, шайтаннар хәзрәте гыйфритне, ягъни мәсәлән, Иблис мәлгуньне табарга, танырга һәм бөтен инсаният каршында фаш итәргә кушылды. Югыйсә Җир кешеләрен зур бәлаләр, казалар көтә. Онытма, син Илаһи Күк каршында, Аллаһы Тәгаләнең Үзе каршында җавап бирәчәксең... Җавап бирәчәксең... Җавап бирәчәксең...

Мәүлетнең төш шаукымына бирелгән зиһененә бик авыр барып җитте бу хәбәр. Нинди Иблис? Нинди Газазил? Аларга Мәүлетнең ни катнашы бар? Аллаһы Тәгалә иңдергән бөтен догаларны хөрмәт итсә дә, аның бер тапкыр дога кылганы, намаз укыганы юк ласа. Хет мәчеткә барып, сәдака бирсен иде. Нигә ул, нигә башка бер дога иясе, диндар кеше түгел? Ник-нигә?..

Күреп, ишетеп торган диярсең, төшендәге изге зат тагын Мәүлет каршында пәйда булды һәм өзек-өзек сүзләр белән аның сорауларына җавап бирә башлады:

– И изге бәндә! Аллаһыбыз сине сайлады, чөнки син көннәр буе Адәм балаларын агарту, чистарту белән мәшгульсең. Агарынган, чистарынган кешеләрдән кабул иткән рәхмәт савапларының иге-чиге юк...

Ходай исеменнән сөйләүче пәйгамбәри карт, ничек пәйда булса, шулай ук кинәт юк та булды. Мәүлет күзләрен ачканда бүлмәдә беркем дә юк иде инде. Аңа караңгы коридор буенча капшана-капшана, ялгызына гына чыгып китәргә туры килде...

**3**

Бу юлы Шәмси карт Мәүлетне серле елмаеп каршы алды.

– Ничек? Имчегә бардыңмы? Нәрсә диде? Ну-ну...

Мәүлет, киресенчә, үтә дә җитди иде. Шуңа күрә дә тиз генә җавап бирмәде. Җавап бирергә уйламады да, ахры. Ул зиһенен томалап алган уйларыннан айнып җитмәгән иде әле.

Чынлап та, Мәүлет өчен төш белән өн алышынган мәл иде бу. Бу кадәр хикмәтле хәлләргә юлыгасын белсә, йөрер идемени ул имче эзләп!.. Тик утырыр иде үзенең аулак бүлмәсендә. Көн саен мунчага кереп, парланып чыгар иде, башкаларны чабып кинәнер иде. Соңыннан бөтен арганнарын тар бүлмәсендәге тар караватында калдырып, кабат терелеп китәр иде.

Ә монда Аллаһы Тәгаләнең үзе белән эш итәргә туры киләчәк, имеш. Ходай белән генәме?! Иблис белән! Шайтаннар атаманы белән! Ай-ай-ай, килеп каптың да соң, Мәүлет иптәш!

– Шәмси бабай, әйт әле: ни өчен мин? Нигә Иблисне мин табарга тиеш? Бүтән кеше беткәнме әллә? Менә син, ягъни мәсәлән. Күп явызлык күрдем, дисең бит. Сихергә каршы догалар да беләсең. Мәчеткә дә йөрисең.

– Сиңа да догага ирешергә, намазга басарга туры киләчәк, балакай. Бу изге эштә тәнең генә түгел, күңелең дә, рухың да, җаның да саф, иманлы, догалы булырга тиеш.

– Мин бит каршы түгел, Шәмси бабай! Догага күңелем ачык минем. Кирәк икән – намазга да басармын. Тик таба алырмынмы соң мин ул Иблис шайтанны? Таба алмасам, нишләрмен? Җир нишләр, кешеләр нишләр? Ахырзаман җитәрме?! Кыямәт кубармы? Ә?

Шәмси карт мәсьәләнең бик җитди икәнен аңлап алган иде инде. Ул Мәүлеткә ияреп керде. Күтәлмәгән хәлләрдән җан тынычлыгын югалткан танышын ялгыз калдырасы килмәде, ахры. Ә менә Иблискә карата аның үз фикере бар икән.

– Менә син, Мәүлет балакай, мунчада эшлисең. Аңа күз-колак булу сиңа тапшырылган. Кешеләрнең тән чисталыгы синнән тора, значит! Ә син беләсеңме соң, Хода бәндәсе, Иблиснең Адәм галәйһи-әс-сәлам балаларыннан аермасы нидә? Аның койрыгы була! Ул гына түгел, аның кендеге булмый, чөнки ул – явыз рух! Аның яшәеше генә түгел, тумышы башка төрле...

– Моның белән нәрсә әйтмәкче буласың, Шәмси бабай?

– Вәт шул: ул койрыкны кайчан күреп була? Чишенеп, шәрә калганда. Ә бәндә заты кайчан шәрә кала? Юынганда! Ул күбрәк кайда юына? Мунчада! Белдеңме инде Аллаһы Тәгаләнең ни өчен сине сайлаганын? Дөрес сайлаган ул, аңлыйсыңмы?! Ходай бит ул!.. Аллаһ!..

– Юатма мине, Шәмси бабай. Бу барыбер дөрес түгел. Аллаһы Тәгалә күктән куган Иблисне минем кебек гади кеше баласы ничек тапсын, ди?! Аннары, нишлим мин аның белән? Иблискә каян минем көчем җитсен?! Их, Шәмси бабай, хәзер шул төштәге картка ышанып яшәргәме инде? Ә? Төш кенә бит ул! Төш ул – әкият, хыял, уйдырма, шулай түгелмени?!

– Ә имчедәге хәлләрне кая куясың, балакай?

– Анысын аңлата алмыйм. Шул куркыта да инде мине, Шәмси бабай...

Күктән сөрелгән Иблис тарихын ничек кенә хәтереннән чыгарып ташларга теләсә дә, Мәүлет булдыра алмады; бу төш, бу тарих аның күңеленә генә түгел, җанындагы, тәнендәге һәр күзәнәк бөртегенә иңеп өлгергән иде инде. Ул шуны да бик тиз аңлап алды: бүгеннән аның гомере тап ике өлешкә бүленә: моңа кадәр яшәгән гомеренә һәм алда яшисенә. Яшәячәк гомеренең авыррак булачагын, явыз рухлар, шайтани затлар эзләп үтәчәген ул күңеле белән тойса да, аңлап та, язмышына кабул итеп тә бетерә алмый иде әле.

Төнлә төшенә тагын теге карт керде. Бу юлы ике дөнья арасындагы пәрдә ачылып, картның әйткәне аермачык ишетелә иде:

– И адәм баласы! Максатың изге, күңелең ихлас, рухың көчле булсын! Аллаһтан, аның догасыннан аерылма! Иблискә каршы тору өчен син иң элек Ходай мәрхәмәтенә ирешергә тиеш.

Иртән торуга Мәүлет, Шәмси картка кереп, догалар китабын алып чыкты. Аннан таныш хәрефләр белән язылган беренче догасын укыды: «Әгузү билләһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмил-ләһир-рахмәнир-рахиим.» (Таш белән атылмыш шайтаннан Аллаһыга сыгынамын. Шәфкатьле һәм мәрхәмәтле Аллаһы исеме белән.)

Укыган саен аның күңеле тынычлана, җылына барды. Дога уку аның өчен өшеп-туңып йөргән кешенең җылыга керүе, терелүе, тормышка кайтуы белән бер иде.

Мәүлет урам себерүче картның «Иблис койрыгы» хакындагы әкияте белән генә берни кырып булмаячагын бик тиз аңлап алды. Һәм ул Ходайның хакыйкый тәгълиматына бөтен күңелен баглады, Коръән сүзе белән үзенең үксез җанын тәрбияләде, какшый башлаган рухын ныгытты. Юл уңаеннан күршедәге китапханәгә дә кереп чыкты, Илаһи Күктән сөрелгән Иблис тарихы белән якыннанрак танышасы килде аның.

Мәүлетнең йөрәге тукталып калгандай булды. Китапханәнең якты залында укырга китаплар өләшеп утыручы кыз йөз-бит чалымнары белән таныш имче кызга охшаган иде. Мәүлет бу хәлгә аптырамаска тырышты. Кем кемгә охшамас! Аннары ул имче кыз янындагы хәлләрдән соң юлында очраган һәр гүзәлкәй, сихерче яисә пәри заты булып күренүе мөмкин бит!

– Исәнмесез? Сезне нәрсә кызыксындыра?

– Иблис... Иблис тарихы.

– Аңламадым.

– Гафу итегез. Ничек әйтим икән. Миңа Ходай катыннан Җир өстенә сөрелгән шайтани затлар һәм Иблис хакында нинди хәбәр бар, шуларның барысын да уку залына китерегез.

– Хәзер аңладым. Соңгы вакытта, нишләптер, барыгыз да Иблис белән кызыксына башладыгыз.

– Барыбыз да? Тагын кемнәр кызыксына?

– Кичә бер ир кеше кереп чыкты. Газазил-Иблис затлары хакында фәнни эш язып йөри икән. Чынлыкта, ул шушы Иблис тарихын поэма итеп язган бер шагыйрьне өйрәнә. «Һәр талантлы шагыйрьдә иблислек буладыр инде, минем шагыйрь дә шундыйрак» дип сөйләнеп торды.

– Кызык бу, ләкин миңа карамый. Минем үз иманым, үз Иблисем.

– Бераз көтегез, хәзер алып киләм.

**4**

Мәүлеткә намаз җиңел бирелде. Ике-өч көндә тиешле догаларын ятлап, идәнгә «баш орырга», сәҗдәгә китәргә өйрәнде. Ләкин зиһененә дога сеңсә дә, күңеленә тынычлык та, канәгатьләнү дә иңмәде. Ятлаган догаларына ул рухын да, йөрәген дә баглый алмый җәфаланды.

Шәмси карт бу хәлгә үзенчә аңлатма бирде:

– Син, Мәүлет балакай, хәтереңә дога алсаң да, күңелеңә Аллаһның үзен ала алмагансың әле. Менә әйт әле: намаз вакытында нәрсә хакында уйлыйсың?

– Нәрсә хакында дип... Мунчадагы хәлләр хакында. Нинди ризык юнәтү, кайчан кая бару хакында, иртәгә иртән нинди эшләр эшләү хакында.

– Шул шул! Намазлык өстендә боларның барысы да артык. Намаз гыйбадәте вакытында синең күңелеңне, зиһенеңне, җан һәм тән шәрифләрен Ходай биләп алган булырга тиеш. Бу вакытта синең белән Аллаһы Тәгалә генә булырга тиеш. Син аңа эндәш, аңа сәҗдә кыл, гөнаһларыңны ярлыкавын телә, иман китер. Кайчакта гафу үтен, хәтта тәүбә ит!

– Аңладым, Шәмси бабай.

– Юк, аңламадың әле. Сиңа боларны аңлау өчен вакыт кирәк. Дога күңелеңнең ихтыяҗы булып әверелгәнче шактый гомер үтәчәк әле. Шуны онытма, балакай: иманлы күңел белән генә Иблис мәлгуньне табып, фаш итеп булачак.

– И-и Шәмси бабай... Һаман шул бер нәрсәне тукыйсың. Син чынлап та ышанасыңмы әллә шул Иблис тарихына?

– Ә син? Син ышанмыйсыңмыни?

– Белмим. Күңелем белән ышанамдыр да. Ләкин зиһенем һич кенә дә ышанырга теләми. Төш кенә бит ул, Шәмси бабай. Ничек ышанасың, ди, аңа?

– Алайса нигә имчегә бардың соң? Нигә китапханәгә кердең? Нигә намаз мәшәкатенә бирелдең?

– Бардым, бирелдем... Анысы дөрес. Бигрәкләр дә ялварып дәшә иде шул ул төштәге карт. Иблис өчен түгел, күңелем тынычлансын өчен эшлим бит мин боларны, Шәмси бабай.

– Тынычландымы соң? Күңелеңне әйтәм...

– Юк шул. Шуңа да Ходайга якынайдым, намазга бастым.

– Мәүлет балакай, бу эштә син миңа караганда да акыллырак булып чыктың, шуңа күрә бүтән киңәш бирә алмыйм. Ләкин бер сүз әйтәм.

– Нинди сүз ул, Шәмси бабай?

– Син ничек тә Иблисне фашларга тиеш. Сиңа шундый бурыч йөкләнгән.

– Бик каты куясың син мәсьәләне, Шәмси бабай. Бөтен кешелекне Иблис коткысыннан яклап чыгарга мин кем соң әле?

– Сине Аллаһы Тәгаләбез сайлаган, һәм син Аның ихтыярына буйсынырга тиеш!

– Анысын да аңлыйм, беләм. Ходайдан башка эшләнмәгән бу эш. Төшләрнең аның ишарәсе, илаһи ымы икәнен дә тоям. Тик ни өчен мин соң? Мең-миллион мәртәбә сорыйм: ни өчен мин, ә башка берәү түгел, ә?

– Син и баста! Димәк ки, бу минутта син – кешелекнең иң ышанычлы һәм тугры вәкиле. Тагын әйтәм: син бу эшне үтәп чыгарга тиеш. Мин хәтта төгәл беләм: син аны эшләп чыгачаксың.

Мәүлетнең тар бүлмәсендә озак кына утырдылар. Бергә чәй эчтеләр, намаз укырга өйрәнделәр.

Шәмси карт чыгып китәргә кузгалгач, Мәүлет аның җиңеннән тартты.

– Шәмси бабай, син Иблиснең барлыгына ышанасыңмы?

– Вәт сиңа мә! Баядан бирле шуны сөйләшеп утырдык лабаса! – Шәмси карт каушавыннан кабат урындыкка чүкте. – Ышанам, ник ышанмаска? Ходай катыннан куылган бит ул. Димәк, важный кош. Ходайга ышанган кеше аңа да ышанырга тиеш. Иблис белән шаярырга ярамый, ай-һай, ярамый.

Мәүлет кич буе уйланып ятты. Төнгә бөтен өйрәнгән, белгән догаларын укып керде. Әмма төшендә Ходай илчесе белән очраша алмады. Бала чагы керде, бик иртә дөнья куйган әнисе, яшьлектә яратып йөргән Нәзифә сылу, дуслары, туганнары... Әмма таныш карт төшенә кермәде. Икенче көнне дә, өченче көнне дә күренмәде ул. Мәүлет аңа үпкәләргә генә тора иде, җиденче көн дигәндә, өндәге кебек, ап-ачык булып каршында пәйда булды ул. Булуын булды, әмма бер сүз эндәшмәде, елмаеп баш кына какты. Мәүлет үзе дә елмаеп җавап бирде. Ул инде аңлап алган иде: изге зат аңардан разый, ул аның гамәлләрен, уй-ниятләрен хуплый.

Тик соңыннан картка нидер булды. Ул Мәүлеткә нидер әйтергә теләде. Җитдиләнде. Ләкин әйтергә өлгерми калды.

Шулай елмайган килеш уянып китте Мәүлет. Нишләптер, шундук имче кызны исенә төшерде. Дөресен генә әйткәндә, ул фәрештә кебек асыл затны бервакытта да онытмады, тик моңарчы, күз алдына чыгармыйча, күңеленең иң матур җирендә саклап, иркәләп тотты. Хәзергә кадәр аптырап бетә алмый Мәүлет: каян белеп, сизеп чакыртып алды икән ул Мәүлетне? Соңыннан нәрсә булды? Каядыр юкка чыкты бит ул. Изге карт белән сөйләшү, аралашу шатлыгыннан ничек чыгып киткәнен сизми дә калган иде ул вакытта. Ай-һай, сәер, шаукымлы зат булып чыкты бу чибәркәй! Һаман бер тойгы тынгылык бирми: гүя Мәүлетне кабул итү өчен генә, аңа Ходайның теләгән ирештерү өчен генә яратылган кебек ул.

Мәүлетнең бик тә, бик тә имче кызны күрәсе килде. Юк анысы, башка гозере, үтенече юк-югын. Барысы да тәртиптә. Шулай да, бер генә күреп каласы иде үзен. Аңа карап, күңелне юатасы иде, җанны тынычландырасы иде!

Нишләп булмасын?! Бик мөһим үтенече бар аның имче кызга. Бүген төшендә Хозыр-Ильясның ни әйтергә теләгәнен беләсе иде. Тагын нидер хәбәр итәргә теләде бит ул Ходай илчесе. Хәтта борчылган кебек иде.

Бу юлы Мәүлет имче кыз янына озын чират торып керде. «Минем хакта оныткан, оныткан!» дип, үпкәләгән, битәрләгән кебек, балаларча уйлап та алды.

Чираты җитеп барып кергәндә, чибәркәй аны аяк өсте басып көтеп тора иде.

– Юк, онытмадым, – диде ул, Мәүлетнең баягы уйларын укыгандай. – Без

хәзер синең белән бер язмыш ияләре. Син хәзер минем янга гел киләчәксең. Аңлыйсыңмы мине? Юк? Аңламавың хәерлерәк. Аңлый башласаң, акылдан язачаксың син. Дөнья чиге бик шаукымлы, кешеләр өчен түгел. Бу чиккә килеп кагылу белән адәм балаларының зиһене какшый башлый, күңеле иләсләнә.

Мәүлеткә, риза булып, баш кагып кына утырасы калды.

– Карт тагын килдеме?

– Килде. – Мәүлет, тотлыга-тотлыга, төшендә күргәннәрен сөйләп бирде. – Баштарак разый булып торса да, соңыннан нидер әйтмәкче булды. Әйтә алмый калды. Ни әйтергә теләде икән ул?

– Ул, чынлап та, борчылган. «Яңа Ай тулганчы Иблисне тапмасаң, Җир өстен караңгылык, бәндәләр күңелен явызлык, күзләрен кан-яшь томалап алачак», – димәкче була ул.

– Боларны каян беләсең, мин бит әле сиңа бүгенге төшемне күрсәтмәдем?..

– Бу кирәк тә түгел. Ул изге зат инде минем белән. Ә мин аның белән... – Чибәркәй тыйнак кына, әмма бик серле елмаеп куйды.

Имче кызның нәрсә әйтергә теләгәнен аңлап бетермәсә дә, Мәүлет баш кагып куйды. Ләкин елмаймады. Аның күңеленә таныш түгел бер шик кереп оялаган иде шул инде. «Ай тулганчы» ди бит.

Шулвакыт имче кыз, иңрәп-ыңгырашып, күзләрен йомды. Аның сызлануыннан өй эчендәге нурлы һава куерып киткән кебек иде.

– Аһ!.. Аһ!.. М-м-м...

Мәүлет сикереп торып, ярдәм итәргә ашыкты. Тик имче кыз кул ишарәсе белән, аны шундук туктатты.

Юк, гади генә имче түгел бу. Дөнья сихере, җиһан илаһияте белән бәйле зат ничек гади булсын, ди?! Ходайга каршы баш күтәргән Иблис мәлгуныннән Җирне саклап калу өчен аяусыз көрәшкә күтәрелгән каһарман зат кебек күренде ул бу минутта.

Бераздан имче кыз тынычланды, йөзен ачып, күк төсендәге күз алмаларын дөньяга чыгарды...

– Бар, ашык. Яңа Ай тулганчы Иблисне табасың бар. Анда, күктә борчылалар.

Инде китәргә дип торып баскач, Мәүлет баядан бирле күңелен борчып торган сорауны бирде:

– Ничек була инде – яңа Ай тулганчы?

– Төнге күккә караганың бармы?

– Бар.

– Хәзер Ай ни рәвешле?

– Чып-чын Ай ул хәзер, урак кебек.

– Менә шул Ай тулып, түгәрәкләнгәнче вакытың бар...

– Күпме була инде ул?

– Ике атна, ундүрт көн.

– Шулай гынамы?

– Бу – азмыни?

– Белмим.

– Бу – бик күп. Бу вакыт эчендә яңа туган сабыйга аң иңә, кешенең каны алышына, кояшның җылысы, йолдызларның яктылыгы килеп җитә. Син дә үз теләгеңә ирешерсең.

## 5

Имче кыз янында булып кайтканнан соң, Мәүлет тагын мунчадагы тар бүлмәсенә кереп бикләнде. Тагын уйлар ихтыярына бирелде. Соңгы берничә көндә аның тормышына ургылып килеп кергән хикмәтле хәлләрне тагын бер мәртәбә күңеленнән кичереп, уй-фикерен җыеп, алдагы көннәренә ниятләр корасы бар иде.

Бу минуттагы яшәешендә аның күңелен һәм зиһенен бары тик бер уй, бер гамь генә биләп алган иде – Иблис уе, Иблис гаме!

Ярый. Иблис булсын да, ди. Күктән Җиргә куылсын да, ди. Аны табып фаш итү эше Мәүлеткә кушылсын да, ди. Тик кайда ул Иблис дигәннәре? Каян, ничек табарга аны? Ай тулганчы, имеш. Әйтүе генә җиңел. Ике атна эчендә таныш-белешне дә табу кыен әле.

Әй, йөрсен лә шунда коткысын таратып! Җир йөзендәге явызлык, вәхшилек, әхлаксызлык, ахыр чиктә, Иблистән генә тормый бит! Адәм балаларының үзләреннән тора! Кешенең үзәге нык икән, асылы саф икән, күңеле хөр икән, ул Иблискә генә баш бирми инде, бу кешелек тарафыннан меңмиллион мәртәбә расланган хакыйкать. Аннары. Изгелек янәшәсендә һәрвакыт явызлык торган. Бу кешелек яшәешенең, юк, алай гына түгел, бөтен табигать дөньясының иң мөһим шарты. Изгелек белән явызлык бер-берсеннән башка яши дә алмыйлардыр инде. Әнә, изге Коръәндә дә иман китергәндә: «Тәкъдирнең хәере һәм яманы Аллаһы Тәгаләдән», – дип әйтергә куша бит. Хәере – игелек-изгелек булса, яманы – кешелеккә килеп ирешкән илаһи сынау була инде... «Һәр шайтанга – бер фәрештә» дигән аятьне кая куясың?

Ә монда Иблис кайгысы.

Ә бит чынлыкта Иблис булмаса, бәндә аны үзе эзләп таба, таба алмаса, үзе Иблискә әверелә. Бу инсаният дөньясында шулай ук мең мәртәбә расланган.

Юктыр, кеше Иблискә әверелә алмыйдыр ул. Иблис – фәрештә. Ләгънәтләнеп сөрелгән булса да, фәрештә. Ә кеше бервакытта да фәрештә була алмаячак. Ул бары тик бу шайтани затның коткысына гына биреләдер. Коткы? Кот-кы... Ничек төгәл әйтелгән! «Кот» сүзе мәҗүсилек чорында «рух»ны, «җан»ны, «калеб»не, ягъни күңелне белдергән ләбаса! «Кот-кы» – шушы рухны, җанны, калебне эчтән кимерүче, аны җимерүче, бозучы тәгълимати бер шәйдер. Иблиснең шул коткысына эләксәң, котылам димә инде. Котылу? Монда да шул сүз! «Кот-ылу» – димәк, «кот»ны, «җан»ны, «рух»ны, «калеб»не саклап калу, кабат үз асылыңа, рухыңа ия булу, аны явыз шаукымнан коткару. Нәкъ шулай: «Кот-кару»! Шул изге гамәлне кылып, Аллаһының «котлау»ына ирешү. Әйе-әйе, бу очракта да «кот» – төп чара, дәлил һәм хакыйкый ишарә!

Мәүлет тагын бер хакыйкатьне белә. Белмәсә дә, тоя, сизенә.

Аллаһы Тәгаләнең сынавы зур булган кебек аның игелеге дә киң. Адәм баласы үз гомерен, шушы сынауны үтеп, игелеккә, хәтта изгелеккә ирешүгә багышлый. Соңгысына ул Ходайның рәхмәте һәм мәрхәмәте белән, иман һәм илаһият юлында ирешә. Күрәсең, Мәүлеткә дә шушы юл билгеләнгәндер. Игелек – үзең өчен булса, изгелек – бөтен кешелек өчен – моны гына аңлый Мәүлет. Шуңа күрә дә бу бурычны бик борчылып, хәтта бераз шикләнеп кабул итә.

Шулай да, ул кире чигенмәячәк. Шулай икән – шулай! Кешелекнең якты киләчәгенә илтә торган юл – иң саваплы юл түгелмени?! Иблис тикле Иблис белән алышка аны сайлап чыгарганнар икән инде – Мәүлет сынатмаска тырышачак. «Фашланган Иблис көчен югалта», ди изге Коръән. Фашланган Иблис кабат Ходай катына кайтарылуга, Җир дөньясы тагын якты, имин, саф тормышта яши башлаячак, имеш. Бу юлда корбан да булырга мөмкин, каһарманлыкка да ирешеп була. Менә нинди язмыш көтә аны.

Мәүлетнең елыйсы килде. Һәм ул, туарылып, күңелен иркенгә җибәреп, үксеп елады. Аннан көләсе килде. Күз яшьләре аша кычкырып көлде. Ә өченче тойгы исә аны куркытты, сикереп торырга мәҗбүр итте: тукта, Иблис хакындагы уйлары белән ул акрын гына акылыннан язып килә ләбаса!

Дәррәү торып, йөгереп диярлек эшкә чыгып китте. Көне буе мунча мәшәкатьләре белән мәшгуль булды. Ләкин Иблис тойгысыннан барыбер котыла алмады. Бу тойгы аның бөтен тынычлыгын алган иде. Әмма бу тойгы аңа тормыш гамен, яшәеш кануннарын югалтмыйча яшәргә ярдәм дә итә иде.

Фикер мантыйгы бик гади булып чыкты. Аңа Мәүлет үзе дә аптырады: Иблис мәлгунь иң элек адәми затларны юлдан яздыру өчен, аларның күңелен, зиһенен саташтыру өчен җибәрелә ләбаса! Менә шундый сынау. Кайсы гына изге китапны укысаң да, кайсы гына риваятьне тыңласаң да, шул хакта сүз бара: Иблис һаман адәмнәрне аздыра, алдый, куркыта, зиһенен ала, боза, саташтыра, буташтыра, ялгыштыра, юлдан яздыра. Димәк, ялганчы мошенниклар, әхлаксыз затлар, бозык бәндәләр, азгын ирләр, хатыннар, гайбәтчеләр, кара сихерчеләр яныннан эзләргә кирәк ул тәмуг кисәвен!

Мәүлет үзе эшләп йөрде, үзе алдагы көннәргә ниятләрен кылды: иң элек кая барырга, кемнәр белән очрашырга. Бистәдә, аның ике як очыннан ук тоташып китә торган авыл белән калада Иблис яратырдай урыннар күп булып чыкты. Дөресен генә әйткәндә, кая гына барма – шунда Иблис булырга мөмкин икән. Ләкин Мәүлет шуны да белә: Иблис – шайтан түгел. Ул – шайтаннарның фәрештәсе. Димәк, ул, урам сукбае кебек, түбәнчелеккә төшеп йөрмәячәк, бәлки, иң элек затлы урыннарда күренәчәк, коткысын да асыл затлар күңеленә салырга тырышачак...

Юк, Мәүлет үзен барыбер инандырып бетерә алмады. Тегеннән укыган, моннан ишеткән белән генә әллә ни кырып булмаячагын аңлап-төшенеп җиткәнче, әнә күпме вакыт узып киткән инде! Ә бит төп китап, төп чыганак бар. Коръән үзе бар! Анда Иблис ләгыйньнең ниндилегенә, кайдалыгына ишарә бар да бар инде!

Әллә авыр уйлардан, әллә эштән арып-талчыгып, урамга чыкканда, аны Шәмси карт көтеп-сагалап тора иде инде.

– Ходайга тапшырдыңмы?

– Тапшырдым, Шәмси бабай.

– Саклану чараларын күрдеңме соң?

– Нинди чараларны?

– Иблис юлына төшәрдән элек, рухыңны, йөрәгеңне аңа каршы торырлык итеп ныгытып куярга кирәк, балакай.

– Ничек була ул?

– Иң элек кирәкле догаларга ия бул. Изге аятьләрне күңелеңдә тотарга, шул аятьләр буенча яшәргә өйрән.

– Ягъни мәсәлән?

– Шайтани затлардан саклану догалары бар. Сиңа шуларны белергә кирәк. Иң элек «Әгузү билләһи»не әйтә бел.

– Тел очында гына тора, Шәмси бабай. Искә генә төшерә алмыйм... Ничек әле ул?

– «Әгузү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим» дигән дога ул. Шайтан коткысыннан Аллаһы Тәгаләгә сыенам, димәктән әйтелә. Бу доганы «Бисмилла» белән раслап куялар. «Бисмиллаһир-рахманир-рахим» диюгә, Аллаһы Тәгалә исеме белән башлап, тәүбә итәсең, Ходайдан үткәндәге хата-кимчелекләреңөчен кичерүен сорыйсың. Аннары гына гамәлгә керешәсең, эш башлыйсың, кылган ниятеңә тотынасың...

– Шәмси бабай, миңа Коръән белән ныклап танышырга кирәк. Шунсыз миңа кыен булачак. Синдә аның татарча аңлатмасы бар бугай, шуны биреп тор әле.

– Син, Коръәнгә керешеп, зур җаваплылык аласың, Мәүлет балам. Ниятләгәнсең икән инде, хуплыйм, мин сиңа әле күптән түгел генә басылып чыккан «Ногмани тәфсирен» әзерләп куярмын. Бүген кич кереп алырсың. Хәдисләр белән дә танышырга кирәк булыр. Алар Коръән аятьләренә ачкыч кебек бит...

Мәүлет Шәмси карт яныннан күтәренке күңел белән кузгалып китте. Кая барасын төгәл генә белмәсә дә, адымын кызулата барды, бер чатта да тукталып тормыйча, ярты бистәне урап, кабат үзенең мунчасына кайтты, тәһарәтләнеп, намазына кереште. Ул әле намаз догаларында ялгыша, хәрәкәтләрен дә җиренә җиткезеп башкарып бетерә алмый. Ләкин аның күңеле инде тыныч, йөрәге үз урынында, җаны җылыда. Хәзергә иң мөһиме шул. Калганы – иртәгә.

**6**

Китапханәдән алып кайткан яисә Шәмси карт биргән кайсы гына китапны ачып караса да, Мәүлет бер фикергә тап булды: Иблис үз коткысын адәми затларның калебләрен ярып сала имеш... Кайчандыр Иблис белән Аллаһ арасында бәргәләнгән мәшһүр Шәйхзадә Бабичтагы кебек:

Керде һәр инсанга Иблиснең төге,
Әмма изге булмады эшнең төбе:
Эчкә кергәч, төк ярылды урталай,
Килде чыкты уртадан шайтан малай...
Һәр адәмнең кальбенә урнашты ул,
Бар иман, вөҗданны аска басты ул.
Тик нәфес берлә икәүсе дус болар,
«Нәфес шайтан» дип аңа ат куштылар!..
Нәфес шайтан кергәч, инсан дөньясы
Азды-тузды, чыкты чиктән һәммәсе.
Инде җирдә изге бәндә калмаган,
Ямь вә тәмнән нам-нәшан[1] да калмаган!..
Бер заман, иңмәс борын Иблис ләгыйнь,
Торды инсан ал да гөл дә, син дә мин...

[1] Нам-нәшан – исеме дә, әсәре дә.

Ул заманны җирдә пакь фитрәт[2] иде,
Һәр адәмдә кардан ак күкрәк иде.
Ул заман оҗмах йөрәк – инде дозах[3]!..
Әй матур чак! Әлфирак[4]! Калдың озак!..

Туктале! Җир йөзендәге бөтен явызлыкка, азгынлыкка да Иблис гаеплеме соң? Юк, әлбәттә! Чынлыкта Иблис кешене аздырмый, аның яшәү көчен генә ала, кеше, рухы белән көчсез калган адәми зат, үзе аза. Әйе, көчсез кеше генә Иблискә бирешә. Ә кем көчсез? Кем ихтыярсыз, максатсыз... Кем ихтыярсыз? Кемнең кальбе зәгыйфь? Зиһенен, хисен җыя алмаган кеше. Ә кем зиһенен, хисен җыя алмый? Исерек! Эчкече! Иң элек шулар яныннан эзләргә кирәк Иблис мәлгуньне! Шул мәхлуклар күңеленә исерткеч салып йөридер әле ул ләгыйнь! Шулай булмыйча! Җир йөзенә Иблис тарафыннан аракы индерү тарихын, әнә, мәшһүр Бабич та язып калдырган:

...Сөйләде озак, бирде дәрт, кыйлды вәгазь,
Барлыгын язсаң әгәр, җитмәс кәгазь.
Сөйләде инсан котырту юлларын,
Нинди коткы, вәсвәсә һәм шом барын;
Сөйләде алда кылачак эшләрен,
Алмый калмыйм, ди, Ходадан үчләрем.
Сөйләде хурлап мөселман җеннәрен,
Тар-маритик, ди, аларның илләрен...
Соңра көттереп халыкны, җирсәтеп,
Ул диде, кулда шәрабын күрсәтеп:
«Иң элек җәннәттәге ширбәт иде,
Һушны алмый һәм исертми – пакь иде.
Мин төкердем дә моны «иблисләдем» –
Пакь шәрабны саф исерткеч эшләдем!..
Мә, туганнар, сезгә ташлыйм, алыгыз!
Шул төбәктән бер тирән күл табыгыз!..
Ташлагыз илтеп шәрабны шунда сез,
Күл хәмергә әйләнер һич шөбһәсез!..
Безгә мәңге ул исерткеч күл булыр,
Аннары соң безгә ал да гөл булыр,
Һәм адәмнәргә таратырбыз аны,
Аздырырбыз, туздырырбыз дөньяны!..»
Дип, озын нотыгын тәмамлап бетте дә,
Һәм халыкка ширбәтен ыргытты да,
Керде китте балконыннан эчкәре,
«Шу» килеп калды шаятин тышкары...
Иблис ыргыткан шәрабны тоттылар,
Күлгә ташларга алып та киттеләр.
Күлгә ширбәтне җибәргәч ыргытып,
Башлады кайнарга күл гөр-гөр итеп...
Берничә көннәр быгырдап кайнагач,
Язмышына аһ-ваһ фөрьят әйләгәч,
Тынды күл рәнҗеп шаятин явызына,
Әверелеп калды аракы хәвезенә...
Күлне буйлап бихисап өйләр ясап,
Әллә нинди шайтани сыйлар ясап,
Һәм «хәмер күл»дән чиләкләп, мичкәләп,

---

[2] Фитрәт – пәйгамбәр килмичә торган заман.
[3] Дозах – тәмуг.
[4] Әлфирак – аерылышу.

Бер дә тынмас, туктамастан эчкәләп,
Ду галәмәт сиптереп көн вә кичен,
Тантана берлән хәсис Иблис өчен,
Атналар, айлар буе туй иттеләр,
Гел әдәпсез, язмаганча типтеләр...

Димәк, Иблис Җирдәге явызлыгын инсан дөньясына аракы зәхмәте кертүдән башлаган. Иң элек кешенең исен, һушын һәм зиһенен алган. «Бөтен әшәкелекнең анасы – хәмер», – дигән бит пәйгамбәребез дә. Икенче бер урында ул болай ди: «Аллаһы Сүбеханә вә Тәгалә аракыга ләгънәт кылды, эчүчегә, эчертүчегә һәм аны ясатучыга да ләгънәт кылды.»

Иблис хакында бит бу хәдис! Аның шайтани асылы хакында!

Мәүлет ныклы бер карарга килде: ул Иблисне эчкечеләр арасыннан эзләргә булды. Бәлки исерекләр арасында булмас та ул. Ләкин ул аларны туендырып тора бит. Явыз бәндәләр ике төркемгә бүленә – явызлыкны тудыручылар һәм явызлыкка иярүчеләр. Исерекләр – аңа иярүчеләр генә. Ә менә Иблис токымы – явызлыкның үзен тудыручы нәсел. Ничек кенә булмасын, алар барыбер бергә, алар бер-берсеннән башка яши алмый...

Мәүлет якындагы кибетләр рәте буйлап китте. Кая карама – аракы, көмешкә, шәраб... Хәтта кием-салым, балалар уенчыгы сата торган палаткаларда да аракы сатыла... Әлләни кыйммәт тә түгелдер... Бу кадәр халык чират тормас иде. Араларында төрлесе бар. Бик бетәшкәннәре дә, затлы гына киенгәннәре дә. Андыйлар берән-сәрән генә. Әнә шундыйлардан берәү – затлы күзлек киеп алган, ачык йөзле мөлаем карашлы ир заты – бер тартма тутырып, аракы сатып алды да сатучыга адресын язып бирде. «Шушы адрес буенча илтерсез, юл хакын шунда түләрмен», – диде. Шунда янәшә генә басып торган бер исерек ир тел шартлатып куйды:

– Көн саен шулай: сатып ала да бөтен кеше күз алдында чүп арбасына салып җибәрә. Ну, дошман! Ни үзе эчми, ни башкаларга бирми, сволочь!

Шунда әлеге сәер ир заты Мәүлеткә таныш кебек тоелды: кайдадыр күргәне бар кебек ул аны. Тик кайда? Кайда?..

Бераздан аның игътибарын аракы кибетенең башка әһелләре җәлеп итте. Әнә бер карт майланып, каешланып беткән чалбар кесәсеннән соңгы тиеннәрен чүпләп алды да, калтыранган кулларын алга сузып, чиратсыз-нисез генә эчкә кереп китте. Халык, ике якка аерылып, аңа юл бирде. Мәүлеткә бу кызык булып тоелды. Кем соң бу мәхлук бәндә? Нинди генә сихри гипнозга, тылсымлы шаукымга ия икән ул? Аны күрүгә кешеләргә әллә нәрсә була – балаларча елмаеп, карт алдында баш иеп калалар. Бер шешә аракы өчен бер-берсен ботарлап ташларга әзер исерекләрне үрә катырып куйды бит!..

Түзеп-түзеп карады да Мәүлет бу мәзәк хәлгә авыз ерып карап торган бер кызмача ир-аттан сорарга батырчылык итте:

– Кем соң ул? Аның янында нигә алай кыланалар?

Теге бәндә Мәүлеткә йотардай булып, акаеп карады. Бу караштa «Син нәрсә? Айдан төштеңме әллә?» дигән шөбһәле сорау бар иде. Мәүлет исә сер бирмәскә тырышты, кабатлап, бу юлы тавышын күтәребрәк сорады:

– Кем ул?

– Кем булсын – безнең Мәйрух абзый ул. Хөрмәтле кеше. Бер ул гына

кибет эченә чиратсыз керә ала, аракыны да чиратсыз алырга хокуклы. Безнең «акыл иясе». Ул безгә өлкән абый кебек, хәтта әти кебек.

«Иблис» дими, шайтан сыңары! Һаман яратып сөйли. Шундый исерек затларны да яратып булыр икән.

Әлеге ир-ат сөйләгәннәрдән Мәүлет шуны аңлап алды: эчкече халык арасында «авторитет» кебегрәк кеше икән ул. Монда да бөтен кеше үз гаилә-ыруларына бүленгән булып чыкты. Мәйрух дигән бу кеше иң зур «шайтани нәсел»ләрнең берсенә күз-колак булып тора икән. Мәүлеткә шул җитә калды – ишектән теге бәндә күренүгә, аның артыннан иярде. Мәйрух урам ташына аяк кына басты, аракы кибете каршында торган халык, бер-берсен этә-төртә, тагын эчкә омтылды.

Кайсы күзләре белән күреп өлгергәндер, бераз баргач, теге бәндә, кинәт кенә артына борылды да кай арада ачылып өлгергән аракы шешәсен Мәүлеткә сузды:

– Мә, авыз ит.

– Кирәкми, мин аракы өчен түгел. Минем сезнең белән сөйләшәсем килә. Аңлагыз, зинһар.

– Сөйләш соң. Сөйләшкән өчен акча сорамыйлар бездә. Ә менә аракы салып бирәләр. Бу – факт.

– Аракысы да, акчасы да кирәк түгел, кумагыз гына.

– Ай-һай, кызык кеше булып чыктың әле син. Әйдә, арттан калма. Хәзер килеп җитәбез.

Чынлап та, ике-өч йорт узуга алар бер тар гына ишегалдында пәйда булдылар, аннары, аулак тыкрык аша узып, бер ташландык йортка барып керделәр. Анда халык җыелып өлгергән иде инде. Барысы да Мәйрухны көткәннәр, аны күрүгә, аяк өсте торып бастылар, табын хәстәрли башладылар. «Өстәл» дигәннәре иске генә бер шкаф булып чыкты, аның йөз ягына ябыштырылган көзгесе төрле якка таҗларын сузган чәчәк кебек ватылган... Шул көзге өстендә азык төлек калдыклары – катып беткән ипи кисәкләре, сыр, колбаса телемнәре, тешләп ташланган алмалар чәчелеп ята...

– Таныш булыгыз, карагыз аны, тел-теш тидерәсе булмагыз, барыбызга да урын җитә. Мин Мәйрух булам, син кем?

Мәүлеткә төбәлеп карап торган карашлар бу юлы якын, үз, хәтта мөлаем булып күренде.

– Мәүлет.

Халык җанланып алды. Кемдер һәркем ишетелерлек итеп әйтеп куйды:

– Кара син аны, үзе ияртеп кайткан, үзе исемен дә белми.

– Цыц! Җиттеме сезгә?! Тагын бер сүз ишетсәм – иманыгызны укытам! Сез мине беләсез.

– Беләбез, беләбез. Кулың каты синең...

Мәүлет һәр кеше белән күрешеп чыкты. Аракы сөременә каткан бу бәндәви затлар гайрәтне җибәрерлек дәрәҗәдә керле, исле һәм ят иде аңа. Намаз иясе була торып, керер идемени ул аракы сөреме сеңгән бу исерек дөньяга? Иблис кирәк булмаса, бу кадәр түбәнчелеккә төшәр идеме?

Өстәлдә яткан соңгы алманы үрелеп алды да бер читтә торган иске диванга барып утырды ул. Башын артка ташлап, бүлмә эчендәге тормышны күзәтә

башлады. Аракы шаукымына бирелгән исерек җаннар баштарак аның бу табигатенә сәерсенеп, күз читләре белән карап-карап алсалар да, бераздан аның барлыгын тәмам оныттылар, ахры. Бер сәрхуш бәндә генә, берничә мәртәбә килеп, стакан төбендә чайпалган аракысын тәкъдим итеп булашты...

– Ял итсен, арыган ул, – дип, кайсыдыр җилтерәтеп алып киткәч кенә, Мәүлетнең җанына да, тәненә дә тынычлык инде.

Бу тормыш көтелмәгәнчә кызык булып чыкты. Иң элек шул күзгә бәрелде: бик үк тәртипсез түгел икән мондагы вазгыять. Кереп, чыгып, туктаусыз алмашынып торган эчкечеләр «гаиләсе» бик кызык кануннар белән яши булып чыкты. Бөтен кеше Мәйрух ихтыярына буйсына. Монысы кире кагып булмый торган факт. Ләкин калганнар барысы да бер чамада, бер дәрәҗәдә аралаша. Ник берәрсе ялгыш кына тәкәбберлек күрсәтсен яисә кемнедер кимсетсен?! Әлбәттә инде, бер аек кеше дә юк, тик дөм исерек тә юк. Аракы сөременнән тилереп, исен-акылын җуйган адәмнәрне хөрмәт итмиләр, ахры, монда. Шундый бер-ике бәндәне күрше бүлмәдәге караватка илтеп салдылар, кемнедер култыклап өенә алып кереп киттеләр.

Иң кызыгы бу да түгел икән әле. Менә бервакыт Мәйрух үз иярченнәрен төрле мәсьәләләр буенча «кабул итә» башлады. Иң элек ул бер яшь кенә ирне чакырып китерде.

– Син нишлисең, Сәлмән? Ник кеше көлдерәсең? Нигә бу кадәр түбәнлеккә төшәсең?

– Мин нишләгән соң?

– Нишләгән-нишләгән, имеш... Кибет алдында кул сузып, акча теләнеп тордыңмы?

– Тордым.

– Шуны колагыңа киртләп куй: моннан соң хәер сорашып йөрисе булма! Акчаң юк икән – миннән сора, без нигә соң монда, бер-беребезгә ярдәм дә итә алмагач. Менә хәзергә сиңа яшәп торырлык акча, иртәгәдән урам чатындагы кибеткә эшкә чык, бер вагон карбыз кайтуы көтелә, бераз тир түгеп алсаң да ярар. Хуҗасы белән үзем сөйләшермен. Бар, хәзер кайтып йокла, ял ит, буыннарыңны ныгыт.

Аннары Мәйрух каршында Мират дигән бәндә пәйда булды. Анысын да мактарга чакырмаган икән.

– Ә син нигә хатыныңа кул күтәрәсең? Бүген дә күз төбе кара янып чыккан иде. Синең эшме? Бу гадәтеңне ташламасаң, кара аны, мәңге хатын-кызга якын бармаслык ясыйм. Хәзергә җәза шул – өч көн авызыңа бер тамчы да алмыйсың. Аннан күз күрер...

– Ну, Мәйрух! Өч көн ничек түзим мин? Булмый, хет бер көн бир, ә? Үтенеп сорыйм!

– Өч көн!

– Ант итәм, моннан соң мин аны сөеп кенә торырмын.

– Өч көн! И баста!

Шактый ялынды-ялварды әле теге бәндә, аннары язмышы белән килешеп, башын иеп чыгып китте.

Тагын берничә кеше кереп чыкты. Берсенә эш кирәк, икенчесенә – торыр урын. Барысын да булдыра алган кадәр җайлады «гаилә башлыгы».

Ниһаять, бүлмәдә икесе генә торып калдылар. Мәйрух, ярымҗимерек

шкаф артыннан тузанга баткан шешә тартып чыгарды да өстәл өстенә куйды, аннары Мәүлеткә өстәл артыннан урын күрсәтте. Ике стаканга тутырып, аракы салды. Бер чите сындырып алынган икмәктән ике телем кисеп куйды.

– Бик сәер кеше син, кем... Мәүлет. Үзеңә нәрсә кирәген үзең дә белмисең бугай... Син бит аракы эчәргә кермәдең, шулаймы? Хәзер инде дөресен әйт: сиңа бездән нәрсә кирәк?

Мәүлеткә бу сорау ошый иде.

– Иблис кирәк. Миңа аны табарга, фаш итәргә кирәк. Монда күренмәдеме? Үзеңә авырлык алма – синең Иблис түгел икәнеңне беләм.

– Ә-ә, шулаймы? Бер-бер хикмәт бар дип уйлаган идем аны. Аңладым. Тик... Иблис хакында кычкырып сөйләшергә ярамый бит.

– Миңа ярый. Мин үзем аны эзләп чыктым, белеп, ишетеп торсын!

Мәүлет үзе сөйләнде, үзе тирә-ягына каранды, гүя Иблис шушы ташландык йортның бер аулак почмагында яши. Менә ул килеп чыгар да Мәүлеткә үзенең агуын чәчә башлар кебек... Бу шик-шөбһәләрдән котылу өчен ул үз-үзен үгетләргә кереште:

– Юк, Иблисне исерекләр арасыннан эзләргә кирәкми. Монда юк ул, була да алмый. Булса да чыгып кача... Исерек кеше – кешелеклелеген югалткан дигән сүз түгел әле. Исерек бәндә – бик үк иманлы да, инсафлы да түгелдер... Кайчан дога кылганын да оныткандыр инде ул... Ләкин ул иң кирәген саклап калган: җанын, йөрәген сатмаган, кальбенә явызлык орлыгы кертмәгән. Бераз ихтыяр көчен, йөз һәм күңел матурлыгын, хыялын, өметен югалткан, ә яшәү дәртен югалтмаган. Ул исән, ул ниндидер хәтәр авыруга гына юлыккан. Менә бит нидә хикмәт!

– Кешене тормыш арбасыннын төшереп калдыру гына җиңел ул. – Мәйрух стаканын күтәреп эчеп куйды да чеметеп икмәк капты. – Ә син беләсеңме бу Хода бәндәләрен? Кемнәр алар? Нишләп бу хәлгә төшкәннәр? Нинди бәлагә тарганнар? Белмисең... Күпләр белми, белергә теләми дә... Ә син килгәнсең, рәхмәт. Уйларың да дөрес, күңелең дә дөрес синең... Иблис дисәң инде... Телисеңме – әйдә мин Иблис булам! Мине фашла! Мин дә Иблистән ким түгел...

– Баштарак мин шулай уйлаган идем дә... Исерекләр синең тирәдә бөтерелеп йөри бит. Һәр әйткән сүзеңне әмер кебек кабул итәләр, һәр күз карашыңнан сискәнәләр...

– Алай ук түгел түгелен. Шулай да... тыңлыйлар, хөрмәт итәләр. Мин дә аларны ихтирам итәм, шулай да, үзләренә башлык итеп, хөкем чыгаручы итеп куйганнар икән инде, мин аларның ышанычын акларга тиеш. Кайчагында мин аларга катырак торам икән, бу шулай тиеш булганга гына. Безнең бит монда үз тәртипләребез бар, кем шул тәртип кысаларыннан чыга, ул үзенә күрә җәзага тартыла. Без монда бигрәк тә хатын-кызны, картларны, балаларны рәнҗеткән кешеләрне, карак-бурларны, сүз йөртүчеләрне, гайбәтчеләрне, коткы таратучыларны яратмыйбыз, аларны рәткә кертергә тырышабыз, рәткә керә алмаганнарны сөреп җибәрәбез. Үзең чамалыйсың инде, алары Иблис өчен дә кызык түгел, минемчә. Андый түбән һәм көчсез җаннарга хәтта Иблис тә, башка шайтан затлары да иярмәшми.

– Аракы акылны ала, зиһенне буташтыра – бу күптән билгеле. Дин дә шулай ди. Аракы кешене эчтән җимерә, аның иманын зәгыйфьләндерә. Ә бу инде Иблис галәмәте, аның шаукымы, шулай түгелмени?

– Шулай дип тә, шулай түгел дип тә әйтмим. Бары тик мисал гына китерәм. Бая сине аракы эчәргә кыстап йөргән кешенең кем икәнен беләсеңме? Белмисең. Белмәвең әйбәтрәктер дә. Ул – техник фәннәр докторы, профессор. Хәзерге вакытта авиация институтында укыта. Атнаның беренче биш көнендә укыта, калган ике көнендә безнең белән аракы эчә. Шулай кирәк аңа, югыйсә ул акылыннан язачак. Аның башындагы идеяләр гади кеше өчен артык катлаулы шул. Шимбә көнне ачы таң белән башын тотып килеп керә ул. Шундук салып бирәбез. Ике көн буе сәрхуш булып йөри-йөри дә дүшәмбедә, ак күлмәген, кара костюмын киеп, затлы галстугын тагып, укытырга чыгып китә.

– Теге, эш сорап кергән бәндә кем? Анысы бер дә юньлегә охшамаган.

– Юньлегә охшамаган дисең инде. Ә менә әйт әле: юньсезгә охшаганмы ул?

– Юк! Юньсез дип тә әйтмәс идем.

– Менә-менә. Нишләп соң без кеше турында уйлаганда иң элек: «Бу юньсез түгелме?» – дип уйлыйбыз. Нигә: «Бу юньле бәндә түгелме?» – дип уйламыйбыз? Безнең сорау ук дөрес түгел. Без үз-үзебезгә дөрес сорау бирмибез. Сорау дөрес булмагач, җавабы да дөрес булмый инде. Менә шундый фәлсәфә, туганкай. Ә теге бәндәгә килгәндә, ул ике ай элек әшәке авырудан интеккән хатынын күмде, балалары бөтенләй булмаган. Ул шулай болын кадәр өендә ялгызы утыра-утыра да шешәсен күтәреп, тагын килеп җитә. Туйганчы эчеп, елап, күңелен бушатып китә. Шулай үзенчә тынычланырга, юанырга, гомерен озайтырга тырыша. Без аңа кешеләрчә аралашыр өчен шартлар гына тудырабыз. Эч дип тә, эчмә дип тә әйтмибез. Ул эчү-эчмәүне үзе хәл итәргә тиеш. Әйбәт якка хәл итәр дип уйлыйм. Хәзер ул күбрәк эчү өчен түгел, аралашу, сөйләшү өчен килә. Яңа эш таптык үзенә, янында бер матур гына хатын да пәйда булды. Икенче тапкыр гомер яши башлау бик кыен шул. Безгә нәкъ шундыйлар җыела да. Аларны да Иблис коткысы белән бәйләп куябызмы инде?

Мәүлет дәшмәде. Аның бу бәндәнең сүзләрен хуплыйсы да, кире кагасы да килмәде. Ләкин бер нәрсәгә аның акылы ирешкән иде инде: монда Иблис юк! Монда аның исе дә, төсе дә юк. Рухы юк та юк инде.

## 7

Мәүлет тиз-тиз генә җыенды да урамга чыгып китте. Аның бик тә катык эчәсе килгән иде. Бу аракы сөременнән, аракы гаменнән катык эчеп кенә котылып булыр кебек иде. Янәшәдә генә сөт кибете күзгә чалынды. Ләкин Мәүлет аңа кермәде. Аның организмы да, күңеле дә чын катык, ачы катык сорый иде. Урам башында халыктан җыелып оешкан сәүдә рәтләрен күргәч, сөенә-сөенә шунда ашыкты. Бу базарда булганы юк икән әле аның. Берничә сәүдә рәтенә тезелеп сату итүче базар әһеле чуарлардан чуар иде. Анда бәрәңгесен, сөтен, итен бертуктаусыз үтереп мактап торган үзебезнең татар абзый-апалары да, суганнары белән данлыклы чуваш кардәшләр дә, көнбагыш, гөмбә тутырылган кәрзиннәргә стакан яисә кечкенә чиләк утыртып куйган мари-удмурт халкы да, шулай ук өрекләре, кара җимешләре белән ыгы-зыгы килүче үзбәк-кыргызлар да, алларына помидор таулары өеп куйган азәрбайҗаннар да күзгә керердәй, йөрәккә төшәрдәй булып торалар.

Мәүлет бөтен йөз-битен йон баскан татар кешесе сату иткән, чират әллә ни

озын булмаган өстәлне сайлап, барып басты да әлеге гайре табигый кыяфәтле кешене өйрәнә башлады. Бу кешенең хатыны сөт-катык тирәсендә мәш килсә, ул үзе ит ризыклары сату белән мәшгуль. Ләкин алар үзара сөйләшмиләр диярлек. Ым-ишарә белән генә аралашалар. Хатыны бу ямьсез бәндәдән кыенсынган кебек. Үзе чибәр генә күренә! Бу җен-шайтан кыяфәтле иргә ничек кенә кияүгә чыгарга җөрьәт иткәндер?! Күр инде бу гыйбрәтне! Йөзендәге җөйләрнең, яра эзләренең исәбе-саны юк. Үзе бик тә елгыр күренә. Ит үлчи башласа, кулы кулга йокмый. Кай арада бүлеп ала, кай арада бизмәнгә салып өлгерә. Итле калҗа янына сөяген дә төртеп куярга онытмый. Иң кызыгы бу да түгел әле, иң кызыгы: үлчәү белән эшләүдәге өлгерлеге, елгырлыгы. Бизмән тәлинкәсенә ит кисәген куярга өлгерми, алып төрә дә башлый. Менә шунда чамалап алды да инде Мәүлет: алдый бит бу! Дөрес үлчәми!

Чират җитәргә ике-өч кеше бар иде әле. Якыная төшкәчрәк бу алдакчы-хәйләкәр сатучының кулыннан тотмакчы булды Мәүлет. Фаш итмәкче булды. Шунда, акрын гына кузгалып, аның күңелендә бер саллы уй тернәкләнә башлады. Ә бит Иблис дигәннәре дә шушында гына булырга мөмкин. Ялганның иң соңгы дәрәҗәсенә җиткән нәмәстәкәй шул түгелмени?! Кеше алдап, астыртын эш йөртеп, гөнаһка баткан ул гыйфрит шушы базар әһелләре арасында булмас дип, кем әйтә ала?! Әнә бит, әнә, соңгы елларын яшәп ятучы бер әбекәйгә дигән ит кисәге һич кенә дә дөрес үлчәнмәде, маймыл кыяфәтле сатучы хәтта бизмәндәге авырлыкны күрсәткән сырларга карап та тормады. Ә менә бу кешене – затлы костюм-чалбар кигән, ак күлмәк өстенә галстук бәйләгән, колагына затлы күзлек элгән хәлле генә ир заты белән озак булашты. Бер салды ит кисәген бизмән тәликәсенә, бер кире алды, тагын салды, тагын алды. Ахыр чиктә ит үлчәнде, күз иярмәс тизлектә бизмәннән юкка да чыкты, затлы гына пакет эченә кереп тә посты. Барыбер Мәүлетнең күңелендә олы шик калды, чөнки үлчәү ышандырып җитмәде, яшеренебрәк эшләнде...

Мәүлет ике кило ит үлчәргә кушты. Ит сатучы абзый үз эшен тиз тотты. Төгәллеге хакында әлегә әйтергә иртәрәк, әмма күз иярмәс хәрәкәтләр белән үлчәнгән ит җәһәт кенә Мәүлет кулындагы целлофан капчыкка күчеп өлгерде. Менә шунда фаш итү сәгате сукты да инде. Мәүлет үз кулындагы пакетның авызын ачып куйды да, андагы ит кисәгенә ишарәләп, башын өстәл өстенәрәк сузып:

– Зинһар, тагын бер тапкыр үлчәгез әле, күбрәк салып ташламадыгызмы? – диде.

– Юк-юк, барысы да тәртиптә. Төгәл ике кило үлчәдем.

– Барыбер үлчәгез әле. Настаиваю.

– Ярый-ярый, үлчим, борчылмагыз, менә күрәсезме – нәкъ ике кило. Бер грамм артык та, ким дә түгел.

Мәүлет ялт итеп бизмәнгә үрелеп карады. Ул, чыннан да, төп-төгәл ике килограмм авырлык күрсәтә иде.

– Гафу итегез, миңа тоелган гына. Кичерегез. Зинһар.

Шулвакыт теге адәм затына әллә нәрсә булды. Ул прилавканың бу ягына чыкты да, беләгеннән тотып, Мәүлетне берничә адым читкә алып китте. Ул бу мәлдә гаепле эш эшләп, бераз каушаган, әмма гаебен таныргга батырлыгы җиткән сабый баланы хәтерләтә иде.

– Мин бит, акыллы кеше, бу кварталларда яшәүчеләрне күптәннән беләм. Хәл-әхвәлләрен, кесә якларын, проблемаларын, хәтта гаилә тормышларын, язмышларын, дигәндәй. Беләм, акчаларын саный башлау белән эчке характерларын, яшәү рәвешләрен чамалый башлыйм. Ә сез беләсезме, кеше акча санаганда ачыла. Бер пенсиягә яшәүче ялгыз әбекәй белән дөнья җимерттереп яшәүче ир кеше акчаны төрлечә саныйлар. Дөрес тойгансыз: әнә теге әбигә итне күбрәк салдым, чөнки ул ялгыз яши, башка беркаян да керер акчасы юк. Бүген, әнә, соңгы тиеннәрен күтәреп килгән. 250 граммга артыграк куйдым. Ышанмыйсызмы? Әйдәгез үлчәп карыйбыз.

Сатучы ир сөт алучылар чиратында басып торучы таныш карчыкка табан бер адым атлап та куйды, әмма Мәүлет аның ике баштан җыйма белән тарттырып бәйләнгән, терсәкләрен тузудан саклап торган җиңсәсеннән тартып, чак туктатып калды.

– Ышанам-ышанам, тик... болай, һәр кешенең хәленә кереп сата башласаң, үзеңә табыш бөтенләй дә калмаячак бит. Аннары...

– Нәрсә «аннары»?

– Аннары... Коръәндә үк әйтелгән. «Дөрес үлчәгез» диелгән.

– Шулай диелгәнме? Нәкъ шулаймы? Коръәндә алыш-биреш хакында да аять бармы?

– Бар. Анда кешелек яшәеше өчен кирәк булган бар нәрсә хакында да аять бар. Ышанмыйсызмы?

– Ышанам, әлбәттә. Тик... төгәлрәк беләсе иде бу хакта. Вчү-теки, «берүк тигез итеп үлчәгез» дип үк әйтелмәгәндер бит безнең Изге Китабыбызда? Мәгънә чыгарырга була ул, ә менә төгәл язылышы, әйтелеше ничектер бит әле аның.

– Нәкъ шулай диелгән: ялгышмасам, «Алыш-биреш эшләрендә нәрсә дә булса үлчәгәндә, яхшылап эшләп бетерегез, кешегә зарар китерерлек ким үлчәүчеләрдән булмагыз», дип, һәркемгә дә аңлашылырлык итеп язылган. Тагын бер аятьтә: «Үлчәгәндә тигез, дөрес үлчәүләр белән үлчәгез», дип әйтелгән. Коръәндә дөрес үлчәмәү Җир йөзенә шайтан коткысы, явызлык таратуга тиңләнә хәтта. «Үлчәгәндә хыянәт итеп, кеше хакына кермәгез, вә шуның белән фәсәд, золым эшләрен кылмагыз, явызлыкны җир өстенә таратмагыз», диелә. Мин моны төгәл истә калдырдым. Чөнки Иблис мәлгуньне эзләп йөргәндә, шушы аятьләр кергән «Шагыйрьләр» сүрәсен ныклап өйрәнеп чыгарга туры килде. Минемчә, бу сүрәне халык белеп бетерми. Ә анда халык өчен кирәкле бөтен нәрсә дә бар. Тормыш өчен, диюем. Адәми затларны бозып йөрүче шайтаннар хакында да, имче-яучылар хакында да, ялганчылар, мошенниклар турында да, әлбәттә инде, шагыйрьләр хакында да. Исеме үк әйтеп тора: «Шагыйрьләр» сүрәсе.

– Алай икән. Каян алып укып була икән ул сүрәне, мин бит гарәпчә белмим.

– Коръәннең «Ногман тәфсирен»нән укып белә аласыз. Саф татарча язылган.

– Шулаймы? Бүген кайтышлый ук мәчеткә сугылам әле. Аларда бардыр. Ә мин, исәр, үземчә дөреслек урнаштырмакчы булам җир йөзендә. Димәк ки, изгелек эшлим дип, икенче кешегә хилафлык кылу барыбер язык булып

чыга? Укыйм әле бу хакта, ныклап укыйм... Мин бит нишлим? Әбигә өстәп биргән 250 грамм итне әнә теге затлы костюм киеп, галстук бәйләп, базарга килгән адәмнең акча янчыгыннан алып калдым. Аның нәкъ менә 250 грамм итен салып бетермәдем, бу этлегемне таныйм, танымый нишлим, дөресе шул. Иманым камил: ул кеше ресторанда гына тукланадыр, затлы ризык кына ашыйдыр. Шулайдыр. Итне дә мең мәртәбә тотып карап, сайлап ала. Ә ул аны этенә дип аладыр әле. Кызганып карап торса тора, каршындагы ятим карчыкка бер тәгам ризык яисә берәр сум акча бирү хакында уйлап та карамый. Булдыра алмаганнан түгел, гомумән, уйлый алмый ул бу турыда. Шуңа күрә үзең хәл ит инде, иптәш, кем диим?..

– Мәүлет.

– Ә мин Тимерҗан абзаң булам. Ничек хәл итсәң, шулай була. Әмма мин үземдә гаеп сизмим. Мине шайтан сыңары, Иблис токымы дип тиргәрсең дә, бәлки, әнә Иблис эзләп йөрисең икән бит, ләкин мин йөрәгем ни кушса, шуны эшлим. Дөнья гадел булсын дип тырышам. Үз урынымда тырышам.

Сөт-катык чиратына барып баскан Мәүлет янына тагын килеп җиткән Тимерҗан дигән итче. Менә ул як-ягына каранып алды да аяк очларына басып, йөнтәс йөзе белән Мәүлетнең колагына үрелде:

– Син, ни, Мәүлет энем... Ниме, вчү-теки таба алдыңмы теге хәшәрәтне?

– Кемне?

– Ну... Тегене гыйфритне инде. Шайтаннар башлыгын. Иблисне!

– Юк шул, сез булышмассызмы дип уйлаган идем.

– Мин ничек булышыйм инде?! Үземне шайтан дип белдерсәм генә инде. Хатын болай да мине, «Шайтаным», ди. Әнә ул нинди чибәр минем, ә мин?.. Ничек кенә түзеп яшидер? Ярата ул мине, беләм. Ә мин ансыз гүпчим тора алмыйм. Менә шундый любовь. – Бераз уйланыбрак торгач, бик мөһим сүзе калган кеше кебек кыланып, кабат Мәүлетнең колагына үрелде. – Мәүлет туганым, мин беләм аның кайда икәнлеген. Теге мәлгуньне, гыйфритне әйтәм. Мин әйткән җирдән хәзер барып табасың аны. Дөньядагы бар яманлык әнә шул эчкечелектән, аракы зәхмәтеннән. Шул тирәгә бар әле син, эзләгәнеңне бик тиз табарсың.

– Анда булдым инде мин, шул яктан кайтып килеш. Рәхмәт Тимерҗан абзый. Сау булыгыз!

Кем булды соң әле ул? Кайда күрде? Ә! Аракы кибетендә! Мәүлет кайтып җиткәнче базарда ит сатып алган ир хакында уйланды. Аңа кадәр дә очраштылар кебек. Теге төш күргән көнне, урамга атылып килеп чыкканда, ул бит нәкъ шушы бәндә белән маңгайга-маңгай бәрелеште! Менә ул кайда хикмәти хәлләр.

**8**

Мәүлет, алган итен, катыгын куенына кыстырып, туп-туры мунчасына кайтты. Аракы исе сеңгән бөтен киемен салып ташлап, коенып та тормыйча, парилкага кереп чумды. Күп итеп эссе салды, йөзен мунча ташыннан бөркелеп торган пар җиленә куеп, күзләрен йомды. Күзләрен йому белән каршына теге вакытта төшендә күргән илаһи карт килеп басты. Менә ул, ни хикмәттер, иреннәренең бер күзәнәген дә кыймылдатмыйча, Мәүлеткә эндәште: «Сиңа, Исхак улы Мәүлеткә, Иблис мәлгуньне табарга, танырга

һәм бөтен инсаният каршында фаш итәргә кушылды. Югыйсә Җир кешеләрен зур бәлаләр, казалар көтә. Онытма, син Илаһи Күк каршында, Аллаһы Тәгаләнең Үзе каршында җавап бирәчәксең. Җавап бирәчәксең... Җавап бирәчәксең...»

Мәүлет айнып китте. Сынын турайтты. Сынын гына түгел, зиһенен, уйларын турайтты. Ләкин иң беренче уеннан ук сискәнеп, сикереп торды – аның бүгенге көне заяга узды. Аңа бирелгән ундүрт көннең берсе юкка чыкты. Унөч көн калды. Унөч? Ун-өч... Нинди хәтәр сан бу! Нинди хәтәр көн!

Ачык тәрәзәдән бүлмәсенә килеп кергән умарта корты булмаса, нишләр иде икән ул бу мәлдә? Бу корт бүлмә хуҗасының хәлен аңламады, безелдәп, берничә тапкыр баш очыннан әйләнеп узды да агулы энәләрен аның муен тамырына батырды. Мәүлет хәтта сикереп куйды. Үзе дә сизмәстән, кизәнеп, муенына китереп сукты. Шактый нык тамызган булып чыкты: бермәлгә күз аллары караңгыланып киткәндәй булды, аң-зиһене иңке-миңке хәлгә килде. Мәүлет айнып киткәндә, аңа һөҗүм иткән бал корты аяк астында бәргәләнеп-сыргаланып җан биреп ята иде. Менә ул соңгы мәртәбә койрык очын дерелдәтеп алды да башын артка ташлап, хәрәкәтсез калды. Дөньяда тагын бер җан кыелды. Ходай тарафыннан яратылган, табигать тарафыннан тәрбияләнгән җан ә дигәнче кеше тарафыннан кыелды да куйды. Гөнаһ эшләнде. Аның үзе кылган яманлыгы, гөнаһысы җан бәрабәренә торырлыкмы соң? Мәүлет үз борчуларын онытты, бөтен күңелен әле генә күз алдында булган табигать фаҗигасенә баглап куйды. Акрынлап, фәлсәфәгә юл ачылды, соңгы вакытта тынгы бирмәгән «Иблис гаме» бу юлы да зур мәгънәләр, әһәмиятле уйланулар, фикри һәм хисси ачышлар вәгъдә итеп, өскә калкып чыкты: Иблис мәлгунь токымы әнә шул җан кыючылар арасында булырга тиеш ләбаса! Һичшиксез шулай! Чөнки иң зур гөнаһ ул – гаепсезгә, юк-юк, гаепсезгә генә түгел, гомумән, нинди генә булса да, теләсә нинди җанны кыю, бу җан иясен яшәү халәтеннән, яшәү бәхетеннән мәхрүм итү. Шул рәвешле Аллаһы Тәгалә ихтыярындагы башка язмыш-тәкъдирләргә тыкшыну, аларны җимерү. Нишләп бу уй аның башына шундук килмәде икән? Ә бит Иблис токымын иң элек әнә шундый кеше үтерүче җинаятьчеләр арасыннан эзләргә кирәк! Тукта, ни-нәрсә ди соң әле бу хакта Изге китап?

Мәүлет үзенә кирәген «Маидә» сүрәсеннән тапты. «Әгәр берәү кеше үтермәгән кешене яки җир өстендә бозыклык кылмаган кешене үтерсә, бөтен кешеләрне үтергән кебек булыр, бер кешене үлемнән коткарса – бөтен кешеләрне үлемнән коткарган кебек булыр» (32 нче аять). Шунда ук җәза мәсьәләсенә дә ачыклык кертелә: «Аллаһка һәм Рәсүленә каршы сугышкан ки җир өстендә бозыклык, яманлык кылган кешеләрнең җәзасы: үтермәк яки асмак, яки уң кулын, сул аягын кисмәктер, ягъни үтерүчене – үтерергә, үтерүче һәм талаучы булса – асарга, талаучы һәм урлаучы булса – аягын-кулын кисәргә, яки сөреп җибәрергә. Бу җәза – аларга дөнья газабы, һәм ахирәттә дә аларга олы газап булыр» (33 нче аять).

Кайсы мөһимрәк? Дөнья, яшәеш, кешелек өчен кайсы мөһимрәк? Җинаятьме, җәзамы? Әллә?... Гыйбрәтме? Сабакмы? Бу хакта төгәл итеп җинаятьчеләр, шул ук кеше үтерүчеләр генә әйтә аладыр. Ничек итеп шайтан коткысына бирелүләрен, ничек кеше җанын кыю кебек хәтәр җинаятькә баруларын... Ничек җәза кичерүләрен...

Мәүлет аптырап калды. Аның төрмә белән бәйле беркеме дә юк икән. Ләкин ул мунча кешесе бит әле! Ә мунчага барысы да йөри: урам сукбае да, министры да, элеккеге зэк та, шул зэкны төрмәгә утырткан прокурор да! Төрмә хезмәткәрләре дә йөридер мунчага. Йөрми булмас. Сораша белергә генә кирәк. Ничек тә барып керергә иде шул төрмә диварлары эченә. Мунча кассасында гомерен үткәргән Мөршидәттәй ярдәм итсә генә инде.

– Синең елмаеп каравыңнан чамалап алдым, туганым, нидер сорашмакчы буласың, ахры... – дип каршы алды ул арткы ишектән генә үз янына килеп кергән Мәүлетне.

– Әйе шул, каян белдегез?..

– Белмичә соң, самимилегең, балаларча кыланмышларың йөзеңә чыккан бит. Нигәдер аптырап, нишләргә белмичә йөрисең, ахры.

– Шулайрак шул. Миңа төрмә әһелләреннән берәр кеше кирәк иде. Безгә йөрүчеләр арасында андыйлар күренмиме? Мин үзем белмим.

– Бар, нишләп булмасын, шушында йөреп картайган берәү бар. Кайчандыр погонында вак йолдызлар гына иде, хәзер әллә ничә эре йолдыз тагып йөри. Кителен монда кимәсә дә, урамда шинель белән күргәнем бар. Төрмәдә бик зур начальник. Каян беләмме? Бер бик чибәр ханым белән килгәли ул. Икесенә генә аерым номер алалар. Хатыны түгел, анысын төгәл беләм. Әмма төпченеп сораганым юк. Безнең эш бәләкәй бит: нәрсә заказ бирәләр, шуны үтибез, түләсеннәр генә. Ә ул бик әйбәт түли. Артык-портык сорау бирерлекне калдырмаслык итеп түли! Вәт! Туктале, туганым, ул сиңа нигә кирәк булды әле? Төрмә басарга җыенмыйсыңдыр бит? Әллә берәр кешең шул тирәдә иза чигәме?

– Юк-юк, икесенең берсе дә түгел. Просто кирәк иде. Зинһар, таныштыр әле, Мөршидә апа. Бер сорау гына бирәм дә вәссәлам! Ну бик кирәк!

– Алайса, бүген сиңа җай килеп тора. Ул әле бу минутта теге тәти ханым белән ике сәгатьлек номерда. Сөйләшермен. Чыгышлый миңа берәр тәмлүшкә биреп китә торган гадәте бар. Ә син бу тирәдә күз көеге булып йөрмә, җайлап кына әйтермен үзенә. Берәр сәгатьтән кереп чык, яме.

Бер сәгатьтән барысы да ачыкланды. Теге төрмә башлыгы Мәүлеткә иртәнге сәгать унга атаклы Пләтән төрмәсенең ишек катына килеп басарга кушкан иде.

Төгәл кеше икән. Нәкъ ун тулганда, авыр, калын ишек ачылып китте дә эчтән уң беләгенә кызыл тасма бәйләгән офицер егет килеп чыкты. Ялт-йолт як-ягына каранып алгач, күз карашлары бер читтә басып торучы Мәүлеткә эләгеп туктап калды.

– Сез – мунчаданмы?

Мәүлет телен тешләде. Маңгаен җыерып, бермәл ничек дип җавап бирергә дә белми торды. Причём тут мунча?! Аннары гына үзалдына елмаеп куйды. Мунчадан булмый, каян булсын?! Мөршидә апасы мунчада сөйләшүләр алып барды бит.

– Әйе, мин ул мунчадан. Сәгать унга килергә кушканнар иде.

– Марат Сафиевич көтә. Сезгә ун минут вакыт. Сөйләшүне озакка сузмагыз. Бик мөһим киңәшмә булачак. Зинһар, мине подводить итмәгез.

– Аңладым, лейтенант, барысы да әйбәт булыр. Ун минут тек ун минут. Сүзем озын түгел, эшегезгә авырлык китермәм.

Шунда төрмә ишегендә тагын берәү пәйда булды. 55-60 яшьләр тирәсендәге абзый кеше. Чал чәчләрен бәрхетләре уңа башлаган киң кәләпүше каплап бетерә алмаган. Җыйнак сакал-мыеклы. Алары да ап-ак. Йөзе дә ак. Гадәттә, төрмәдән чыккан кешеләрнең йөзләре кара янып, хәтта тәмәке төтененнән корымланып, майланып тора, ә бу кешенең йөзе – сабыйлар йөзе кебек ап-ак, тик бу йөзне аркылыга буйга яргалаган тирән җыерчыклар гына әлеге сабый йөзле кешенең нинди авыр язмышка дучар булуы хакында сөйли кебек. Ә менә күзләре нурлы. Якты, ачык, ихлас, иманлы. Башка бик күп матур, мөлаем сүзләр белән белдерергә булыр иде бу күз карашларын. Төрмәдән андый күзле-карашлы кешеләр дә чыгар икән!

– Егетләр, якындагы мәчеткә юлны әйтә алмассыз микән?

Лейтенантка җан керде:

– Әйтәбез аны, Кирам абзый. Менә шушы урам буйлап барасыз да, сул якка борылып, бер бакчага кереп китәсез. Шул бакча аша чыкканда ук, каршыгызда «Таш мәчет» бинасы калкып чыгар. Бик тарихи бина ул. Әмирханнар тоткан мәчет. Фатих Әмирхан дигән язучыны беләсезме? Менә шуның атасы имам булып торган мәчет. Янәшәдә мәдрәсә дә булган. Табарсызмы?

– Табам-табам... Әмирханнарныкы да булгач.

Кәләпүшле абзый, рәхмәт әйтеп, саубуллашып китеп барды, лейтенант, Мәүлеткә үзе артыннан барырга ишарәләп, эчкә кереп китте.

Марат Сафиевич дигән кеше төрмә башлыгының урынбасары булып чыкты. Телефоннан сөйләшә-сөйләшә каршы алды ул Мәүлетне. Ишарәләп кенә утырырга кушты. Аның бөтен сөйләшүе телефонны колагына куеп тору булды. Кемдер аңа әмерләр бирәме, әллә берәр мәгълүмат хәбәр итәме, белгән юк, чынлыкта телефонның икенче башындагы кешенең әйткәннәре аны бик кызыксындырмый да иде бугай. Ул шулай телефон тотып утырган вакытта сынаулы күз карашлары белән күбрәк Мәүлетне өйрәнә иде. Телефон да шуның өчен кирәк сыман... Менә ул, кемнеңдер монологын тыңлап бетереп, телефон трубкасын колагыннан читкә ала башлады, шулай да каршы якка: «Ярар, эшлә!» – дип әйтергә өлгерде.

Өстәл аша үрелеп кенә күрешкәч, сәгатенә карап алды. Мәүлет аңлап алды: бу очракта ул үзенең берничә минутка гына керүен әйтергә тиеш.

– Мин сезне озак тоткарламам, Марат Сафиевич. Бер бик мөһим сорау гына бирәм дә...

Марат Сафиевич көлеп җибәрде.

– Гадәттә, бу бинада сорауларны мин бирәм.

Аңа кушылып, Мәүлет тә көлгән булды. Әмма фикеренең җеп очын югалтмаска тырышты.

– Бик сәер сорау ул, дөрес аңлагыз. Көлмәгез дә, ачуланмагыз да. Сездән башка беркем дә бу мәсьәләдә ярдәм итә алмаячак.

– Ну ярый-ярый... Күп сөйлисең син, кем... Исемеңне әйтмәдең.

– Мәүлет мин, Мәүлет.

– Тыңлыйм, Мәүлет. Мөршидә апа хакына гына тыңлыйм. Мин аны бик уважать итәм. Шуңа да син монда. Ә бездә мондый приёмнар не положено. Йә, нәрсә әйтмәкче булган идең?

– Марат Сафиевич, кеше үтергән берәр заключенный белән сөйләшергә

иде. Юк-юк, мин бер оешма вәкиле дә түгел. Просто сөйләшәсем килә, аңлыйсым килә: ничек алар бу җинаятькә барганнар? Ничек алар Иблис коткысына, шайтан вәсвәсәсенә бирелгәннәр? Бу бик мөһим: кеше кадәр кеше үтерүгә этәргән сәбәпләрне ачыклый алсам, Иблис токымы булган шайтаннарны да фашлый алачакмын.

– Стоп! Тукта! Синең бер сорау дигәнең мең сорауга әверелде, дустым. Нинди Иблис, нинди шайтан турында гәп куертасың син?! Кеше үтерүчеләргә аларның ни катнашы бар?!

– Бөтен яманлык, явызлык Иблис-шайтаннан килә дигәннән әйтүем.

– Ә мин сине җитди сүз белән килгәнсеңдер дип уйлаган идем. Әйтик, кемнедер яклап, кемнеңдер тоткынлыктагы шартларын яхшырту турында үтенеч белән. Гадәттә, шуларны сорап киләләр. Ә син Иблис дисең, шайтан дисең. Кеше үтерүчеләр белән сөйләшергә, аңлашырга булыр анысы. Тик, аңа кадәр минем сиңа шуны әйтәсем килә, Мәүлет туган: кеше җанын кыючыларны асрый торган мондый төрмәләрдән Иблис тә, хәтта аның шайтаннары да ерак йөрергә тырышалар, син шуны колагыңа киртләп куй. Сиңа бу нигә кирәк булгандыр – анысын сорап тинтерәтмим, әмма монда килеп, Иблис эзләп йөрүең һич кенә дә дөрес гамәл түгел. Күреп торам: синең моңа кадәр кеше җанын кыючыларны күргәнең булмаган. Шулаймы?

– Юк, күргәнем юк.

– Димәк, син аларны белмисең. Ә мин гомерем буе шулар белән эш итәм. Дөрес анысы, кеше үтерүчеләр арасында да төрлесе була. Кемдер ялгышлык белән кыла бу җинаятьне, кемдер саксызлык белән. Ә менә үзләре белеп, теләп, шушы явызлыгыннан тәм табып яшәүче маньяклар да бар. Бу яшәүне яшәү дип әйтеп булса инде. Кайберәүләрне кан үче, нәсел үче җинаять юлына алып керә, кайберләре белән иң гадәти хөсетлек идарә итә. Алар күп түгел, әмма алар бар. Һәм андыйлар турыдан-туры Аллаһы Тәгалә кулында. Мин шулай уйлыйм. Аллаһыбыз мондый җинаятьләрне Иблис-шайтаннардан да аерып куя хәтта. Дәлил кирәкме?

Марат Сафиевич, үрелеп, өстәл читендә яткан калын гына китапны алды. Мәүлет аны шундук танып алды. Шул китап микән дип, ул хәтта урындыгыннан күтәрелеп, үрелеп карап алды. Марат Сафиевич та аның бу «кагынып куюын» искәргән икән.

– Әйе, Ногманиның «Коръән тәфсире» бу. Миндә шулай: өстәлнең бер читендә төрмә Уставы ятса, икенче ягында – Изге китабыбыз тора. Устав буенча гына очына чыга алмасам, кайбер сорауларга җавапны шушы «Тәфсир»дән эзлим, Һәм табам да! Бая әйткән сүзләремә ялгап, мин хәзер сиңа Адәм атабыз гаиләсендә булган бур гыйбрәтле тарихны – кешелек тарихында беренче кеше үтерү вакыйгасын укып китәм. – Тиешле битен табып, укый башлаганчы, Марат Сафиевич, телефонын күтәреп, киңәшмәне кичектерергә, тагын берәр сәгать үзен борчымаска кушты. – Тыңла: «Маидә» сүрәсенең 26 нчы аятеннән башлана бу тарих: «И Мөхәммәд галәйһи әссәлам! – дип дәшә Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребезгә. – Адәм галәйһи әссәламнең угыллары хакындагы хәбәрне хаклык белән укыгыл!» дип ныклап боера. «Хаклык белән укы» ди бит. Дөреслекне, хаклыкны алга алырга куша. Ә тарихы болай: – Кабил белән бер карында яткан Әкълимә Һабилгә тиешле иде. Әмма Кабил: «Әкълимәне үзем алам», – дигәч, Аллаһ икесенә дә корбан

чалырга боерды. Ике егет корбан чалдылар, берсенеке, ягъни Һабилнеке, кабул булды, икенчесе – Кабилнеке – кабул булмады. Шунда Кабилнең көнчелеге артты һәм ул әйтте: «И Һабил, мин сине, әлбәттә, үтерәчәкмен», – диде. Һабил, чалган корбанының кабул ителүен искәртеп, әйтте: «Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә тәкъва кешеләрнекен кабул итәдер», – диде.

Һәм Һабил тагын Кабилгә әйтте: «Син мине үтерергә кулыңны суза торган булсаң да, мин сине үтерергә кулымны сузачак түгелмен. Мин бөтен галәмнәрне тәрбия итүче Аллаһ газабыннан куркам, – диде. – Әгәр мине үтерсәң, минем гөнаһымны һәм үз гөнаһыңны йөкләп, Аллаһы Тәгаләгә кайтуыңны телим; бу золым эшеңне эшләсәң, ут әһеленнән булырсың. Ут газабы – залимнәргә тиешле җәзадыр».

«Нәфесе аңа (Кабилгә) галиб булды, ягъни нәфесе Кабилне җиңде, аны Һабилне үтерергә өстерде. Кабил Һабилне үтерде һәм хәсрәтләнүчеләрдән булды».

Марат Сафиевич, китапны ябып, сак һәм итагатьлек белән урынына куйды, тышын учы белән йомшак кына сыйпап алды.

– Йә, туганым, әйт хәзер: кайда монда Иблис коткысы, шайтан вәсвәсәсе кайда? Бөтен кылынган гамәлләр Аллаһы Тәгалә ихтыярында һәм җәзасында карала. Иблис коткысы бик күп золымга, фетнәгә, бозымга юл ача, әмма ул, кешелеккә күбрәк сынау булып төшә. Мин шулай уйлыйм. Ә кеше җанын кыючы залимнәр язмышы турыдан-туры Аллаһыбыз карамагында. Шуңа да күп кенә залимнәр, авыр җинаятьләреннән соң да, кан-яшь белән тәүбә итә-итә, кешелекле, хәтта игелекле тормышларына кайталар. Әйе, Аллаһы Тәгалә барысын да эшкәртә, үз урынына куя. Шундыйларның берсен бүген чыгарып җибәрдек. Бәлки, күргәнсеңдер дә, син керер алдыннан гына хушлаштык без аның белән. Ике кеше гомерен кыеп, унике ел каты режимда утырды ул. Шулай ук татар кешесе, мөселман өммәтеннән. Соңгы елларда дингә бик бирелде. Башкаларны да тәкъвалыкка өндәде. Мин үзем дә аның тәэсирендә кулыма Коръән алдым. Шулай дисәм, һич ялган булмас. Имам хәзрәт кебегрәк вазифа башкарды ул төрмәдә. Менә син әйт: ничек килештереп була бу язмышны кеше үтерүче язмышы белән? Юк, моны Иблис фәлсәфәсе генә аңлата алмый. Монда Ходай үзе кирәк, Аның сүзе, ихтыяры һәм хөкеме кирәк! Ходай хөкеме катлаулырак. Әле бит Кыямәт көне бар, Ахырзаман бар. Барыбыз да, кубарылып, Раббыбыз каршына басачакбыз лабаса. Хәтта Иблис үзе дә басачак һәм иң ахыргы зат буларак хөкем ителәчәк. Менә бит нидә хикмәт!

Тагын телефон шалтырады. Ничек кенә сөйләшәсе килсә дә, вакыт юклыгына ишарәләп, Марат Сафиевич кулларын як-якка җәеп җибәрде, торып басты, саубуллашырга җыенды.

– Теге кешенең исемен әйтә алмассыз микән? Бүген ireккә чыккан абзыйның исемен. Бәлки, күреп-сөйләшергә мөмкин булыр. – Мәүлетнең чын-чынлап кеше үтерүче имам белән танышасы килә иде, чөнки белә: кылынган золымлыкларга барыбер дә Иблис ләгыйньнең катнашы булмый калмас. Ә бу хакта шушы золымлыкны кылган кеше үзе генә әйтә ала!

Марат Сафиевич бик теләп аңа тиешле мәгълүматны бирде:

– Кирам Хамматов. Кушаматы «Кирхам». «Зэк имам» дип тә әйткәлиләр. Син аны мәчет тирәләреннән эзлә. Шул тирәгә эшкә урнашырга уйлап йөрми микән?

Инде хушлашып беткәч, Марат Сафиевич, тоткарланырга кушып, Мәүлеткә кул изәде. Бу юлы инде үзе аның янына килеп, ярым пышылдап кына серле сүзләрен әйтте:

– Ни. Мөршидә апаң артыграгын да әйткәндер минем хакта. Битәрләмә, яме. Шулай да була: беренче мәхәббәтне һич онытып булмый, кайчакта ул гомер буе озатып килә, гомер буе, бәхетнең сыңар канаты булып, янәшә яши. Минем шундый очрак.

Төрмәнең авыр һавасыннан соң, урам һавасы баллы-майлы булып тоелды Мәүлеткә. «Бу тирәгә бүтән якын килергә язмасын», дип уйлап куйды ул. Әмма үзенең визитыннан разый иде. Төрмә тикле төрмәдә шундый ачык җанлы, ихлас күңелле кешене, чын мәгънәсендә гыйлем иясен очратуына шат иде Мәүлет. Хәзер инде бу «төрмә эпопеясы»ның очына чыгасы гына калды.

**9**

«Таш мәчет»кә өйлә намазы башланыр алдыннан барып керде Мәүлет. Сөннәткә керешкәннәр генә әле. Ул арттагы рәттә калган бер буш урынга барып басты да дога гаменә бирелде. Ә дога бик кирәк иде аның күңеленә. Төрмә һавасыннан арынырга, төрмә рухиятеннән котылырга кирәк иде аңа. «Әссәламегаләйкүм вә рәхмәтуллаһ...» Башын сул якка каерып, сөннәт намазның соңгы кәлимәсен әйткәндә, Мәүлетнең күз карашы әле күптән түгел генә төрмә ишеге алдында күргән кәләпүшле абзыйның күз карашлары белән кабат очрашты! Бермәл бу карашлар, бер-берсен танып, аерылыша алмыйча, эләгешеп, сыенышып тордылар, аннары гына алларына дога өмет итеп сузылган куш учларына кереп сыендылар: «Әстәгъфируллаһ... Әстәгъфируллаһ... Әстәгъфируллаһ!..»

Фарызны укыр алдыннан, шайтан керерлек тә ара калдырмыйча рәтләрен тигезләп, янәшә бастылар, бер-берсенең тән җылысын тоеп, изге дога гаменә бирелделәр. «Фатиха» сүрәсен күңеленнән үткәргәнче, Мәүлет шуны гына уйлап өлгерде: «Сабый кулы кебек, җылылык бөркеп торган шушы йомшак, иманлы куллар ничек итеп кеше тикле кеше җанын кыя алды икән?!»

Фарыздан соң укыла торган сөннәт рәкагатьләрендә дә Мәүлет яңа танышы белән янәшә калды, абзый кеше үзе дә читкә тайпылмады. Алар шулай, бер-берсенең кул-беләкләрен тоеп, ниндидер серле-сихри ым-ишарәләр белән аралашып, сөннәтне башкарып чыктылар. Намаздан соң ул җылы, әмма үтә дә ябык кулларга таба беренче адымны Мәүлет ясады.

– Әссәламегаләйкүм, хәзрәт!

– Вәгаләйкүм әссәлам, мөселман кардәшем!

Кул биреп күрештеләр.

– Мин бит сине төрмә каршында күрдем, шулаймы?

– Нәкъ шулай.

– Рәсим чыгып каршы алган кеше, гадәттә, төрмә башлыгына килгән була. Значит, син Марат янында булдың? Берәр кешегез бармы әллә ул тирәдә? Бәлки, мин беләмдер?

– Юк-юк, беркемем дә юк. Төрмә тирәсендә, гомумән дә, булганым-ниткәнем юк иде. Бүген беренче мәртәбә барып чыктым.

– Булырга да язмасын, кем...

– Мәүлет. Дөресен генә әйткәндә, миңа сез кирәк идегез, Кирам абзый.

– Мәүлет? Мәүлет. Минем Мәүлет исемле улым бар иде. Үтерделәр. Шул улым өчен ике кешенең җанын кыйдым. Белеп үтердем, шуңа күрә дә дөрес утырдым. Ярый, анысы минем тарих. Ә сиңа мин ни өчен кирәк булдым инде? Һич кенә дә фикер очыңны тотып ала алмыйм. Мин кем дә, син кем, дигәндәй.

– Юк-юк, мин сезне белмим, сез мине белмисез. Без бүген беренче тапкыр очраштык. Әмма сез миңа бик кирәк. Бер мәсьәлә буенча кирәк.

– Алайса... нәрсә диим инде? Тыңлыйм.

– Ләкин аяк өсте генә сөйләшә торган сүз түгел. Бик җитди сүз. Әйдәгез, берәр кая кереп утырыйк әле. Монда эскәмияле заллар бар, аулаграк урыннар... Әйдәгез, мин сезгә булышам.

Алар икәүләп Кирам абзый күтәреп килгән төенчекләргә барып ябыштылар. Күршедәге чишенү бүлмәсенә кереп, кара-каршы эскәмияләргә урнаштылар.

«Зек-хәзрәт» һаман әле киеренке халәттән чыга алмый иде. Күз карашлары җитдиләнгән, хәтта йөзен сарып алган җыерчыклар да тартылыбрак киткәндәй булган.

– Ну, нәрсәгә кирәк булдым инде? Башта ук әйтеп куям: гөнаһлардан саклый да, арындыра да алмыйм. Үземнең гөнаһларым да баштин ашкан. Аның өчен имам-муллалар җитәрлек.

– Кирам абзый, мин сезгә хәзер бер тарих сөйлим, дөресрәге, төш сөйлим, ә сез соңыннан үзегезнең төпле сүзегезне әйтерсез. Килештекме?

– Йә, сөйлә. Гомерен төрмәдә үткәреп, бүген генә иреккә чыккан, моннан соң тормышын иманлы гамәлләр белән дәвам итәргә теләгән карт җан синең кебек гөнаһсыз бәндәгә нинди сүз әйтә алыр икән соң?!

Мәүлет бу юлы җавап бирмәде. Иблис коткысы хакында хәбәр иткән сәер дә, серле дә төшен сөйләргә кереште. Мәүлет бер нәрсәгә игътибар итте. Төше хакында никадәр дулкынланып, хисләнеп сөйләргә тырышса да, тыңлаганнарына Кирам абзыйның битендә бер генә мускулы да селкенмәде.

Бу бик сәер иде. Ләкин Мәүлет аңламый түгел, бик аңлый: үз гомеренең иң матур еллары булырга тиешле унике елны тоткынлыкта үткәргән кешедән нинди хис-тойгы көтәсең инде?! Әнә бит: сөйләшүе дә каты-коты гына.

– Сине конкрет нәрсә кызыксындыра, Мәүлет энем?

– Мине конкрет Иблис кызыксындыра. Мөселманнар тормышында, язмышында хәлиткеч һәм хәтәр роль уйнаган Иблис тарихы мине борчый. Юк, мине генә түгел, бөтен кешелекне, дөньяны борчый. Менә шуны табарга, фашларга кушылган миңа. Хөкемен Аллаһы Тәгалә үзе башкарыр, әмма мин аны фашларга тиеш. Мин бу төшне шулай аңладым.

– Шулай да, конкрет нәрсә кирәк сиңа? Соравыңны төгәл итеп бир. Кыландырмый, матурламый гына.

– Алайса, турысы белән әйтәм: менә сез адәмнәр җанын кыйгансыз. кулыгыз ничек барды бу адымга? Иблис ничек итеп сезнең җанга үзенең мәкерен, золымын сала алды? Нигә бирештегез аның коткысына, шайтан вәсвәсәсенә ничек бирештегез? Шуны ачыклый алсак, бәлки, аңа каршы торыр әмәлләрне дә чамалар идек...

– Рәхмәт, син турысы белән сорадың, мин дә турысы белән җавап бирәм: минем фаҗигале язмышымда Иблиснең бер катнашы да юк.

Минем күз алдымда ике әтрәк-әләм бердәнбер улымны үтергәч, улым кайгысыннан хатыным җан тәслим кылгач, мин үзем Иблискә әверелдем. Аңлыйсыңмы, үзем Иблис тарихына дучар булдым. Миндәге ачу, золым, димәк ки, үч коткысы мең шайтан коткысыннан да көчлерәк иде. Мине бу хәтәр ниятемнән берни дә, беркем дә аерып та, каерып та ала алмый иде: кыелган ике җанга ике җан кыелырга тиеш иде. Һәм мин аларны күңелем булырлык, үчем кайтырлык итеп дөмектердем, сагалап торып, ау мылтыгыннан атып үтердем, бернинди икеләнүсез, шикләнүсез, үкенүсез кылдым бу җинаятемне; үзем үк милициягә барып әйттем. Шул.

Бераз сүзсез тордылар. Икесенә дә авыр иде. Мәүлеткә авыррак та булгандыр әле. Шул авырлыкны бераз җиңеләйтү өчен, әлбәттә инде, уңай җавап өмет итеп, ул иң мөһим сорауны бирергә булды:

– Ә бүген үкенәсезме? Бүген сез һаман да Иблисме?

– Үкенмим, әмма мин ул вакыттагы гамәлләремне хупламыйм да. Күрәсең, шуңа күрә дә мин бүген Иблис түгелдер.

– Ничек инде? Үкенмисез дә, хупламыйсыз да? Алай да буламыни?

– Була. Менә син Иблис мәлгуньне эзләп йөрисең. Бүген ул кемдер, әйтә алмыйм, әмма ул вакытта Иблис – мин идем. Мине котыртырга кирәк түгел иде, мин үзем бөтен дөньясын үч дәрьясына, шайтан коткысына күмә ала идем ул вакытта. Бер көн эчендә бәхетле гаиләмне таркаттым бит, бөтен, бәхетле тормышымнан мәхрүм калдым, язмышымны югалттым. Ничек үчләшмисең дә, ничек Иблис рәвешенә кермисең, ди?! Шуңа күрә дә ул чактагы тәртибем өчен үкенмим. Ләкин хупламыйм да. Чөнки Иблислек, шайтан фетнәсе – үзе үк Аллаһы Тәгалә тәгълиматына каршы гамәл, каршы фетнә. Кеше җаны баштан ахырга кадәр Аллаһ карамагында, – яшәештә иң беренче канун шул булырга тиеш. Кайчакта кеше җаны кешеләр карамагында кебек тоелса да, чынлыкта, хәлиткеч хөкемне Аллаһы Тәгалә чыгара. Һәм ул хөкем төрле юллар белән кешеләргә килеп ирешә. Төш беләнме, дога ашамы, сәҗдә халәтендәме, очраклы бер таныш, кардәш исә бөтенләй таныш булмаган дәрвиш сүзе беләнме. Мин бүген – мөселман өммәтеннән булган, үз гөнаһларымны таныган, алардан чистарынырга тырышкан, мең-миллион мәртәбә тәүбәгә килгән бер бәндә. Мин инде Иблис битлеген ун ел элек салып аттым, Иблис рухиятеннән тагын да иртәрәк арындым, уйларым да, гамәлләрем дә хәзер Аллаһы Тәгаләгә юнәлгән.

– Бөтен җинаятьче дә Иблис битлегеннән котыла аламы соң? Аннан котылу өчен дә көч кирәктер бит?

– Котыла. Көчлеләр котыла. Ә көчсезләрдә Иблис үлә, юкка чыга. Бу бәндә инде тере мәеткә әверелә.

– Коръәндә җан кыючылар хакында сүз барганда, Иблис хакында бөтенләй дә әйтелми. Иблис токымы башка төрле җинаятьләр кылынганда гына коткы таратучы буларак телгә алына. Ә бит адәм баласы кинәт кенә үтерүче-катыйль булып китмәскә мөмкин. Күп еллар буе Иблис коткысында агуланып, начар гамәлләр, золымнар кылып, акрынлап кеше үтерү ниятенә килергә мөмкин. Шулай түгелмени? Бу мантыйкка ничек карыйсыз?

– Мәүлет энем, иң явыз сугыш-чукмары да, иң елгыр угры-карак та, йорт басучы да, иң астыртын, тотнаксыз зиначы да, башкалар бәхетенә көенеп, хәтта үчләшеп яшәүче иң хөсетле җан да кеше җанын кыю алдында

торганда, бу канлы гамәлне кылмыйча туктап кала. Һәм иң йомшак, юаш, басынкы бер үшән, хөрәсән зат та, үз сәгатен көтеп алып, кеше җанын кыя. Төрмәдәге үтерүчеләрнең күпчелеге әнә шундыйлар. Үчләрен баш бирмичә җан кыйган миндәйләр дә сирәк кенә очрый. Андыйлар Иблислектән тизрәк тә котыла әле. Чөнки алар көчле, аларда рух көчле. Хәзер аңлашыламы? Ничек кенә булса да, һәркем, ахыр чиктә, Аллаһы Тәгалә юлына керергә, Аңа сыенырга тиеш. Менә мин дә шул юлны сайладым.

Мәүлет Кирам абзыйның уйлары-ниятләре белән кызыксынды. Аны үзенә кунакка чакырды. Мунча тәкъдим итте. Бу тәкъдим «зэк-имам»га аеруча хуш килде.

– Менә монысы ярар иде. Чын мунча сагындырды. Бер керәм әле мин сезгә, бер керәм. Юынып, чистарынып чыгам. Тәнемне генә түгел, күңелемне, җанымны ышкып-ышкып юасы килә! Ләкин бүген түгел, керәсе җирләрем, күрәсе кешеләрем, туганнарым бар, алар өметләнеп көтеп торалар. Мин дә аларны бик сагындым. Ә мәчет белән мунча – соңыннан. Бәлки, берәр мәчет яки мунча тирәсенә эшкә дә төпләнеп калырмын. Вчү-теки, кешеләрне чистарта торган урыннар бит.

Мәүлет белән Кирам абзый бик җылы итеп, дусларча куллар бирешеп, туганнарча арка кагышып хушлаштылар. Юк, бу сүз туры килми. Һич кенә дә «хушлаштылар» диясе килми. Саубуллаштылар, чөнки тагын очрашырга сүз куештылар.

Мәчет чатында ялгызы гына басып калган Мәүлет бер төенчеген аркасына аскан, икенчесен кулына асылындырган «зэк-имам» артыннан шактый карап торды, эченнән генә аңа алдагы тормышында иминлекләр, уңышлар теләде. Үзенең исә тизрәк бу төрмә тарихыннан арынасы килде, бу гыйбрәтле, авыр язмыштан котылу өчен бер генә юл бар иде – кайнар парларын бөркеп торган мунчага кереп чумарга, көннәр буе шуннан чыкмыйча, зиһенне иләсләндерерлек дәрәҗәдә изрәп йомшанырга, аннары кабат туарга, шул котсыз, йөнтәс, хәсис Иблис шаукымына каршы торырлык көч җыярга. Шул мәлгуньне койрыгыннан урап тотып, болгап-болгап атарга. Кешеләр язмышына шул койрыгын тыгып бутамаслык итәргә!

**10**

Мәүлет йөгереп диярлек юыну бүлмәсенә чыкты. Беренче тапкыр күргән кебек, шәрә тәннәр белән шыплап тулган залны җентекләп өйрәнә башлады. Кемнедер, нидер эзләгән кебек һәр кешегә текәлеп карап, аның тән шәрәфләрен өйрәнергә кереште. Баштарак ни-нәрсә эзләгәнен үзе дә аңлап бетермәде ул. Бераздан гына зиһен калебендә күптәннән таныш, әле берничә минут элек кенә баш калкыткан мәҗүси уй чәбәләнеп алды: «Иблиснең койрыгы булырга тиеш!»

Мәүлет зал буйлап китте. Аның бу сәер кыланышына баштарак игътибар итүче булмады. Карана-карана, залның урта бер җиренә барып җиткәндә генә, кемдер әйтеп куйды:

– Карале безнең «банщик»ны! Нишләгән ул? Әллә ориентациясен алыштырганмы? Алларны-артларны карап йөри...

Икенче берәү бу хәлне көлкегә алырга тырышты:

– Сакланыгыз, егетләр, юкса, кызлыгыгызны югалтуыгыз бар.

Мунча эчендә көлеш китте, ир-атлар арасында гына була торган мәгънәсез шаярулар, тел чарлаулар башланды.

Мәүлет аларны ишетмәде дә. Ул инде эзләгәнен тапкан иде. Әнә ул – баштан-аяк йон баскан, җөнтәс битле, куе кашлы, җитү чәчле адәм заты. Адәм дип әйтерлеге дә юк. Җендер бу, шайтандыр. Бәлки әле Иблиснең үзе үктер? Ләкин ничек кенә текәлеп каранса да, теге җөнтәс бәндә Мәүлеткә алды белән дә, арты белән дә борылмады, юри ирештергәндәй, һаман янякларын юуында булды. Ә Мәүлет китапханәдә укыган китаплардан белә: Иблис затының корсагында кендеге дә, бот арасында – җан җирендә – ит кисәге дә булмый, ә менә артында койрыгы тәгаен була! Мәүлет аптырап бетте: бу бәндәнең корсак турысын да, җан җирен дә шулкадәр калын йон баскан, анда ни-нәрсә булуын һич кенә дә аңлап булмый. Ә менә койрыгы күренергә тиеш. Тиеш тә... Күренми шул. Анда да шул ук кыргый күренеш – уч-уч укмашкан йон.

Ул арада Мәүлет янына Миндияр исемле мишәр танышы килеп җитте.

– Нәрсә булды сиңа, әзи? Берцяк кенә сәер син бүген. Әйдя, утырып садись монда, бөтен кешене аптыратып, үря катып торма.

Аның пәйда булуы Мәүлеткә җан иңдергәндәй булды. Ул Миндиярдан сораша башлады:

– Кем ул – теге җөнтәс бәндә?

– Ә, аны әйтясеңме? «Азәр» ул, то есть азәрбайҗан кешесе. Базарда точкасы бар, болай зыяны-фәләне тигәне юк.

– Бигрәк кыяфәтсез, шуңа сорашуым.

– До-а... Анысы шулай, әзи. Бөтен кеше аптырый, шуңа да аның янына юынырга беркем утырмый. Чирканалар, димме. Минемчә, юкка. Беркөн сөйләндергән идем – биш сабые бар, катыны, туганнары – барысы да дәррәү күчеп килгәннәр. Базар тоталар. Безнеңчә дә шәп сукалый.

Мәүлет барыбер ышанмады. Ниндидер сәер тойгы аны әлеге җөнтәс кеше янына сөйрәп диярлек китерде. Янына утыртты. Сабын күбегенә капланган теге бәндә исә аны, көтеп алган кебек, татарчалап, әмма үзләренчә «т» гә «ч»не өстәп үзгәртеп сөйләнергә кереште:

– Аптырама, тчуган, безнең нәсел билгесе ул. Азәрбайҗанда шундый аул бар – анда бөтчен кеше дә йонлы тән белән тчуа. Безнең баш пәйгамбәребез булган Али галәйһиссәламнең дә бөтчен тәне җөнтәс булган, шуңа да безне «пәйгамбәр нәселеннән» дип йөртәләр.

Мәүлет авызын ачып, бер сүз дә әйтмәде. Әйтә дә алмый иде. Ул бары тик ниндидер шаукымга эләккән кебек бу сәер бәндәнең гайрәтне чигерерлек кыргый тәненә карап торуында булды.

– Ышанмыйсыңмы? Мине ниндидер җен-пәри дип уйлыйсыңмы? Бәлки әле, койрыгы бардыр, дип тә шикләнәсеңдер?

Мәүлет бу кадәр ачыктан-ачык сөйләшүне көтмәгән иде. Ул хәтта каушаудан, кыенсынудан йөткерергә кереште. Ә теге «азәр-бәндә» сүзен дәвам итте:

– Мә, кара... Юк, анысы юк, тамчы да шикләнмә. Әгәр инде сиңа койрыклы кеше кирәк икән, мин андый кешене беләм... Тик нәрсәгә ул сиңа – һич аңламыйм...

Мәүлет тәмам телсез калды. Аның уйларын укыган кебек сөйләшә ләбаса

бу. Чынлап та, берәр рухи затмы әллә? Күңелгә, зиһенгә керә бит. Юктыр, охшамаган. Хәзер үк нидер җавап бирергә кирәк, юкса адәм көлкесенә калачак ул. Ни дип әйтергә соң? Нигә, дөресен әйтергә!

– Әйе, мин койрыклы шайтан эзлим. Иблис диләр аны, ишеткәнең бармы? Син белгән койрыклы кеше – шул Иблисме соң?

Теге бәндә, юынуыннан туктап, Мәүлет янәшәсенә утырды.

– Белмим. Иблискә бер дә охшамаган ул. Шуны гына беләм: Иблис, шайтан коткысына бирелеп, шактый таптаган ул Чечня урман-тауларын. Элек боевик булган диләр, дөрес булса. Дөрес булса, ниндидер гаепләре өчен үзенекеләр үк аңа койрык тагып куйганнар, имеш...

– Ничек инде – тагып? Аны тагып та буламыни?

– Була, нишләп булмасын. Кавказда яшәгән һәр кеше белә моны – иң хәтәр җәзаларның берсе ул. Дөресрәге, икенчесе. Беренчесе «кызыл галстук» дип йөртелә. Кешенең бугазын тишеп, шуннан аның телен чыгарып куялар. Мондый җәзадан соң кеше исән калмый. Акылдан яздырырлык күренеш... Карабах сугышында үземнең күргәнем булды. Ә менә «шайтан койрыгы» дигәне кешене үтерми, ә менә бик катчы әрнүләргә дучар итә...

Азәр бераз тын калып, уйланып торды. Йөзен чыта-чыта уйланды ул. Яңак сөякләре киеренке бер хәлгә кереп, йодрыклары, бүтән ачылмаска төйнәлгәндәй, сабынлы мунчалага чат ябышкан иде...

– Теләсәң, сөйлим. – Үзе, Мәүлеттән җавап та көтеп тормыйча, сөйли дә башлады. – Чечняда булган бу хәл. Садир (ул кешенең исеме шулай) дигән чечен егете белән булган. Пленга эләгеп, зинданга ябылган, берничә ай мәсхәрәләнеп җәфа чиккән бер рус кызын – федералларның шәфкать туташын качырып җибәрә ул. Кызгана инде. Ләкин ул кызны барыбер тоталар һәм мәсхәрәләп үтерәләр, әмма Садирга да җәза бирәләр, койрык тагып куялар. Нәрсә эшлиләрме? Аркасыннан бер буй-тасма тән тиресен ярып-сыдырып төшерәләр дә шул килеш асып куялар. Бераздан бу тән тиресе ката, әмма өзелеп тә төшми, койрык булып асылынып кала...

Бераз тын тордылар. Бу хәлләрне күз алдына китереп утырган Мәүлет үзенең йөрәгендә ниндидер авырту тойды. Ул көчәйгәннән-көчәя бара иде.

Уйларының да рәте-чираты юк. Нигә килде ул монда, нигә сөйләтте бу җөнтәс бәндәдән йөрәккә төшәрлек хәтәр хәлләрне? Гел шулай: шайтан гаменә бирелеп, Иблис токымын эзләп йөри башласа, ул һаман-һаман авыртуга, борчуга, шик-шөбһәләргә дучар була лабаса...

Мәүлет юынып-коенып та тормыйча, аннан-моннан гына киенде дә бүлмәсенә чыгып китте. Намазына, догаларына ябышты. Барыбер тынычлана алмады. Юк ла, азәрбайҗан кешесе сөйләгәннәрдән генә өшемәде аның җаны; анысы бер ишарә генә булды кебек аның йөрәк газапларына.

Менә бит ничек килеп чыкты – бөтен дөнья белән, шушы гамьле, гөнаһлы, шаукымлы яшәеш белән күзгә-күз карашып, япа-ялгыз калды ул! Шушы унөч көн эчендә аның язмышы хәл ителәчәк, аның язмышы гына түгел, бөтен дөньяның язмышы. Мәңгелектән килеп, мәңгелеккә баручы дөнья, кешелек яшәеше шушы урында тукталырга, яисә кирегә китәргә мөмкин. Дөнья чикләре юылып, бу фани тормышка җен-шайтан халкы, Иблис токымы хуҗа булырга мөмкин. Мөмкин, әгәр дә Мәүлет аны таба алмаса.

Үзенең тар гына бүлмәсендә иләс-миләс хәлдә яткан Мәүлет, батып баручы бәндә саламга ябышкандай, бөтен күңел ярсуы белән төшендәге таныш картны чакырырга кереште. Төшенә түгел, күз алдына да килмәде ул изге зат. Күз алдына килергә, ул бит аны төшендә күрде. Күзләрен йоммыйча килә димени ул?!

Күзләрен йомганга да шактый инде. Мәүлет ойый ук башлады. Әмма таныш карт килмәде дә килмәде. Аның каравы, аның йокылы-уяулы зиһенендә теге сихерче кызның гүзәл чырае чагылып-чагылып киткәләде. Бик хикмәтле чырай иде ул. Нинди дер бер мизгелдә ямьсез һәм котсыз кыяфәткә кергән кебек була. Иң кызыгы, Мәүлет хәшәрәт чырайны күреп тә бетерә алмый, аны шундук имче кызның гүзәл сурәте алыштыра.

Берзаман бу гүзәл сурәт Мәүлетнең күңел күзләре каршында аермачык булып балкып тора башлады. Ачык-нурлы гына түгел, тере, җанлы иде бу сурәт. Һәм бик тә, бик тә мәхәббәтле иде. Менә ул Мәүлеткә тагын да ныграк якынайды, аның күңеленә, зиһененә тагын да ныграк үтеп керде. Ул шулай нурлы, көләч йөзе белән, җылы тыны белән аны тагын да ныграк әсир итә, шаукымлы сихеренә дучар итә бара иде.

Мәүлет бу юлы кызның ап-ак шәрә тәнен, зифа буй-сынын, тәгәрәшеп-уйнап торган күкрәкләрен – барысын да аермачык күрде. Күреп кенә калмады, үзенең дә тәне тулышып, йокылы-уяулы хәлдә ашыга-ашыга чишенергә кереште.

**11**

Мәүлетнең бу кадәр иләсләнеп, мәрткә китеп йоклаганы юк иде. Ул хәтта иртәнге намазына соңга калды. Анысына бер аптыраса, үзенең шәп-шәрә килеш, бот-чатларын як-якка аерып, иләмсез, хәтта оятсыз кыяфәттә ятуына тагын бер гаҗәпләнде. Мондый хәлнең бер дә булганы юк иде ләбаса! Хатын-кыз җенесенә ымсынып, табигый теләкләреннән шашынып яткан чаклары булды булуын, әмма бу кадәр дә оятсызланганы булмагандыр.

Туктале! Тагын бер тойгы бар монда! Бу тойгы Мәүлеткә ниндидер татлы һәм затлы ис белән килеп иреште. Бу хуш ис һичшиксез хатын-кыз белән бәйләнгән иде. Һәм ниндидер таныш хатын-кыз белән! Таныш, бик тә таныш булырга тиеш ул. Ә аның бер генә танышы бар – кайчандыр төшен юраган, шуның белән Мәүлетне бетмәс-төкәнмәс борчуларга дучар иткән сихерче! Кичә кич җанлы сурәт булып аның каршына килеп йөдәткән имче кызый! Гүзәлләрнең гүзәле! Татлыларның татлысы!..

Имче кызны исенә төшерү белән Мәүлет бик тә сәер, һәрхәлдә моңа кадәр үзенә таныш булмаган тойгы кичерде. Гүя шул кыз белән булган, аның белән йоклаган, җенси якынлык кылган... Тәнендәге бушану, җанындагы җиңеллек, рәхәтлек шул бит инде! Ә бу дымлы җәймә? Ә бу татлы хушбуй исе каян, дисең? Шул кызый исе ләбаса ул, аның гына исерткеч-шаукымлы исе!

Мәүлет үзенең хәтәр ачышыннан сикереп торды. Ул, куркынып, тирә-ягына каранды. Ишек ягына караш ташлады. Ябылып бетмичә калган ишек аның күңеленә ургылып керә барган шомлы уйларны көчәйтте генә. Нишләргә белмичә, ул кабат түшәгенә ауды, учлары белән йөзен каплады. Күңеленнән генә кичә булган хәлләрне кичерә башлады. Исерекләр, мунча, сурәт. Әле шайтан кыяфәтенә кереп, әле имче кыз булып аның каршына

килгән серле йөз-чырай. Йокылы-уяулы зиһенен бимазалап йөргән сурәт. Бөтен хикмәт шул сурәттә булырга тиеш...

Аннары... Каян килсен ул кыз? Каян белсен ул Мәүлетнең кайда яшәгәнен? Янында җенси зиналык кылып яткан кызыйны тоймаслык дәрәҗәдә тиле һәм хыялый түгел ләбаса ул! Кем белсен?! Бәлки инде ул акылдан шашкандыр? Үзенең нәрсә эшләгәнен, ни кылганын да белмидер?

Болай уй коткысына бирелеп ятса, чынлап та диванага әвереләчәген аңлап, Мәүлет сикереп торды, ашыгып киенә башлады. Кабат яшәргә җыенды. Юынды, тәһарәтен яңартты, соңга калган намазын башкарып чыкты. Тынычланды. Түшәгенә килеп утырды. Шунда аңа, соңлап булса да, күптән килергә тиешле уй килеп иреште: «Кичәге хәлләр – алдагы тормышына, бүгенге кыласы гамәлләренә ишарә генә булса? Зиналыкка, шайтан коткысы дип саналган җенси бозыклыкка ым-ишарә булса? Бу төш кисәге (төш булса инде) Мәүлеткә шуны аңлатмакчы була, күрәсең: ул Иблисне зина кылучылар, тәннәрен сатып кәсеп итүчеләр, бозыклыктан тәм табучылар, җан рәхәтеннән бигрәк тән рәхәтен өстен күрүчеләр арасыннан эзләргә тиеш. Мишәр Миндияр юкка гына: «Хатын-кызның бер канатында фәрештә утырса, икенче канатында шайтан утырыр», – дип әйтми торгандыр. Шайтанны азып-тузып йөрүче хатын-кызлар тирәсеннән эзләргә кирәк – Мәүлет хәзер моны төгәл белә!

Мунчадан ашыгып чыгып килгән Мәүлеткә бервакытта да кулыннан себеркесен төшерми торган Шәмси карт очрады.

– Кая барасың болай кабаланып, олан?

– Лутчы сорама, Шәмси бабай, белүеңә караганда, белмәвең хәерлерәк.

– Шулай укмыни? Юньлегә түгел алайса бу сәфәрең?

– Юньлегә түгел. Анысы хак. Тик син тирәнгә кереп уйлама, яме. Барысы да контрольдә, барысы да Ходай кулында. – Мәүлет үзе дә сизмәстән бармагы белән күккә ишарәләде.

– Кызлар белән булашып, көлкегә калма тагы, олан!

– Каян белдең?

– Минем яшькә җит әле, белерсең – минем яшьтәгеләр белән беркем дә кызлар хакында сөйләшми...

Мәүлет ни әйтергә дә белмәде, ык-мык килеп, бер урында таптанып торуында булды.

– Димәк, начар кызлар янына барасың? Юньлегә түгел бу, егет. Соңыннан үкенмәссеңме? Кара аны!

– Юк ла, син уйлаган әйбер түгел бу. Мин алар янына теге Иблис хәзрәтләрен, юк ла, Иблис хәсрәтләрен эзләп барам.

– Һаман шул Иблис гамендә йөрисең икән әле, саклану чараларын күрдеңме соң?

– Шәмси бабай, минем бер генә саклану чарам бар – Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәтенә ирешү, Аның ярдәменә лаек булу. Ул да беләдер бит инде минем бу хәлләрне, ә? Ул мине ташларга тиеш түгел, мин бит Аның да эшен эшләп йөрим. Аның ым-ишарәсе белән табарга тиеш ләбаса мин ул юньсезне, Аның ярдәме белән ул хәсиснең юлын кисәргә тиеш, явыз ниятләреннән ваз кичтерергә тиеш! Ярдәм итмәсә, Ул Ходай да булмас иде, шулай түгелмени? – Мәүлет бу юлы ярсынып китте, арлы-бирле йөренеп, кулларын болгый-болгый сөйләнергә кереште.

– Чү-чү, олан, артык кызма. Ходай турында болай сөйләшмиләр. Мең мәртәбә әйттем бит инде мин сиңа – Аның мәрхәмәтенә догалар багышлап, изге гамәлләр кылып кына ирешеп була. Башта изгелек кыл, аннары илаһи ярдәм турында уйла.

Мәүлет тынычлангандай булды.

– Мин боларны аптыраганнан гына сөйлим бит инe, Шәмси бабай. Син әйткәннәрне үзем дә беләм. Тик менә... Акылым белән белсәм дә, күңелем ярсый, җаным тынгысызлана.

Ниндидер мөһим сүз әйтергә җыенган кебек кулындагы себеркесен мунча ишегалдына алып керә торган таш капканың диварына сөяп куйды. Әйтергә теләгәне чынлап та җитди булып чыкты:

– Кая гына барсаң да, ниләр генә кылсаң да, шуны бел, олан: бервакытта да акылыңны, зиһенеңне җуйма, ихлас күңелең, чын йөрәгең белән изгелек кыл, тормышта үз тиңең белән яшә. Бу минем сүзләр түгел, изге китапларда шулай язылган.

– Нишлим соң, алайса. Гел генә Аллаһтан ярдәм сорарга туры килә.

– Сора, сора! Сорама дими бит. Тик син: «Аллаһы Тәгаләм, миңа адым саен Синнән ярдәм сорамаслык көч бир, акыл бир, сабырлык бир», – дип сора.

– Рәхмәт яхшы сүзең өчен, бик кыен иде – хәзер инде күңелем урынына утырды. Моннан соң да яхшы сүзеңнән, догаларыңнан ташлама, яме.

Мәүлетнең Шәмси картны кочаклап аласы килде, күзләреннән төртеп чыккан берничә яшь бөртеге генә аңа якын килүдән тыеп калды. Шул күз яшьләреннән кыенсынып, Мәүлет тизрәк китү ягын карады.

– Мин китим инде, яме, Шәмси бабай. Рәхмәт. Сау бул.

– Сау бул, олан. Барысы да әйбәт булыр, күңелем сизә.

Мәүлет, юлындагы тар тыкрыкны кистереп чыгып, олы урамнарның берсенә төште. Төшүен төште, әмма ул үзенең кая барасын белми булып чыкты. Аның бит моңа кадәр бер генә мәртәбә дә зина кылып йөрүче хатыннар, җилбәзәк кызлар, тәннәрен сатып көн күрүче фахишәләр белән эш иткәне булмады. Моннан соң да аларга якын бармас иде дә бит. Тәкъдир бар, язылган язмыш бар, илаһи миссия бар. Бөтен дөнья аңа карап торганда, җәһәннәм тишегенә дә керергә риза ул бүген. Җәһәннәм тишегенә? Карале, нәкъ шундый исемдә бер караңгы аулак җир барлыгын белә бит Мәүлет. «Җәһәннәм тишеге» дип йөртелә торган бу бистә кебек торак җир шәһәрнең бер ерак читенә урнашкан. Ни өчен «Җәһәннәм тиешеге»ме? Беренчедән, ерак. Икенчедән... Икенчедән, бик куркыныч җир, ахры, ул... Ул урында бик күп кеше югалган, дип тә сөйлиләр. Бигрәк тә хатын-кызлар. Ни өчен дигәндә, Казанның иң атаклы фахешханәләре, притоннары, «тере товар» сатыла торган сутенёр «лавка»лары, бот-чатларын як-якка аерып, күкрәкләрен иләмсез рәвештә изүләреннән чыгарып куйган төнге күбәләкләр тезелеп киткән урам-тыкрыклары белән данлыклы икән ул. Мәүлетнең таныш-белешләреннән Миндиярның гына барганы булган бу бозык бистәгә. Аның сөйләве буенча белә дә инде ул әлеге «Җәһәннәм тишеген.»

Шунда барачак Мәүлет. Әгәр Иблис бар икән инде, әгәр дә ул зиначылыкның шайтани бер гәүдәләнеше икән, ике дә уйламыйча әйтергә була – нәкъ менә шул «Җәһәннәм тишеге»ндә булачак ул!

Ләкин Мәүлетнең көткәне акланмады. Әллә ничә транспортка утырып, очраган бер кешедән сораша-сораша бара торгач, көндезге намаз вакыты җитеп бетте. Әмма күз күреме җиткән тирә-якта мәчет манаралары күренмәде. Шулай да ул, очраган беренче бакча түренә кереп, аулак почмактагы киң эскәмиягә барып чүгәләде. Гөнаһлы җиргә барган кешене Ходай да өнәп бетермәде шикелле – Мәүлет кыйбла якны билгели алмыйча аптырады. Ничек булдыра алды – шулай хәл итте тагын. Тагын бер бәла – гомердә булмагаганча, намаз догаларын ялгышып бетте.

Шәһәрнең башка төбәкләреннән берни белән дә аерылмый торган иң гадәти урамнар буйлап шактый йөрде Мәүлет. Тик бозыклыкка, зиначылыкка, ягъни шайтан коткысына ишарә булырдай бер генә кешене дә, бер генә хилаф эшне дә, күренешне дә таба алмады.

«Җәһәннәм тишеге» дигән җирнең кеше сүзе, ялган риваять кенә булуына инанып бетә язган Мәүлет, кинәт исенә төшеп, мишәр Миндиярга шалтыратырга булды.

Миндияр башта ямьсез тавышлар чыгарып көлде. Аның: «Син тегендиме әллә?» – дигән соравы тагын да ныграк аптыратты Мәүлетне.

– Тагын бер чинасаң, трубканы куям. Мин бит синнән кешечә сорыйм. Син дә кешечә җавап бир.

– Бу турыда кешечә сөйләшеп була димени, ә, Мәүлет?

– Нәрсә хакында?

– Кешелектән чыккан кыз-хатыннар хакында.

– Монда андый хәл күренми әле.

– Күренмәячәк тә. «Җәһәннәм тишеге»ндә тормыш төнгә кергәч кенә башлана. Шуңа да көләм. Аннары...

– Нәрсә аннары?

– Кызлар кирәк дигәч тә. Шунда кадәр барып йөриләр димени?!

– Син нәрсә, Миндияр?! Мине монда кызлар җитмәгәнгә килде дип уйлыйсыңмы әллә?

– Шулай дип уйлыйм.

– Шулай дип уйласаң, бик нык ялгышасың. Мин монда Иблис токымын эзләп килдем, беләсең килсә.

– Иблис? Шулай бит әле. Берцәк кенә онытып йибәргәнмен, әзи, извини. Мунчадагы халләрдан соң әле дә көләсе килә.

– Менә шул, Миндияр, тиле дисәң дә, миле дисәң дә, син хаклы, ләкин мин үземә тапшырылган эшне үтәп чыгарга тиеш. Иблисне табарга тиеш.

– Синең Иблис дигәнең чын булып чыга, алайса? Ә чын булмаса? Көлкегә каласың бит, әзи?

– Калам. Тик нишлим? Мин моны тикшереп карый алмыйм. Ә чын булса? Бу Иблис токымы кешелек дөньясына бәлаләр китерә башласа, аны газапларга салса, бозыклыкка һәм имансызлыкка дучар итсә?

– Тикшереп карап булмыйдыр шул. Изге гамәл дисең инде? Алайса, хәзер килеп җитәм. Беркая да китмә, шул баскан урыныңда тор. Бераздан ул «җәһәннәм»гә җан керәчәк, үзең күрерсең. Кара аны, шушы бер сәгать эчендә алдаткыч тозакларга эләгә күрмә!

– Анысы нәрсә тагы?

– Нәрсә дип... Давай, баргач аңлатырмын. Сөйләргә озак. Аннары не

телефонный разговор бу. Беркая да китмәсәң, беркемне дә тыңламасаң, тәртип булыр. Әзи, ишетәсеңме мине?

– Ишетәм-ишетәм. Аңладым, Миндияр. Рәхмәт.

– Рәхмәте соңыннан. Хәзер мине тыңла. Мин әйткәннәрне онытма.

Мәүлеткә җан керде. Ул тәмам тынычланып җитте. Бер кафега кереп капкалап чыкты. Аның белән бергә кафедан бер кызый чыкты. Гади генә киенгән. Йөзгә дә ябык, тыйнак, киемнәре дә өр-яңадан түгел. Мәүлет аңа игътибар да итмәс иде. Ул кыз, Мәүлет ишек ачып чыгарганда, шундый итеп карады, бу күз карашы йөрәк-бәгырьләрне үтәли тишеп, җан-күңеленең иң нечкә кылларына кереп сарылды. Үтә дә мөлаем, үтә дә тәэсирле, хәтта бераз шаукымлырак та иде бу караш. Ни өчен шаукымлымы? Мәүлетнең бу кыздан аерыласы килми иде. Бу карашны югалтса, нидер булыр кебек иде. Шуңа да ул кыз артыннан иярде. Озатып кына киләм, әле бер сәгать вакытым бар, дип уйлады ул. Сәбәп тә табылды – кызның кулында зур төенчек бар иде. Куып җитеп, ул кыз кулындагы төргәкне җәһәт кенә эләктереп алды.

– Ой! Шундый куркыттыгыз! Үләм дип торам.

– Мин дә үлемнән чак калдым бит.

– Менә кызык. Ничек?

– Шундый итеп карадыгыз. Прәме йөрәккә тиде. – Мәүлет үзен бу кадәр тәмле телле дип уйламый иде. Менә нишләтте аны очраклы бер очрашу. Ай-һай, сәер бу. Ай-һай, серле.

– Алдыйсыз инде, беләм. Шулай да, бу юлы сезгә ышанасы килә.

– Ышаныгыз, зинһар. Бу юлы мин дә алдамыйм.

Күренеп тора: икесенә дә рәхәт иде бу минутта. Алар, күптәнге танышлар кебек сөйләшә-сөйләшә, якындагы ишегалдына барып керделәр.

– Шулай да, әйт әле, нигә шулай карадың син миңа?

– Карадым шул. Бу якларда синең кебек кешеләр бик сирәк йөри бит.

– Мин нинди соң?

– Синме? Син... Син... Бик тә тәрбияле, чиста күңелле, ихлас кеше кебек күрдем мин сине.

– Нигә кебек дисең, мин шундый ук кеше. Һәрхәлдә, моңа кадәр беркемгә дә зыяным тигәне юк. Үземнән кала.

– Ничек инде? Үз-үзеңә зыян итеп яшисеңмени?

– Шулай дисәң дә ярый. Үз башыма мәшәкать эзләп яшим бугай мин. Менә монда да шул белдеклелегем аркасында килеп эләктем бугай.

– Мин берни дә аңламыйм, кем дип әйтим?

– Мәүлет булам мин, ә сез?

– Магия. Татарчасы – «Маһия». Бөтен кеше дә Магия дип йөртә, шул исемгә үзем дә күнектем инде. – Маһия тыйнак кына, әмма үз йөзенә, үз күзләренә килешле итеп елмаеп куйды.

– Юк, мин сезгә Маһия дип дәшәчәкмен. Магия – сихер, шаукым дигән сүз. Тылсым дип тә әйтергә буладыр, әмма Магиядә сихер барыбер күбрәк, минемчә.

Шунда Маһия-Магияне алыштырып куйдылармыни – ул кинәт кенә күңелсезләнеп, боегып калды. Хәтта картаеп киткәндәй булды. Юкса аңа утыз яшьләр чамасы гына бирергә мөмкин.

– Бирегез төенчегемне. Рәхмәт, хәзер инде үзем дә кайта алам.

Маһиядәге үзгәреш Мәүлетне тамчы да каушатмады. Ул, киресенчә, тагын да батыраеп китте:

– Юк-юк, мине сезне өегезгә кадәр үк озатып куям. Кереп үк тормам, ирегез алдында кыен, ну да ләкин кайда яшәвегезне белеп китәм.

Шунда Маһия кырт борылды да Мәүлетнең җанын өшетерлек итеп, үзәгенә үткәзеп әйтте:

– Сез башкалардан берни белән дә аерылмыйсыз икән. Ә мин бөтенләй башкача уйлаган идем. Гафу итегез, миңа китәргә кирәк.

– Туктагыз әле, иң хәтәр җинаятьчегә дә соңгы сүзен әйтергә вакыт бирәләр, әлегә мин җинаятьче түгел кебек, соңгы сүзне әйтергә ярыйдыр ич? Ә, Маһия?

– Тыңлыйм.

– Сез миңа шундук ошадыгыз. Шундук күңелгә кереп утырдыгыз. Ачуланмагыз, мин бүген үземне үзем дә аңламыйм. Әллә нәрсә булды шунда. Сезне югалтасы килмәгәнгә шулай үҗәтләнәм бит мин.

– Сез үзегез миңа ачуланмагыз, зинһар. – Маһия тагын элеккечә тыйнак елмаеп куйды. – Әллә нәрсәләр уйлый яздым, әлбәттә, сез әйбәт кеше, күзегездән күренеп тора.

– Мин дә сезне күзләрегезгә карап аңладым бит.

– Ай-һай, аңладыгыз микән? Ярый, алайса, озатыгыз. Тик минем тормыштан көлмәгез генә.

Мәүлет ул кадәренә үк өмет итмәгән иде. Тормышына ук чакыра түгелме соң бу сихер-тылсым иясе? Иблис эзләп йөрисе урында кая бара соң ул бу минутта? Бара шул. Бара икән, димәк, шулай кирәк. Тәкъдиргә, дөньяга, күңелгә шулай кирәк. Кем белә, бәлки ул бүген язмышын, мәхәббәтен табып куяр?

Бик тиз барып җиттеләр. Сөйләшмәделәр. Һәрберсенең үз уе уй булды, ахры. Подъезд төбенә килеп җиткәч кенә, Маһия әйтеп куйды:

– Артык шауламыйк әле, кеше күзенә күренәсе килми.

Мәүлетне иң аптыратканы шул булды: икенче катка менеп, ишек төбенә килеп басу белән, Маһия өч тапкыр кыңгырау төймәсенә басты, үзе шундук ачкычларын алып, ишек ачарга тотынды. Мәүлет бу хакта сорарга өлгергәнче, хатын эчкә кереп китте, аннары ялт борылып, кунагын алырга чыкты.

– Әйдәгез, узыгыз, хәзер чәй куям, сезнең бер сәгатегез хәзер үтеп китә ул. Кыенсынмагыз.

Ә үзе ничек кыенсына! Каушавыннан, ишек катындагы кечкенә өстәл өстендә яткан ишек ачкычын өч мәртәбә алып, өч мәртәбә кире куйды инде.

Мәүлет шунда тагын бер мәртәбә хуҗабикәнең йөзенә, буй-сынына игътибар итте. Өстендәге озын кофтасын салгач, ничек матураеп, зифаланып китте ул! Озын, кара чәчләрен дә таратып җибәргәч, болай да сылу, мөлаем йөзе тагын да яшәргән кебек булды.

Бер бүлмәле фатирда артык җиһаз юк иде. Түр стена буенда савыт-саба белән шыплап тулган сервант тора, аның янәшәсендә иске фасонда эшләнгән зур шифоньер урнашкан, алардан соң, ярты бүлмәне биләп, киң караваттүшәк сузылган. Мәүлет үзе дә сизмәстән: «Нигә монда бу кадәр түшәк?» дип уйлап куйды. Шундук дивардагы фотосурәтләрдән, төрледән-

төрле чөйләргә, караваt башларына эленгән кием-салымнан Маһиянең гаилә хәлен белдерердәй ишарәләр эзләргә кереште.

Аның уйларын укыгандай, Маһия үзе сүз башлады.

– Ирем юк минем. Балага узганны белгәч, суга төшкәндәй юк булды. Аннары эшсез калдым. Безнең бу тирәдәге халык шушы авиация заводы белән бәйләнгән иде бит. Ул завод ябылгач, бөтен бистә халкы эшсез, ризыксыз, өметсез калды. Кайда нинди әтрәк-әләм, бандит, шпана бар – шушы караңгы урамнарга кереп тулды.

Мәүлет артыгын сорашмады. Яшел чәй чөмерә-чөмерә тыңлады да тыңлады. Кайчакта гына бер үк сорау күңелен бимазалап куя: «Ничек яши соң бу мөлаем зат бөтен дөньяга даны чыккан тәмуг бистәсендә?» Аның бу каһәрле дөнья белән бернинди уртаклыгы да юк лабаса. Бу йөзнең, бу күзләрнең... Тагын шул күзләр... Җанны үтәдән-үтә теләә торган карашлар!.. Мәүлетнең кайдадыр күргәне дә бар кебек бу сихри карашларны. Тик кайда – һич кенә дә исенә төшерә алмый. Теге зәхмәт төшкере Иблис гаме аның бар булган хәтерен ялап алгандай юкка чыгарган, ахры.

Мәүлет китәргә җыенды. Тик өлгерә алмый калды. Ишек ягыннан кыңгыраунын яшелле-зәңгәрле черелдәвек тавышы яңгырады. Икесе дә сикереп тордылар.

– Кем бу? – Маһия, куркынып, Мәүлеткә карады.

– Кем бу? – Мәүлетнең соравы табигый иде.

Ә менә Маһиянең ни өчен шул ук сорауны бирүен Мәүлет һич кенә дә аңлый алмады. Аның өе, аның кунагы лабаса, ул да белмәгәч, кем белер?

Маһия ишеккә таба китте. Аяк очларына басып, ишеккә уелган пыяла күзгә карап бакты. Һәм шунда ук йөзен ишектән тартып алды.

– Иблис җан! Тагын килгән. Нәрсә җитми инде аңа, бүген ял итәм, дидем бит?.. – Хатын шундук өстен-башын рәткә китерә башлады, ашыгып-кабаланып, иреннәренә иннек, бит очларына кершән якты.

Ишек артындагы кеше кире китәргә теләмәде, шалтыратты да шалтыратты.

Мәүлет, һични аңламыйча, үрә катып тора бирде. Аңламаса да, сизенә иде – нindидер сәер хәлләр бара монда. Бу хәлләрнең бер дә яхшыга булмавын да тоя иде. Тик берни дә эшли алмый. Шулай да бу минутта нindидер шомлы, әмма шул ук вакытта шактый өметле уй аның күңелендә чәбәләнә башлаган иде инде: «Иблис җан», – диде бит. Димәк, бу хәсис кайдадыр якында гына. Сак һәм сизгер булырга кирәк.

Маһия, йөз-бите белән эшен бетереп, кабат ишеккә омтылды. Ул шунда гына нишләргә белмичә басып торган Мәүлетне шәйләп алды.

– Син?.. Син менә монда утырып тор. Курыкма – анда инде берәү бар. Ачуланма берүк – шулай кирәк булды. Телефоның булса – сүндер...

Маһия дивар буендагы олы шифоньер-шкафның ишегенә барып тотынды, яңагын куеп тыңлап карады, аннары акрын гына шакылдатырга кереште. Ул арада шкаф эченнән нindидер шыбырдау тавышы ишетелде. Менә эчке яктан чыкылдап, келә күтәрелде, бераздан шифоньерның бер як ишеге каерылып ачылып китте. Мәүлет эчкә кереп урнашуга, ишек кабат ябылды. Дөм караңгы дөньяга күзе күнеккәнче, ул иң элек тыштагы тавышларга игътибар итте. Әнә, Маһия ишеген ачты. Кемдер, атылып-бәрелеп диярлек, эчкә килеп керде. Килеп керде дә хуҗабикәгә ябырылды:

– Син нәрсә? Ярты сәгать буе ишек төбендә тотасың? Син минем табанымны үбәргә тиеш! Урамда каласың киләме әллә? Урамга чыксаң – сине шундук ботарлап ташлаячаклар бит. Балаңны кем карар? Ә? Нигә дәшмисең? Дәшәрлегең юк шул.

– Хасисә апа, кичерегез.

– Кичерәм, кичерәм. Тагын кичерәм инде. Тик син моның өчен берьюлы ике клиентның күңелен күрергә тиеш буласың. Бүген үк, хәзер үк!

– Ике кешенең? Хасисә апа, мамка.

– Дәшмә! Шушы бүрек кадәр йодрыгым белән авызыңны томаларга да күп сорамам.

Шифоньер ишегенә уелган кечкенә тишектән ургылып кергән яктылыкка күнегә башлаган Мәүлет иң элек каршында пәйда булган ике ут чаткысын чамалап алды. Җеннәр эшеме бу? Әллә җеннәрнең үземе? Бу хәлләрдән Мәүлетнең йөрәге ярыла язды. Ләкин моннан соң күз алдында пәйда булган күренештән аның җаны бөтенләй очып чыгып китә язды. Очмаслык та түгел шул – караңгы шкафның аргы почмагында очкынланып янган күзләрен «чалт-чолт» йомгалап, 5-6 яшьләрдәге малай утыра иде!

Мәүлет, бөтен хәлен, көчен җыеп, сорау бирә алды, шул сорау аны акылдан язудан коткарып та калды:

– Син кем?

Теге малай да Мәүлеттән күрмәк, пышылдап җавап бирде:

– Рамил.

– Син каян?

– Әниемнән.

– Ә-ә... Син Маһиянең малаемы әллә?

– Малае.

– Монда нишләп утырасың?

– Ә син нишләп утырасың?

– Качып утырам.

– Мин дә качып утырам.

– Кемнән?

– Синнән. Әнием кушты. Безгә кунаклар килгәндә, мин гел шулай итәм.

– Курыкмыйсыңмы соң?

– Куркам. Ә син?

– Башта курыккан идем, хәзер курыкмыйм.

– Хәзер мин дә курыкмыйм инде.

– Тс-с!.. Әйдә, сөйләшмик... Тыңлыйк әле.

Ә анда – бүлмә эчендә – Маһия шыңшып елый иде. Теге «Иблис җан» булып кергән хатынның карлыкканрак тавышы колакларны ярып керә:

– Шундук әйтеп куям – әрмәннәр. Алар икәүләп бер хатын-кыз белән күңел ачарга яраталар. Сәерлекләре бар, диләр. Бер теләкләренә дә каршы килмә. Дәшмә, күз яшеңне дә чыгарасы булма! Еласаң, җеннәре-шайтаннары котырына башлый, ди. Ишетсен колагың! Не подводи! Ун минут вакытың бар. Мин киттем. Менә монда ризыклар, менә – акча.

Көтелмәгән кунак чыгып китүгә бүлмә эчен үлем тынлыгы басты. Шкаф эче дә тын иде. Тышкы яктан Маһиянең үксеп елавы ишетелә башлагач кына, Мәүлет тышка чыкты, аңа малай иярде.

Мәүлет Маһияне ничек юатырга да белмәде, кухня өстәленә маңгаен куеп, ачыргаланып елаган хатынның хәлен аңлый иде, шуңа да дәшмәде, бары тик янында басып торган малайның башыннан сыйпап тик торды.

Менә бермәлне Маһия башын күтәрде, шешенгән күзләре белән Мәүлеткә туры карап, җикеренеп диярлек эндәште:

– Бар, чыгып кит бу җирәнгеч дөньядан! Бүтән күренәсе булма күзләремә! Ымсындырып йөрмә җанымны! Иблис кирәк идеме сиңа? Менә кайда ул Иблис оясы! Әнә – әле генә чыгып китте ул шайтан сыңары. Бөтен тирә-якны шул Хасисә карчык үз кулында тота. «Мамка» диләр аны. Ялгызы калган, ярдәмчесез яшәгән бер генә хатын-кызга да рәт юк монда. Бөтенесе сатылган, бөтенесенә түләнгән. Ә ничек яшәргә соң? Нәрсәгә яшәргә? Нәрсә хакына? Кем хакына? Менә шушы малай хакына. Аның ярты гомере шушы караңгы шкаф эчендә үтә. Син шуны беләсеңме? Ә? Ник дәшмисең? Бар, хәзер үк чыгып кит, зинһарлап сорыйм. Миңа әзерләнергә кирәк. Иң әшәке сәгатьләремә әзерләнергә кирәк.

Мәүлет лаякыл исерек кебек ишек яңагына бәрелә-сугыла чыгып китте. Баштарак ул кая барганын да белмәде. Аннары килеп җитәргә тиешле Миндиярны исенә төшерде. Хәбәрләшер өчен телефонына үрелде. Тик аның телефоны теге котсыз-караңгы шкаф эчендә калган иде.

Мәүлет кая барырга белмичә туктап калды. Аның башында бер уй өлгереп килә иде: «Әгәр ул Маһия янына киләчәк әрмәннәрнең юлын бүлсә?» Барыбер Миндиярны таба алмаячак. Ә болай... Хет бер бала анасының язмышын саклап калачак.

Йөгерә-атлый барып җиткәндә, кара-тут йөзле ике кеше подъезд ишегенә барып тотынганнар иде инде. Ләкин аларга ишекне ачып керергә насыйп булмады.

Теленә каян килеп кергәндер – Мәүлет гомерендә беренче күргән бәндәләрдән: «Тартырга бармы? Тартырга булмаса, эчәргә бирегез», – дип сорамасынмы?.. Үзе дә аптырады: Иблис эзли-эзли, ул үзе дә шайтан кыяфәтенә кереп бара, ахры.

Алар бик озак әүмәкләштеләр. Читтән карап торган кешегә кемнең кем белән сугышканын һич аңларлык түгел. Икесенең дә изүенә ябышкан Мәүлетне теге кара кешеләр берничек тә үзләреннән аерып алып ташлый алмыйлар иде. Юньләп суга да алмыйлар. Шулай да, бераздан Мәүлетнең хәле бетә башлады. Менә ул авыр итеп аһылдап куйды да, затлы күн плащ якаларына ябышкан бармакларын бушатып, җиргә ауды.

Хәлсез, җансыз гәүдәне бик озак типкәләделәр. Мәүлетнең җаны чынлап та очып чыгып киткән булгандыр. Очмаса, бу кадәр тукмауга түзәр иде микән? Юк-юк, очмаган икән. Әнә бит, ара-тирә ул, тамагы белән түгел, җаны-күңеле белән иңрәп ыңгырашып ала.

Бераздан теге ике ир дә арды. Алар, каяндыр көзге чыгарып, җимерек йөзләренә, ертылып беткән күн киемнәренә карап алдылар да, кара кан катыш җир пычрагына буялган подъезд ишеге ягына кул селтәп, караңгылык эченә кереп югалдылар.

Мәүлетнең җаны, чынлап та, үз урыныннан купкан иде. Ләкин аның тәненнән аерылып та китә алмыйча, төш дөньясына эләгеп калган иде. Ә төшендә таныш йөз-чырай. Шундый да мөлаем, саф-пакь, изге сурәт. Хәтта үтә күренмәле. Рухларда гына була торган якты, әмма шомлы нурланыш.

Тукта, каян таныш соң ул Мәүлеткә? Каян булсын, төшендә! Төшендә күрә торган Хозыр-Ильяс ләбаса бу! Әнә ул, иелеп, Мәүлеткә нидер дәшә, тик аның тавышы чыкмый. Беренче мәртәбә дә шулай тавышсыз гына сөйләшкән иде. Ул вакытта имче кыз «телен ачкан» иде. Бу юлы аның телен кем ачар? Әйтәсе сүзе бик мөһимдер шул. Бу кадәр җанга үтеп карамас иде. Бу кадәр борчылмас иде. Борчылган, димәк, Мәүлет белән нидер булган. Ниндидер начар хәлгә тарган ул. Күрәсең, бу хәл аны изге максатыннан ерагайта бара – әнә бит, хәтта изгеләр дә тынычлыкларын югалткан.

**12**

Бу юлы ул Хозыр-Ильясның тавышын аермачык ишетте. Ул үзе күренми, ә менә тавышы, моңлы аһәң чыгарып, яңгырый да яңгырый.

– Син нишләдең, малай, ә? Каян килеп эләктең бу гыйбрәткә? Бу гөнаһлы җиргә, кан-яшьтән торган дөньяга ничек эләктең?

Мәүлетнең телен язарлык түгел, кыл кыймылдатырлык та хәле калмаган, ә шулай да иң мөһим нәрсәне онытмаган:

– Теге Иблис кайда? Якын җибәрмә син аны! Ул кешеләрнең бәгырен кимерә, җанын ашый. Мин аны күрдем.

– Каян килсен монда Иблис? Акылыңдамы син?! Тор, әйдә кайтабыз.

Тукта, кем тавышы соң бу? Хозыр түгел, монысы хак. Таныш тавыш. Тынгысыз мишәр! Шул, шул! Миндиярдан башка кем булсын?! Ник күренми соң ул үзе? Ник кача? Әллә ул да Иблистән куркамы?

Көчкә эзләп таптым. Кафеда сине бер кыз артыннан китте, димәсәләр, ул кызның кем икәнлеген, кайда яшәвен әйтмәсәләр, шушы каһәрле почмакта җан очыра идең бит, әзи.

Менә хәзер Мәүлет барысын да аңлады. Хәзер күзләрне ачарга да ярый. Ләкин күңелне ачарга кирәк түгел. Аны шыплатып ябып куярга да, бүтән ачмаска! Берничә минут элек кенә булган әрнүле вакыйгаларны башкача искә төшермәскә!

Баягы кафега кереп, озак кына утырдылар. Аңарчы шул кафеның юыну бүлмәсендә Мәүлетнең шешенгән йөзен, күгәргән кулларын салкын су белән чылаттылар, маңгаеның тап уртасында пәйда булган ай-җәрәхәтне бәйләделәр.

Сүз сүзгә ябышмады. Әмма бу сөйләшү Мәүлеткә бик кирәк иде. Төнге вакыйгаларны онытып торыр өчен булса да кирәк иде. Шуңа да ул баштан ук сүз җебен үз кулына алды:

– Беләсеңме, Миндияр, мин ялгышканмын. Иблис дигән хәшәрәт бу якларда яшәмидер ул.

– Нигә алай дисең?

– Мин аңладым: бозыклык кешенең юньсез булуыннан гына килми. Бозыклык, зиначылык артында гөнаһлы уйлар, сатлык хыяллар гына түгел, яшәргә омтылыш, киләчәккә өмет һәм иманлылыкка сусау да бар. Бүген төнлә мин чынлап та иманлы бозыклык, гөнаһсыз зина күрдем.

– Бәлки, бозык иманлылыктыр?

– Юк-юк, нәкъ менә иманлы бозыклык. Маһия исемле ул, тәнен сатып көн күрүче татар хатыны. Ә бит мин аңа гашыйк була яздым. Күзләрендәге сагыш артында нинди язмыш торуын күреп бетермәдем шул.

– Ну, дальше? Син гашыйк булдың, ә ул урамга куып чыгардымы?

– Куып чыгарды шул. Кая кергәнемне белмичә кердем, үзем гаепле.

– Да-а... Аптыраттың син, брат, мине... Мишәрне аптыраткан кеше дә булыр икән.

– Аптыратты, ди... Мин үзем аптырадым әле монда. Менә син шкаф эчендә яшәгән берәр малайны беләсеңме?

– Нәстә? Син теге ниме әллә? Ычкындыңмы?

– Ә мин беләм. Маһиянең малае ул. Бераз вакыт аның янында шул караңгы шкафта утырырга да туры килде.

– Слушай! Ташлале шул әкиятеңне! Хәзер нишлибез – шуны әйт син?

Мәүлет гүя аны ишетмәде дә. Ул бу минутта үз-үзе белән сөйләшә иде.

– Шундый да акыллы ул. Шул яшендә миңа караганда акыллырак. Ни өчен дигәндә, миңа караганда да күбрәк күргән ул, күбрәк кичергән... Ә иң мөһиме, иң аптыратканы – үзе клиентлар кабул иткәндә, аны дөм караңгылыкка ябып тотса да, әнисен шундый ярата. Боларны күрсәң, син акылдан язар идең, билләһи! Мин дә язар идем, теге ике әрмән булмаса.

– Ярый әле күрмәгәнмен, синең белән булсам, мине дә типкәләп ташларлар иде.

– Ә мин үкенмим. Кыйнадылар кыйнавын, әмма миңа рәхәт кенә. Мин хәтта бәхетле. Аларның юлына аркылы төштем бит мин, Маһиянең тәненә дә, җанына да якын җибәрмәдем.

– Шуннан ни? Ә иртәгә? Иртәгә тагын шул кәсебенә керешәчәк бит ул. Тагын тәнен сатып көн күрәчәк! Тамак хакына теләсә нинди ирнең астына ятачак. Шайтан коткысы бер эләксә, тиз генә котылам, димә!

– Юк, иртәгә ул инде бүтән кеше булып уяначак.

– Как так?

– Чөнки бүген ул мине күрде. Ә мин аны. Безнең арада нидер булды. Шуңа да без инде бүтән кешеләр.

– Ә Иблис белән нимә кыласың соң? Проблема-то кала!

– Күрдем мин ул Иблис җанны, Хасисә исемле «мамка»ны. Иблиснең үзе үк булмаса да, аның хәшәрәт сакал төкләрен күп ашаган ул.

– Беләм мин аны. Мондагы бөтен кызлар аның кулында. Мин сине шул пәри хатыны белән таныштырырга уйлаган идем дә инде.

Ул арада кафега шаулап, өч хатын килеп керделәр. Икесе яшьрәк, чандырлар, уртадагысы – юантык-тазарагы, шактый «төшереп» алганы – башлыклары булса кирәк, ул җикеренеп куюга, теге чандыр хатыннар шундук шым булдылар, аның күңелен күрү чарасына керештеләр. Менә алар, алпан-тилпән килеп, түргә уздылар, каршыларында очраган урындыкны аударып, буш өстәл артына барып утырдылар. Шунда Мәүлет танып алды – бая телдән төшмәгән Хасисә бит бу! Шул сутенёрша «мамка»! Шайтаный зат! Иблис токымы!

– Менә сиңа мә! Ныклап уйласаң, күз алдына килә, диләр иде, дөрес икән. Әнә ул теге Иблис токымы... – Мәүлет, үзенең барлыгын сиздермәскә теләгәндәй, костюм якаларын күтәреп, исерек хатыннар утырган өстәлгә аркасы белән борылды.

– Әһә, куркасыңмы?! – Миндияр, киресенчә, бу минутта тантана итә иде. – Хәзер белеп киләм – Иблис җанмы ул, әллә гөнаһсыз фәрештәме?

Һа-һа-һа!.. – Тешләрен ыржайтып көлеп торган Мәүлеткә бөтен кафе халкы борылып карады.

Менә бервакыт Миндияр үзенең утырган урындыгын кискен кубарып алды да баягы исерек хатыннар янына китте. Ул шунда ук алар белән уртак тел тапты, ахры, шау-гөр килеп сөйләшә дә башлады. Мәүлет бераз вакыт йөз-бит яраларын сыйпаштырып утырды да, әллә йөрәгендә кайнаган нәфрәтеннән котыла алмыйча, әллә кызыксынуын баса алмыйча – үзе дә аңлап бетермәде, аның артыннан Мәүлет иярде. Ул барып җиткәндә, Миндияр яңа танышларына кызып-кызып, нindiдер оятсыз мәзәк сөйли иде.

– Кайтып керсә, ни күрсен – үзләренең бозык эшләреннән соң, ах-ух килеп, ире шкафта, сөяркәсе караватастында ята, һа-һа-һа...

Хатыннар көлмәде. Бигрәк тә таза гәүдәле хатынның – Маһияне әрмәннәр астына салырга теләгән Хасисәнең – кәефе юк иде бугай, – әнә бит, чөмәкәй эчемлек салынган стаканны кысып тоткан килеш аракы сөременнән тоныклана башлаган, гыйбрәтнең дә гыйбрәте булып күренгән күзләрен акайтып, әле Миндиярга, әле Мәүлеткә карап, тик утыра. Борын астындагы эре сирәк мыегы белән ияк очындагы бер тотым сакалы бик сәер тоелса да, уң күз төбенең кара янып торуы аның табадай киң, килбәтсез йөзенә табигый килешеп тора иде.

Бераздан Миндияр бу хатыннарга тәмам үз кеше булып китте, ахры, кыю-кыю гына сүзләр дә ычкындыра башлады:

– Менә әйт әле – син ниме?.. Иблис белән туган тегелме?

– Иблис? Кем ул? Нишләп мин аны белмим? – Хатынның карлыккан тавышында әллә нинди авыр язмыш аһәңнәре яңгырый иде...

– Белмисең? Тут что-то не то... – Миндияр, Мәүлеткә таба борылып, җилкәләрен сикертеп алды. Аннары кулларын болгап, бармакларын күккә төбәп, Хасисә-«мамка»га кызып-кызып аңлатырга тотынды:

– Иблис ул – кешеләрне кешелектән чыгару өчен күкләрдән сөрелгән фәрештә, белдеңме? Баштарак ул Аллаһның яраткан мәләге булган, аннары, тәкәбберләнеп, баш бирми башлаган. Зазнался, значит. Шуннан соң аны Аллаһы Тәгалә күктән җиргә сөргән. Ә бит Иблис төшкәнче кешеләр тату яшәгәннәр. Теге юньсез аларны боза башлаган – аракы эчәргә, зина кылырга өйрәткән. И так далее... Шулаймы, әзи?

– Ну, шуннан? Мин тут при чём? – Хасисә Миндиярның сөйләгәннәренә битараф калды.

Миндияр кабаттан аңлатырга кереште:

– Иблис кешеләрне бозарга җибәрелгән, дим бит. Син дә шуны эшлисең түгелме? Күпме кешене, күпме кыз-кыркынны, кыз-хатынны юлдан яздырасың, дөресме? Ходай тарафыннан адәм балалары бер-берсен яратыр өчен яратылган, ә син бер кешене икенче кеше астына көчләп саласың.

– Тукта!.. Хәзер мин сөйлим. Әйт әле – син мине күпме беләсең? Өч ел? Биш ел? Сиңа берәр зыяным тигәне булдымы? Юк? Ә сиңа? (Мәүлет башын читкә борды.) Шулай булгач, инде дөрес сөйләмисең. Ә кызларга килгәндә... Алар үзләре мине сайладылар. Бу эшне оештырырга үзләре сорадылар. Миңа кадәр алар урамга да чыга алмыйлар иде. Йә түләмичә көчләп китәләр, йә кулдан-кулга сатып җибәрәләр. Җаннарын алырга да күп сорамыйлар. Хатын-кызның бәясе бер тиенгә тормаган чак иде

ул. Ә мин утырып кына чыккан. Курыкмагыз, кеше үтереп утырмадым. Ашарга бер тәгам ризык калмагач, бала хакына дип, кибеттән бер бәйләм колбаса суккан идем. Өч ел утырып чыктым. Чыккач та татыдым мин яңа тормышның бөтен тәмен. Бер җиргә эшкә алмыйлар. Эш булмагач, пропискага кертмиләр. Бераз авторитет бар барын. Утырып чыккан хатын-кызны хөрмәт итә иде ул вакытта «блатной» халык. Кеше арасында сүз үтә. Анысы, үземә дә күп эләкте вакытында. Хатын-кызлар төрмәсендә «мужик» иттеләр, менә, йөз-битне кырып бетерделәр. Төрмәдән чыккан көнне үк биш ир тотып көчләде. Чак-чак аякка бастым. Мин ябылып ятканда, унбиш яшьлек кызымны да җәберләп үтергәннәр. Йә, әйт, кем монда Иблис? Минме? Әйе, «мамка» диләр мине. Мин бүген күп кешенең әти-әнисен алыштырам. Аларга эш бирәм, яшәрлек акча, ашарга ризык бирәм. Эшем мактанырлык түгел анысы, мин моны таныйм. Тик... башка эш юк бит! Заводларны ябып бетергәч, халык урамда калды, үзең дә беләсең. Бигрәк тә хатын-кызларга төште тормыш авырлыгы. Кайберләренең ирләре эчеп үлде, кемдер читкә качты, кемдер төрмәгә кереп котылды. Шушы әшәке дөньяда, сабыйларын кочаклап, хатын-кыз ялгыз калды. Юк, уйламагыз да, мин яшь кызларга кагылмыйм. Аларның үз иманнары. Үз исәп-хисаплары. Мин аларны, гомумән, аңламыйм. Алар мохтаҗлыктан түгел, күбрәк рәхәтлек эзләп керәләр бу кәсепкә. Юри белешеп кара: урамда торган кызларның күбесе тулы гаиләдән, җитеш дөньядан. Алар акчага мохтаҗ түгел. Кайберләре үз точкаларына машиналарында килә хәтта. Беләсеңме, аларга җан тынычлыгы түгел, тән ләззәте кирәк, тормыш мәшәкатьләреннән онытырырлык язмыш маҗаралары кирәк. Миңа алар кызык түгел. Минем тормышта да, язмышта алар өчен урын юк. Мин бернинди ризыксыз, ярдәмчесез калган хатыннарга гына булышам. Йә, әйт – шуннан соң мин Иблисме?

– Иблис! Син – Иблис! Кичә бер хатынны ике әрмәнгә биреп талата яздың! Ә аның кечкенә баласы бар, между прочим! – Үзен-үзе дә белештермичә, хәтта бераз ярсынып, сүзгә Мәүлет кушылды.

– Ә-ә, син аны әйтәсеңме? Каян беләсең? Каян гына белсәң дә, барысын да белмисең шул. Тукта-тукта, кичә син бәйләнеп булаштыңмы әллә аларга?

– Мин... Мин ул әшәкелеккә юл куярга теләмәдем.

– Бу җәрәхәтләрең дә шуннан калган алайса? Аларның куллары каты шул. Менә минем биткә дә төшеп калды «әрмән мөһере».

– Ничек? Сине дә кыйнадыларммы?

– Алар хаклы, түләнгән эш эшләнергә тиеш. Магиянең эшен миңа башкарырга туры килде. Шул гына.

– Ачуланма, мин сиңа начарлык теләмәдем. – Мәүлеткә ни өчендер кыен булып китте. Ул гафу үтенергә дә җыенган иде, Хасисәнең карлыккан тавышы ниятеннән баш тартырга мәҗбүр итте.

Мәүлет тыңласа да тыңлады, тыңламаса да тыңлады. Бу мәлдә аның уйлары бөтенләй башка якка юнәлгән иде инде.

– Хасисә... Мамка... Шулай дисәм, ярыймы? Минем сиңа бер сүзем бар. Син бүтән беркемне дә китермә Маһия янына, яме? Мин аны үзем шефлыкка алам. Үзем ярдәм итәм...

– Син аның кеме соң?

– Беркеме дә түгел.

– Булмагач, сүз озайтуның мәгънәсе дә юк.

– Мин аның яхшы танышы, без инде аңлаштык дип уйлыйм. Зинһар, миңа бир аны, миңа калдыр.

– Ярар-ярар, сиңа булыр. Мин бит шат кына. Тик кара аны, рәнҗетә башласаң, әрмәннәр кебек битеңнән сыйпап кына калмам, каты минем кулым. – Хасисә Мәүлетнең күз алдында ирләрнекенә тиң килбәтсез йодрыгын уйнатып алды.

Бераз тын утырдылар. Мәүлет тирә-ягына каранды. Төнге кафеда кеше азайган. Кереп-чыгып йөрүчеләрне исәпкә алмаганда, өч исерек ир белән, бер почмакка посып, эшләп алган акчаларын санап утыручы ике «төнге күбәләк»тән башка кеше юк. Урамда нindидер шау-шу. Кемнәрдер әле бер якка, әле икенче якка йөгереп уздылар. Нindидер разборка бара, ахры. Хәзер үк урамга чыгарга ярамас.

Тагын бераз вакыт узды. Бу вакыт эчендә Мәүлет Маһия һәм аның малае хакында уйланды. Хәзерге минутта нишлиләр алар? Ни-нәрсә булганын аңладылар микән? Мәүлет дигән яңа танышларын истә калдырдылар микән? Онытмаслармы? Иртәгә кич Мәүлет аларга килеп кергәндә танырлармы? Кабул итәрләрме? Үз яннарына, җаннарына алырлармы?

Ниһаять, Мәүлет белән Миндияр дә кузгалырга булдылар. Шактый төшереп алган Миндиярны кайтырга күндерү җиңел булмады булуын, әмма, бер кузгалгач, ул кабат утырмады, Мәүлетне этә-төртә, ишеккә юнәлде.

Инде торып китәм дигәч, Мәүлетнең чабуыннан тарттылар. Хасисә икән. Аның сарык башы хәтле кулы һәм тышкы якка бүлтәеп чыккан тома күзләре икән!

– Тукта! Син эзлисеңме Иблисне?


Мәүлет ни әйтергә дә белмәде. Чөнки ничек кенә җавап бирсә дә, ул җавап дөрес булмаячак. Шулай да, тизрәк җавап бирсәм, тизрәк кузгалып китеп булмасмы, дигәндәй, тотлыга-тотлыга сөйләнергә кереште:

– М-м-м... Мин, әйе... С-с-с... Син Иблис түгелдер бит?..

– Иблис кирәк булса, тыңла! Син аны унар, йөзәр мең кеше эшләгән завод-фабрикаларны яптыручылар арасыннан, аларның иярченнәре тирәсеннән эзлә. Иблис кенә берничә ел эчендә шулкадәр әшәкелек кыла аладыр үз бәндәләренә. Бөтен тормышны тузгыта аладыр. Күз алдында күпме кеше әрәм булды, әле күпме кеше әрәм булачак! Иблис коткысы әнә шунда – өстәге хуҗаларның очсыз-кырыйсыз, исәпсез-хисапсыз, мәгънәсез, кешелексез киңәшмәләреннән башлана.

Алар, очраган бер машинаны туктатып, мунчага таң сызыла башлагач кына кайтып җиттеләр. Миндияр нindидер көй шыңшый-шыңшый үзенә кереп китте, Мәүлет исә, тиздән килергә тиешле урам себерүче Шәмси картны көтеп, урамда калды.

*(Дәвамы киләсе санда.)*



Руслан
Сөләйманов

# БЕЗ – МЕҢ ҮЛЕП, МЕҢ ТЕРЕЛГӘН МИЛЛӘТ...

## Татар җыры

Җырлап киткән татар, җырлап кайткан,
Каян кайткан? Канлы сугыштан.
Ахры, Аллаһ үзе саклагандыр
Татарларны соңгы сулышта.

Кайталмаса яугир – җыры кайткан,
Аның батырлыгы турында.
Батырларча һәлак булды диеп,
Татар улы, сугыш кырында.

Бер уйласаң, татар улларының
Бар гомере – тоташ җыр сыман.
Җыр өзелсә – гомер туктап кала,
Җыр сузылса – яшәү бар сыман.

Менә тагын җырлар ишетелә.
Җырда шатлык, сагыш, игелек.
Җырда хикмәт – җыр яшәтә безне,
Татар җыры җирдә мәңгелек.

## Йөрәкләрдә чыңлый Чәрмәсән

Ерак сәфәрләрдә йөргән чагым,
Юлларыма чыкты якташым.
«Кушнареннанмы?» дип сорау бирдем,
«Әйе!» диеп какты чал башын.

«Ничек таныдың?» дип сорама да,
Белеп кал син, якташ, белмәсәң:
Кушнареннан чыккан кешеләрнең
Йөрәгендә чыңлый Чәрмәсән.

---

Руслан СӨЛӘЙМАНОВ (1985) – *шагыйрь, Башкортстан Язучылар берлегенең татар әдипләре секциясе җитәкчесе, мөгаллим; «Уйларымны салдым сандалларга» исемле шигырьләр җыентыгы авторы. Уфада яши.*

## Уфаны һәм сине сагынам

Сәфәрләрдә әгәр озак йөрсәм,
Уфаны һәм сине сагынам.
Бармы икән тагын Җир шарында
Минем кебек шашып сагынган?

Тәбәнәкме, биек йорттамы мин,
Син яшәгән йортны юксынам.
Шул йорттан да күркәмрәк булган
Уфаларда бер җир юк сыман.

Кыскамы ул, озынмы ул урам –
Икәү йөргән урам кадерле.
Исеңдәме, сиңа җырлаганым
Сөю җырын, таңга кадәрле?

Еракмы ул бакча, якындамы? –
Икебезгә уртак бит әле.
Без Уфада шунда күрдек тәүге
Шау чәчәккә баткан юкәне.

Сәфәрләрдә әгәр озак йөрсәм,
Уфаны һәм сине сагынам.
Әйтерсең лә, шушы гүзәл шәһәр
Бары синең өчен салынган.

## Җылылык

Кулларының җылылыгын тойдым
Күптән күрешмәгән кешемнең.
Дистә еллар буе шул кулларның
Җылылыгын тоймый өшедем.

Күзләренең сихәт нурын тойдым
Күптән күрешмәгән кешемнең.
Күңелемә тансык шул күзләргә
Сусаганмын, яңа төшендем.

Сүзләренең назлылыгын тойдым
Күптән күрешмәгән кешемнең.
Тавышының моңлы аһәңнәрен
Бер мизгелдә искә төшердем.

Күңел нурын, җан җылысын тойдым
Күптән күрешмәгән кешемнең.
...Тик югалып кабат юлларымнан
Бүлә күрмә татлы төшемне.

## Күзләр

Их, шул күзләр... Мине сүзсез итте,
Чуалттылар бөтен зиһенне.
Сине очратканчы әллә соң мин
Балык төсле телсез идемме?

Их, шул күзләр... Мине сихерләде,
Исерттеләр шәраб эчмичә.
Исән калу мөмкин микән хәзер,
Яннарыңнан синең китмичә?

Их, шул күзләр... Мине әсир итте,
Исәр итте тәүге күрүдән.
Хәзер менә үзем куркып йөрим,
Шул күзләргә күзләр тиюдән.

Их, шул күзләр... Тагын Җир шарында
Кемдә генә шундый күзләр бар?
Ярый әле шуны данлар өчен
Туган телдә асыл сүзләр бар.

Их, шул күзләр... Яшәү-үлем балкый,
Алар сөю назын тарата.
Шул күзләрне күреп туялмам күк,
Күз алмыйча гомер карап та.

## Сандугачым

Кума мине яннарыңнан,
Яныңа килдем тагын.
Сандугачым, киңәшеңә
Шулкадәр мохтаҗ чагым.

Хәсрәт төште башларыма,
Ни сайрарсың «чүп» тә «чүп»!
Чынлап чүп бөтен хәсрәтем,
Мәшәкатьләр бик тә күп.

Авырыймын өченче көн
Ни сайрарсың? «Түз» дә «түз»!
Мәңге килгән авыру түгел,
Килеп китәр тагын йөз.

Гашыйк булдым бер чибәргә,
Ни сайрарсың? «Үп» тә «үп»!
Син биргән киңәш-табышка
Рәхмәтләрем күптән күп.

Кума мине яннарыңнан,
Сайра, өздер, акыллым!
Ходай сиңа биргән икән
Аксакаллар акылын.

## Сукыр өмет

Эт халкына минем бер үпкәм юк,
Бөтенесе урап йөрделәр.
Теләкләре булса, курка-курка,
Капка асларыннан өрделәр.

Песи халкына да бер үпкәм юк,
Каралары юлны кисмәде.
Песи очратсам, юлым уңды,
Уңышларга һушың китмәле.

Кешеләргә генә үпкәм зурдан,
Утка салды, суга – кешеләр.
Сукыр өмет белән гомерем үтте
Кешелеклелек көтеп кешедән.

## Яка

*Без – бер күлмәкнең ике якасы.*
Альберт Борһанов

Тоталар да ябышалар
Шул күлмәк якасына.
Күпме михнәтләр кичердек
Без ятлар арбасында...

Берсе игътибар да итми
Таушалган төймәсенә.
Илем әйләнеп беткән бит
Милләтләр төрмәсенә.

Берсе игътибар да итми
Күлмәкнең укасына.
Татар, башкорт булу авыр
Бер дәүләт уртасында.

Берсе игътибар да итми
Мең ертылган җиңенә.
Күпме халык зур арбага
Ат урынына җигелә.

Берәр нәрсә була калса,
Ябышалар якага.
Әйтерсең дәүләт таркала
Безнең генә аркада.

Инде озак яшәрбезме
Горур башларны иеп?
Болай барса, бар да йөрер
Якасыз күлмәк киеп...

## Ясин чыгасызмы туган телгә?

Ясин чыгасызмы туган телгә?
Теләгегез бармы? Чыгыгыз.
Ясиннан соң бар бит савыкканнар,
Юк, соңгысы булмас җырыбыз.

Җеназаны бүген укыйсызмы?
Теләгегез бармы? Укыгыз.
Җеназада әгәр торып бассак,
Сез үзегез әле куркырсыз.

Кабер казыйсызмы туган телгә?
Теләгегез бармы? Казыгыз.
Без, татарлар, кабер туфрагыннан
Кубарыла гына алырбыз.

Без – мең үлеп, мең терелгән милләт,
Җир йөзенә күпләп таралган.
Сез үлсәгез, кабат терелү юк,
Дога сорарсыз бит татардан?!

## Медаль

Карт комиссар сабый баланың
Медаль сала нәни учына.
Шатлык булса иде, яшь ялтырый
Балакайның керфек очында.

«Еламале!» диләр зурлар аңа,
Тик еламый ничек тыелсын.
Алтын Йолдыз кеше алыштырмый,
Хет миллионлап күктән коелсын.

Үзе елый, үзе телгә килә:
«Медаль түгел, әткәй кирәк лә.
Олы булып, шуны аңламыйсыз,
Сездә, абый, юктыр йөрәк тә».

Карт комиссар шунда катып калды,
Дөрес сүзгә нәрсә әйтәсе?
Донбасс җирләрендә ятып калды
Шушы кызның Герой-әткәсе.

## Качак җыры

«Качам» дисең. Качып кара! –
Чикләрдә тотылырсың.
Бәргәләнгән җаның белән
Барыбер отылырсың.

Кешеләрдән качып була,
Үзеңнән качалмассың.
Үз намусың – төрмә сиңа,
Ишеген ачалмассың.

Намус тәрәзәләре дә
Пыяла түгел хәзер.
Тимер рәшәткә сугылган,
Сулкылдап куя бәгырь.

Илдән качып була да ул,
Син уйла кайтасыңны...
Качак булып озак гомер
Чит җирдә ятарсыңмы?

Үз илеңә җитәме соң,
Читләр якын итәрме?
Илнең чиген үтү белән
Башлар сөрген китәрме?

Бер афәттән качам диеп,
Тарыма яңасына.
Ятлар потлап тоз сибәрләр
Йөрәгең ярасына.

«Качам» дисең. Качып кара! –
Чикләрдә тотылырсың.
Шул мизгелдә тынычлыктан
Мәңгегә котылырсың.

## Фиргавеннәр заманы

Фиргавеннәр заманы бу,
Фиргавеннәр заманы.
Коллыкта яшәп түзәрлек
Һичбер әмәл калмады.

Кемнәрдер күкләргә чөя –
Чөеп котылып булса?!
Куллардагы богауларны
Җаһил ныграк кыса.

Кемнәр баш та күтәрәләр –
Кылыч кисә муенны.
Муса туып туктатырмы
Бездә барган уенны?

Кемнәр үлеп котылалар –
Соңгы чик күбесенә.
Сабырлыклар теләп үлә
Үлгәне тересенә.

Фиргавеннәр золымына
Чара тап инде, Ходай!
Югыйсә бит мин үзем дә
Фиргавен булам болай.

Фиргавенгә әверелгәч,
Мин тормамын үтенеп.
Халкымны азат итәрмен,
Үз-үземне үтереп.

## Шагыйрь колагы

Колакларым шәлперәйде, малай,
Юлны тоттым колак базарына.
Монда нинди генә колаклар юк,
Тагам берсен көннең азагына.
Сатучы әйтә: «Монысы – гайбәтчедән.
Аласыңмы, кыйбат булса да?
Алып җибәр бер дә үкенмәссең,
Ишетә ул, кышын туңса да.
Икенчесе – мәчет мулласыннан.
Аласыңмы әллә, и морзам?
Ишеткәне моның тик бер инде:
Коръән аятьләре һәм азан.
Өченчесен киеп карыйсыңмы?
Казый колагы бу, бир бишне.
Ул колакка «хак һәм нахак» дигән,
Канун дигән сүзләр килешле.
Дүртенчесе. Кулың сузасыңмы?
Зинданнарны күргән бурныкы.
Кемнең, күпме, кайда яшеренгән!
Белеп тору әллә хурлыкмы?
Бишенчесен бик очсызга бирәм,
«Нигә?» дисәң, сукбай колагы.
Син, җирәнеп, әгәр алмый калсаң,
Алыр әле берәр дурагы».
Бар да миңа чаксыз. Аптырагач:
«Бармы, – дидем, – шагыйрь колагы?
Хакы күпме, сезнең базарларда,
Шундый колак кыйбат торамы?»
Сатучыга җан кергәндәй булды:
«Шәлперәйгәне дә – миллиард.
Әллә үзегезнекен, жәлләмичә,
Миңа сатасызмы, шагыйрь-карт?»
Җилләр алсын, нинди дорфа фикер?!
Андый колак җирдә сирәк лә.
Шигырь моңын ишетәлгән колак
Үземә дә бик тә кирәк лә.
Ярый әле, шул базарга бардым,
Алып кайттым уйның зиннәтен:
Бармый калсам, белми үләр идем
Шагыйрь колагының кыйммәтен.

## Диетический шигырь

Тулыланып киттем әле, дуслар,
Күрә калсаң – хәйран калырлык.
Минем генә ис китмәгән була,
Урындыкка төшә авырлык.

Яхшы кеше мул булырга тиеш,
Хатын көйли ләкин зарларын:
«Таллар сыман нәзек кенә идең,
Филләр төсле, җаным, кабардың».

Кем гаепле? «Чәйләп алыйк!» дисәм,
Чәй янына куйдың бәлешен.
«Минем шундый хәлгә җитүемдә
Синең дә бит бар, дим, өлешең?»

«Юк, юк!» дигән була. Ай, хәйләли.
Хәйләләсен, аңа килешә.
Үзе бит ул юанаймас өчен
Көн дә кефир эчә бер шешә.

Мин дә менә – җәйләр генә җитсен –
Күчәм әле бары кыярга.
Юкса хатын ташлап китүе бар,
Нәфесеңне кирәк тыярга.

Тулыланып киттем әле, дуслар.
Күрә калсаң – хәйран калырлык.
Симерүе җиңел, ябыкканда
Бирсен иде Ходай сабырлык.

Рафис
Корбан

# АРТЫК КЕШЕЛӘР

РОМАН-ЭССЕ

**15**

1928 ел Салих өчен гаять тә уңдырышлы булды. Болай булыр дип, аның башына да кереп карамаган иде.

«Наёмщик»ның репетицияләре башланган көннәр генә иде әле. Салих радиостудиядә чираттагы тапшыруда авылдан килгән берничә һәвәскәр җырчы хатынны туры эфирга җырлатыр өчен репетиция үткәреп бетерде дә бүлмәсенә кереп, чөйдә эленеп торган пәлтәсен алып, иңбашына гына салды һәм эфир вакыты җиткәнче дип, тәмәке тартып керергә ишегалдына чыкты. Төтен пыскытып торганда, студиягә каяндыр пуф-пуф килеп, ашыгып, Исмәгыйль Усманов кайтып керде.

– Уф, өлгердем бугай, тапшырулар башланганчы өлгермим, ахры дип, йөгерергә туры килде. Шыбыр тиргә баттым, – диде ул.

– Өлгердең, вакыт бар әле синең тапшыруга кадәр. Авыл һәвәскәрләренең берничә җырын тапшырабыз башта, – диде Салих. – Мә, тартып ал, – дип, ул кесәсеннән папирос кабы чыгарып, Исмәгыйльгә сузды.

– Армия сәнгатькярләре союзында булып кайттым, – диде Исмәгыйль, кабыннан папирос ала-ала. Ул кесәсен капшап, шырпы эзләде, аның юклыгын күреп, кабызыр өчен Салихның тәмәкесенә үрелде. Ут алгач, капны кире биреп, сүзен дәвам итте: – Казан дивизиясе политотделы нәчәлникләре җыелган иде. Кызыл Армиянең унберенче еллыгын каршылау буенча чаралар планын төзеделәр. Мин дә бит анда идарә әгъзасы, комитет шефының сәркатибе. Шунда сүз булды: Якуб Чанышевның дивизия өчен поход маршы яздырасы килә икән. Салих алынмас микән, сөйләшеп кара әле дип, миннән сорадылар.

– Һе, – диде Салих, йөзе уйчанланып. – Белмим шул, булыр микән. Юк, бәгырь, миннән булмастыр ул. Мин бит лирик. Нинди хәрби инде мин? Аннан соң, күреп торасың, монда вакыт та юк. Ничек азапланам. Ике фронтка эшлим бит. Җитмәсә, бу «Наёмщик»ны чыгарыр вакыт җитеп килә.

– «Наёмщик» чыгар ул. Ашыгыч түгел, вакыт бар бит әле. Тулы өч ай чамасы.

Салих бер сүз дә әйтмәде, «ә» дә димәде, «җә» дә димәде. Тәмәкесен тартып бетерде дә керергә ашыкты. Исмәгыйльнең дә тапшыру алдыннан

---

*Дәвамы. Башы 7 нче санда.*

әзерләнәсе бар иде, гозерен яңадан кабатлап тормады. Шулай да ул Салихның күзендә ниндидер чаткылар күргән кебек булды. Бу «Наёмщиг»ы белән эшен бетергәч, тагын бер исенә төшереп карыйсы булыр дип уйлады да Салих артыннан иярде.

«Наёмщик» куелганны көтәргә туры килмәде. Икенче көнне үк Салих Исмәгыйльне өйлә вакытында үзләренә дәште. «Әйдә, бездә генә капкалап киләбез. Безнекеләр бүген Насретдин җизниләргә киткән булырга тиеш», – диде. Ни өчендер аның кәефе юк иде.

– Кәрим абый сагындыра, – диде ул. – Боларның эшләре бармый. Барыбер киредән чакыртып кайтарырлар шикелле сизә күңелем.

– Киләсе елдан театр Лядов урамына күчә, Кызыл Армия Йортына. Зуррак бинада мөмкинлекләр дә зуррак булачак. Күбрәк спектакльләр чыгарыла башлаячак. Шул чагында инде боларның көче генә җитмәячәк. Кайтарачаклар Кәрим абыйны. Театрны беренче оештырган кеше бит ул. Егерме икенче елда Ташкенттан кайтып, таралышып беткән бөтен артистларны туплап.

Салих та шул елны Оренбургтан кайтып эшли башлаган иде ул театрда. Ә аңа кадәр егерменче елда үз теләге белән Төркестан фронтына Кызыл Армиядә хезмәт итәргә китте. Армия тормышын, әлбәттә, яхшы белә. Кызыл Армиянең җиңүләренә үзеннән өлеш керткән солдат. Әле Оренбургта «Озын сәфәр» дигән беренче әсәрен иҗат иткән чакларда ук солдатлар өчен марш язарга ниятләгәне бар иде аның. Кичә Исмәгыйль белән сөйләшкәннән соң ул көне буе шул марш хакында уйлап йөрде. Нотасын язган кәгазьләре дә каядыр исән бугай дип, театрдан кайткач, чемоданнарын актарып, шуларны эзләп тапты. Исмәгыйльнең бер башлаган эшне ахырына җиткермичә туктамаганын ул яхшы белә. Шуңа күрә үзен тынгылыкта калдырмаячагын, марш дип аптыратачагын аңлый ул. Яңадан искә төшергәләгәнче, үзе эшне дәвам итәргә дигән фикергә килде.

Өйгә кайтып, примуска чәйнекне кайнатырга куйды да, фортепиано алдына барып утырды. Маңгаен җыерып, клавишалар буйлап бармаклары белән йөгертеп чыкты да беренче аккордларны алып, кәгазенә карап уйный да башлады. Аңа тынсыз гына карап торган Исмәгыйль шунда ук сизеп алды:

– Марш бит бу! – дип кычкырып җибәрде.

Салих туктап, кәгазенә тагын ниндидер ноталар өстәде дә аны бер читкә алып куйды һәм:

– Юк! Барып чыкмый, – диде һәм урыныннан торып, кайнап чыккан чәйнекне алып, өстәлгә илтте. Аннары: – Аш ашыйсыңмы? – дип сорады.

– Булса, зыян итмәс, – диде Исмәгыйль.

Салих өстәл астыннан идәндә торган кәстрүлне алып, примус өстенә куйды.

– Хәзер кайный. Оренбургта чакта ук сызгалаган нәрсәләр инде бу.

Ул тәрәзә буена килеп, урамга карап тора башлады. Аның кашлары күтәрелде, маңгае җыерылды. Аннары карашы яктырып киткәндәй булды.

– Карап карарга кирәк, – диде ул ачылып киткән чырай белән. Яңадан фортепиано янына килеп утырды һәм уйный башлады.

Исмәгыйльнең йөрәге ярсып тибәргә тотынды. Күз алдына мәйдан

буйлап марш атлап барган гаскәр килеп басты. Менә көйнең һәр такты солдатларның нык басып аяк атлавын хәтерләтте. Ул ихтыярсыз кычкырып җибәрде:

– Марш бит инде бу, Салих! Син моны миңа бир әле. Алып барып күрсәтим әле дивизия оркестры җитәкчесенә.

Салих уйнап бетерде дә, кәгазьләрне җыеп, Исмәгыйльнең кулына тоттырды.

– Күрсәтеп кара, – диде дә кайнап чыккан ашны кәстрүлдән тәлинкәләргә сосып: – Әйдә, ашап алыйк, – диде.

Ашап чыккач, Салих яңадан театрга китте. Ә Исмәгыйльнең күңеле инде кош тоткан бала шикелле алгысынган, ул тизрәк ноталарны капельмейстерга илтеп бирим дип, Кызыл Армия Йортына юнәлде.

Салих ноталарны бирде дә онытты. Бу «Наёмщик» аның бөтен вакытын алды. Премьера булганчы, ул гел шуның белән генә яшәде. Исмәгыйль дә берни әйтмәде, эшеннән бүләсе, борчыйсы килмәде. Ә капельмейстер маршны бик ошатты ул вакытта.

– Бер дигән марш бит. Тизрәк оркестр өчен эшләп бирсә иде, – диде ул Исмәгыйльгә, ноталар буенча рояльдә уйнап чыккач.

– Бер минут та вакыты юк аның. Үзегез карагыз инде, – диде Исмәгыйль.

– Рөхсәт итәрме икән соң?

– Бирде бит инде. Димәк, каршы түгел.

Шуннан соң капельмейстер үзе оркестровка эшләп, репетицияләрен дә башлап җибәрде. Исмәгыйль исә, Салихка берни әйтми-нитми, Кызыл Армия Йортына кергәләп йөрде. Радиостудиядә тапшырулар эшләүчеләр өчәү генә иде: Исмәгыйль, Салих һәм Кутуй. Исмәгыйль инде берничә мәртәбә репетиция вакытында оркестрның маршны уйнавын карап, тыңлап торды. Салихка берни әйтмәсә дә, серне Кутуйга чишмичә йөрәге түзмәде.

– Бер сер бар, беркем дә белергә тиеш түгел, – диде ул Кутуй дустына.

– Нинди сер? Сер бар дигәч, ул сер булудан туктады инде.

– Эчне кытыклап тора шул. Кемгәдер әйтәсе килә.

– Әйт инде алай булгач, эчеңне тишеп чыга күрмәсен.

– Әйдә, үз күзләрең белән күреп кайтырсың. Барып кайтыйк, – диде Исмәгыйль.

– Кая чакырасың?

– Ерак түгел, Кызыл Армия Йортына гына.

– Нәрсә бар инде анда?

– Әйдә, баргач күрерсең. Йә монда ук башкаларга сөйләп бетерерсең. Серне ачарга ярамый.

Алар шулай шаяртып сөйләшә-сөйләшә, Кызыл Армия Йортына киттеләр.

Кутуй маршны исе китеп, шаклар катып тыңлады.

– Сәйдәш бит бу! – диде ул оркестр уйный башлау белән үк.

– Сәйдәш шул. Ул әле үзе дә белми. Оркестр өчен эшләгәннәрен дә, инде репетиция ясап ятуларын да. Уйнап карасыннар дип кенә биргән иде.

– Нишләп әйтмәдегез? Үпкәләр бит.

– Сюрприз ясамакчы була оркестр җитәкчесе. «Наёмщик»ны чыгаргач алып килеп тыңлатырбыз.

Салих аңа әйтмичә генә оркестрлаштырган өчен чынлап та нык ачуланды.

– Йөрмим дә, күрәсем дә килми, – диде ул үпкә белдереп, музыкаль драманың премьерасыннан соң Исмәгыйль аңа марш турында әйткәч.

– Алай димә, бик әйбәт нәрсә язгансың, – диде Кутуй, Салих дустын тынычландырырга теләп.

– Син дә беләсеңмени?

– Беләм генә түгел, тыңладым да. Бер дигән марш чыккан. Котлыйм.

Кызыл Армия Йортында Салихның марш тыңларга киләсен беләләр иде. Алар анда Исмәгыйль, Кутуй һәм Салих өчәүләп бардылар. Салих чынлап та ошатмады маршны. Чыраен сытып, бик ачулы йөз белән тыңлады.

– Булмаган бу, – диде соңыннан. – Ашыккансыз. Эшләнеп бетмәгән нәрсә килеп чыккан. Күпме көчегезне әрәм иткәнсез.

– Зыян юк, – диде капельмейстер. – Монысы да бик матур. Яңадан эшләсәгез, тагын да әйбәтрәк булыр. Без моңа шат кына.

– Ярар, хезмәтегез өчен рәхмәт. Мин яңадан карап чыгармын. Ноталарны җыеп бирегез, – диде Салих.

Оркестрантлар һәрберсе алларында яткан кәгазьләрен Салихка китереп бирделәр.

Салих эшне озакка сузмады. Бер-ике көннән инде ул инструментлар өчен эшләп, яңа партитурасын язды һәм дирижёрга илтеп бирде. Ә алар репетицияләрен башлап җибәрделәр. Берничә көннән Исмәгыйль, Кутуй белән Салихны ияртеп, тагын оркестрны тыңларга киттеләр.

– Каяндыр марш турында Габдрахман Минский да ишеткән, – диде Салих юлда барганда дусларына.

– Ишетсә соң, аның ни эше бар? – диде Усманов.

– Бәйләнде бит, Кызыл Армиягә багышланган пьеса язып ятам. Маршыңны шуның спектаклендә уйнатыйк әле, ди.

– Акылы алтын икән, – диде Кутуй. – Син нәрсә дидең соң?

– Нәрсә дим, Якуб Чанышев заказы белән яздым. Шуннан барып сора, дидем.

– Ул сорар. Җитмәсә, шуның дивизиясендә армия хезмәтен үтеп ята, – диде Усманов. – Үзе ике көннең берендә театрда. «Шлем» дигән спектакль куйдырырга йөри бугай. Шунда уйнатырга телидер инде.

– Ә син аның спектакле өчен аерым марш яз. Бу марш бит спектакль кысаларына гына сыя торган түгел. Бу бит зур тантаналарда, гаскәрләр мәйданнан парадта үткәндә уйнала торган марш.

Кутуйның бу сүзләреннән соң беркавым сүзсез барган Салих әйтә куйды:

– Исмәгыйль маршның Оренбургта чакта яза башлаган беренче ноталарын алып киткәннән соң утырып, бер нәрсә язып караган идем. «Каршылау маршы» дип атала. Бәлки шуны күрсәтеп караргадыр үзенә.

Бу Усманов өчен яңалык иде.

– Ну өлгер дә инде үзең! Кай арада яздың әле анысын? – дип, гаҗәпләнүен белдерде ул.

– Үзең миннән дә өлгеррәк булып чыктың. Сорап-нитеп тә тормыйча оркестровкасын эшләткәнсең дә, уйнатып та ятасың.

– Гафу. Төзәттек бит хатаны. Менә хәзер үзең күрерсең. Бик әйбәт марш

килеп чыккан, диләр хәрбиләр. Шедевр. Мировой уровеньда! Дивизия башлыклары да репетициягә килеп, маршны тыңлап киттеләр. Бик ошаттылар. Чанышевка аеруча ошаган, диделәр. Командование маршны Кызыл Армиянең унбер еллыгына багышланган җыелышта Беренче Татар полкына тантаналы шартларда тапшырырга булган.

– Кит инде?!

– Шулай ди шул. Чанышев, Салих Сәйдәшев оркестрга үзе дирижёрлык итсә, әйбәт булыр иде, дип әйтеп әйтә, ди.

– Кызык икән. Язып та бир, уйнап та бир. Бик майлы бәлеш булмыймы соң ул?

Сүзгә Кутуй кушылып:

– Үзең уйнасаң, әйбәтрәк булачак. Тантаналырак, – дип куйды.

– Ярар, күз күрер. Башта тыңлап карыйк әле. Нәрсә майтардылар икән, – дип, Салих шунда ук килеште.

Салихның үзенә дә ошады марш. Оркестр уйнап чыкканнан соң, ул барып, капельмейстерның кулын кысты да дирижёр урынына басты.

– Кая, үзем селтәнеп алыйм әле, – диде.

Дирижёр рәхәтләнеп риза булды.

Салих беркавым тынып торды. Аннары дирижёрдан алган таякчыгын маршның беренче авазларын бирергә тиешле быргычылар тарафына карап, акрын гына селтәп алды.

Подвалны тетрәтеп, марш яңгырый башлады. Салих хәрби капельмейстердан аермалы буларак, гәүдәсе белән артык ыргылмыйча, кулындагы таякчыгын җай гына селкеп, тыныч һәм үзенә нык ышаныч белән дирижёрлык итте. Маршны тыңларга Кызыл Армия Йортында булган барлык хәрбиләр җыйналды.

– Сәйдәшев үзе идарә итә! – дигән чышын-пышын тавышлар ишетелде.

Үзе хәрбиләрчә тантаналы да, үзе чын татарча моңлы да, ягымлы һәм җитез яңгырашлы марш барысын да беренче авазларыннан ук әсир итте. Менә кызык, барысының да күзендә яшь иде. Салихның да болай да нечкә күңеле тагын да нечкәреп, зәңгәр күзләрендә иртәнге чык бөртеге кебек яшь тамчылары җемелдәде, бугазына төер тыгылды.

Оркестрантларга рәхмәт әйтеп, эшләреннән канәгатьлек белдереп, Кызыл Армия Йортыннан чыгып киткәч, Салих:

– И бәгырькәйләр. Дөресен генә әйткәндә, бу минем иң беренче язган әсәрем иде, – диде. – Оренбургта чакта шундагы хәрбиләр өчен бер марш шикелле нәрсә маташтырып булмасмы дип уйлаган идем. Ноталарын сызгаладым да, ошатып бетермичә, чемодан төбенә салып куйдым. Менә шуннан бирле җиде-сигез ел ятты бугай инде ул. Ә беренче дип, халыкка чыгарган әсәр «Озын сәфәр» булды. Анысы да шул хәрбиләр тормышын күз алдында тотып язылган нәрсә иде.

– Искиткеч килеп чыккан! Котлыйм! – диде Кутуй һәм Салихның кулын кысты. – Елаттың.

– Инде Кызыл Армия туган көнне тантаналы рәвештә тапшырасы гына калды. Үзең хезмәт иткән беренче татар полкы бит! Якуб Чанышев егетләре! – диде Исмәгыйль.

– Шамил абый сөенер инде, – дип куйды Салих.

Ул үзеннән ике генә яшькә өлкән булса да, Шамил Усмановка абый дип дәшә иде.

Санаулы көн тиз уза, диләр бит. 23 февральнең килеп җиткәне сизелми дә калды.

Кызыл Армия Йорты ул көнне хәрбиләр белән шыгрым тулы иде. Кая карасаң да, солдатлар өелешеп тора.

Салихны өеннән комдив автомашинасында килеп алдылар. Халык телендә Офицерлар йорты дип йөртелә торган бинаның ишек төбендә аны Чанышев үзе каршы алды.

– Бик яхшы марш язгансың, Салих туган! – диде ул бернинди дә рәсми, коры телдә сөйләшмичә, киресенчә, якын, үз итеп. – Әйдә, керик. Кичәбезнең рәсми өлешенә репетиция ясап алыйк.

Рәсми өлеш дигәнендә Салих Сәйдәшевкә «Казан гарнизонының Почётлы кызыл армиячесе» дигән таныклык, хәрби киемнәр бирелергә, һәм Сәйдәш «Кызыл Армия маршы»ның ноталарын Беренче Татар полкы командирына тапшырырга тиеш икән. Ләкин алары әле соңыннан, кичә башланганда гына.

– Ноталарны тапшырганда, кыскача гына нотык тотып алсаң, начар булмас иде, – диде Чанышев.

Салих каушап, бераз аптырашта калды һәм янында басып торган Сөләйман Вәлиев-Сульвага карап:

– Менә, Сульва гына сөйләсен инде минем урынга. Бер дә сөйләү куәсем юк бит, бәгырь, – дип куйды. – Ул – рәсми кеше, театрның баш режиссёры. Сөйли дә белә. Мин менә партитураны гына тапшырырмын да, шул бик җиткән.

– Ну ярар, шулай булсын. Аннары маршны уйнаганда, оркестрга берүк үзегез дирижёрлык итәрсез инде, – диде Чанышев.

– Анысы була. Анда сөйлисе юк.

– Булды, килештек.

Салихның кулына маршның партитурасын тоттырдылар. Ул каты тышлы папка эченә салынган. Тышында: Салих Сәйдәшев. «Кызыл Армия Маршы» дигән язу. Астарак «Беренче Татар укчы полкына, Кызыл Армиянең XI еллыгы истәлегенә», дип язылган һәм, «Раслыйм. Командир Чанышев», дип, кул куелган.

Ниһаять, дулкынланып көткән минутлар якынлашты. Зал хәрбиләр белән тулы иде. Алар командир Чанышевны һәм Сәйдәшне аягүрә торып басып каршы алдылар. Быргы тавышлары астында залга дивизиянең Байрагы чыгарылды. Салих дирижёр пультына менеп басты. Җитмеш кешедән торган хәрби оркестр аның таякчык тоткан кул ишарәсенә буйсынып, маршның кереш аккордларын уйнап җибәрде. Залны тетрәтеп, Сәйдәш маршы яңгырады. Солдатлар аны аягүрә басып тыңладылар. Марш беткәч, зал ура тавышларына күмелде. Шуннан соң Салихның «Казан гарнизонының Почётлы кызыл армиячесе» итеп алынуы турында дивизия командирының боерыгын укыдылар һәм кулына солдат киемнәре белән Мактау кәгазе тоттырдылар. Көчле кул чабулардан соң дирижёр пультына оркестрның үз җитәкчесе менеп басты һәм марш тагын бер тапкыр башкарылды. Бәйрәм рухы Кызыл Армия Йортыннан Казан урамнарына бәреп чыкты. Бу көн Казанда зур бәйрәмгә әверелде. Сәйдәш маршы бәйрәменә.

## 16

«Наёмщик» белән «Кызыл Армия маршы»ннан соң Салих Сәйдәшевнең даны тагын да күтәрелде. Казанда нинди генә чара үткәрелсә дә, аларда катнашучылар өчен күрсәтелгән концертларда төп урынны Сәйдәш әсәрләре алып торды. Аның спектакльләргә язган җырлары, увертюралары, сюиталары, арияләре, биюләре яңгырады. Ул җәйдә чит илләрдән – Германиядән, Америкадан кунаклар килде. Алар да үзләренә күрсәтелгән концертларда Сәйдәш музыкасына мөкиббән китеп, аның үзен һәм башкаручыларны үзләренә кунакка дәштеләр. Кыскасы, Салих халык арасында зур абруй казанды.

Ләкин Салихның күңеле урынында түгел иде. Хатыны Валентина үлгәннән соң ул менә өченче ел инде ялгыз, бер юанычы бар – улы Альфред. Аның белән дә аерым яшәргә туры килә – улын хатынының әнисе Анна Ивановна тәрбияли. Салих, вакыты булганда гел улын күрергә йөгерә. Анна Ивановнаның да тормышы җиңел бармый. Уллары Анатолий белән Юрийның да үз тормышлары. Альфредка да ике яшь тулды. Ата-ана назын күрмичә, әбисе тәрбиясендә үсә. Салихның үзенә дә кеше гаиләсендә, чит кашык булып яшәү бер дә рәхәт түгел. Ичмасам Валя шикелле аның җанын аңлый торган, аның хәленә керә белә торган, икесе бер уй, бер мәсләк белән яши торган хатын да очрамый. Өйләнеп куяр иде дә, тик кемгә? Соңгы вакытта ул бу хакта күп уйлый башлады. Эзләнде, әйләнә-тирәсендәге кыз-хатыннарны күзәтте. Танышлары, дуслары арасында да берәр акыллы, аны аңлардай хатын белән таныштырам дип торган кеше күренми ичмасам. Яше дә бара. Беренче күрүдә үк гашыйк була торган ваемсыз чаклары да артта калып бара.

Кызыл Армия бәйрәмнәре үткәч, Салихның юраганы юш килде, Казанга Әстерханнан Кәрим Тинчурин һәм аның белән киткән бер төркем артистлар кайтып төште. Алар барысы да театрда эшли башладылар. Театрның чынлап та көймәсе комга терәлгән иде. Ачуың килмәслек түгел, бер көтү режиссёр йөри, артистлардан күп. Ә спектакль чыгара алмый интегәләр. Егерме тугызынчы елга кергәч, гыйнвар аенда «Ханбикә» дигән бер спектакль чыгардылар да, шуның белән Аллаһы әкбәр.

Тинчурин белән Әстерханнан тагын берничә яңа кеше ияреп килгән иде. Шуларның берсе яшь кенә, мөлаем гына кыз – Сафия. Ул да театрга эшкә урнашты. Артист булып түгел, кассага утырттылар.

– Ул кызны Тинчурин иярттеп кайтты, – дип сөйләде Арапова.

Арапова үзе Кәрим Тинчуринга битараф түгел иде. Кәрим Казаннан сөрелгәндә, аның белән китте. Халык арасында аның хатыны Заһидәгә:

– Кара аны, Кәримең тиккә генә Араповаңы иярттми. Җибәрәсең юк ялгызын гына, – диде озын телле хатыннар.

Заһидә ул вакытта институтта укытучы булып эшли. Укытуын ташлап, берничек тә Әстерханга китә алмый иде. Аннан соң ул Кәримен бик ярата һәм аңа ышана иде. Арапованың Кәрим турында, Сафияне иярттеп кайтучы, дигән сүз чыгаруы көнчелектән, ачудан булырга тиеш. Һәрхәлдә Салих шулай дип уйлады. Салихның кассир булып эшли башлаган шул Сафиягә күзе төште. Моны сизеп алган Тинчурин исә шикле рәвештә аңа: «Чуалма ул кыз тирәсендә», – диде. Салих моны бик аңлап бетермәде: Кәримнең аңа чынлап та күзе төшеп йөргәнме, әллә ул кызга ышанырга ярамый дип

кисәтү ясарга теләгәнме? Салих артыгын төпченергә кирәксенмәде. Ләкин кыз аның үзенә ошый иде. Тәртипле булырга охшаган, күп сөйләшми, мөлаем. Һәм бер көнне ул шаяртып кына аңа сүз катып карарга булды.

– Театрда эшләве куркыныч түгелме, бәгырь? – диде ул сүзен нәрсәдән башларга белмичә аптыраганнан.

– Нәрсәсе куркыныч булсын? Монда бит урман түгел, кыргый бүреләр юк.

– Күңелсездер бит, кеше белән аралаша алмыйсыз, ялгыз гына утырасыз.

– Моңаерга бирмиләр монда сезнең озын телле артисткаларыгыз.

– Нигә алай дисез?

– Күп сөйләгәннәре өчен шулай дим.

– Нәрсә сөйлиләр инде, шулкадәрле, кәефегезне җибәрә торган?

– Сөйлиләр инде, җыен юк-бар.

– Минем бер дә ишеткәнем юк. Бик кыерсытсалар, үземә генә әйтегез, хәзер кирәкләрен бирермен мин ул җүнсезләрнең.

– Ай-һай, бирә алырсыз микән? Алар белән сүзгә кермәвегез хәерлерәк. Югыйсә бөтен тормышыгызны бозып ташлаулары бар.

– Минем куркасы юк, бозыласы бозылган инде.

– Нишләп алай дип әйтәсез?

– Бозылган булганга күрә әйтәм.

– Әллә хатыныгыз белән аерылыштыгызмы?

– Юк, аерылышмадым. Ул үлеп китте шул, бер малай табып калдырып.

– Ялгыз башка бала үстерүләре җиңел түгелдер алай булгач.

– Малайны үстерүчеләр бар. Үземә иптәш юк.

– Минем шикелле икән.

– Ничек инде алай, яшь, чибәр кызның иптәше юк? Аңлашылмый. Нишләп йөри Казан егетләре?

– Шулай инде минә. Егетләр белән танышырга җай чыкмый монда утырып. Үзләренең килеп дәшкәннәре юк. Театр егетләре барысы да парлы.

– Барысы да түгел шул. Әйтеп торам бит минә.

– Ә мин каян белим, маңгаегызга язып куймаган.

– Белдегез инде минә хәзер.

– Хәзер белдем инде.

– Белгәч нишлисез инде?

– Берни эшләмим, бары белеп торам.

– Мин тагын, иптәшегез булам, дип әйтерсез дип көтәм.

– Алай дип кенә буламы соң ул? Бәлки мин сезгә ошамыймдыр.

– Ошамасагыз, болай туктап сөйләшеп торыр идемме?

– Бик ышанып бетәсем килми сүзегезгә. Сезне бит Казанның бөтен хатыннары ярата, диләр. Спектакльләрдән соң затлы фаэтоннарга гына утыртып алып китәләр.

– Алар яратадыр да, мин яратам микән соң? Шул хатыннарның бәйләнүләреннән туйганга күрә иптәш эзлим бит инде. Алар белән тормыш корып булмый. Ә миңа тормышта иптәш кирәк. Сөеп, яратып өйләнгән хатыным үлде дә, минә өч ел инде тилмерәм ялгыз башым. Күкрәгенә башым салып, күңелемне бушатырлык иптәш кирәк. Күңелемдә әллә нинди вулканнар кайный.

– Алай укмыни? Пешереп ташламасмы соң ул вулканнар мине дә?

– Ташламас, бул әйдә минем иптәшем. Туйдырды мондый ялгыз тормыш.

– Тормыш иптәшем бул дисез инде?

– Әйе, шулай дим.

Салих шушы сөйләшүдән соң Сафияне җитәкләде дә өйләренә алып кайтты. Кыз карышып тормады. Аның бәләкәй бер чемоданыннан башка бернинди мөлкәте дә юк иде. Өйдәгеләр нәрсә дип әйтергә дә белмәделәр. Барысы да шок хәлендә калды. Татарча әйткәндә, шаккаттылар. Шок сүзе урыска шул шаккату дигәннән кергәндер инде, күрәсең.

Бу яңалыктан театрда да халыкка шок булды.

– Тыңламадың сүземне алайса, – диде Тинчурин. – Ярар, син малай-шалай түгел, үзең хәл иткәнсеңдер. Сиңа яшисе, – диде дә шуның белән бу сүзгә кире әйләнеп кайтмады.

Өч көн, өч төн туен иттеләр, гел әкияттәгечә булды. «Анда мин дә булдым, рәхәтләнеп сыйландым, ачы балдан авыз иттем, мыек кына чыланды», дигән шикелле, театр гына түгел, бөтен Казан бәйрәм итте Салих белән Сафия туенда. Оркестр уйнап торды, артистлар җырлады, биючеләр биеде. Башта кәефләре кырылган туганнарының да күңеле күтәрелде.

Туй мәҗлесләре үтәргә дә өлгермәде, Татарстан әдәбият һәм сәнгать вәкилләренең ил буенча бер айга сузылган сәяхәтләре башланды. Узган ел Максим Горький кунакка килгәч, Татарстан сәнгатькярләренә һәм язучыларына үз иҗатлары белән СССР халыкларын таныштырыр өчен ил буйлап сәяхәтләрен оештырырга дип сүз биреп киткән иде. Егерме сәнгатькяр белән язучы ирләре һәм хатыннары белән бергәләп, Казан – Әстерхан – Махачкала – Баку – Ереван – Тифлис – Батуми – Симферополь – Харьков – Мәскәү маршруты буенча Идел буйлап пароходта сәфәргә чыгып киттеләр. Салих белән Сафия өчен бу үзенә күрә ширбәт ае кебек матур бер сәяхәт булды.

Һәр шәһәрдә зурлап каршы алдылар. Үзе белән алып килгән артистларны җыеп, яңадан Казанга кайтып киткән Кәрим Тинчуринның озак та тормый үтеп барышлый булса да, кабат кунакка килүенә Әстерхан татарлары аеруча шатланган иде. Көндез шәһәргә чыгып, халык белән очрашулар үткәрделәр. Ә кичен пароход палубасындагы салонда оештырылган әдәби-музыкаль кичәне карарга шәһәрнең иң күркәм, күренекле татарлары җыйналды. Тинчурин гынамы, Казаннан татарның иң затлы зыялылары килгән бит! Сәйдәш үзе генә ни тора! Сәйдәшнең бу аеруча күкрәгән елы. «Кызыл Армия маршы» СССРның барлык төбәкләренә барып җиткән иде. Ул язучылар: Шәриф Камал, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Гадел Кутуй, Газиз Иделле, Кави Нәҗми – барысы да хатыннары белән җитмәсә, берсеннән-берсе атаклы шәхесләр, берсеннән-берсе уздырып, чыгышлар ясадылар, төрле истәлекләр, мәзәк хәлләр, шигырьләр сөйләделәр. Кави Нәҗминең хатыны Сәрвәр Әдһәмова барысын да көндәлек дәфтәренә язып, теркәп барды. Казанга кайткач, сәяхәтнамә язып чыгарга дип вәгъдә итте.

Барысы өчен дә иң кызыклы очрашулар Кырымда булды.

Батумидан соң Кырымга сәфәр чыккач, Туфан белән Кутуй Такташ дусларыннан көләргә тотындылар.

– Барыбыздан да бигрәк Такташ ашкына инде Кырымны күрергә, – диде бермәлне Кутуй.

– Ни өчен? – дип сорашты кызлар.

– Ә юк, кызларга бу хакта белергә ярамый, – дип шаяртты Туфан.

– Белсәң, яшермә, әйт! – диде Сәрвәр. – Мин юлъязма язам. Көндәлеккә теркәп куясым бар.

– Алай булгач, бигрәк тә әйтергә ярамый икән, – дип, Туфан белән Кутуй белгән сергә Нәҗми дә кушылды.

Ә сер чынлап та ачылырга тиешле булып чыкмады. Чөнки ул Такташтан адым да аерылмыйча йөргән хатыны Гөлчәһрәгә бәйле икән.

Сүзнең нәрсә турында барганын Такташ үзе дә бик яхшы аңлый иде.

– Алай яза торган булгач, бигрәк тә сөйләргә ярамый ул хакта, – диде Такташ, Кутуй белән Туфанга бармак янап.

Бу серне бары тик шушы дүрт кешедән башка берсе дә белми иде. Такташ әле 1920 елда Казанга килгәч, иң беренче булып Гөлсем Мөхәммәдова исемле кызга гашыйк булган икән. Ә ул кыз – хәзергесе вакытта Кырымда дәваланып ятучы, сәяхәттәгеләр барысы да барып күрергә, хәлен белешергә дип ашкынган Галимҗан Ибраһимовның хәләл җефете! Бу хакта белеп алса, Такташның койрыгы шикелле ияреп йөргән Гөлчәһрәсе аны Кырымда Галимҗан Ибраһимовлар өенә аяк та атлатмаячак. Такташ чынлап та Ибраһимовны күрергә теләве хакында хатынына әллә кайчан ук әйтеп куйган иде инде. Иренең Галимҗаннан бигрәк кемне күрергә теләве генә Гөлчәһрәгә мәгълүм түгел иде.

Биредә аларга Кырымның шифалы һавасын сулап, Кара диңгездә су кереп, рәхәтләнеп, бер атна ял итәргә вакыт бирелде. Санаторийга урнашып алган көнне үк, дөрестән дә, Такташ Галимҗан Ибраһимовларның адресын эзләп китте. Алар Кырымга әле узган елны гына килеп урнашканнар иде. Галимҗанның үпкә чире ачылып, Горький Казанга кунакка килгәч, аңа диңгез буенда дәваланырга киңәш биргән иде.

Хатынының күренекле шагыйрь Һади Такташның элекке сөйгән кызы булуы хакында Галимҗан белми иде булса кирәк. Такташ аларны эзләп табып, бусагада күренүгә ул:

– Өммегөлсем! Күрче, кем килгән безгә! – дип, хатынына кычкырды.

Ләкин Гөлсемнең Һадины күреп, әллә ни исе китмәде. Ул аны соңгы тапкыр әле узган ел гына Гадел Кутуйның «Күк күгәрчен» спектаклен карарга баргач күргән иде. Анда да әллә ни сөйләшмәделәр, аның Һадига күңеле сүрелгән иде. Бары тик: «Менә нинди күренекле язучылар аның артыннан йөгерә!» – дип, бик эре, горур тотты Гөлсем үзен ул вакытта. Хәзер дә аның йөзендә шундый масаю сизелде. Ул хәтта Һадига чәй куеп эчертергә дә ашыкмады. Такташ, Галимҗан белән күрешеп, хәл-әхвәлләр сорашып, беркадәр вакыт сөйләшеп утырдылар да Гөлсемнең тәкәбберлегенә гарьләнеп, тизрәк кайтып китү ягын карады. Шуннан соң башка вакытта иптәшләре Галимҗан Ибраһимовны күрергә барырга җыенгач та, беркая да ашыкмады, Гөлчәһрәсен һәм улы Аванны алып, диңгезгә су керергә генә киттеләр.

Аның каравы Сәйдәш озаклап сөйләште Галимҗан абыйсы белән.

– Ничек анда Кызыл Байрак? – дип сорашты Ибраһимов.

– Үсә, гөрли. Яңа йортлар салына, яңа җирләр үзләштерелә.

– Иң кызыгы, балык тоту инде. Идел буенда кармак чирттереп утырудан да рәхәте юк.

Ибраһимов әле Идел аръягындагы буш яткан җирләрдә татар авыллары төзү идеясе туганда ук моны яклап чыга. Шиһап Әхмәровның бу тирәләргә иң беренче булып, Салих Сәйдәшевнең әти-әнисе Җамалетдин белән Мәхүпҗамал туган Дөбъяз якларындагы аз җирле авылларда яшәүче крәстияннәрне күчереп утырта башлауны да хуплый. Үзе дә еш кына Кызыл Байракта язучылар өчен салынган өйләргә килеп, язу эше белән шөгыльләнә.

– Минем «Тирән тамырлар»ны укыгансыңдыр бит? Анда барган вакыйгаларда сурәтләнгән табигать тулысы белән шушы тирәләрдән күчереп алынган. Игътибар иткәнсеңдер, – дигән иде Галимҗан Ибраһимов Салихка, шулай бервакыт Кызыл Байракка ял итәргә килгәч. – Нинди гүзәл җирләр бит монда! Татарның Швейцариясе!

– Шиһап туган нишләп йөри? Һаман да шул Кызыл Байрак дип йөгерәме?

– Аның шул инде. Кайтып та кергәне юк. Авыл кешесен җирле итәм дигән уй белән яши.

– Изге эш эшли. Авыл кешесен җирле итүдән бигрәк, Иван Грозный явыннан соң су буйларына кырык чакрымнан да якынрак килергә дә рөхсәт ителмәгән татар кешесенә Иделен кире кайтару белән шөгыльләнә. Мәрхәбә аңа! Югыйсә кара инде син, Идел буендагы бер дигән уңдырышлы җирләрдә ни татар хуҗа түгел, ни урыс хуҗа була белмәгән. Октябрь инкыйлабына кадәр бу җирләр ниндидер италияле бай алпавытның мөлкәте булган бит. Буш яткан җирләрдә анда-санда шул италияленең идарәчесе булып торган Муратов һәм сәүдәгәрләр Гребенщиков белән Стонешников карамагындагы Шеланга, Тәмте, Антоновка, Печещи авыллары урнашкан. Ә Шиһап белән Али Ганиевләр кыска гына вакыт эчендә Берек, Шура, Нариман, Кызыл Байрак авылларын корып чыктылар. Булдыралар, халык өчен, милләт өчен җан аталар.

Йә, ярар, милли сәясәттән читкәрәк китеп сөйләшик әле. Ничек анда шәхси тормышың? – дип сорап куйды Ибраһимов. – Парың да табылганга охшап тора бугай.

– Шулайрак. Әле бу сәфәргә чыгар алдыннан гына менә шушы ханым белән өйләнештек.

– Бик әйбәт булган. Казан кызымы? Кай яклардан?

– Юк, Әстерхан кызы. Кәрим абый өченче ел Әстерханга китеп барган иде бит. Менә шуннан ияртеп кайткан кыз. Үзебезнең театрда эшли.

– Артисткамыни?

– Юк үзе дә. Инде менә хәзер минем хатын булып эшли, – дип көлдереп алды Салих аларның әңгәмәсен бүлдермичә тын гына тыңлап торган иптәшләрен.

– Шулаймыни? Әстерхан кызымыни?

Галимҗан шулай диде дә хатынына дәште:

– Өммегөлсем, бире кил әле. Менә монда синең якташың килгән бит әле кунак булып, – диде.

Салих Өммегөлсемнең Әстерханда туып үскән кыз икәнен белә иде. Ибраһимовка кадәр аның Такташ дусты белән сөешкәнен дә белә. Әмма ул аңа хыянәт итте ул чакта, кияүгә чыгам дип вәгъдә бирде дә, Такташ әти-әнисенең ризалыгын алырга дип, Сыркыдысына кайтып киткәч, Ибраһимовка кияүгә чыгып куйган иде. Кызның Казанда университетның медицина факультетында

укып йөргән чагы була. Ул салкын тидереп авырып китә һәм ике имтиханны үз вакытында тапшыра алмый кала. Гөнаһ шомлыгы, шул вакытта университетка академик тикшерү комиссиясе килеп, имтихан бирә алмаучыларны ачыклап йөри. Ә тикшерү комиссиясенең җитәкчесе – Галимҗан Ибраһимов. Әгәр дә белсәләр, укудан куып та чыгарырга бик мөмкиннәр. Гөлсем ярдәм сорап, Әстерханнан килгән танышы Басыйр Абдуллин дигән кешегә ялвара. Абдуллин аны ияртеп, Ибраһимовка бара һәм кызның хәлен сөйләп бирә. Галимҗан исә күзе төшкән кызны беркайчан да үзеннән ычкындырмый инде. Ул Гөлсемнең имтиханын ике атнага кичектерергә рөхсәт бирә. Ә үзен Совнаркомга тәрҗемәче итеп эшкә урнаштыра.

Иренең, Әстерханда туып үскән кыз бездә кунакта, дигәненә әллә ни исе китмәде Гөлсемнең.

– Шулаймыни? – диде дә үз эшен дәвам итте.

– Ярар, игътибар итмәгез аңа. Кичектермичә башкарып куясы эшләре бар иде. Минем бер мәкаләмне русчага тәрҗемә итеп ята ул, – дип, Галимҗан хатынының битарафлыгына сәбәп тапкан итенде.

– Кайткач, Шиһапка зур сәламнәремне тапшыр, – диде Ибраһимов. – Яшьлек дустым бит ул минем. Әле «Шәрык клубы»нда эшләп йөргән чакларыннан, «Мәктәп» журналын нәшер иткән көннәрдән бирле белешәбез. Инкыйлаб дип, патша самодержавиесен бәреп төшерәбез, халыкка социаль ирекләр алып бирәбез, татар халкының үз дәүләтен булдырабыз дип янып йөргән яшьлек елларыбыз бергә үтте. Их, бар иде заманнар! Данлы еллар, шанлы еллар иде! Шул елларның данлы тарихы турында китаплар язып ятам менә хәзер. Каһәр суккан бу чир генә комачаулый. Әллә нинди зур планнар бар иде. Хәзер менә шушы язучылык белән шөгыльләнергә генә калды. Мине ак чехлар кулыннан һәлак булудан коткарып калган дустым бит ул Шиһап. Миңа хатын-кыз киемнәре кидереп, култыклашып, урамда йөрергә чыккан ир белән хатын кебек, кача-поса, Арча кырына хәтле озатып куйды бит ул мине. Хәзер көлке, ул вакытта бер дә көлке түгел иде. Мулланур Вахитов харап булды ул көннәрдә шул явызлар кулыннан.

Бераз тын алып, тукталып торганнан соң ул сөйләвен дәвам итте:

– Уңышларыңны белеп торабыз. Татар профессиональ музыкасын тудыручы дип саныйм мин сине. Милли көйләребезне заманча итеп эшкәртү белән генә чикләнеп калмыйча, пентатониканы Европа, рус композиторлары язган алымнарга якынайтуың, ярымтоннар белән эш йөртүең бик күркәм. Татар музыкасын оркестр белән башкаруга күчүең бик зур нәрсә! Ул Донбасс шахталарыннан кайткан тальян гармун белән генә чикләнеп калмыйча, музыкабызның диапазонын киңәйтәсең. Афәрин сиңа! Алга таба да шулай эшлә! Сезнең Тинчурин белән язган «Зәңгәр шәл»егез, Таҗи Гыйззәт белән тудырган «Наёмщиг»ыгыз – татар сәнгатенең шедеврлары. «Кызыл Армия маршы»н инде әйтеп тә торасы юк! Котлыйм, Салих туган! Күтәр халкыбызны! Күтәр аның музыкасын. Дөнья мәйданына алып чык! Барыгызга да шул теләк, егетләр, кызлар! Эшләгез, тырышыгыз! Күтәрегез татарыбызның данын!

Шулай күтәренке тонда озак сөйләү Ибраһимовның хәлен алды. Ул караватына барып ятты. Әдип белән сөйләшмәсәләр дә, аны күрү, аның Салих белән әңгәмәсен тыңлап тору башкалар өчен дә кызык иде.

– Ярый, егетләр, кызлар, гафу итегез, бүген Галимҗан абыегыз арыды. Икенче вакытта тагын килегез, – дип, Гөлсем аларга китәргә вакыт икәнлеген исләренә төшерде. Язучылар, шагыйрьләр остазларына үзләренең китапларын бүләк иттеләр.

Алар Кырымда атна буе булдылар. Такташтан кала язучылар барысы да берәм-берәм дә, бергәләп тә, Ибраһимов янына берничә мәртәбә барып килделәр. Аеруча Кави Нәҗми озаклап утырды аның янында. Татар язучылары оешмасының башында торган Нәҗми белән Ибраһимов арасында сөйләшеп-киңәшләшеп хәл итәсе мәсьәләләр шактый җыелган иде бугай шул.

Пароходта бер айга сузылган сәфәрләре Мәскәүдә төгәлләнде. Биредә аларны Кремльдә Максим Горький һәм Совнарком председателе Михаил Калинин үзе кабул итте. Ә кичен Мәскәү татарларына зур концерт күрсәттеләр. Концертта, нигездә, Салих Сәйдәшевнең симфоник әсәрләре яңгырады. Оркестрга Сәйдәш үзе дирижёрлык итте.

## 17

Салих Казанга кайткач, бер айлык сәяхәт вакытында күргәннәрен өйдәгеләргә бәйнә-бәйнә сөйләде. Шиһап җизнәсенә Галимҗан Ибраһимовның сәламнәрен җиткерде.

– Кырымда илдә барган хәлләрдән читтә тыныч кына яшәп ята Галимҗан, – диде Шиһап. – Менә монда хәлләр куера әле безнең. Шулардан бихәбәр бугай ул анда.

– Нәрсә булды шулай борчылырлык? – дип сорады Салих җизнәсеннән.

– Озын колаклардан килеп иреште, имеш Мирсәет Солтангалиевне кулга алганнар, ди. 1923 елда милли мәсьәлә буенча дөрес юлдан бармый дигән гаеп тагылып, Милләтләр эшләре буенча халык комиссариатындагы вазифаларын-нан бер читләштерелгән иде инде. Большевикларның уникенче съездында Сталин линиясенә каршы чыгып, автономияле республикаларның хокукларын союздаш республикалар белән тигезләргә чакырып чыгыш ясаганы өчен ОГПУ тарафыннан эзәрлекләнә башлады. Шуннан соң бөтен вәкаләтләреннән читләштерелеп, сунарчылык союзы консультанты дәрәҗәсенә төшерелде. Инде менә узган елның декабрендә аны халыкара империализм агенты дип гаепләп, «солтангалиевщина» дигән эш ачканнар икән. Кулга алуның сәбәбе шунда.

– Ә сезгә нинди катнашы бар «солтангалиевщина»ның?

– Ничек булмасын, милләтчелектә гаепләү өчен бер дигән сәбәп. Идел аръягындагы бу җирләрдә татар авыллары төзү идеясен Солтангалиев яклап чыккан иде бит. Аның ярдәме белән Совнаркомның карарын чыгартуга иреште Али Ганиев. Әле съездга кадәр үк республикаларның территорияләрен билгеләү, ызанлаштыру мәсьәләләре буенча Троцкийга да мөрәҗәгать иткән булган Мирсәет хат белән. Троцкийчыларга каршы көрәш тә көчәя. Бу яктан да Солтангалиевкә әллә нинди гаепләр тагып бетерергә мөмкиннәр.

Салих өчен болар бөтенесе дә чит нәрсәләр иде. Ул сәясәттән ерак торган кеше, аның өчен музыка, сәнгать бар. «Сәнгатькә хезмәт итсәм, шуннан артыгы мине борчымый», дип уйлап йөргән көне. Ләкин ул әле сәнгатьнең дә сәясиләштерелгән бер нәрсә икәнен аңлап бетерми иде шул. Бу өлкәдәге эзәрлекләүләр аның өчен әлегә барысы да алда.

«Ил» драмасын Кәрим Тинчурин Әстерханга китәр алдыннан, эштән чыгарылгач язган иде. Сөргендә чакта ул элек үзе чыгарган, бәләкәй составлы труппа белән уйнала торган спектакльләр генә куеп йөрде. Казанга кайтып төшүгә «Ил»не яңа сезонның репертуарына керттерде. Ә сәяхәттән кайткач, алар Сәйдәш белән шул спектакльне эшләргә керештеләр. Режиссёр итеп, Вәлиев-Сульва билгеләнде. Спектакль музыкаль драма итеп куелырга тиеш булды.

«Ил» татар драматургиясендә музыкаль драма жанрын үстерүдә яңа этап буларак кереп калды. Аның музыкаль кереш өлеше, биюләре, андагы «Сандугач» җыры, арияләр – һәрберсе пьесада сөйләнгән вакыйгаларга органик рәвештә ялганып, әсәрнең динамик үсешен тәэмин итеп торалар иде. «Ил»дән соң Тинчурин белән Сәйдәшев бары тик бер генә шундый колачлы әсәр иҗат итәргә өлгереп калдылар. Ул да булса «Кандыр буе» музыкаль драмасы. Аннан соң шул ук 1932 елда «Тургай» спектакле чыкты. Ләкин анысының пьесасын Тинчурин Риза Ишморат белән берлектә язганнар иде. Ул гади спектакль буларак кына барды. Сәйдәш аның музыкаль бизәлешен генә эшләде.

Ләкин Салих 1929 елны үзенең тормышындагы иң югары, кульминацион биеклеккә күтәрелгән ел дип исәпли. Һәм менә хәзер, ул театрдан куылып, бернинди эшсез, тамак туйдырыр өчен табыш китерә торган чыганаксыз калган бер көндә әнә шул үзенең иҗатының һәм популярлыгының иң биек ноктасына күтәрелгән елны хәтергә төшерде. Бу ел аның өчен гаять каршылыклы, авыр ел булды. Популярлык белән бергә ул аның гаилә тормышында зур фаҗига дә алып килде. Гаиләнең нигезен җимерә торган тетрәндергеч фаҗига!

«Ил»нең премьерасы булган шатлыклы көн иде. 26 ноябрь. Кызыл Байракка су юлының өзелгән чагы, пароходлар йөрми, ләкин әле боз рәтләп катмаган. Иделне турыдан боз өстеннән генә кичәргә иртәрәк. Шиһап җизнәсе спектакльдән соң артистларны өйгә алып кайтып, матур гына банкет шикелле нәрсә оештырып алды. Салихның шулай матур итеп, ихластан шатланып, дусларына карап сөенеп, тормышның матурлыгына хозурланып утырган соңгы кичәсе булгандыр бу, мөгаен. Шушы утырышудан соң аларның тормышында кискен борылыш башланасын, дөньяның асты өскә киләсен беркем дә башына да китермәгәндер.

– Барыгызны да Кәрим әфәнденең театрыбыздан аерылып, ерак Әстерхан якларында яшәп кайтканнан соң куелган беренче спектакле премьерасының уңышлы үтүе белән котлыйм! – дип башлады сүзен Шиһап Әхмәров.

Шунда Кәрим «Ил»нең язылу тарихын сөйләп алды.

– Кайбер дусларның тырышлыгы белән мине егерме җиденче елда эштән куып чыгардылар бит. Йөрим шулай, нишләргә инде дип, кая барып бәрелергә, нәрсә белән шөгыльләнергә белмичә аптырап. Заһидә җиңгәгез әйтә: «Әйбәт булды әле бу. Югыйсә иртән иртүк күзеңне тырнап ачасың да эшкә дип чыгып йөгерәсең. Кич соң гына кайтып, төн утырып язасың-язасың да иртән тагын шулай торып чыгып китәсең. Күргән дә юк иде үзеңне. Язарга вакытың күп булыр хәзер. Тик утыр өйдә язып», – ди. Үзем дә башта шулай уйлаган идем. Тик алай түгел икән шул. Берни керми башка өйдә утырып. Кулга китап алып карыйм, укып булмый, күз

йомыла да, йоклап китәм. Шуннан, малай, эшкә урнашты бит абзагыз. Эшнең дә ниндие диген әле. Тик утыра торган эш. Эш эзләп йөри торгач, Политпросветка барып кердем бит. Штатта өч кенә кеше монда. Берсе – Вафа Борнаш. Икенчесе аның сәркатибе, өченчесе – мин фәкыйрегез. Эш юк, зарплата бара. Тукта мин әйтәм, язу белән шөгыльләним булмаса. Төнлә генә язып өйрәнелгән, башта бик авыр булды. Аннан тотындым берзаман язарга. «Ил»не менә шунда сырлап ыргыттым, өч көн эчендә. Тик дуслар монда да тынгы бирмәделәр. Моннан да сөреп чыгардылар. Киттем шулай, үзегез беләсез, театрның иң кәттә артистларын ияртеп Әстерхан якларына. Рәхәт яшәдек без анда. Заһидә җиңгәгезгә уылдык гына җибәреп яттым. Минсез театрның эше бармаган. Чакырып кайтардылар ике елдан соң.

– Менә бит! Файдага булган дусларыңның синең өстән язулары. Бер дигән спектакль чыгардыгыз. Зифабануның «Сандугач»ы гына ни тора! Әйдә, Галия, сузып җибәр булмаса шул «Сандугач»ны.

– Тукта, Салих, балалар йоклыйдыр бит. Уятырбыз, – дип каршы төште Кайбицкая.

– Алар ияләшкән инде. Мин дә төне буе фортепиано артында утырам бит, эштән кайткач, спектакльгә музыка язам дигән булып.

– Әйдә, әйдә, Галия, җырла, – дип, рөхсәт дигән шикелле сүзгә Шиһап абзый кушылды.

– Оркестр юк инде, фортепианога гына җырлыйбыз, – дип, Салих инструмент артына барып утырды.

Беренче аккордлар яңгырауга, Галия сандугачның үзеннән дә уздырып, моңлы итеп җырлый да башлады.

– Җир җиләге ачы була, ачы була
Үз вакытында, үз вакытында пешмәсә, шул.
Җәйге җилләр яшь йөрәккә шифа була,
Сөйгән ярың каш уйнатып эндәшсә, шул.
Сандугач, кошчыгым, күңелем ач син бүген.

– Браво! Афәрин! – дип, Шиһап кул чаба башлауга, аңа башкалар да кушылдылар.

– Эштән куылган башыгыз белән курыкмыйча, нинди гүзәл әсәр язгансыз, Кәрим абый, – дип, Галия үзенә әйтелгән мәдхия сүзләрен Тинчуринга күчерергә теләде. – Ничек итеп шундый кешене эштән куарга була?!

– Кәрим абый шундый ул. Ул әле мине дә башлы-күзле итте, – дип, Салих Тинчуринга рәхмәт яудыра башлады. – Югыйсә күпме йөргән булыр идем әле шулай каңгырып, – дип, янында утырган Сафиясенең иңбашыннан кочып алды.

– Сөйлә әле, Кәрим, ничек итеп миңа өйләнүең тарихын, – дип, көлеп җибәрде Гөлсем Болгарская.

Табын артындагылар башта аптырашып, Гөлсем белән Кәримгә карашып алдылар.

– Колмәмәтең көнләшмәсә, рәхәтләнеп, – дип көлеп җибәрде Тинчурин да, Гөлсем белән икесе генә белгән ниндидер серле вакыйга турында искә төшереп.

Колмәмәтнең чын исеме – Хәмит Азимов – Гөлсемнең ире. Бу мәзәк хәл турында ул бик яхшы белә иде. Шуңа күрә елмаеп кына:

– Нәрсәсенә көнләшәсең аның, – дип куйды. – Заһидә ханым көнләшә димәсәң, сөйләп җибәр.

– Моннан бер ун еллар элек булды инде ул хәл, – дип сөйли башлады Тинчурин. – Без әле Заһидә белән өйләнешмәгән идек.

– Таныш та түгел идек әле, – дип төзәтеп куйды Заһидә.

– Әйе. Минем карт егет чак. Берзаманны Казанга авылдан әни килеп төшмәсенме? Эзләп тапкан бит, әдрисемне, торган җиремне дә белмәгән килеш. «Ничек таптың, әни?» – дим. «Әртис икәнеңне әйттем дә, барабыз китерде дә куйды», – ди. Ул чакта «Шәрык клубы»нда эшләп йөри идек әле. И тузына, и дулый бу. «Нәрсә булды, әни?» – дим. «Кая марҗа хатының? Кемнең рөхсәте белән өйләндең аңа?!» – ди. Башта аптырап калдым инде. «Кем әйтте аны?» – дим. «Сугыштан яраланып кайтып барышлый күрше авыл егете безгә тукталып, шул сөйләде. Кәримнең театрда эшләгәнен белеп, эзләп табып янына кердем, ди. Бик матур бер марҗа кызына өйләнде. Туйларында үзем дә булдым, ди. Марҗаның исеме Болгарская дип әйттеләр, ди. Туйлары бик күңелле булды. Кунаклары бар да Казанның байлары иде. Акча түләп кенә кереп, ашап-эчеп утырдылар, ди». Ул да түгел, әни марҗа Болгарскаяның үзен дә эзләп тапкан. «Менә шушы марҗага өйләнгәнсең», – дип, Болгарскаяны тотып күрсәткәч, эшнең нәрсәдә икәнен аңладым. Герман сугышында яраланып кайтып барган ул солдат чынлап та мине эзләп, «Шәрык клубы»на килеп чыккан иде. Күреп китсен минем нәрсә белән шөгыльләнгәнне дип, Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр» спектаклен күрсәтеп, озатып җибәргән идем. Шунда минем Незнамов ролендә Кручинина-Болгарская белән өйләнешүебезне чын дип кабул иткән булган. Авылга кайтып, шуны сөйләгән дә, әни ышанып, мине орышырга Казанга килеп җиткән иде.

– Элегрәк була торган иде шул андый хәлләр. Ышанып карый иде халык спектакльне. Чынлап булган хәл итеп, – дип куйды Гөлсем Болгарская. – Бу әле ул кадәр көлкеле хәл түгел. Бер елны Донбасска баргач, шахтёр егетләр «Җырчы Гайшә» спектаклен караганда, Гайшәне мыскыл итәргә теләгән Галләм Саттарны сәхнәгә менеп дөмбәсләргә үк тотынганнар. Артистлар спектакльне туктатып, ялына-ялвара торгач кына туктаганнар. Менә анысы көлке.

Алар шулай төрле көлкеле хәлләрне искә төшереп, шактый озак утырдылар. Төн уртасы җиткәндә генә таралыштылар. Салих белән Сафия беренче каттагы бер як ишеге бакча ягына чыга торган бүлмәдә торып калдылар. Җизнәсе белән Әминә апасы үзләренең икенче каттагы бүлмәләренә менеп киттеләр. Әниләре Мәхүпҗамал белән Зөләйха һәм балалар күптән йоклыйлар иде инде. Өй тынып калды. Салих чишенеп, урынга ятса да, күзенә йокы кермәде. Бердән, спектакль үзе һәм икенчедән, спектакльдән соң булган бу утыру аны беркадәр ярсыткан иде. Ул тәмәке тартып, бераз тынычланып булмасмы дип, бакча ягына чыкты. Шул вакыт урам ягыннан машина килеп туктаган тавыш ишетелде. Кемнәрдер капка дөбердәттеләр. Тавышка беренче катта яшәүче, китап нәшриятында эшләүче Гыйльман Гобәйдуллин уянды.

– Кайсы йөри инде бу кара төндә. Берәрсе әйберсен-мазар онытып калдырган, ахры. Иртәгә килеп алыр иде әле, – дип сукрана-сукрана, иңенә пәлтәсен салып, капка ачарга чыкты. Ул капкага барып җиткәч: – Кем бар анда? – дип сорады.

– Ачыгыз, без ОГПУдан, – дигән тавыш ишетелде.

– Нинди гпудан? Бу вакытта җүнле кеше йоклый, кеше капкасын какмый, – дип сукранды Гыйльман. Үзе капканы бикләгән эшермәне тартты.

Капкадан кара мех якалы күн куртка кигән өч егет килеп керделәр.

– Гражданин Әхмәров сез буласызмы?

– Юк, мин түгел.

– Ул биредә торамы?

– Әйе. Икенче катта яши. Үтегез, әнә керә торган ишекләре, – дип, Гыйльман Шиһап Әхмәровлар квартирасына керә торган ишекне күрсәтте.

Кемнәрнеңдер капка шакыганын әле йокларга ятарга өлгермәгән Шиһап ишеткән иде. Ул икенче каттагы урам якка караган тәрәзәдән «Кара козгын» килеп туктаганын һәм аннан өч егетнең алар капкасын какканын күрде. Аның төнлә килеп ОГПУ егетләренең кара машинада кемнәрнедер алып киткәләгәне хакында ишеткәне бар иде. Әмма үзе артыннан да шулай тиз килеп җитәрләр дип уйламаган иде. Ул керүчеләр шакыганчы ук баскычтан төшеп, ишекне ачты.

– Сез Шиһап Әхмәровмы? – диде егетләрнең берсе.

– Әйе, мин булам.

– Киенегез һәм әйдәгез безнең белән.

– Кая?

– Баргач күрерсез. Менә сезне кулга алу турында постановление, – диде аның белән сөйләшүче егет һәм кесәсеннән кәгазь чыгарып, күзенә якын китерде.

Ул арада алар янына эчке күлмәктән генә, башына кара шәл бөркәнгән, аягына киез итек кигән Әминә килеп басты.

– Нинди кешеләр бу, Шиһап? Кая алып китмәкче булалар?

– Мине алырга килгәннәр. Борчылма, тикшерерләр дә җибәрерләр, – диде Шиһап.

Салихлар сәяхәттән кайткач кына сөйләгән иде җизнәсе, хәлләр катлауланып тора дип. Салих та җизнәсен алырга шулай тиз килерләр дип уйламаган иде. Салих, тәмәкесен ташлап, алар янына чыкты.

– Нинди гаебе бар бу абзагызның, бәгырь? – дип сорады ул кулына кәгазь тотып торган егеттән.

– Сез кем буласыз? – диде егет сорауга каршы сорау белән.

– Мин аның каенише.

– Исем-фамилиягез ничек?

– Салих Сәйдәшев.

– Композитор Сәйдәшевме?

– Әйе, композитор Сәйдәшев.

– Борчылмагыз, Салих абый. Безне менә бу иптәшне алырга җибәрделәр. Анда тикшерерләр. Гаебе булмаса җибәрерләр.

– Гаебе зур булырга охшаган, – диде икенче, арттарак торган егет.

– Нинди гаебем булсын? Аңлашылмаучылык бу.

– Ярар, күп сүз көрәштереп тормагыз, киенегез дә, киттек.

Шулай дигәч, Шиһап өйгә кереп, өс киемнәрен, бүрек белән пәлтәсен дә киеп, егетләр артыннан урамга чыкты.

– Борчылмагыз, гаебем юк. Тикшерерләр дә җибәрерләр, – диде ул, аптырашта калып, тораташ булып каткан хатынын тынычландырып.

Шиһап җизнәсен алып киттеләр. Өй тып-тын булып калса да, аннан тынычлык качты. Әнкәйләре һәм балаларыннан кала барысының да йокылары ачылды. Күршеләре Гыйльман Гобәйдуллин да бакча якка чыгып, тәмәке тартып керде. Алдагы төнне китап нәшриятыннан да директорны Черек күлгә алып киткәннәр иде.

Салмак кына кар яварга тотынды. Быел инде ноябрь ахыры килеп җиткәндә дә, кар күренми иде әле. Бу кышның беренче кары иде. Менә ул тагы да көчәеп, ишелеп үк яварга кереште. Биш-ун минутта бөтен бакчаны, ишегалдын ап-ак юрган белән каплагандай итте. Башка вакыт булса, беренче кар дип сөенер, шатланыр идең. Ә бүген моңа һич кенә дә сөенәсе килми. Күңелне нindидер бер шом, афәт хисе биләп алды. Кешеләр унсигезенче елны Казанны ак чехлар басып алган көннәрдә шундый шомлану хисе белән яшәгәннәр иде.

Нindидер бер мәгънә бар шикелле күренде Салих өчен бу карда. Әйтерсең лә, ул тормышның бөтен шатлык-борчуларын, сөенеч-көенечләрен хатирә итеп кенә калдырып, шушы ак юрган астына каплап куйды да тормышның яңа бер дәверен яза башлау өчен ап-ак кәгазь бите булып күз алдына килеп басты. Ә ул дәвер шундый шомлы да, билгесез дә, әлегә әйтелмәгән һәм җавабы нинди булачагын гөманларга да мөмкин булмаган табышмак та кебек тоела иде.

## 18

«Кара козгын» урамнар буйлап әллә ни озак бармады. Берничә тыкрык борылды да нindидер таш дивар буена килеп туктады. Шиһап үзен Черек күл изоляторына китергәннәрен аңлады. Аны дымлы, тынчу, караңгы камерага кертеп бикләделәр. Камера шактый иркен булып чыкты, ахры, ул анда үзеннән башка да кешеләр барлыгын шәйләде. Ул ишек янындагы буш сәндерәгә барып утырды. Уйламаганда, көтмәгәндә килеп чыккан бу хәлдән әле һаман исенә килә алмыйча беркадәр утырганнан соң өстеннән пәлтәсен салып, сәндерәгә түшәде дә аягыннан киез итеген дә салып тормыйча сузылып ятты. Аның миен төрле уйлар игәүләде. Тәгаен «солтангалиевче»лектә гаеплиләрдер, дигән уй өстенлек итте. «Милләтче» дигән ярлык тагачаклар инде. Милләтең турында уйлауның ни гаебе бар икән соң? Татар авылы оештыруның ни гаебе бар? Рус авыллары да бар бит. Беркем дә аларны милләтчелектә гаепләми. Әллә соң Кызыл Байракка русларны да күчереп утыртырга кирәк булганмы?

Күрше сәндерәдә ятучылар да йокламыйлар иде бугай. Шиһап шикелле әйләнгәләп-тулгангалап ятучылар да күренә. Кайсыдыр ыңгырашып-ыңгырашып ала. Кайсыдыр начар төш күрә, ахры, йокы аралаш нидер сөйләнә.

– Син кем? – дип дәште аңа ярымпышылдап кына күрше сәндерәдә ятучыларның берсе.

– Әхмәров мин. Үзара ярдәм банкы идарәчесе, – диде Шиһап.

– Шиһап, синмени? – диде сорау бирүче.

Шиһапка аның тавышы таныш булып тоелды.

– Вәли, әллә синме? – дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды ул.

– Мин шул. Кичә тотып ябып куйдылар.

Бу Татарстан китап нәшрияты директоры Вәли Шәфигуллин иде. Аның кулга алынуы турында кичә Шиһаплар белән бер йортта, беренче катта яшәүче Гыйльман Гобәйдуллин Мирсәет Солтангалиев турында сөйләшкәндә, сер итеп кенә әйткән иде. Вәли Шәфигуллин – Галимҗан Ибраһимов белән берлектә китап нәшриятын оештыручыларның берсе. Әле 1917 елның апрелендә үк большевиклар партиясе сафына кергән, Малланур Вахитов белән бергә Мөселман социалистлар комитетын оештыруда катнашкан, актив журналист-матбагачы. Менә шул кеше белән бер үк көндә диярлек кулга алынган булып чыкты Шиһап.

– Ни өчен кулга алдылар соң? – диде Шиһап.

– Мирсәет Солтангалиевкә совет хөкүмәтенә каршы эш алып баруда ярдәм иткәнсең дигән гаеп тагалар.

– Ә Солтангалиев нинди эш алып бара икән соң советка каршы?

– Аны бит егерме өченче елда ук кулга алып утыртып куйганнар иде. Шуннан соң берничә елдан азат итеп, хөкүмәт тирәсендәге бөтен эшләрдән читләштерделәр. Тормыш алып барырга кирәк. Азмы-күпме ярдәмебез булыр, гонорарын алыр дип, Ленин әсәрләрен татарчага тәрҗемә итәргә биргән идек үзенә. Менә шуның нинди гаебе бардыр инде? Ә сине ни өчен яптылар?

– Белмим. Милләтчелектә гаепләргә җыеналар, ахры. Иртәгә әйтерләр. Шуннан да зуррак гаеп уйлап тапмасалар тагын.

– Ярар, йокларга тырыш. Югыйсә иртәгә кыен булачак. Бик зәһәр кыланалар. Совет властеның иң куркыныч дошманнарын тотып япканнар диярсең.

Шулай диде дә Вәли Шәфигуллин тынып калды. Шиһап та, «Йокларга кирәк инде. Иртәгә күренер. Сорау алулар башланганчы йоклап калырга кирәк», – дип, пәлтәсенең бер ягын өстенә ябып йокларга тырышып карарга булды.

Ләкин күзен йокы алмады. Ул бөтен узган гомер юлын уйлап ятты. Кырык җиде яшь бит инде аңа. Бу яшьтә кешене сугышка да алмыйлар. Ә ул «халык дошманы» булып, совет төрмәсенә ябылды. Совет властe өчен күпме хезмәт куйды ул. Егерме яшеннән «Шәрык клубы»нда халыкка мәдәни хезмәт күрсәтте, әдәби-музыкаль кичәләр оештырып, халыкның зәвыгын, аң-белемен күтәрәм дип тырышты. Наширлек итте, «Мәктәп» журналын чыгарды. Тукай, Фатих Әмирхан, Сәгыйть Рәмиев, Гафур Коләхмәтов, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимовларның китапларын бастырды. Инде менә җиде ел Идел аръягында авыллар салып, аз җирле авылларның крәстияннәрен шунда күчереп, милләт өчен изге эш башкарып ята. Сәнгать әһелләре шунда ял итә, язучылар иҗат белән шөгыльләнә. Шул хезмәтләре советка каршы эш булып санала микәнни?!

Икенче көнне камерадагыларның барысын да берәм-берәм сорау алу камерасына чакырттылар.

Шәфигуллин әйткәннәр рас булып чыкты, сорау алучы Миңнеәхмәт Гыйльметдинов бик рәхимсез кыланды.

– Йә, сөйләп җибәр, ничек итеп Солтангалиев белән берлектә халыкара империализм тегермәненә су коясыз анда?!

Шиһап башта сорау алучының нәрсә турында әйтергә теләвен аңламыйча торды.

– Нинди халыкара империализм? Нинди тегермән? Сез ялгышасыз бугай. Мин бит сәяси эшләрдән бөтенләй читтә яшим.

– Син үзең ялгышасың, контра! Үзәгендә яшисең син сәяси эшләрнең. Шуны оештыручы син!

– Соң, мин бит Югары Ослан районында буш яткан җирләрдә авыллар салу белән шөгыльләнәм.

– Ә бу нәрсә, сәясәт түгелмени? Бу бит милли сәясәт! Син бит милләтче! Син бит анда татарларны бер тирәгә туплап ятасың. Үзегезнең сәяси оешмагызны төзеп ятасыз, авыл салабыз дигән булып. Әле шунда бер тирәгә язучыларны, журналистларны, артистларны туплап, оешмагызның җитәкче үзәген оештыргансыз!

– Сафсата.

– Бирермен мин сиңа сафсатаңны! – дип, Гыйльметдинов урыныннан сикереп торды һәм Шиһапның эченә китереп типте. – Контра!

Шиһап тәгәрәп китте.

– Тор! Нишләп ятасың анда! – дип кычкырды Гыйльметдинов.

Шиһап кинәт тибүдән тыны кысылып, беркавым тора алмыйча ятты. Аннары өстәл янында торган урындыкка барып утырды.

– Үрә бас! Кем кушты сиңа анда утырырга?! – дип кычкырды тикшерүче.

Шиһап торып басты һәм көчкә тын алып, аның намусында уйнап оялтырга теләп:

– Мин синең атаңнан да өлкәнрәк кеше, нинди намус белән шулай олы кешегә тибә аласың син, ә?! – диде.

– Минем сиңа тибү генә түгел, атып үтерергә дә хокукым бар!

– Судсыз-нисез кеше атарга беркемгә дә хокук бирелмәгән әлегә.

– Алайса, әйт дөресен: халыкара империализмга хезмәт итүче солтангалиевчеләр оешмасында тагын кемнәр бар?

– Мин берниндидә оешманы белмим.

– Беләсең, кабахәт! Солтангалиевне беләсең бит?!

– Беләм.

– Белгәч, нишләп аның оешмасында тагын кемнәр булуын әйтергә теләмисең?!

– Мин андый оешманы белмим.

– Әйтерсең! Әйттерербез!

Гыйльметдинов шулай диде дә ишек артында торган конвойга кычкырды:

– Шәйдуллин!

Ишектә табак битле, кызыл чырайлы, мир үгезе кебек симез егет күренде.

– Алып чыгып кит. Карцерга! Әйбәтләп эшкәртегез. Белмим дигән нәрсәләрен исенә төшерерлек булсын!

Кыйналудан башы-бите җәрәхәтләнеп, кара янып, канга батып беткән, эченә тибүдән бавыры, бөерләре авыртуга түзә алмыйча тәмам кешелектән

чыккан Шиһапны камерага кич җитәрәк кенә ике конвоир култыклап өстерәп кайтарып ташладылар.

– Нишләткәннәр кешене, – диде Вәли, конвоирлар ишектән чыгып киткәч Шиһап янына килеп. – Гаебен танымаган, беркемне дә сатмаган, димәк.

– Эһ, су бирергә иде моңа. Хәлен тәмам алганнар, кабахәтләр, – диде икенче сәндерәдә ятучы тоткын.

– Ярамый, су бирергә ярамый. Тибеп эчәкләрен өзгәләп бетергән булырга мөмкин. Мин врач кеше. Беләм. Ятсын шулай, бераздан хәл керсә, үпкә-бавырына зыян килмәгәне ачыкланыр.

Авыртуга түзә алмыйча ыңгырашып ята торгач, Шиһап йоклап китте. Тавыш-тыны булмагач, Шәфигуллин аның янына килеп, пульсын тикшереп карады.

– Тибә. Йоклый мескен. Карцерда кыйнаганнар. Шәйдуллин дигән кабахәт нык кылана. Шуның эше булырга тиеш, – диде табиб. – Мине дә шул дөмбәсләде. «Нигә алай вәхшиләрчә кыйныйсың?» – дигәч, «Мин – батрак малае. Сезнең кебек буржуй калдыкларына шул кирәк», – дип җавап бирде. «Мин бит врач, кешеләрне дәвалыйм», – дигәч, «Син патша заманында укыгансың. Ул вакытта минем ише батрак малайларына уку мөмкин булмады. Синең кебек буржуй балалары гына укыды университетларда, – ди. – Революциядән соң чит илгә качып бетте синең кебекләр. Ә син монда калып, диверсия белән шөгыльләнәсең. Яшерен рәвештә корткычлык алып барасың. Синең кебекләрне җир йөзеннән себереп түгәргә кирәк. Халыкара империализмга хезмәт итәсез барыгыз да!» – дип, тагын да ныграк дөмбәсләргә тотынды.

– Менә шуларны дәвалыйбыз, укытып кеше итәбез, шуларга мәдәни хезмәт күрсәтәбез дип йөрисең, ә ул томаналар шуны һич аңларга теләмиләр.

Яңа елга хәтле Гыйльметдинов, Шәйдуллин кебек җансыз башкисәрләрдән никадәрле кыйнатып та, үзләре теләгән җавапны ала алмагач, Шиһап Әхмәровны гыйнвар башында Пләтән төрмәсенә күчерделәр. Монда аны озак тотмадылар. Атна-ун көн дигәндә, СССР Югары суды хәрби коллегиясенең күчмә утырышы биш минут эчендә суд карарын чыгарып, аны биш елга ирегеннән мәхрүм итте. Ике ай буе ирен күрергә зар-интизар булып, аңа кирәк-ярак, кием-салым, ашарына ризык, тәмәке ише нәрсәләр күтәреп төрле төрмәләр буйлап йөргән Әминәгә, ниһаять, Пләтән төрмәсендә иренең РСФСР Җинаять кодексының илле сигезенче статьясы нигезендә биш елга ирегеннән мәхрүм ителүе, аннан соң да биш ел барлык гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителеп, лагерьга озатылуы хакында әйтеп кайтардылар. Шулай итеп, узган елның егерме алтынчы ноябре төнендә бер гаепсезгә кулга алынып, ике айдан артык кайдалыгын, нинди төрмәдә утыруын да белми яшәгән Әхмәровлар һәм Сәйдәшевлар үзләренең кадерле кешеләре белән ун елга аерылыштылар.

Бу вакытта илдә «милләтче-тайпылучылар» өстеннән ачык процесс әзерләнә башлаган иде. Бу процессның беренче җәза күрүчеләре солтангалиевчелектә гаепләнгән төрки-мөселман милләтчеләре булырга тиеш иде. Шиһап Әхмәров та, Вәли Шәфигуллиннар да әнә шушы зур эшнең беренче гаепләнүчеләре, киләчәктә «троцкичылар» дип аталырга тиешле зур махинаның беренче шөрепләре булды. Солтангалиев «троцкийчы»

дип хөкем ителергә тиешле элекке ленинчы большевикларның иң беренче корбаны булырга тиеш иде. ОГПУ алдына Солтангалиевне гаепләү өчен ул оештырган яшерен оешманың булуын фаш итәргә һәм ул оешма әгъзаларын юкка чыгарырга дигән куркыныч бурыч куелды.

Әхмәров та, Шәфигуллин да, егерме тугызынчы елда «халык дошманы» дип кулга алынганнарның берсе дә бу мәкерле план хакында, әлбәттә, белмиләр иде. Аларның берсе генә дә гаепләрен танысалар-танымасалар да, азат ителергә тиеш түгел, кимендә ун елга ирегеннән мәхрүм ителергә, яисә атып үтерелергә тиеш булды. 1929 елгы кулга алулар әле бу вәхши планның беренче дулкыны гына. Тагын берничә елдан, ленинчы большевиклар Бухарин, Каменев, Зиновьев, Троцкийлар берәм-берәм юк ителеп беткәнче бу дулкын әле берничә мәртәбә кабатланырга тиеш иде. 1929 елда Татарстанда «солтангалиевчелек»тә гаепләнеп, 76 кеше кулга алынды. Шуларның егерме бере, 1918–1920 елларда большевиклар партиясенә кергән иң актив революционерлар, атарга хөкем ителде. Ә калганнары төрле срокларга лагерьларга җибәрелде. Шул исән калганнарның берсе Шиһап Әхмәров ун елга ирегеннән мәхрүм ителеп, биш елын төрмәдә, калган бишен лагерьда үткәрергә тиеш иде. Соловкига сөрелүчеләр арасында Мирсәет Солтангалиев үзе дә бар иде. Троцкийны юк итү операциясенә фәрман бирелгәч, 1939 елның декабрендә СССР Югары судының хәрби коллегиясе Солтангалиевне атып үтерергә дигән хөкем карары чыгарды.

**19**

Шиһап җизнәсенең «халык дошманы» дип кулга алынуы һәм хөкем ителүе Салих өчен зур фаҗига булды. Ул моны акылы белән дә, күңеле белән дә аңлый һәм кабул итә алмады. Ничек инде шундый кеше, халык бәхете өчен җанын фида кылырга әзер торган большевик халык дошманы булсын? Менә хәзер, үзе кирәге юк дип, эштән кыскартылгач, бу җәмгыятьтә артык дип табылган иң беренче якын кешесе җизнәсе Шиһап Әхмәров булган икән дигән уй килде аның башына. Шушы җәмгыятьне төзү өчен бөтен җанын, тәнен бирергә әзер булган кеше аның өчен бөтенләй дә кирәксез, артык кеше икән ләбаса! Башка сыймаслык, зиһен кабул итмәслек гаҗәп хәл. Артык кеше.

Бәлки ул ялгышадыр. Бәлки бу җәмгыять Ленин төзергә уйлаган, изелгән халыкка – ирек, крәстиянгә – җир, эшчегә азат хезмәт алып килергә тиешле социаль революция башка юлдан киткәндер. Ленин уйлаган юлдан түгелдер. Ләкин ничек итеп Сталинга ул алып барган юлның ялгышлыгын, дөрес юлның башкача булуын аңлатырга соң? Ник бу илдә бары тик ул гына дөрес уйлый да, аның белән килешмәгән һәркем дошман соң? Халык дошманы.

Салихның миен әнә шундый хәтәр уйлар бимазалады. Әйе, хәтәр уйлар иде бу. Әгәр дә берәрсе алдында шулай уйлаганыңны сүз белән әйтсәң, үзеңнең дә халык дошманына әйләнгәнеңне сизми дә калачаксың. Ләкин инде соң, хакимият башында бөек Сталин утыра. Бөтен ил аны дөрес юлдан алып баручы юлбашчы дип, халыклар атасы дип саный.

Салихның үз баш өстендә дә язмыш кылычы шактый уйнаклап алды ул елларда. 1931 елның 8 декабрендә Сәйдәшнең иң якын дусларыннан берсе Һади Такташ вафат булды. Шул елны гына аның «Камил» дигән драмасы уйналган иде. Салих аның музыкаль бизәлешен эшләде. Хәтерендә

әле, инкыйлаб елларындагы аталар белән балалар арасында киеренке мөнәсәбәтләр турында бәян итүче бу әсәрнең сәхнәгә менүен бик теләгән иде Такташ. Аңа хәтле алар Такташның «Күмелгән кораллар» драмасын чыгардылар. Шагыйрь буларак, халыкны авызына каратып торган Такташ, сәхнә әсәрләре иҗат итү ягыннан да зур уңышларга ирешәсе драматург иде, яшьли китеп барды шул. Кем белә, тәнкыйтьчеләрнең шулай утка тотулары да йөрәк итен ашагандыр мескеннең. Бигрәк тә «Яңалиф» журналында драматурглар белән сәхнә әсәрләре өчен музыка язучы композиторларга камчы күп төште. Белгәне дә, белмәгәне дә, аңлаганы да, аңламаганы да язды. Төрлесе булды. Сәйдәшнең бигрәк тә хәтерен калдырган тәнкыйтьче Туфан булды ул чакта. «Яңалиф» журналы биргән анкета сорауларына җавап язганда, тетмәләрен тетте Туфан драматурглар белән Сәйдәшнең. Әйтерсең лә, музыка өлкәсендә тирән белемгә ия зур белгеч. Менә хәзер, театрдан куып чыгарылгач искә төшерә дә Салих Туфанның ул җавапларын, хәзер ул үзе укып караса, ни дияр иде икән(?) дип уйлап куя. Үзе шикелле үк «акыллы баш»ларның тәнкыйте аркасында каядыр сөргендә ята хәзер мескен.

«...Пентатоника пролетариат музыкасы нигезенең ташы да, цементы да түгел, хәзергә шуларның составына катнаша торган бер элемент кына ул. Хәзер көйләр пентатоникадан чыгу юлы белән үсәләр», – ди Туфан. Аныңча, имеш пентатоника ул татар фольклор музыкасында гына яши. Ә хәзерге пролетар музыкасы иҗат итү өчен пентатоника яраклы түгел булып чыга. «Пентатониканың пролетариат музыкасы өчен нигез була алмавы түгел, кимендә бронза чорыннан бирле яшәп тә, җимерелеп җитә алмавы характерлы. Бу биштавышлылык, билгеле музыкаль-фольклорның төп хуҗасы булган хезмәт массасының арттагы гасырлар эчендәге тормышы да «биш тавышлы» гына булуга кайтып кала», – дип акыл сата шагыйрь. «Әллүки», «Тәфтиләү», «Зиләйлүк»ләрнең милләтче интеллигенциянең гимны булулары – бу көйләрнең эчтәлеге вак буржуа карашын сөйли алганга икәне билгеле нәрсә», – дип җиппәрә Туфан. Сәйдәш музыкасына килгәндә ул: «Сәйдәштә иҗат көче бар, ләкин пролетариат проблемалары өстендә тикшеренми. Шунлыктан, әсәрләрендә – әйтик, гаскәри маршында – халтурага, «Шәрык балеты»нда фокстротка якынлашып, хаталар ясый», – ди.

Хәсән Туфанның мондый акыл сатуларын аның якын дусты Такташ та яратмады ул чакта. Аның: «...Сәйдәшнең музыкаль драмаларга язган ария һәм башкалары шуларның антихудожестволы, күпчелеге яраксыз эчтәлекле текстларыннан күп өстен. Киресенчә, шул ук Сәйдәшнең маршлары эчтәлекне бирү ягыннан байтак түбән торалар», дигән сүзләре Такташ өчен дә, Сәйдәш өчен дә башларына күсәк белән тондыру белән бер иде.

Эх, Туфан, Туфан. Кайларда йөрисең икән син хәзер? Ул утызынчы еллардагы бу акыл сатуларың үз башыңа дөмбәс булып төштеләр дип уйламыйсың микән?

Язучылар, журналистлар язар инде, аларга акыл сатарга гына булсын. Әле композитор дип саналганнар да бер-берсенең башын ашый бит. Латыйф Хәмиди дигән бер егет «Кызыл Татарстан» гәзитәсендә: «Сәйдәш – вак буржуаз композитор. Үзенең спектакльләргә язган көйләрендә һаман да шул патша заманында җырланган фольклор җырлардан ерак китә алмый», – дип язган, хәерсез.

Такташның үлеме көтмәгәндә һәм сәер булды. Бернинди авыруы да юк иде кебек. Һәрхәлдә, зарланмады. Такташ, имеш, тифтан үлгән, диделәр.

Үләр алдыннан гына Такташ солтангалиевчеләрне гаепләп, шигырь язды.

...Бер авылда яшь бер комсомолның
Канлы тәне кырдан табылган...
Укыгансыңдыр...
Ул эшне мин синең кулың белән
Эшләнгән эш диеп карадым,
Һәркөн булып торган шундый корбаннарны
Синең корбаннардан санадым.
Чөнки,
Син, хамелеон, төсең алмаштырып,
Безнең арабызда калгансың;
Кулакларны яклап һәр эшеңдә,
Җимрү юлын алып баргансың.
Без көрәштә булган һәр уңышны
Йөрәк каны биреп алганда,
Мең авырлык белән ял итмичә,
Соңгы җиңүләргә барганда, –
Син кулыңны биреп, оялмыйча,
Солтангалиевтәй этләргә,
Көрәшкәнсең,
Һәрбер адымыңда
Таяк тыгып безнең эшләргә.
Без бүгеннән дошман!
Дуслыгымны саклар өчен
Йөрәгемдә бер хис тапмадым;
Бел!
Бүгеннән соң
Син һәм синең кебекләргә
Пуля саклап йөртә башладым.

Бу шигырен бер дә яратмады аның Сәйдәш. Беренче күрешкәндә үк үз фикерен әйтмичә калмады.

– Һади дус, менә син солтангалиевчеләрне аяк астына салып таптагансың инде. Минем җизнине дә солтангалиевчелектә гаепләделәр. Димәк, аны да шул исемлеккә теркәгәнсең булып чыга. Болай булгач, сине дус дип атаргамы соң инде миңа хәзер?

– Мин гаепле, Салих. Ас, кис, туна. Нишләсәң дә разый. Куштылар язарга. Язмасаң, үзеңне дә солтангалиевчелектә гаеплибез, диделәр.

– Туфанга да куштылар микән алайса мине вак буржуа композитор дип язып чыгарга? Укыдыңмы Туфанның «Яңалиф»тәге анкета сорауларына җавапларын? Минем тетмәмне теткән.

– Укыдым, Салих, укыдым. Туфан да ялгыша. Ул да шул гаеп тагарлар дип куркудан язган булса кирәк. Аның ул язмасы миңа да кагыла. Минем пьесаларга да музыканы син яздың бит.

Әйе, бик буталчык, болгавыр, аңлашылмый торган заман килгән иде. Язучылар арасында «Җидегәнчеләр» дигән төркем килеп чыкты. Аның җитәкчеләре дип Нәкый Исәнбәт белән Гадел Кутуйны утыртып та куйдылар. Мөсәгыйт дигән журналист туздырырга тотынды барысын да.

Язучылар, сәнгать кешеләре «Кызыл Татарстан» гәзитенең һәр яңа санын кулларына, Мөсәгыйт тагын кем турында язды икән инде дип, котлары чыгып ала торган булып киттеләр.

Куркыныч заман килде. Такташ булып, Такташны куркыттылар.

– Сиңа гына әйтәм, Салих, курка башладым мин хәзер. Гәзитәләрдәге Мөсәгыйт мәкаләләреннән түгел, физик юк итүләреннән куркам. Беләсеңме ни булды беркөн минем белән?

– Ни булды?

– Аттылар миңа. Төнлә язып утырган чакта кемдер тәрәзәдән атты. Ядрә колак төбемнән очып үтеп, шкафка барып тиде. Үтерергә теләүләре булдымы, куркытып алырга гынамы? Куркытулары булды бугай. Үтерергә теләсәләр, үтергән булырлар иде. Ә болай, хәзер куркып яшәргә калды. Менә хәзер ни кушсалар, шуны язарга туры килә.

Бу сөйләшүдән соң Такташның Салихка сер итеп кенә әйткән сүзләре хакында бөтен Казан сөйли башлады. Юк, Салих чыгармады ул сүзне. Такташка атучы кеше Фатыйх Мөсәгыйт икән, диделәр.

Озак та үтмәде, көтмәгәндә, Такташ чынлап та үлде. Аны, имеш, тифтан авырып үлде, дип чыгардылар. Хәтта атып үтерә алмагач, Такташны Мөсәгыйт агулап үтергән икән дигән сүз дә таралды.

Такташны озату мәрәсиме Мәдәният йортында үткәрелде. Мәрәсимне үткәрү буенча махсус комиссия төзелгән иде. Комиссия сайлап-сайлап кына, шагыйрьнең дусларына, хөкүмәт кешеләренә хушлашыр өчен сүз бирде. Ни хикмәттер, якын дусты Кутуйга сүз бирмәделәр. Ә менә Туфан сөйләде. Туфан хушлашты дусты белән. Салихка да сүз бирүче булмады. Хәер, ул теләк тә белдермәде. Аның каравы, мәрәсим буе аның Сакай маршын уйнап торды оркестр. Такташ дус дип йөргән күп кешеләргә рәнҗеп киткәндер кебек. Аны бер Мөсәгыйт кенә, Туфан гына рәнҗетмәде. Аның шигырьләрен пыран-заран китереп, Гомәр Толымбай да, Гомәр Гали дә, Фатыйх Сәйфи-Казанлы да, Галимҗан Нигъмәти дә авыз чайкадылар. Ләкин халык ярата иде Такташны. Мәңгелек юлга озатырга дип, күпме кеше килгән әнә! Мәдәният йортыннан Карл Маркс урамына кадәр өзлексез халык ташкыны агылды аның табуты артыннан. Такташны Арча кыры зираты каршындагы совет хөкүмәте өчен күп хезмәтләр күрсәткән кешеләрне җирләр өчен махсус корылган зиратта салдылар ләхеткә. Җир куенына салыр алдыннан тагын нотык тоттылар. Аннары солдатлар һавага төбәп өч мәртәбә залп бирде.

Китте Такташ. Бу каһәрләнгән дөньяга рәнҗеп китте. Менә хәзер, вафатыннан соң унҗиде ел узгач, эштән куылып, урамда ялгызы басып калгач, Салих шулай каһәрләнгән Такташ дустын искә төшерде. Аны да бит бу җәмгыять читкә какты, ят күрде. Ул да бит Сәйдәш кебек үк артык кеше булды бу тормышта. Салихның күңеле нечкәрде, күзләренә яшь килде, бугазына төер утырды. Бу минутларда ул Горький паркындагы Такташ кабере янында басып тора иде...

## 20

Җизнәсе хәсрәтен Салихның икенче улы туу шатлыгы да оныттыра алмады. 1930 елның 12 февралендә Сафия ир бала тапты. Аңа Нәүфәл дип исем куштылар.

Нәүфәлнең тууы Салих белән Сафия арасындагы мөнәсәбәтләрне киеренкеләндереп җибәрде. Болай да әнисез үскән Альфредка салкын карашлы Сафия үз баласын тапкач, аңа карата тагын да кырысланды. Әле өч яше генә тулып узган малайны энесе янына якын җибәрмәде, аны сөеп иркәләмәде, тәртипсезләнсә, артын чәбәкләргә дә күп уйлап тормый иде. Боларны, әлбәттә, Салих та күрде, шуңа күрә аның да Сафиягә күңеле ятмый башлады.

Гаиләнең башында торган, аның бөтен проблемаларын хәл итүче, гаилә белән җитәкчелек итүче Шиһапның инде тиз генә әйләнеп кайтмаячагы билгеле булгач, асылда Сәйдәшевләр һәм Әхмәровлар гаиләсеннән торган йорт, икегә бүленергә дигән карарга килде. Көннәрнең берендә күршеләре Гыйльман Мәхүпҗамалга шундый киңәш бирде:

– Мәхүпҗамал апай, Шиһап кайтмый бит инде. Бер йортта ике гаилә булып яшәп ятулары җиңел түгел. Йортның үзегезгә тиешле өлешен сатыгыз да, Әминә үз балалары һәм каенанасы белән аерым яшәргә күчсен, сез, Салих һәм аның уллары, хатыны белән аерым яшәргә квартира табыгыз, – диде.

– Шулай итмичә булмас, Гыйльман күрше, – диде Мәхүпҗамал.

Алар шулай эшләделәр дә: йортның үзләре торган өлешен саттылар. Әминә ул акчага үзләренә фатир сатып алды. Салихларга фатир сатып алу өчен акча җитми иде.

– Бер дә борчылмагыз, безнең фатир зур, безгә дә, сезгә дә җитәрлек, – диде Кәрим Тинчурин.

Тинчуриннар ул вакытта Петропавел белән Банк урамнары чатындагы Заһидәнең әтисеннән калган йортта яшиләр иде. Салихны үз туганыдай якын күргән Кәрим квартирасының ике бүлмәсен аларга бүлеп бирде. Шулай итеп, бер-берсен туганнардан да якын күргән ике дус бер түбә астында яши башладылар.

Сезон төгәлләнеп, бөтен гаилә белән Кызыл Байракта ял итә башларбыз дип торганда гына, Тинчурин Салихка яңалык әйтте:

– Бар да тынычланды, гаиләң матур гына яши бирсен, ә синең белән минем алда бер эш тора, – диде.

– Нинди эш тагын? Җәй бит. Ял итәргә кирәк. Шиһап җизнинең Кызыл Байрактагы йорты ятим калды. Шунда барып, бакчасын карарга кирәк. Яшелчә, җиләк-җимешен карап үстерәсе бар.

– Бакча карауч‍ы табылыр. Мәхүпҗамал абыстай үстерер бакчаны. Ә безне бик җитди бер эш көтә.

– Нинди эш инде ул тагын?

– Беләсеңме, бер идея туды башта. Авылларда колхозлаштыру бара бит. Колхоз авылы турында берәр спектакль чыгарып булмас микән. Без синең белән велосипедларга атланыйк та республика буйлап чыгып китик, авыллардан әйләнеп кайтыйк, колхоз темасын өйрәник. Йөри торгач, берәр сюжет килеп чыкмасмы.

– Таптың эш. Шул гына кирәк иде, – диде Салих, уфтанып.

– Күрәсеңме нәрсә бу? – диде Кәрим, корсагын тотып.

– Нәрсә булсын, корсак.

– Корсак шул. Ә ул – хатын-кызның привилегиясе, ир кешедә булмаска тиеш.

– Әлбәттә. Менә бит, миндә юк, – диде Салих, үз корсагын күрсәтеп.

– Көн буе бертөрле тормыштан корсак үсми нишләсен. Менә велисәпиттә Татарстанны әйләнеп кайтсак, корсак та шиңәр, спектакль язарга сюжет та табарбыз.

– Синеке шиңәр, ә мин нишләрмен? Шуның өстенә, минем бер тапкыр да велисәпиттә йөргәнем юк.

– Булмаса, өйрәнерсең. Аның бернинди авырлыгы да юк. Сиңа физкультура булыр. Миңа иптәш тә кирәк бит. Үземә генә күңелсез булыр югыйсә.

Салих әле ризалыгын бирмәгән, хәтта Тинчуринның мондый идеясе барлыгын белми дә, ә ул инде Салихка да, үзенә дә велисәпитләр алып куйган булып чыкты.

– Курыкма, ерак районнарга чыкмабыз, Казан арты авылларында йөреп кайтсак та, пьеса өчен материал җитәрлек булачак. Хәзер һәркайда колхозлашу бара. Җитмәсә «Правда» гәзитәсендә Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» дигән мәкаләсе басылганнан соң колхозлардан чыгу күренешләре күбәйгән. Колхоз оештыру өчен шәһәр предприятиеләреннән коммунист эшчеләрне авылларга җибәрә башлаганнар. Кулаклар нык каршы тора, ди. Менә шуларның барысын үз күзләребез белән күреп, колхозлашуның ничек баруын өйрәнеп кайтсак, бер дигән музыкаль драма эшләп чыгарырбыз дип уйлыйм.

– Ярый алайса, күндердең. Үзебезнең Дөбъяз районыннан башлыйк эшне. Туган авылларда да булырбыз, – дип ризалашты Салих. Аның күптән инде әтисе туган Өбрәдә булганы юк, әнисе ягыннан бабасы Миңлебай туган Битаманны да бер күреп кайтасы килеп йөри иде.

– Ситдыйкны да алыйк үзебез белән. Ул бит без барасы Дөбъяз янындагы бер авылдан. Ничек әле исеме? Бер агач бугай инде.

– Әйе шул, Чыршыдан.

– Чыршыда да колхоз төзелгәндер бит. Безне авылы белән, авылдашлары белән таныштырыр.

– Шәп идея! Риза булыр микән соң? Аңа да велисәпит алырга туры киләчәк бит.

– Үзе алыр. Аңа йөрисе бит.

Ризалашты Ситдыйк. Алар шулай өчәүләп, Сөхәрикә тау башыннан Кадыш авылы аша Әлдермеш юлы белән Дөбъяз якларына чыгып киттеләр. Сөхәрикә дип, руслар Әлдермеш – Дөбъяз юлы өстендәге Коры Елга (Сухая Река) дип йөрткән бистәне атыйлар иде. Әлдермеш артында гына Өбрә – Салихның әтисе Җамалетдин туган авыл. Анда аның 1921 елда алтмыш яшен дә тутырмыйча үлеп киткән Бикмөхәммәт абыйсының төпчек улы Әхмәт яшәп ята. Әхмәт – әле өйләнергә дә өлгермәгән егерме яшьлек егет. Салих юлдашларын сәфәрне Өбрәдән башларга күндерде.

Бикмөхәммәт абзыйның йорты Өбрәнең Әлдермеш ягыннан кергән үзәк урамының теге башында ук диярлек, үрдә утыра иде. Йорт хуҗасының дөнья куйганына инде ун ел булып килә. Аннан соң өйдә хуҗа булып калган Әхмәтнең Кызыл Армия сафларына алыныр чагы җитеп килә икән.

– Җыен бәйрәмнәре узгач, солдатка каралырга чакырдылар, – диде Әхмәт Салих абыйсына. – Йорт ялгыз кала инде, нәүмиз булып.

– Габидулла абзыйның оныгы Мөхәммәт бар бит әле авылда. Алар күз-колак булыр.

Габидулла абзый дигәне Бикчәнтәй бабайның абыйсы иде.

– Алар бар барын. Аларның да үз тормышлары шул. Мөхәммәтнең этисе Фатыйх абзый да үткән-сүткәндә гел кереп, хәлне белешеп тора, – диде Әхмәт.

– Менә бит, нәселегез корымаган әле. Нигезегез яши, – дип куйды Кәрим.

Әхмәт аларны инде яше җитмешләрнең теге ягына чыккан Фатыйх абзый янына алып барды. Фатыйх кунакларга авыл тарихы турында, аның килеп чыгышы хакында төрле риваятьләр сөйләде; муллаларын искә төшерде. Кәримне ни өчендер тегермән кызыксындырды.

– Бар иде авылда тегермән. Җил тегермәне иде, – диде карт.

– Авылыгызны икегә ярып, инеш тә ага икән бит.

– Әйе, Сая суы ага авыл уртасыннан. Ләкин аның тегермән чарыгын әйләндерерлек көче булмагандыр, күрәсең, авыл байлары җил тегермәне генә корып куйганнар.

– Алай икән, – диде Кәрим. – Ә колхоз? Колхоз нишли?

– Колхоз таралды ул, Кәрим туган, – диде Фатыйх карт. – Чәчүне көчкә оештырып башкарып чыктылар. Яңадан корып маташалар бугай инде.

– Ә үзең? Кермәдеңмени колхозга?

– Миңа нәрсә. Карт бит инде мин. Минем урасы урылган, сугасы сугылган. Яшьләр керсен әнә колхозга. Әхмәт кебек егетләр.

Фатыйх абзыйсының үзенең исемен атап әйтүенә каршы Әхмәт:

– Мин быел солдатка каралам. Аннан кайткач, күз күрер тагын, – дип куйды.

– Дөресен генә әйткәндә, юк нәрсә ул – колхоз, – дип куйды Фатыйх абзый.

Бу сүздән Тинчуринның күңеле шомланып китте. Ул як-ягына, аннан тәрәзәдән урамга карап алды да:

– Нишләп алай дип әйтәсең, Фатыйх абзый? – дип сорады.

– Мин яшьрәк булсам да, кермәс идем ул колхозга. Мескен крәстияннең бөтен малын-мөлкәтен тартып алып, йортында атын да калдырмыйча колхозга тапшырталар. Эрвәлүсие булганда, крәстиянгә ирек бирелә, җир бирелә, диделәр. Хәзер әнә шул җирне киредән тартып алалар. Өй артында унбиш сутый бәрәңге бакчасы калдыралар да, шуның белән шул. Икмәкне уртакка үстерәсе, имеш. Абзарында атың да кешнәп тормагач, ул унбиш сутый бәрәңгене дә көрәк белән казып кына утыртып чыгып була микән ул? Колхозга керергә теләмәгән крәстиянне единоличник дип, хөкемгә тартмакчы булалар. Имеш, кеше яллап эшләтергә ярамый. Кеше ялламыйча ничек эшкәртеп бетерсен ул үз җирен? Ә уртакка эшләп мантып була микәнни? Әнә аръяктагы ялкау Ибрай хөрәсәннең колхозга бирергә ни сыеры юк, ни аты. Шул да колхозга ике атын, биш сыерын биреп кергән күршесе Самат белән уртак малдан файдаланып яшәячәкме? Эшләмәячәк ул колхозда да, кеше белән бер булып. Ялкау бит ул. Безнең Өбрәнең болай да җире юк иде инде. Шул юкны да юк иткәч, нишләсен инде ул мескен крәстиян?

Безнең авылның борынгыдан килгән имам-хатыйбы Җәләлетдин мулла

булган. Аннан соң олы улы Гыйльман муллалык итте. Гыйльман яшьли үлеп китте. Урынына улы Гомәр калган иде. Гомәр мәктәптә укытты, халыкка аң-белем өләште. Дингә каршы көрәш башлангач, шул кешене авылдан сөрделәр. Мәчетенең манарасын кисеп, клуб иттеләр. Өен сүтеп, сәвит йорты ясадылар. Мәктәбендә укыту дәвам итә. Шулмы инде эрвәлүсиенең ярлы крәстиян өчен китергән рәхәт тормышы? Белмим, белмим, озакка бармас мондый тормыш. Без генә күрә алмабыз ничек булып беткәнен.

Фатыйх картның сөйләгәнен дүртесе дә тын да алмыйча тыңлап утырдылар.

Кәрим генә соңыннан «һе» дип көрсенеп куйды.

Өбрәдә кунганнан соң алар Чыршыда булып, Ситдыйк Айдаров туган авыл белән таныштылар. Авылга кергән олы юл өстендә утырган зур гына тегермән игътибарын үзенә җәлеп итте Тинчуринның.

– Егетләр, бер идея туып тора башта, – диде ул. – Күрәсезме, нинди матур тегермән?

– Берәр байдан калган борынгы тегермәндер инде бу, – дип куйды Салих.

– Адайлар тегермәне дип йөртәләр иде аны, – дип, Ситдыйк тегермәннең хуҗасын да тапты.

– Менә шул тегермән тирәсендә корырга була сюжетны. Татар авыллары барысы да су-инеш буйларына утырган. Чыршының суы юктыр, ахры.

– Бар, нишләп булмасын. Чыршы суы дип атала да.

– Мин тагын чыршы агач булгач, чыршы урманы тирәсенә урнашкан авыл булгандыр, дип торам. Җитмәсә, тегермәне дә япан кыр уртасында. Җил тегермәне. Су буйларындагы авыллар тегермәнне суга салганнар, тегермән колачасын шул судан әйләндергәннәр.

– Алай тегермән чыгырын әйләндерерлек түгел шул Чыршы суы. Әнә, күрәсезме теге баштагы чокырны? – дип, Ситдыйк авыл уртасындагы чокырга таба күрсәтте. – Менә шул чокыр төбеннән агып, Сола суына барып кушыла. Сола – Солабаштан агып чыга торган инеш. Солабашта безнең дус Габәши туган.

– Шулаймыни?

– Әйе, аның атасы Хәсәнгата Габәши Уфага киткәнче шул авыл мулласы булып торган. Кабере дә шунда – Кече Солабашта.

– Анда да кереп чыгарбыз әле, бәлкем, – диде Кәрим. – Тәк, менә шул тегермәнне пьесада су буенда итеп күрсәтеп, әйтик, Кандыр суы буенда... шул суны тирәнәйтеп, тегермән колачасын гына әйләндереп калмыйча, электр бирә торган итеп ясарга кирәк. Авыл халкын колхоз төзүче итеп кенә түгел, яңа совет авылын төзүче итеп тә күрсәтергә.

– Кызыклы гына килеп чыгарга тиеш, – дип куйды Салих.

– Менә шундыйрак сюжет: шәһәр предприятиеләренең берсеннән колхоз төзүдә ярдәм итәр өчен җибәрелгән егерме биш меңче коммунист Акбирдинның Кандыр елгасы буенда утырган авылда «Кызыл йолдыз» колхозында майтарган эшләре хакында сүз барачак пьесада.

– Нинди елга соң ул Кандыр? – диде Салих. – Кандыз дигәнен беләм болай, Баулы якларында ага шундый бер инеш. Апас районында Кантур күле бар, Кызыл Тау авылы янында. Зур Күккүз авылы янында Каудырт чишмәсе бар. Кандыр турында бер дә ишеткән юк.

– Эш елга исемендә түгел. Кандыр дигән су юктыр, безнең пьесада булсын. Исемен дә «Кандыр буе» дип куйсак, начар түгел бит?

Ситдыйк Чыршыдан соң Казанга кайтып китәргә ашыкты.

– Мин сезгә Чыршыга да керәбез дигәнгә генә ярдем, абзыйлар. Кайттык, күрдегез Чыршыны. Тегермәнен дә күрдегез. «Кызыл йолдыз» колхозының егерме биш меңче председателе белән дә очраштыгыз. Инде мин китәм. Мине Казанда көтәләр. Без Уфага гастрольгә чыгып китәргә тиеш, – диде ул.

Шулай итеп Ситдыйк Айдаров Казанга кайтып китте. Ә Сәйдәшев белән Тинчурин, көпчәкле атларына атланып, Битаман якларына юл тоттылар.

Битаманнар икәү – Олы Битаман һәм Кече Битаман. Салихның әнисе Мәхүпҗамал – чыгышы белән Битаманнан. Олы Битаманның Хәмидулла исемле кеше гаиләсендә 1834 елда туган Миңлебай абзыйның кызы була. Салих яшьрәк чакларында Насретдин җизнәсе белән дә, әнисенең энеләре Мостафа һәм Мозаффар абыйлары белән дә Битаманга кайткалыйлар иде. Өбрә Сабан туена кайткан җирләреннән, әтисенең абыйсы Бикмөхәммәт тә ат җигеп аларны берничә мәртәбә Битаман Сабан туена да алып баргалады.

Битаманда төзелгән «Алга» колхозы 1931 елда таркалган иде. Райком тәкъдиме белән яңа колхоз председателе итеп Фәтхерахман Усманов исемле яшь егетне сайлаганнар. Кәрим белән Салихны ачык чырай белән каршы алды яшь председатель. Велисәпитләрен сәвит йортында калдырып, үзенең тарантасына гына утыртып, күршедәге Кече Битаман, Бикнарат, Ювас авыллары белән таныштырып йөрде. Бикнаратка җитәрәк берничә яңа йорт салынып ята иде.

– Монысы «Авангард» колхозы, – диде Фәтхерахман. – Халык үткер телле бездә. Авылны Никкүчтем дип йөртә башладылар. Мине дә Пәттери дип кенә йөртәләр.

– Ник алай? – диде Кәрим. – Күчкәннәренә үкенәләрме әллә?

– Шулайрак килеп чыкты. Инде менә йортлар да салып яталар иде. Сталинның «Правда» гәзитендә чыккан мәкаләсеннән соң, безнең «Алга» колхозы тарала башлады да, болар да чыгабыз колхоздан, ник күчтек икән авылдан, дип сөйләнә башлаганнар. Халык шуны элеп алган да, «никкүчтемнәр» дип йөртә башлады үзләрен. Артка юл юк, яңадан керәчәкләр колхозга. Авылның киләчәге – колхоз, – диде яшь председатель.

Кәримнең шунда ерактан ук урман буенда күренеп торган тегермәнгә күзе төште.

– Әллә тегермәнегез дә бармы? – дип сорады.

– Ә-ә, аны әйтәсезме? – диде Пәттери, шунда ук Тинчуринның нәрсә турында соравын аңлап. – Апанаевлардан калган тегермән ул. Хәсәнбай асты дип йөртелә торган җирдә, Ашыт суына салынган тегермән иде. Апанаевларның утарына электр тогы биреп торган. Революциядән соң җимерелгән. Менә шуны эшләтәсе иде яңадан.

– Менә бит, «Кандыр буе» өчен бер дигән чимал, – дип куйды Кәрим, Салихка карап. – Әйдә, барып күреп килик әле, – дип, Пәттеригә мөрәҗәгать итте.

– Безнең колхоз түгел анысы, Кече Битаманның «Партизан» колхозы җирләре. Ярар, барып карап килик булмаса, – диде Пәттери, һәм аларны

тарантаска җигелгән кара айгырында җилдереп кенә Хәсәнбай асты дип йөртелгән шул җимерек тегермән торган җиргә алып китте.

Алар Апанаевлардан калган ташландык биналарны карап йөрделәр.

– Әрәм ята күпме мал, – дип куйды Кәрим. – Боларны бит торгызырга да, авылга хезмәт иттерергә.

– Кече Битаман председателе Ибнеәмин Җаббаровның тегермәнне торгызып, авылга электр чыбыклары сузарга исәбендә бар. Менә колхозны аякка бастырып, эшли генә башласын дип өметләнә.

– Кирәк, бик кирәк тегермәнне торгызырга, – диде Кәрим. – Менә безнең дә башта шундыйрак пьеса язарга дигән уй туды, иске тегермәннәрне карап йөри торгач.

– Исемен «Ашыт буенда» дияргә кирәк пьесаның, – дип куйды шунда Салих.

– Юк, минем план башкачарак. Ашыт бит, күреп торасың, тулып агып ята. Монда әзер тегермәнне торгызып кына куясы бар. Ә минем пьесада башта чишмәләрдән су китереп бәләкәй генә инешне тирәнәйтү, көчәйтү. Колхозчыларның эшен шушы максатка туплау. Шуннан соң гына тегермән корып, колхоз өчен электр уты алуга ирешү, – дип, үз планын ачып салды Кәрим.

Алар Хәсәнбайдан соң Олы Битаманга кайтып, сәвит йортына кереп ашап-эчеп чыктылар һәм Фәтхерахман Усманов белән саубуллашып, Алат спирт заводы авылына илтә торган юл белән Әтнә районына чыгып киттеләр. Исәпләре Алат астыннан Ашыт буйлап кына кояш баеганчы Бәрәскәгә барып җитү һәм шунда куну иде.

– Сәлим дусның Бәрәскәдә өе бар. Үзе дә авылда ятмый микән әле, Ашытта балык каптырып, – дип куйды Салих. Ул Сәлим дип Хәким Сәлимҗановны атап йөртә иде.

– Бик әйбәт булыр иде, бер-ике көн кунак булып китәр идек. Балык чирттерсәк тә, начар булмас иде, – дип, кулларын угалады Тинчурин.

– Талдырды да бу сәпиттә көпчәк әйләндерү.

Ләкин төнне Бәрәскәдә түгел, Алат белән Бәрәзә арасында, Ашыт буенда үткәрергә туры килде аларга. Салихның тәгәрмәчле айгырының сипләре шестерня дигән нәрсәсеннән ычкынып чыкты. Педале зырылдап әйләнеп утыра, ә көпчәкләре тәгәрәми башлады.

– Уху, барып җитеп булмый Бәрәскәгә, – диде Кәрим, аның велисәпитенә күз салгач. – Шушында Ашыт буенда гына төн кунарга туры киләчәк болай булгач.

– Сәяхәт булгач, сәяхәт булсын инде. Учак ягып, су буенда төн кунуның үз романтикасы бар бит аның.

– Ярар, мин сәпитеңне карыйм, син Ашыт буендагы әрәмәлектән коры-сары җыеп кил. Учак ягып җибәрербез, – диде дә Кәрим Салихның велисәпитен карарга кереште.

– Ярый әле Пәттери шәпләп сыйлап җибәрде. Югыйсә төн үтеп, таң атканчы, Бәрәскәгә барып җиткәнче корсагың шиңеп бетәр иде, – диде Салих. – Минем болай да булмаган корсак бөтенләй умырткага ябышыр иде.

Алар Салих җыеп килгән ботак-сатаклардан учак ягып җибәрделәр. Кич айлы һәм җылы иде. Кәрим сумкасыннан кәгазь-каләм чыгарып, булачак пьесаның планын язды. Салих исә сызгыргалап, көйләр чыгарырга

маташып утырды. Авылларда йөреп, халык белән аралашып, һәр кешенең үз каланчасыннан торып сөйләшүе, колхозларга карата төрле фикерләр ишетү аларның икесен дә уйга салган иде бугай.

– Кәрим абый, бу Фатыйх абзыйның сөйләгәннәре уйга калдырды әле мине, – диде Салих, кулындагы таяк белән учакта янган агач ботакларын аралавыннан туктап.

– Син дә шуны уйлыйсыңмыни?

– Дөрес тә сөйли кебек, ялгыша да кебек.

– Социалистик җәмгыять төзү күзлегеннән караганда ялгыша. Чөнки социалистик революциянең максаты шул иде бит инде: кешенең кеше өстеннән эксплуатациясен бетерү. Ә наёмный хезмәт бу тәгълиматка каршы килә. Шәхси эшеңне эшләтер өчен башка кешене яллыйсың икән, димәк, син – эксплуататор, кулак.

– Анысы шулай да ул. Ә колхоз? Аңа көчләп кертү? Единоличник үзе генә эшләсә, ул колхозга нинди зыян китерсен?

– Зур җир биләмәләрең булса, берничек тә үзең генә эшләп бетереп булмый ул. Кеше яллап эшләтергә туры килә.

– Ә берничә кеше, әйтик, өч-дүрт кеше генә үзара берләшеп, килешеп эшләсәләр? Аның ни гаебе бар. Бернинди дә наёмный хезмәт булмый бит.

– Партиянең установкасы андый түгел. Аңа каршы килгән кеше – дошман. Партия менә шулай куя бит мәсьәләне.

– Сталин үзе дә колхозга көчләп кертү булырга тиеш түгел, дип язып чыккан бит әнә.

– Шулаен шулай да ул, кулаклар нык каршы тора, ди, бит анда. Колхоз председательләрен үтерәләр, ди. Шуңа күрә кулаклар үзләре единоличникларга каршы көрәш алып барырга мәҗбүр итә.

Алар беркавым сүзсез тордылар.

– Катлаулы мәсьәлә бу. Сәясәт. Сәясәт белән шөгыльләнү куркыныч хәзер, – диде Кәрим, сөйләшүне түгәрәкләргә теләгәндәй. – Колхоз төзүнең прогрессив эш икәнен күрсәткән, авыл кешесен шушы эшнең тормышны алга җибәрү өчен мөһимлеген тасвирлаган драма тудыру бурычы тора бүген безнең алда. Партия бүген синең белән миннән шуны таләп итә.

– Без бит партия әгъзалары түгел.

– Түгел дә, театр шушы партия җитәкчелек иткән хөкүмәтнеке. Ә без шул театр хезмәткәрләре. Берни эшләр хәл дә юк.

– Колхоз колхоз инде. Кулаклар ниндидер корткычлык та эшлидер. Ә менә Шиһап җизнинең нинди гаебе булды икән соң? Шуңа аптырап йөрим мин. Бернинди хәбәр юк үзеннән. Апайга, ун елга хөкем ителде, дигәннәр дә, төрмәгә җибәрелде, дигәннәр.

– «Солтангалиевчелек»тә гаепләгәннәр, ди бит.

– Ә ул «солтангалиевче» булу нәрсә икән соң ул? Илгә нинди корткычлык китерә икән? Изге эш эшләп йөрде бит. Җирсез крәстияннәргә җирләр биреп, йортлар салып. Гомере буе халыкка мәдәни хезмәт күрсәтү артыннан чапты. «Шәрык клубы» кичәләрен үткәрү белән шөгыльләнде. Шул социалистик революция булсын өчен дип йөрде. Партиягә керде. Һәм менә шул кеше партиянең дошманы булып чыкты. Илгә корткычлык китереп яткан. «Халык дошманы». Башка сыймый.

– Ярар, Салих, бу хакта сөйләшү икебезнең арада гына калсын. Кешекарага авыз да ачма бу мәсьәләләр хакында. Әйдә, йоклыйк. Төн кыска, озакламый таң да атар. Болыннан яшь үлән йолкып килик. Шуны түшәк итеп, учак күмерләре җылысында йоклап алыйк бераз.

Алар берәр кочак үлән йолкып килделәр дә, аны учак янына түшәп, әле һаман ялкынланып янган учактан төшкән күмер җылысында йокларга яттылар.

Җәйге таң тиз атты. Кояш күренүгә, алар чишенеп, Ашытта су кереп чыктылар, аннары велисәпитләренә атланып, юлга кузгалдылар.

Юраган юш килде, бәхет басты сәяхәтчеләрне. Хәким авылда ята иде. Галиясе белән бергә кунакка кайткан булганнар. Авылларда Сабан туйлары башланган чор икән. Аларны болай да кулда гына күтәреп йөртмиләр иде инде: абруйлары шулкадәр зур, һәркайда кунак итәргә генә торалар. Бәрәскәдә тагын да зур булды игътибар. Хәкимне дә бик үз итәләр икән авылдашлары. Салих Сәйдәшев белән Кәрим Тинчурин кайтканын ишеткәч, нишләргә белмәделәр. Җитмәсә, тагын ике көннән Сабан туе. Халыкның кәефе шул бәйрәм рухына көйләнгән. Авыл яшьләре кич клубта концерт куйдылар ул көнне. Ике җырның берсе Салих Сәйдәшев белән Кәрим Тинчуринныкы булды. Һәр җырны игълан иткән саен, «Авторлары үзебезнең арада, залда утыралар», – дип, икесен дә кат-кат бастырып аптыратып бетерделәр. Һәр баскан саен «ура» кычкырып кул чабуларны әйтәсе дә юк. Үзләрен дә сәхнәгә чыгарып бик җырлатасы иделәр дә, «Без җырлый белмибез шул. Бүген без кунак кына», – дип, көч-хәл белән котылдылар. Ә Сабан туе көнне Тинчуриннан конферансье ясадылар. «Зәңгәр шәл»дән ат урлау монологын сөйләтмичә бәйләнүдән туктамадылар. Авылдашлары Хәким Сәлимҗановны да онытмадылар. Аннан да әллә ничә мәртәбә спектакльләрдән монологлар сөйләттеләр.

Бәрәскә Сабан туеннан соң Хәким белән Галия Сәлимҗановлар – Казанга киттеләр, Тинчурин белән Сәйдәшев велисәпитләрендә, Кенәр якларына юл тоттылар.

Кызыл Юл колхозы авылларында да әле берсендә, әле икенчесендә чиратлап, яз бәйрәмнәре бара торган булып чыкты. Шундый матур көннәрнең берсендә Өчиле авылында кулаклар колхоз председателенең гомерен өзгәннәр. Кәрим бу вакыйганы да җайлап кына пьесага кертеп җибәрәсе булыр дип уйлап куйды. Кулаклар тарафыннан үтерелгән яшь председатель Ахунҗанның берсеннән-берсе бәләкәй ике баласы – улы белән кызы ятим калган. Әтиләрен җирләгәндә, Кәрим Тинчурин белән Салих Сәйдәшев ул балаларны кулларына алып сөйделәр. Алар ул малайның киләчәктә татарның танылган язучысы Гариф Ахунов булыр дип башларына да китермәделәр әлбәттә.

Дөбъяз һәм Кызыл Юл районнарында күргәннәрдән Тинчурин колхоз төзелешен яктырткан пьеса өчен бер дигән материал туплады. Ул аның аерым күренешләрен авылларда йөргән чакта ук уйлап, дәфтәр битенә сызгалап барды. Авыллардан әйләнеп кайткач, Кәрим дә, Салих та театрның яңа сезонында репертуарның үзәк спектакле булырга тиешле әсәрне иҗат итү хәстәренә керештеләр.

– Кәрим абый, син яз инде башта, – диде Салих. – Авыл юлларында

велисәпит өстендә тузан ашап йөреп, шактый шиңде корсагың. Әмиңа ял кирәк. Мин иртәгәдән Кызыл Байракка китәм.

– Алтын икән акылың, булмаса да сакалың, – диде Тинчурин. – Кызыл Байрак язучылар өчен бер дигән иҗат итү урыны инде ул. Мин дә шунда гына язармын дип планлаштырып тора идем. Ярар, бергәләп ял итә-итә язарбыз.

Салихның әнисе килене Сафия, оныклары Нәүфәл һәм Альфред белән күптән Кызыл Байракта яшиләр иде инде. Иртәгесен Салих белән Тинчурин да шунда китәргә җыендылар. Тинчуринның Заһидәсе дә шунда ял итә икән. Салих кармакларын алды. Кәрим дә бер кулына кәгазь-каләм тутырган сумкасын, икенчесенә кармаклар тоткан иде.

– Син нәрсә, балык каптырып утырырга җыенасыңмыни? Пьесаны кем язар? – диде Салих.

– Балык чирттергәндә, шәп эшли ул баш. Түлке икебез ике җирдә салырбыз кармакларны.

– Нишләп?

– Син бит сызгырып утырасың, бердән, балыкны качырасың, икенчедән, миңа уйларга комачауларсың.

– Мин бит яңа спектакльнең музыкасын көйләп утырам. Син өйдә генә язып утырсаң, әйбәтрәк булыр. Тизрәк язып бетерерсең.

– Ярар, карарбыз. Их, кармак алмаганмын дип үкенерлек булмасын. Алыйм әле.

Салих каршы килмәде, чөнки ул белә иде: Тинчурин бер яза башласа, кәгазь-каләменнән аерыла алмый яза да яза. Бу юлы да шулай булачак дип уйлады.

Алар шулай итеп, кармакларын күтәреп, Усиягә төшеп киттеләр.

Чынлап та Салих уйлаганча булып чыкты.

Салихның, кич җиткәч кенә, балыкларын күтәреп өйгә кайтып керүен Тинчурин көн саен түземсезлек белән көтеп тора иде. Аның язган кадәр өлешен тизрәк Салихка укып күрсәтәсе килә. Укып бетерә дә: «Булганмы? Йә ничек?» – дип сорап куя.

– Бара, бара, Кәрим абый, – дип хуплый Салих.

– Юк, син хуплап утырма. Турысын әйт, ничек чыга?

– Әйбәт, дим бит инде.

Тинчурин чынында да бик җиңел һәм халыкчан тел белән, шома яза торган иде. Һәр персонажы халык әйтемнәрен кулланып, мәзәкчел итеп сөйләшә. Тыңлаган саен тыңлыйсы гына килеп тора. Гомумән, ул бөтен әсәрләрен дә шулай яза. Шуңа күрә дә халык яратып карый. Спектакльләре башка авторларныкына караганда аншлаг белән бара. Бу юлы да шундыйрак спектакль килеп чыгар, мөгаен.

– Син аның теленә карама, сюжеты матур корыламы? Каршылыклар юкмы? Шунысын әйт, – ди Кәрим.

– Сине өйрәтергә түгел инде, Кәрим абый. Тизрәк язып бетер дә, миңа да эш булыр.

– Менә әйт син, тегермәнче Галинең җыры белән башлап җибәрү дөрес булырмы?

– Синең бөтен пьесаң да җыр белән башлана бит инде. Нәрсә сорап торасың, монысы гына башкача булмас. Бик әйбәт булыр.

– Алайса, менә сиңа эш: шул җырга музыка иҗат ит:

Кандыр буе, ай, кара урман,
Киек җәнлеккәйләр оясы,
Без җырлыйсы җырлар шунда туган,
Шунда туган Кандыр чишмәсе.
Кандыр иңен йөзеп буйлаганда
Уртасында басып тын калдым,
Иңнән-иңгә сине айкаганда,
Синең өчен, Кандыр, оялдым.

Һәм менә, ниһаять, ял итә-итә, көн саен аз-азлап яза торгач, Тинчурин колхозлашуның гади крәстиян хуҗалыгыннан өстенлекләрен күрсәткән, шул ук вакытта колхоз төзүнең гаять катлаулы, авыр шартларда баруын тасвирлаган, үз заманы өчен актуаль булган әсәр тудыруга иреште.

Гади пьеса гына түгел, шигырь белән бизәкләп, музыкаль драма булсын өчен җыр, ария текстлары белән үрелдереп барган әсәр килеп чыкты. Корып, коргаксып яткан инешне бөяп, суын арттыру нәтиҗәсендә яңа тегермән генә түгел, авылларны Ильич уты белән тәэмин иткән электр станциясе төзүне күрсәткән, гади колхоз төзелешен генә түгел, яңа тормыш коруны сурәтләгән заманча драма дөньяга туды бу сәяхәт нәтиҗәсендә.

Тегермәнче Галинең Кандыр суының сайлыгыннан гарьләнеп җырлаган җыры белән башланган драма, буеннан буена, бүлектән бүлеккә үстерелеп, Фәридәнең:

Саф Кандырның, ай, сулары
Сикереп-сикереп акканда,
Ударниклар җиң сызганып,
Эшкә җырлап барганда...
Дөнья яңгырасын,
Сулар шауласын,
Ялкау, кит юлдан,
Урын биләмә!
Эшкә чыныккан
Батырлар килә,
Батырлар килә,
Бирегез мәйдан! –

дигән җыр-ариясе аша яңа тормыш төзелүен сурәтләү белән тамашачылар күңелен биләрлек хәлгә килде. Нәтиҗәдә, колхоз төзүнең авыл хуҗалыгын үстерүдәге роле генә түгел, яңа тормыш төзү, авылларны электрлаштыру процессы, монтёрлар җыры рәвешендәге яңа тормыш төзүчеләр маршы булып яңгыраган «Без кабызган утлар...» дигән сүзләр белән башланган үлмәс җырлардан торган өр-яңа музыкаль драма сәхнәгә менде.

Без кабызган утлар сүнмәс алар,
Сүнмәс алар хәтәр җилләрдә;
Без кабызган утлар якты янар,
Якты янар хезмәт илендә.

Без кичә алмаган юк кара урман,
Без җиңә алмаган дошман тумаган.
Безнең байраклар котлыйлар алар,
Котлыйлар алар хезмәт бәйрәмен.

Эш өстендә гөрләп үсәбез,
Гасырларны елда үтәбез.
Чыныккан якты корычтай,
Без үсәбез ныгып шулай,
Үсәбез, үсәбез, үсәбез!..

«Кандыр буе» өчен Салих егермеләп җыр гына язды. Бригадир кыз Гөләндәм өчен дәртле, оптимистик рухтагы җырлар һәм арияләр, колхоз чебиләрен караучы Фәридә өчен салмак, лирик җырлар, шаян-шук егетләр Әмәк белән Шәмәк өчен шулар рухына туры килгән шаян җырлар, колхозда оештырылган хезмәт бәйрәме өчен язылган монтёрлар җыры, балет сюиталары, вальслар, «Уңыш җыры» дип аталган бию көе – болар барысы да Сәйдәшевнең «Зәңгәр шәл» белән «Наёмщик», музыкаль драмаларында яңгыраган көйләреннән дә уңышлырак килеп чыктылар.

1932 елның 21 мартында «Кандыр буе» музыкаль драмасының премьерасы булды. Ул Салих Сәйдәшев иҗатының тагын да югарырак баскычка күтәрелүен күрсәткән музыка бәйрәменә, Сәйдәш музыкасының тантанасына әверелде.

## Икенче бүлек

### 1

1933 ел вакыйгаларга бай булды. Беренчедән, Салихның театрда эшли башлавына ун ел тулды. Театр бу истәлекле юбилейны зурлап билгеләп үтү турында карар кылды. Икенчедән, бу елны театрны икегә бүлү турында хөкүмәт карары чыгарылды. Беренче состав драма театрында калды. Икенчесенә керүчеләр Музакаль театрда эшләүчеләр дип хәл ителде. Салих Сәйдәшев икенче составка кертелгән иде. Икенче состав артистлары яңа елдан Мәскәү консерваториясендә оештырылачак татар опера студиясенә укырга китәргә тиеш булдылар. Салих, шулай итеп, беренче составта калган Кәрим Тинчурин белән аерылышты. «Кандыр буе» музыкаль драмасы аларның бергә иҗат иткән соңгы эшләре булды.

Тинчуринны Әстерханнан чакырып кайтарсалар да, баш режиссёр булып, озак эшләргә бирмәделәр. Аңа һаман да шул үзе яза, үзе куя, үзе уйный дигән гаеп тактылар һәм утыз икенче елда ук инде гади режиссёр итеп кенә калдырдылар. Хәтта «Кандыр буе»н да ул баш режиссёр буларак куймады. Баш итеп Риза Ишморатны билгеләгәннәр иде.

Сәйдәшевнең юбилей концерты бик зурлап үткәрелде. Композиторны халык ярата иде. Салихны котлап, Кәрим Тинчурин чыгыш ясады.

– Бу ничек була инде, Кәрим абый, мин Мәскәү консерваториясенә барып, ничек итеп опера язарга өйрәнергә тиеш буламмыни инде? Ә безнең музыкаль драмалар, алар нәрсә, операдан кайтышрак нәрсәләр булып чыга микәнни?

– Юк, әлбәттә. Опера – үзенә бер жанр. Музыкаль драма – ул әле яңа жанр. Европада оперетта дигән жанр булуын беләсең. Ул менә шуңа охшашрак. Ул безнең татарга хас, татар тамашачысы яратып карый торган жанр. Бездә бит әле чынлап торып опера язып караган кеше юк. «Сания» белән «Эшче» өйрәнчек әйберләр генә иде. Үзең дә беләсең. Ләкин алар да татар операсы тудыру юлында зур эш булдылар.

– Мин бит инде үз стилемне, үз язу манерамны булдырган композитор. Хәзер мин өр-яңадан музыка язарга өйрәнеп утырырга тиешменме?

– Син анда үзең генә бармыйсың. Нәҗип Җиһанов, Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключарёв, Юрий Виноградов, Заһид Хәбибуллин бергәләп укыячаксыз.

– Алар арасында мин иң өлкәне булам бит. Миңа утыз дүрт яшь тула. Өр-яңадан башлау өчен мин инде карт, ул егерме яшьлек малайлар арасында.

– Юк, Салих, укырга кирәк. Уку беркайчан да комачауламый. Кеше әллә нинди уку йортларын тәмамласа да, үзлегеннән укый, белемен тирәнәйтә. Уку сиңа да файдага гына булачак. Килеш минем белән. Анда композиторлар гына түгел, җырчылар, шагыйрьләр дә укыячак. Җырчылар җырларга өйрәнсә, шагыйрьләргә либретто язу серләрен өйрәтәчәкләр. Өч елдан соң Казанга кайтып, татар опера театрын ачып җибәрерсез.

– Ә сез? Син дә бит бер дигән җыр текстлары иҗат иткән шагыйрь.

– Нишлисең, кертмәгәннәр бит исемлеккә. Өстәгеләр яхшырак белә. Уйлаганнардыр, драма язучылар да кирәк, дигәннәрдер. Кайгырма, драма спектакльләренә дә музыка кирәк булачак. Әле без синең белән тагын бик күп музыкаль драмалар чыгарачакбыз. Тагын да яхшыракларын.

– Без киткәчтен, сезгә дә күңелсез калыр инде. Заһидә белән сиңа бигрәк тә. Күршеләр булып, ничек матур яшәдек. Җитмәсә, Кайбицкая белән Әүхәдиев тә китә.

Галия белән Ильяс 1928 елдан бирле өйләнешеп, Салих гаиләсе белән күршеләр булып, барысы бергә Кәрим Тинчуриннарда яшиләр иде.

Галия башта Ситдыйк Айдаровка кияүгә чыккан иде. Икесе бергә спектакльләрдә баш рольләрне башкарып, шулай матур гына яшәп, уллары Сәйярне үстереп ятканда, Ситдыйк белән Галия гаиләсендә низаг килеп чыга. Бу хакта Салих белеп ала да Тинчуринга әйтә.

– Кәрим абый, нишлибез инде хәзер, Айдаров белән Кайбицкая аерылышалар икән бит? – ди.

– Аерылышсалар, анда синең ни эшең бар. Ир белән хатын аерылышыр да, кушылыр да, – диде Кәрим.

– Анда минем генә түгел, синең дә эшең бар.

– Ни эшем булсын?! Теләсә ни эшләсеннәр. Кеше гаиләсенә тыкшынырга бер дә теләгем юк...

– Алай димә әле син. Галия Айдаровтан гына түгел, Казаннан ук китә икән бит. Безнең драмаларда төп рольләрне кем уйнар?

– Шулай укмыни? Кая китә икән соң ул?

– Әстерхан театры белән килешү төзегән. Улы Сәйярне алып, шунда китәргә булган. Ә аңа хәтле улы белән Уральскига, әти-әнисе янына кайтып, җәйне үткәреп килергә тели.

– Алайса, бик әйбәт. Ял итеп килсеннәр. Ә аннары күз күрер. Әстерханга җибәрмәскә берәр җаен табарбыз, – диде Кәрим.

Шулай җәй үтә. Галиянең Уральскидан Казанга кайтып, Әстерханга китәр вакыты якынлаша. Шунда Кәрим Айдарскийны күрә дә:

– Сез анда Галия белән аерылышып йөрисез икән. Галияне бала белән язмыш иркенә ташлап калдыру егетлек түгел, – ди. – Дөрес, кеше гаиләсе эшләренә тыкшыну – әдәпсезлек. Үзегез хәл иткәнсездер. Тик безнең Салих

белән бер үтенечебез бар: Галиянең улы белән Уральскидан кайтыр вакыты җитеп килә. Ул аннан кайткач, Әстерханга китәргә тиеш икән. Менә шул: син Галиягә хат яз, Әстерханга китмә, анда мин үзем барам, диген.

– Ә мин анда барырга теләмәсәм?

– Теләмәсәң, бармассың. Син язуыңны бел. Галия монда, Казанда кирәк.

– Ул Уральскидан кайткач, минем Әстерханга китмәгәнне күрәчәк бит.

– Күрсен. Анда синең эшең булмасын. Сез икегез дә Казан өчен кирәк.

– Галиягә торыр урын кирәк булачак бит. Ул анда Әстерхан белән торак мәсьәләсен дә хәл иткән.

– Анысы безнең эш. Кайтсын әле әйләнеп. Хәл итәрбез. Урамда калмас.

Ул арада Тинчурин Галиягә юл чыгымнары өчен җибәрелгән акчаларны салып, Әстерхан театрына аның килә алмавы хакында хат яза.

– Инде яшәрләренә урын гына табасы калды, – дип уфтана ул, Салихка карап.

– Идея! – ди Салих, кош тоткан кебек шатланып.

– Нинди?

– Без София белән сезнең ике бүлмәгездә яшәп ятабыз бит. Менә шул бүлмәләрнең берсен Галиягә бирик.

– Үзегезгә кысан кала бит.

– Түзәрбез. Төн кайтып кунарга урын булса, безгә җиткән. Күңелең киң булсын.

– Үзегезгә карагыз, мин каршы түгел, – ди Кәрим.

Мәсьәлә хәл ителде болай булгач, дип шатланган Салих, бераздан тагын кычкырып җибәрә:

– Тагын бер идея бар, Кәрим абый!

– Анысы нәрсә инде тагын?

– Анысымы? Ленинград консерваториясен тәмамлап, театрга эшкә Ильяс Әүхәдиев кайтты бит.

– Ну шуннан?

– Шуннан, утырган да шуган, дип әйтә минем әни. Менә шул Ильяска Галияне димлибез.

– Баласы бар бит. Бала белән алыр микән соң?

– Ул алыр, Галия – чибәр хатын. Галиясе барыр микән диген син?

– Алайса, аны күндерү синең өстә. Мин каршы түгел. Драмалардагы җырчы мәхәббәт каһарманын скрипкәче белән алыштырабыз булып чыга болай булгач. Үзенә үпкәләсен Ситдыйк, аермасын иде хатынын.

Ничек итсә итте, барыбер кодалады Салих Галияне Ильяс Әүхәдиевка.

Мәскәүгә китәр алдыннан Салихка театр ишегалдындагы йорттан фатир бирделәр. Мәскәүгә килеп, укулар башлангач, Салихны анда да гаиләсе булуын истә тотып, аерым фатирга урнаштырдылар. Ул Казандагы фатирында әнисен, балалары Гөлнара һәм Җанбәк белән апасы Әминәне калдырып, София белән улы Нәүфәлне үз янына Мәскәүгә алып китте. Хатыны икенче балага корсаклы булганлыктан, мәшәкате күп булыр дип, инде җиде яше тулган Альфредны Казанда калдырдылар.

– Улым, Альфредны бабулясы Анна Ивановна үстерсен, – диде Мәхүпҗамал апай. – София бик өнәп тә бетерми аны. Үги бала булып, кимсенеп үсмәсен, мин дә авырыйм, озак тора алмам, ахры – диде ул.

Анна Ивановна Альфредны бик ярата иде. Ул аны кызы Валентинага охшаган, дип әйтә торган иде. Оныгын үзенә калдыруларына бик сөенде.

Салихның Воротников тыкрыгындагы фатиры артык зур булмаса да, аларга яшәр өчен җитәрлек иде. Шунысына сөенде Салих: ул Мәскәү татарларының мәдәни үзәге булып торган Әсәдуллаев йорты дип йөртелгән җирдән әллә ни ерак түгел. Биредә урнашкан Татар клубында әледән-әле төрле кичәләр оештырыла. Салих ул кичәләрдә еш кунак булып китте. Аңа татарлар тартыла иде. Шушында ук Мәскәү татар эшче театры да урнашкан, аның режиссёры Гали Ильясов белән Гөлсем Камская да балалары белән шул тирәләрдә генә яшәп яталар. Аралашу Казандагыдан әллә ни аерылмый иде.

Салих башта Кәрим абыйсының үгет-нәсихәтләрен тотып, укуга зур игътибар бирде.

Аны композиция буенча профессор Генрих Ильич Литинский, гармониядән Владимир Васильевич Соколов классларына билгеләделәр. Алар икесе дә чама белән Салих яшендәге кешеләр иде.

Татар опера студиясенең директоры итеп, Галия Кайбицкаяның абыйсы Камил Мотыйгыйның улы Хәмит Төхфәтуллин билгеләнгән иде. Беренче дәрестә Төхфәтуллин профессор Литинскийга аларны берәм-берәм, «Курсант Фәйзуллин, курсант Хәбибуллин», – дип, исемнәрен атап барды-барды да Салихка җиткәч: «Композитор Салих Сәйдәшев», – дип, зурлап таныштырды.

– Ишеттем, ишеттем, – диде Генрих Ильич, – татарлар арасында инде танылган композитор да бар, диделәр. Ләкин безгә барысын да өр-яңадан башларга туры киләчәк. Сәйдәшев кебек танылган композиторлар башка төбәкләрдән дә бар. Аңлыйм, сезгә авыр булачак опера язу серләрен үзләштерү. Сез инде музыкаль сәхнә әсәрләре тудыру буенча дистә еллык тәҗрибәсе булган, өлгергән композитор. Ялгышмасам, Мәскәүгә килер алдыннан гына иҗади эшчәнлегегезнең ун еллыгын зурлап билгеләп үткәнсез.

– Булды андый хәл, – диде Төхфәтуллин. – Сәйдәшев – ул безнең классик.

– Классиклыгыгызны онытып торырга туры киләчәк, кадерлем Салих дускай.

– Арттыралар, Генрих Ильич.

– Сезнең белән аерым шөгыльләнербез, каршы килмәсәгез, – диде Литинский.

– Мин риза. Ничек өйрәтсәгез дә, каршы түгел, – диде Салих.

– Алайса, класс белән бергә шөгыльләнгәннән соң, дәресләр беткәч, аерым калырбыз.

– Яхшы.

Профессорның студия курсантлары белән үткәргән беренче дәресе ошамады Салихка. Юк, дәрес алып бару манерасы түгел, әле композициядә бернәрсә дә белмәгән бала-чагага сольфеджио, адажио, октава кебек терминнар, ноталар, скрипка ачкычы кебек нәрсәләр турында сөйләве аның өчен беренче класс баласына әлифба өйрәткән шикелле күренде. Болар аның өчен инде ул күптән белгән, кем әйтмешли, читэнгә чыгарып элгән нәрсәләр иде. Шуңа күрә дәресләр беткәч, икәүдән-икәү генә калып

сөйләшүгә ул шикләнеп, ышанмыйчарак калды. «Нәрсә турында сөйләшер икән инде ул аның белән?» – дип уйлады. Пентатониканы Казанда да «татар музыкасының үткәне, искелек калдыгы» дип санныйлар иде. Пентатоникада язылган әсәрләрне «вак буржуазия җырлары» дип язарга яраттылар Казан тәнкыйтьчеләре. Имеш яңа пролетар татар музыкасы пентатоникадан китәргә тиеш, диделәр. Беренче дәрестә Литинскийның лекциясендә дә шундыйрак нәрсә сизелде. Дөрес, ул бу хакта турыдан-туры әйтмәде. Ләкин опера музыкасы ул Европа классикасыннан үрнәк алырга тиеш, итальян, рус композиторларының әсәрләре үрнәгендә язылырга тиеш, дигән фикерне алга сөрде. Шулай да профессор Салих уйлаганча ук катгый кеше булып чыкмады.

– Салих Җамалетдинович, белүемчә, сез музыкаль училище тәмамлагансыз?

– Әйе, 1914–1917 елларда Казан музыка училищесында профессор Осип Родзевич классында фортепьяно буенча белем алдым. Аннан соң үзлегемнән өйрәнеп, композиция техникасын үзләштердем. Бу исемнәр сезгә ни дә булса сөйләсә – Ксаверий Александрович Корбут, Бормусов, Чигарина, Юшкова, Литвинов – бу кешеләр минем музыка буенча педагогларым булдылар. Мин алардан фортепианода уйнау осталыгымны камилләштердем, гармония, композиция нигезләрен үзләштердем. Былтыр республикада иҗади эшчәнлегемнең ун еллыгын билгеләп үттеләр. Ләкин мин инде унике яшемнән музыкант.

– Сүз дә юк, сез инде, Салих Җамалетдинович, өлгергән композитор. Ләкин безнең алга сездән опера иҗат итә торган композитор ясау бурычы куелды. Моның өчен элекке иҗатыгызны онытып торырга туры киләчәк.

– Белмим, бу минем хәлдән килерлек эш түгелдер.

– Халыкта, Салих Җамалетдинович, аюны да биергә өйрәтәләр, дигән сүз бар. Шуңа күрә тырышырбыз. Әлбәттә инде, үзегездән дә тора. Иң мөһиме – теләк булу. Килгәнсез бит әле менә укырга дип. Димәк, теләгегез бар.

– Теләк бар да ул, мин бит инде формалашкан композитор. Калыплашкан стереотипларны җимерү җиңел булмастыр.

– Ә беләсезме, без сезнең белән нишлик? Сезнең бер әсәрегезне алыйк та шуннан опера ясыйк. Нинди спектаклегезне алыр идегез?

– Уйларга кирәк. Генрих Ильич, сез бездән опера иҗат итүче композитор ясарга җыенасыз инде. Мине шундый бер сорау борчый: кирәк микән ул безнең татар халкына опера дигән жанр? Дөньяда итальяннардан, кайбер Европа илләреннән, урыслардан кала японнарның, Индонезия, Африка илләре халыкларының опера жанрының бөтен атрибутлары булган үз музыкаль сәхнә әсәрләре бар. Безнең татарларның да соңгы ун елда шундый спектакльләребез барлыкка килде – музыкаль драма. Анда да, увертюра да, сюита да, балет та, вальс та, бию дә, ария дә, җыр да, речитатив та бар. Минем музыкаль драмаларның барысында да егермеләп җыр һәм ария генә бар. Бу операның бер төре түгелме соң инде? Татарча, милли төре? Пролетар сәнгать дип, без миллилектән, музыкада пентатоникадан китәргә тиеш түгелдер бит. Мин менә шуны аңлап бетермим.

– Белүемчә, Салих Җамалетдинович, татарларда театр дигән сәнгать соңлабрак барлыкка килде. Шуңа күрә сезнең опера кебек катлаулы музыкаль

жанрны аңлау дәрәҗәсенә җиткән катлау әле формалашып бетмәгән. Сезнең алда менә шул эшне башкару, халыкның музыкаль сәхнә әсәренең югары формаларын да аңларлык катлавын тәрбияләү бурычы торачак.

– Бездә опера язарга омтылышлар булды инде.

– Әйе, беләбез. Ләкин аларның әлегә уңышка ирешмәгәнлеген дә беләбез.

– Шулай шул. Халык... нәрсә халык, җәмгыятьнең зыялы катламы да әлегә аны кабул итә алмады.

– Шуңа күрә, әйдәгез, менә сезнең халык тарафыннан яхшы кабул ителгән бер әсәрегезне алыйк та, шуны операга әйләндерергә тырышып карыйк. Студияне тәмамлаганда, шул операны эшләп чыга алсак, сез Опера студиясен әйбәт билгесенә тәмамлады дигән диплом алып чыгачаксыз. Ашыкмыйча, өч ел эшләгәндә, моны башкарып чыга алырбыз, дип уйлыйм.

– Карап карарбыз, – диде Салих.

– Алайса, килештек. Нинди әсәрегезне алабыз инде?

Салих бераз уйланып торды да:

– Кайсын алсак та ярыйдыр. Әйдәгез, безнең драматург Кәрим Тинчурин белән иҗат иткән «Зәңгәр шәл» дигән музыкаль драмабыз бар. Ул татар музыкаль фольклорының, халык авыз иҗатының барлык төрләрен, уеннар, биюләр, татар халкы тормышыннан кызыклы вакыйгаларны туплаган, безнең милли яшәешебезне тулы чагылдырган сәхнә әсәре. Бәлки шуны алыргадыр, – диде.

– Мин карадым сезнең ул спектаклегезне. Көчле әсәр. Сезнең «Кызыл Армия маршы»гыз да искиткеч. Шундый дәрәҗәдә формалашкан композиторга иҗат манерасын үзгәртү кыен булачак. Мин аңлыйм. Ләкин тырышып карарга кирәк.

Салихның Опера студиясендәге беренче дәресендә әнә шундый сөйләшү булды педагог белән укучы арасында. Бу ике якның да бер-берсен аңлап сөйләшүе иде. Ләкин бу сөйләшү Салихта студиянең аңа нинди дә булса белемнәр бирәсенә әллә ни зур өметләр уятмады. Моны профессор да сизде бугай, ул саубуллашканда кулын биреп:

– Вакыт күрсәтер, – дип куйды.

Менә шулай итеп, Татар опера студиясендә опера жанрын үзләштерергә килгән татар иҗат яшьләренең өч елга сузылган Мәскәү тормышы башланды.

Ләкин Салих өчен тормыш аның башыннан ук шактый зур хәсрәтләр алып килде. Озак та үтмәде, ул Казаннан кайгылы хәбәр алды. Алар Мәскәүгә киткәндә, авырып калган әнисе Мәхүпҗамал вафат булды. Ул авырганда, Салих берничә мәртәбә Казанга кайтып килде. Әмма аның сөекле әнисе улының укып бетереп, Казанга әйләнеп кайтканын көтеп ала алмады.

Ә май аенда Сафия икенче улын тапты. Аңа Рәләф дип исем куштылар.

Никадәрле генә талантлы булса да, Сәйдәшкә аның яшендә музыкаль иҗатның яңа техникасын өйрәнү җиңел түгел иде. Шул ук вакытта ул элекке педагогларыннан читтән торып кына үзләштергән белемнәренең дә канәгатьләнерлек түгеллеген сизә. Кәрим абыйсы да тикмәгә генә кайта-кайта: «Укырга кирәк, Салих, укырга», – дип әйтмәде. Салих моны яхшы аңлый иде.

**2**

Студиядә дәресләр бер композиция буенча гына бармый, әлбәттә. Гармония, полифония, инструментовка кебек композиторлык хезмәтенең төп юнәлешләре буенча да дәресләрне калдырмаска кирәк. Ләкин Салих ул дәресләр буенча педагоглар белән Литинский шикелле үк уртак тел таба алды дип әйтүе кыен. Киресенчә, кайберләре белән ике арада эчке каршылык барлыкка килде. Шулай да холкы белән тыныч, һәр кешегә дә ихтирам белән карый торган Салих бу педагогларга карата тискәре мөнәсәбәтен белдермәскә тырышты. Ләкин алар арасындагы аңлашылмаучылык, бер-берләренә карата салкынлык үзен сиздермичә калмады. Бу, әлбәттә, акрынлап, еллар үтә-үтә сизелде. Беренче елларда дәресләргә теләп, кирәклеген аңлап йөргән композитор соңга табарак аларга йөрүдән бөтенләй туктады. Моның педагоглар белән ике арадагы мөнәсәбәтләргә бәйле булмаган, башка җитди сәбәпләре бар иде.

Мәскәүгә Опера студиясендә укыр өчен татар сәхнә сәнгатенең каймагын җыеп җибәргәннәр иде дияргә мөмкиндер. Драматург Фәтхи Бурнаш студиянең әдәби бүлек мөдире булды. Аның белән Мәскәүдә яшәүче Муса Җәлил актив аралашты. Алар алдына татар тарихына кагылышлы «Алтынчәч» операсына либретто язу бурычы куелды. Операның музыкасын язу Борис Владимирович Асафьевка йөкләнде.

Салих укытучысы Литинский белән булган сөйләшү хакында Кәрим Тинчурингa язып җибәрде. Аның алдына «Зәңгәр шәл» драмасын опера либреттосы итеп үзгәртеп язу бурычын куйды.

Тинчурин җавап хатында тиздән Мәскәүгә барырга җыенулары хакында язды. Казанда Татарстан Совет Язучылары союзы оештырылган икән. Август урталарында Мәскәүдә Бөтенсоюз язучылар съезды үтәчәк һәм СССР Язучылар союзы төзелергә тиеш, ди. Кәрим Тинчурин да шул съездга делегат итеп сайланган. Ул гына да түгел, хәтта Татарстан драматурглары иҗаты буенча доклад та ясарга йөкләгәннәр үзенә.

Союз – язучылар өстеннән идарә итә торган, аларның эшчәнлеген күзәтү астында тотарга тиешле оешма иде. Ләкин моның шундый булачагы хакында язучылар әле аңлап бетермиләр. Үзләренең мөстәкыйль союзлары булуга шатланалар, аңа иҗатларын үстерүдә, тормыш-көнкүреш шартларын яхшыртуда ярдәме булыр дип, зур өметләр багладылар. Хәер, нәрсә уйласалар да уйлаганнардыр, Салих Сәйдәшев өчен мәсьәләнең бу ягы караңгы иде. Ул Мәскәүгә үзенең дуслары киләсенә, алар арасында Кәрим Тинчуринның да буласына сөенде.

Тинчурин съездда сөйләр өчен шактый гына күләмле доклад әзерләгән иде. Салих аны һәм тагын берничә дустын – Фатих Сәйфи-Казанлы, Кави Нәҗми һәм Гомәр Галине съезд барган көннәрдә берничә мәртәбә үзенә кунакка алып кайтты. Тинчурин шул вакытта үзенең докладын Салихка да укытты.

– Шактый саллы булган бу, – диде Салих, докладны укып чыккач.

– Ярты сәгать чамасы булыр, – диде Кәрим.

– Килешсәң – килеш, килешмәсәң – юк, докладыңның ахыргы өлеше миңа ошамады, Кәрим абый, – диде Салих.

– Ник алай?

– Үзең беләсең, мин үзем кешене тәнкыйтьләргә бик яратмыйм. Үземне тәнкыйтьләсәләр, әгәр дә ул гадел булса, кабул итәм. Ләкин соңгы вакытта мине дә, синең үзеңне дә вак буржуазия калдыгы дип, милләтчелектә күп гаепләделәр. Докладыңда син дә шул хакта сүз күтәрәсең. Гаяз Исхакый абзыйны нык типкәләгәнсең. «Гаяз Исхаков төсле эмигрант язучылар фашистларның аяклары астында, бакалар шикелле кабарып, сикереп торганда...» дип җиппәрәсең.

– Гаяз Исхакыйны мин дә тәнкыйтьләдем үз докладымда, – дип куйды Кави Нәҗми.

– Менә шул, берегездә булгач, җиткән бит инде. Нигә аның исеме белән тагын авыз чайкап торырга? Җитмәсә, Гаяз Исхакый эмиграциягә киткәнче синең дә яхшы дустың иде.

– Ләкин бит син дә, мин дә китмәдек эмиграциягә. Бу – сәясәт, Салих дускай.

– Шулайдыр инде. Мин сәясәтне бик аңлап бетермим. Аңа катышмаска тырышам.

– Ләкин без партия установкасына каршы килә алмыйбыз инде, гафу ит, дускай.

– Партия әгъзалары булмасак тамы?

– Партия әгъзалары булмасак та.

– Ярар, мин үз фикеремне әйттем. Бу минем шәхси фикерем. Гаеп итмәгез.

Гаяз Исхакый әле берничә ел элек кенә Төркиядән Кәрим Тинчуринга хат салган иде. Хатның конверты ачык, тиешле органнар укыганы әллә каян күренеп тора. Исхакый ул хатта Тинчуринны советларга хезмәт итеп ятасың дип сүккән.

«Кәрим әфәнде! Син бит бик талантлы үзең. Ничек түзеп яшисең син шул тизәк базында? Үз талантыңны әрәм итеп, сифилитик Ленинның артын ялап ятарга ничек гарьләнмисең?» – дигән бик әшәке сүзләр бар иде ул хатта. Шул хатны Кәрим уйлап бетермичә театрда Уразиковка укыткан иде. Менә хәзер, егерме тугызынчы елда «солтангалиевчелек»тә гаепләнеп, Шиһап Әхмәров, Вәли Шәфигуллин кебек дуслары хөкем ителгәч, Тинчурин форсаттан файдаланып, Гаяз Исхакыйны гаепләп, барлык совет язучылары алдында чыгыш ясарга җыенган. Ләкин мондый чыгышның гына аны киләчәктә исән калырга ярдәм итәсенә өметләнү, саламга ябышып котылып калырга теләгән суга батып баручы кырмыска кебегрәк кенә иде. Ләкин нишлисең, кешене шул өмет яшәтә. Бәлки өметләре нигезледер. Киләчәк күрсәтер. Хәер, 1928 елда ук Тинчуринның театрдан куып чыгарылуы һәм Әстерханнардан әйләнеп кайтуы шул хатның нәтиҗәсе булмады микән?

Язучылар съезды озак, ике атна чамасы барды. Аларны озаткач, студиядә Салих өчен шактый газаплы уку чоры башланды. Ул Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин, Фәрит Яруллиннар кебек булачак композитор өчен мөһим дәресләрдән полифония, инструментовка, музыкаль форма буенча педагогларының өметле шәкерте булып таныла алмады. Чөнки бу нәрсәләр аның өчен күптән таныш һәм бу профессорлар аңа ни дә булса яңалык әйтерләр дип өметләнмәде.

1935 елның җәендә студиянең беренче елын тәмамлап, Казанга кайткан

Сәйдәшне партия өлкә комитетына чакырдылар. Ни өчен икән дип аптырап кына барып керде ул өлкә комитет секретаре кабинетына. Керсә, кабинетта секретарь Газыйм Касыймов янында Кызыл Армиянең Казан гарнизоны командиры Якуб Чанышев утыра. Салих кайсына мөрәҗәгать итәргә дә белмичә генә:

– Исәнмесез, – диде дә ишек төбендә басып калды.

Чанышев торып басты да:

– Түрдән үтегез. Казан гарнизонының почётлы кызыл армиячесе Салих Сәйдәшев үзе! – дип, честь биреп, Салих каршына килә башлады.

Үзенең чынлап та «почётлы кызыл армияче» икәнен искә төшереп, Салих беркадәр каушап калды.

– Исәнмесез, Салих Җамалетдинович! – диде Чанышев, аңа кулын биреп.

Бүлек җитәкчесе дә аның каршына килеп, кулын биреп исәнләште.

– Партиясез кешене партия өлкә комитетына нәрсәгә чакырдылар икән дигәнсездер инде?

– Аптырадым бераз, – диде Салих.

– Салих абый, киләсе ел башында Мәскәүдә Советларның җиденче Бөтенсоюз съезды булачак. Съезд делегатлары алдында һәр республика һәм крайдан үзешчән сәнгать коллективларының концертын әзерләргә кушылды. Бездән Идел буе хәрби округы кызылармеецларының хоры чыгыш ясарга тиеш. Әлбәттә инде, Сәйдәшнең «Кызыл Армия» маршыннан башка буламы?! Дивизиянең тынлы оркестры башкаруында марш та яңгырар Бөтенсоюз делегатлары хөрмәтенә. Оркестрга Сәйдәш үзе дирижёрлык итсә, тагын да яхшы булачак дип уйлыйбыз. Сез моңа ничек карыйсыз, Салих Җамалетдинович?

– Мондый зур эшкә каршы килеп буламы соң инде? Әлбәттә, итәрбез. Ә хор нинди җырлар башкарачак?

– Хорны да сез әзерләсәгез әйбәт булыр иде, Салих Җамалетдинович.

– Яхшы. Әзерләрбез. Әле ул көнгә хәтле ярты елдан артык вакыт бар түгелме соң?

– Вакыт бар. Ләкин ул бармак арасыннан аккан ком кебек узар да китәр. Сез каникулга кайтканнан файдаланып, репетицияләрне җәйдән үк үткәреп куйсагыз, дигән идек.

– Яхшы. Кайчан башларга кушасыз?

– Хет иртәгедән. Ләкин аңа хәтле репертуарны килештереп куйсак, әйбәт булыр иде.

– Анысын инде хор белән очрашкач хәл итәргәдер. Халык көйләре булса, ничек карыйсыз?

– Бик әйбәт булыр, – диде Касыймов.

Салих Казанга кайтканда, Татиздатта үзенең ноталар китабын чыгару турында сөйләшеп килергә дип ниятләгән иде. Бу эшне нәшриятта өлкә комитеты белән килештермичә генә эшләмиләр иде. Форсат чыгудан файдаланып ул бу хакта бүген үк сөйләшеп кайтырга дип уйлап куйды.

– Килгән-килгән үземнең дә мөһим бер гозеремне әйтим әле, – диде ул, батырлыгын җыеп.

– Нинди гозерегез бар, Салих абый? – диде Газыйм Касыймов.

– Мәскәүгә китәр алдыннан иҗади эшчәнлегемнең ун еллыгын билгеләп

үттегез. Рәхмәт. Язган әсәрләремнең китап булып басылып чыкканын да күрәсе килә. Шул гозер белән килергә уйлап йөри идем алдыгызга.

– Ә нигә, мөмкин эш. Әсәрләрегезнең ноталарын әзерләп, Татиздатка илтегез. Без директор Самат Җамалетдинович Шәрәфетдинов белән сөйләшеп куярбыз.

– Китап нәшрияты яңа бинага күчеп йөри бит әле бу көннәрдә, Салих Җамалетдинович, – диде Якуб Чанышев. – Камил Якуб исемендәге китап басу фабрикасы да үзе белән бер бинада урнаша. Бауман урамында.

– Шулаймыни? Бик әйбәт. Бер ел эчендә шундый бина төзеп куйдыгызмы? Әле былтыр гына төзелешне башлаганнар иде түгелме соң?

– Заман шулай куша. Тырыша егетләр. Нәшрият хезмәткәрләре үзләре төзеде бинаны. Ярый алайса, килештек, Салих Җамалетдинович, ноталарыгызны күтәреп, нәшриятка барыгыз.

– Юк, башта гарнизон оркестрына барырга кирәктер. Репетицияләрне озакка сузмыйча башларга кирәк. Җәй кыска, узар да китәр, – диде Салих.

– Сез дә хаклы. Килештек, – диде дә Якуб Чанышев Салихка кулын сузды.

– Сау булыгыз.

Салих икенче көнне гарнизонның тынлы оркестры һәм хор шөгыльләнә торган Кызыл Армия йортына китте. Күрәсең, Чанышев Салихның киләсен әйтеп куйган, хормейстр аны көтә иде инде. Алар өлкә комитетындагы сөйләшү буенча хор белән татар халык көйләрен әзерләргә сөйләштеләр. Хор репертуарындагы җырлардан «Төймә», «Әтнә» һәм «Ирәндек» җырларын сайлап алдылар. Репетиция көнен билгеләделәр дә, Салих бүген үк нәшриятка да барып килергә кирәк дип, өенә кайтып китте.

Салихның киләсен китап нәшриятында да беләләр булып чыкты. Директор Самат Шәрәфетдинов аны үзе музыкаль редактор бүлмәсенә алып керде. Редактор булып, Юрий Васильевич Виноградов эшли башлаган икән. Юрий Салих Сәйдәшевның яхшы дусты, композитор Василий Иванович Виноградовның улы, Ленинград консерваториясендә укыган, ләкин сәламәтлеге какшап китү аркасында укуын тәмамламыйча, Казанга әйләнеп кайткан иде. Салих узган елда аның белән соңгы тапкыр Мәскәүдә Опера студиясендә очрашкан иде. Студия директоры Хәмит Төхфәтуллин аны Мәскәүгә курсантларга өйрәнү материалы буларак файдалану өчен «Әпипә» бию көе темасына симфоник әсәр язарга заказ бирер өчен чакырган иде. Ә аның әтисе Василий Иванович Виноградовны Салих заманында радиостудиядән киткән вакытта үзе урынына оркестр белән җитәкчелек итәргә урнаштырып калдырган иде. Ә Мәскәүгә киткәндә, Василий Ивановичтан ул тагын үзен алмаштыруын, театрга дирижёр булып килүен үтенде. Юрий Васильевич берүк вакытта музыка училищесында да эшли торган булып чыкты.

Салих аның янына бер кочак нота күтәреп килгән иде. Самат Җамалетдинович Юрий Васильевичка Салихның ни эш бетереп йөрүе хакында әйтте дә шунда ук:

– Адаш, «Кызыл Армия маршы»ның да ноталарын алып килмәдегезме? – дип сорады.

Самат Шәрәфетдиновның да атасы Җамалетдин исемле булганга, ул

Салихны адаш дип йөртә иде. Аннан соң яшьләре дә бер тирә булганга да шулай якын күрә иде бугай.

– Бар, ул да бар папкада. Минем бит беркайчан да китап чыгарганым юк. Нәрсә чыгарсагыз да разый, – диде Салих.

– Ярар, сез Юрий Васильевич белән үзегез карагыз, минем эшләр бар иде. Сау булыгыз, – дип, Шәрәфетдинов үз мәшәкатьләре белән китеп барды.

Салих бүксәсе кабарып торган калын папкасын Юрий Васильевичка сузды.

– Охо, шактый калын күренә. Ниләр бар монда? – дип сорады ул.

– Юрий Васильевич, маршлар да бар монда, җырлар да, инструменталь пьесалар да. Сез карап чыгыгыз әле башта. Аннан бергәләп утырып сайларбыз, – диде Салих. – Бәлки берәр музыкаль драманы тулысынча бирергәдер?

– Ярый, карап чыгыйм. Уйлашырбыз, Салих Җамалетдинович, – диде Юрий Виноградов.

Ә берничә көннән керсә, Виноградов башын тоткан, аптырап утыра Салихның ноталарына карап.

– Салих Җамалетлинович, монда мин сездән башка берни дә эшли алмыйм, – ди.

– Шулайдыр, шулайдыр, Юра. Минем анда күп әсәрләрнең оркестр партитуралары юк. Мин бит эшне тизләтер өчен еш кына көйне хәтердә саклаган килеш, тавыш өчен генә оркестровка ясап бардым.

– Яңадан утырып эшләргә кирәк булачак болай булгач.

– Кирәк тә, вакыт юк бит, Юра. Тиздән яңадан Мәскәүгә китәсе. Без булганнарын гына сайлап алыйк та, партитуралары булмаганнарын соңыннан чыгарырбыз әле. Дөнья бит моның белән генә бетми.

– Яхшы, алайса «Кызыл Армия маршы»н кертәбез дә, берничә җыр кертәбез. Беренче җыентыкка шулар җитеп торыр. Риза булсагыз.

Берни эшләр хәл дә юк, Салихның яңа баштан әсәрләрен нотага салып утырырга вакыты да, теләге дә юк иде. Ул ризалашып, марш янына унлап җыр сайлап алгач, калган ноталарын күтәреп, кайтып китте.

Берничә тапкыр хәрби оркестр белән репетицияләр үткәргәннән соң Мәскәүгә китәр вакыт та килеп җитте.

Мәскәүгә барганда, Салихның урыны Латыйф Хәмиди белән бер купеда туры килде. Студиядә инде ел буе укып, икесе дә композициядән Генрих Ильич Литинскийга, гармониядән Владимир Васильевич Соколовскийга йөрсәләр дә, аларның аралашканы юк иде. «Кызыл Татарстан» гәзитәсендә үзен вак буржуазиягә хезмәт итүдә гаепләп чыккан язмасыннан соң Салихның аны бик күрәсе дә килеп тормый, Хәмиди үзе дә аның алдында үзен уңайсыз сизә иде кебек, күзгә-күз очрашудан гел кача иде.

Купега килеп кергәч, Салих анда ниндидер таныш түгел ике кеше янында Латыйф Хәмидинең утырып торганын күрде. Әдәп буенча ул купедагыларга «Исәнмесез!» – дип сәлам бирде.

– Исәнмесез, Салих абый, – диде Латыйф уңайсызланып кына.

– Ә, исәнмесез, вак буржуазия хезмәтчеләрен тәнкыйтьләүче музыка белгече, – диде Салих, тегенең эченә тияр өчен юри төрттереп.

– Онытмагансыз икән, – диде Хәмиди.

– Үзегез дә онытмаганга охшаган. Оныткан булсагыз, әллә кайчан килеп исәнләшкән булыр идегез. Ел буе бер казанда кайнап ятабыз бит инде.

– Гафу итегез, зинһар өчен, Салих абый. Яшьлек максимализмы белән булган хатам.

– Безнең авылда «гафуыгыз белән сату итегез» дип әйтәләр, нәнә. Нинди буржуазиягә хезмәт иткән композитор булыйм, ди, мин?! Ике ел Кызыл Армиядә генә хезмәт иттем, гражданнар сугышында катнаштым. «Кызыл Армия маршы»н яздым. Сәвит тормышын мактаган күпме генә җырларым бар. Ә сез буржуазиягә хезмәт итүче дип язасыз. Татар музыкасын яңартуга каршы түгел мин. Ләкин татар җыры сүзләренең татарча булуы белән генә түгел, милли колоритны да саклап калуы белән татар җыры икәнлеген әйтеп тора. Сезнең Муса Җәлил сүзләренә язган «Күңелле яшьләр» дигән җырыгыз да шундый булганга күрә халык тарафыннан яратып кабул ителде.

Шушы сөйләшүдән соң алар бер-берсен кичереп, якынаеп, дуслашып киттеләр. Латыйф Хәмиди үзе дә җырларында да, инструменталь әсәрләрендә дә милли рухны саклап калырга тырышучы композитор иде.

Мәскәүнең Зур театр бинасында Советларның җиденче Бөтенсоюз съезды делегатлары өчен концертны карарга илнең бөтен җитәкчеләре дә килгән иде. Ложада партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре – Сталин, Калинин, Ворошилов, Молотов, Каганович... Илнең бөтен республикаларыннан килгән делегатларга рус, украин, белорус, казакъ, үзбәк, грузин һәм башка союздаш республикаларның хәрби үзешчән сәнгать коллективлары белән беррәттән Татарстаннан Идел буе хәрби округының Казан гарнизоны үзешчәннәре коллективы чыгыш ясаячак. Коллектив тулысынча хор һәм тынлы оркестр башкаручыларыннан тора. Коллективка Салих Сәйдәшев җитәкчелек итә. Башка коллективларның гөрләтеп чыгыш ясавы баштарак каушабрак торган Сәйдәшнең дә кәефен күтәреп җибәрде. Ул үзен кулга алып, әзерләп килгән программаны башыннан ахырына кадәр күтәренке рухта, тамашачыларның көчле алкышлары астында алып барып, уңышлы башкарып чыкты. Халыкка бигрәк тә Сәйдәшнең «Кызыл Армия маршы» ошады. Татарстан вәкилләре чыгышыннан соң Оборона халык комиссары Клим Ворошилов сәхнәгә күтәрелеп, оркестр һәм хорга дирижёрлык иткән Салих Сәйдәшевка үз исеме язылган көмеш сәгать бүләк итте.

**3**

Үткәннәрне баштан кичергәндә, Салих Мәскәү чорының соңгы 1937 нче елын тетрәнмичә искә төшерә алмады. Шушы елны аның бәләкәч улы Рәләф дифтерия чиреннән вафат булды. Аны җирләгәннән соң ул Казаннан олы улы Альфредны үзе белән Мәскәүгә алып килде. Унбер яше тулган Альфред бишенче класста укый иде инде.

Улын алып килергә дип, Казанга кайтканда, Сәйдәшнең иң якын дип йөргән бөтен дуслары да диярлек «халык дошманы» дип кулга алынып беткәннәр иде.

Башта язучылар арасыннан чүпләгәннәр «халык дошманнары»н. Гомәр Галине, Кави Нәҗмине, Шамил Усмановны, Галимҗан Нигъмәтине, Кәрим Тинчуринны кулга алып, тикшерү изоляторларына ябып куйганнар.

Язучылардан иң беренче кулга алынучы Фатыйх Сәйфи-Казанлы узган елның сентябрендә үк ирегеннән мәхрүм ителгән иде. Ә утыз җиденең бишенче августында аны, кайчандыр эсэрлар партиясендә торганлыгын искә алып, хөкүмәт һәм партия җитәкчеләрен юк итәргә әзерләнүдә, милләтчелектә, солтангалиевчелектә гаепләп, СССР Югары Судының Хәрби коллегиясе карары белән атып та үтергәннәр.

Сигезенче март кичендә Зур театрда хатын-кызлар бәйрәменә багышланган тантаналы кичә булды. Кичәдән соң Гомәр Гали белән хатыны Хәрирә, дусларын – Заһидә белән Кәрим Тинчуриннарны, Сәрвәр Әдһәмова белән Кави Нәҗмине, Маһиҗамал белән Галимҗан Нигъмәтиләрне үзләренә кунакка алдылар.

Бәйрәм табыны булса да, ирләрнең сүзе күбрәк эштәге хәлләр хакында барды. Гомәр Татарстан дәүләт китап нәшриятында матур әдәбият редакциясе мөдире булып эшли иде. Нәшриятта инде ике елдан бирле редакторларның сәяси сизгерлеген тикшерәләр. Төрле сорау алуларга, ышанмаучылыкка эләкмәгән бер генә редактор да калмагандыр.

– Бәйрәм бәйрәм белән, ләкин безнең өстә болытлар куера бит, егетләр, – диде Гомәр Гали. – Кичә генә директор Самат Җамалетдинович Шәрәфетдиновны алып киттеләр.

– Нәрсә булган тагын? Кыска гына вакыт эчендә Казанның уртасында бер дигән нәшрият йорты бастырып куйды.

Самат Шәрәфетдиновны аңа хәтле директор булып торган һәм 1929 елда «халык дошманы» дип кулга алынып Соловки лагерена сөрелгән Вәли Шәфигуллин ясаган хаталарны төзәтү турында уйламыйча, киресенчә, сәяси уяулыкны югалтуда, милли-буржуаз агымнарга теләктәшлек күрсәтүдә гаепләделәр.

– Самат Шәрәфетдинов белән генә тукталмаслардыр, ахры, бу юлы, – диде Гомәр. – Самат Җамалетдиновичның Галимҗан Ибраһимов белән элемтә тотуын да гаепкә алганнар.

– Галимҗан белән мин дә элемтәдә тордым, бүгенгә кадәр, – диде Тинчурин. – Аның нинди гаебе бар икән соң? Ибраһимов – күренекле язучыбыз. Инкыйлаб елларыннан ук большевиклар партиясе әгъзасы. Мулланур Вахитовның уң кулы булган кеше.

– Сәйфи-Казанлы да – Мулланур Вахитов җитәкләгән Мөселман комиссариатында эшләгән кеше. Ләкин аңарчы эсэрлар партиясендә булуын искә төшерәләр. Болай булгач, Ибраһимовны да селеккәли башлаулары бик ихтимал. Ул да эсэр булган инкыйлабка кадәр. Ибраһимовны Солтангалиев белән элемтәдә тора, имеш, ул аның яшерен оешмасының эшләрен алып бара икән, дигән сүзләр йөри.

– Сиңа боларны өлкә комитетында сөйлиләрдер инде, Кави туган, – диде Кәрим Тинчурин Кави Нәҗминең Ибраһимов турында сүзләренә каршы.

– Әйтәм бит, болытлар куера, дуслар. Уен-муен түгел. Уяу булырга кирәк.

– Уяу булып нишлисең инде, Кави дус? Киләләр дә алып китәләр. Эшең бетте, вәссәлам. Менә кичә Самат абзыйны алдылар. Нишли алсын. Китте, саубуллашып.

– Кави, син анда Ибраһимовны 50 яше белән котлап яшь язучылар Галимҗан Мөхәмитшин, Ләбиб Гыйльми, Касыйм Шәйхетдинов, Сөббух

Рәфыйковлардан хат яздырып, Ибраһим Салаховны Кырымга җибәргәнсең икән. Болай булгач, бу егетләргә дә эләгәчәк бит инде.

– Салахов җитди авырып киткән. Аңа Кырымга барып дәваланып кайту файдага булыр, дидек. Берьюлы Ибраһимов белән очрашып, аны яшь язучылар исеменнән котлап, юбилее уңаеннан нәшриятта чыгасы китабының кулъязмасын алып кайтмасмы дигән идек.

– Алып кайтыр да ул. Яшь язучыларның язмышын куркыныч астына кую булмасмы? Элемтәчеләр, арадашчылар дигән ярлык такмаслармы аларга?

– Син, Кәрим абый, ул кадәр үк купайтма әле хәлне. Алай ук куркыныч түгел бит. Самат Шәрәфетдиновны алганнар икән, җитди сәбәпләре булгандыр, димәк. Аны бит нәшрият бинасын төзегәндә ясаган зыяннары өчен дигән сылтау белән кулга алганнар. Имеш, нәшрият бинасы социализм төзү чорының кодрәтен күрсәтә алмаган бина архитектурасында.

– Нишләп икән? Бер дигән бина бит. Ачык китап рәвешендә эшләнгән.

– Әле Шәрәфетдинов кына булса бер хәер, Сәлах Атнагулов белән хатыны, производство бүлеге инженеры Зөһрә Мостафинаны, яшьләр-балалар секторы өлкән редакторы Зөһрә Бәшированы да вазифаларыннан азат иткәннәр. Эшләренең нәрсә белән бетәсе билгесез.

Шул вакыт ирләренең кайтканнан бирле гел шул нәшрият хәлләре турында гәп куертуларыннан эче пошып, Хәрирә ханым мәҗлеснең барышына үзгәреш кертергә теләп:

– Җиттеме сезгә?! Бәйрәмме бүген, әллә производство киңәшмәсеме? – дип сүз башлады.

– Бетте, бетте, Хәрирә ханым, – диде Кәрим Тинчурин. – Әлбәттә, бүген кешелекнең гүзәл вәкилләренең бәйрәме! Язның тәүге бәйрәме! Сезне котлап шушы касәләргә тутырылган шәрабларны авыз итеп куярга тәкъдим итәм!

– Авыз итеп куярга гына түгел! Төбенә хәтле бушатып куярга таләп итәбез! – дип, аңа каршы төште Сәрвәр.

– Әлбәттә, әлбәттә! Беренче тостны касәләрнең төбен корытканчы эчеп куярга кирәк! – диде Кави Нәҗми, хатынын хуплап.

Барысы да бәллүр фужерларны чәкештереп, сигезенче март хөрмәтенә шәрабларын уртлап куйдылар.

– Менә бит немец хатыннарының бәйсезлеге өчен көрәшкән җәмәгать эшлеклесе Клара Цеткин нинди бәйрәм уйлап тапкан кешелекнең гүзәл яртысы өчен! – диде Гомәр Гали.

– Бер уңайдан ирләр өчен дә бер дигән бәйрәм! Яшәсен хатын-кызлар һәм аларның ирләре!

– Эһ, егетләр! Баядан бирле утырасыз юк-бар сүз белән баш ватып. Хатыннарыгыз хөрмәтенә берәр шигырь укырга да башыгызга килми, – дип куйды Хәрирә ханым.

– Хәрирә ханым, сез үзегез дә бер дигән әдәбият белгече бит! Әдәбиятны белүегез һәм яратуыгыз белән Гомәр дусның йөрәген яуладыгыз да бугай. Үзегез берәр шигырь укып җибәрерсез, бәлки, – диде Кави.

– Эһ, Кави, Кави! Такташ исән түгел. Такташ булса, үз кулына алган булыр иде инде бу табынны, – диде Заһидә.

– Әлбәттә. Гафу итегез инде без тилеләрне, кадерле хатыннар, – диде

Тинчурин. – Рөхсәт итсәгез, Такташның бер шигырен бүләк итәргә телим сезгә.

– Нинди сорау ди ул! Тыңлыйбыз, сөйләгез, – диде Хәрирә.

Тинчурин торып басты һәм тамагын кырып, башын чөеп җибәреп, Такташның «Алсу» дигән шигырен сөйли башлады:

Урам ташларына карлар ява,
Кар томалый чана юлларын,
Карда шуа-шуа Алсу килә,
Җиң эченә тыккан кулларын...
Җилгә каршы җылы сулышлары
Туңып бөдрә чәчен ак ясый...
Юл буена аны тирги-тирги
Сүгнә-сүгнә кайта Газзәсе:
– Алсу, тукта инде, акыллым,
Абау,
Тагын карга батырдың!..
Ул үпкәләп читкә китә. Аны
Алсу тагын ялынып чакыра:
– Кил, уйнамыйм, бетте...
Кил инде!
Үзе – килсә карга батыра.

Салкын карга басып Алсу килә.
Үзе көлә,
Үзе сөйкемле,
Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле...

Алар төнге уникеләргә хәтле утырдылар. Сәгатенә карап, уникe тулганын күргән Кави:

– Дуслар, таралырга вакыт. Хуҗаларның да йоклыйсылары киләдер. Иртәгә эшләр дә күп, – дип, урынынннан торды.

– Бәйрәм хөрмәтенә гүзәл хатыннарыбыз исәнлегенә берәр чәркә тотып куймыйбызмыни? – диде Гомәр, һәм касәләргә шәраб тутырып, Кәримгә карап: – Ә синнән бер тост! – диде.

Кәрим:

– Була ул! – диде дә ниндидер таныш түгел шагыйрьнең шигырен сөйли башлады:

Матур сыннар, матур кызлар, матурсыннар,
Әйткән чакта исемегез дә матур чыңлар.
Сезне күреп, ямьгә чумып киттем эреп,
Гакылсызлар: «Гакылсыз!» – дип бакырсыннар.
Карап карыйк: гакыллылар нишләр икән,
Бар гакылны көрәшергә чакырсыннар,
Карап карыйк: бер сылуны җиңәр микән, –
Сихри күздән сихри уклар атылсыннар.

Кызыл ирен бер елмайса, Ходай шаһит,
Бөтен фикер әсир төшәр, гакыл шүрләр;
– Ике Тәңре: әүвәле Алла, икенче – Кыз! –
Димәсәгез, билләһи, кяферсеңнәр!

Көчегезгә иман итеп мин багындым,
Йөрәгемә мәхәббәт сал, матур сыннар!

– Афәрин! Нинди матур шигырь! – диде Кави. – Кемнеке бу?

– Кемнеке булса да, кызларга багышланган! Кызларыбызны котлап укыдым, – диде Тинчурин.

– Мин беләм! Мин беләм! – дип, кулларын чәбәкләде шунда хуҗабикә.

– Кемнеке?

– Ул кешенең исемен атарга ярамый. Сер булып калсын, – диде Тинчурин.

– Нишләп ярамасын?! Бүген ярый. Бабич ул! Хатын-кызларны шулай күкләргә чөеп мактаган бер генә шагыйрь бар дөньяда! Ул – Бабич! – диде Хәрирә. – Башка шагыйрьләр барысы да шул Бабичның исемнәр бакчасыннан чыккан!

– Хатыннар хөрмәтенә! – дип, Гомәр касәсен хатыны Хәрирә белән чәкештереп алды. Аннары Сәрвәр белән Заһидәгә сузылды.

Ирләр өчесе дә чупылдатып, хатыннарын битләреннән үбеп алдылар һәм кулларындагы куе кара кан төсендәге шәраб салынган касәләрен төбенә хәтле бушатып куйдылар. Бу аларның шулай бергәләшеп үткәргән соңгы бәйрәм кичәләре иде. Иртәгесен аларның тормышында шул шәраб шикелле канлы авыр чор башланасын алар әле белмиләр, шуңа күрә үзләрен бик бәхетле хис итәләр иде.

Ә иртән «Кара козгын» белән биш кеше килеп, Гомәр Галинең кулга алынуын әйттеләр һәм Черек күлгә тикшерү изоляторына алып киттеләр. Берничә көн үтүгә Кави Нәҗми дә «халык дошманы» дип игълан ителде һәм Черек күл җәлладлары тоткынына әйләнде.

Гомәр Гали һәм Кави Нәҗми кулга алынганнан соң язучылар тормышында шомлы көннәр башланды. Ләкин «дошман» эзләү язучылар арасында гына түгел, бөтен өлкәләрдә колач җәйгән иде. Артистлар арасыннан да чүпләделәр «корткычлар»ны. Режиссёрлар Гали Ильясов белән Гомәр Исмәгыйлевны, артистлар Мохтар Мутинны, Зәки Баязитскийны алдылар. Гәзитләрдә тәнкыйтьчеләр тарафыннан вак буржуа калдыклары, милләтчеләр дип сүгелгән язучылар, журналистлар, галимнәр, укытучылар, бар да кайчан килеп алырлар икән дип калтырап көтеп утыра башладылар.

11 апрельдә Галимҗан Нигъмәти белән Кәрим Тинчурин хатыннары Маһиҗамал һәм Заһидә белән Хәсән Туфаннарда кунакта булдылар. Туфан белән Луиза кызларының туган көне уңаеннан якын дусларын һәм туганнарын мәҗлескә җыйганнар иде. Монда да сүз ихтыярсыз кулга алынган иптәшләре турында сөйләшүгә әйләнеп китте. Галимҗанны Гомәр Гали белән Кави Нәҗми кулга алынганнан соң берничә көн үткәч, педагогия институтының партия оешмасы утырышында, «контрреволюцион элементлар һәм буржуаз милләтчеләр белән элемтәдә торган» дип, партиядән чыгардылар. Партиядән чыгарылган кешене, гадәттә, озак тотмыйча кулга алып, шулай ук «халык дошманы» дип игълан итәләр иде. Шуңа күрә Галимҗан кайчан килеп, аны да алып китәрләр икән дип уйлап йөрде. Галимҗанны кунакка чакыру хуҗаларны да куркыныч астына куя иде.

– Сез курыкмыйча яши аласыз, сез партия әгъзалары түгел, – диде Галимҗан, мәҗлестәшләре Туфан белән Кәримне тынычландырып.

– Гаҗәп инде, партия үзенең солдатларын юк итә, – диде Туфан.

– Тынычлап йоклый аласыз, дип әйтмәкче буласаң инде алайса. Гәзитләрдә вак буржуаз милләтчеләр дип яла язып торсыннар да, ничек итеп тыныч йоклап булсын шундый заманда?!

– Шулай дип язучыларның үзләрен дә тынычта калдырмый ГПУ. Сәйфи-Казанлы нинди генә гаепләр ягып бетермәде язучылар өстенә. Үзе иң беренче булып аждаһа авызына барып керде. Гомәр Гали дә күп язды шундый мәкаләләрне. Кави да кирәгеннән артык әтәчләнде җыелышларында. Партия әгъзасы булуга гына карап тормыйлар, җитәкчеләрне юк итү бара илдә. Күрмисезмени, алынганнар барысы да – җитәкче урыннарда эшләгән кешеләр, – диде Галимҗан, Тинчуринны тынычландырырга теләгәндәй.

– Алай дип уйласаң, синең белән миңа да озак йөрисе калмагандыр иректә, – дип каршы төште Кәрим Галимҗанның бу сүзенә.

Тинчуринның шулай дип әйтүе гүя тәкъдирен алдан белеп торган әүлия җавабы шикелле иде. Озак та үтми, сентябрьдә аларның икесен дә кулга алып, Черек күл изоляторына ябып куйдылар.

**4**

Салих Мәскәүдән дипломсыз кайтты. Иң якын дусларының халык дошманы дип хөкем ителүен ул бик авыр кабул итте. Бигрәк тә Шамил Усманов, Галимҗан Ибраһимов һәм Кәрим Тинчуринның төрмәгә утыртылуын авыр кичерде. Ничек инде, гражданнар сугышы фронтларында каһарманнарча сугышкан, армия хәтле армиянең комиссары булган ялкынлы большевик Шамил Усманов халык дошманы булсын?! Революционер, милли мәсьәләләрдә Сталинның уң кулы, Казанда революцион вакыйгаларның башында торган, Мөселман социалистлар комитетын оештыручыларның берсе булган, Татарстан Республикасын төзү өчен башлап йөргән Мулланур Вахитовның урынбасары Галимҗан Ибраһимов – халык дошманы! Бу акылга сыймый торган гаепләү. Ә Кәрим Тинчурин? Аны ничек итеп халык дошманы дип атарга була? Салих аны әле Әминә апасы Шиһап җизнәсенә кияүгә чыккан көннән үк белә. Ул аларның туенда катнашкан иде. Шул елларда «Сәйяр» труппасында уйнап йөргән артист, аның режиссёры, февраль инкыйлабыннан соң Мәскәүдә Гаяз Исхакый чыгарган «Ил» гәзитәсендә эшләгән журналист, октябрьдән соң яңадан Казанга кайтып, «Сәйяр»не җитәкләгән, шул еллардан бирле гомере буе театр эше белән шөгыльләнгән кеше, артист, режиссёр, драматург. Менә шул кешене халык дошманы дип хөкем иткәннәр. Салих Мәскәүдән кайткач, инде аларның берсен дә күрмәде. Исәннәрдерме алар, бәлки Шиһап җизнәсе шикелле хөкем ителгәннәрдер дә каядыр Соловкида, Колымада иза чигәләрдер.

Эштән куып чыгарылган Салих үзенең хәлен дә әнә шул кадерле кешеләренеке, иң якын дусларыныкы белән бердәй хис итте. Ул да бит бу көннәрдә алар кичергән хисләрне кичерә. Алар башыннан үткән авыр тойгылар аның да миен бораулый. Алар шикелле үк артык кеше булып чыга бит ул бу җәмгыять өчен. Беркемгә дә кирәк түгел икән бит аның да унҗиденче елдан бирле музыка дип, сәнгать дип ашкынып йөрүләре, ул иҗат иткән маршлар, музыкаль драмалар, җырлар...

Хәер, ялгыша бугай. Халыкка кирәк алар. Халык аларны ярата, җырлый,

тыңлый. Салихны урамда очратсалар, аннан аерыласылары килми, аны кунакка дәшәләр, соңгы телемнәренә хәтле аның белән бүлешергә әзер торалар.

Ләкин Мәскәүдән кайтып төшкәч, Салих үзен дә «халык дошманы» дип игълан ителгән кеше кебек хис итте. Театр репертуарыннан аның Тинчурин белән бергә иҗат иткән бөтен спектакльләрен дә алып ташлаганнар иде. Театр гына да түгел, җырчыларның Тинчурин сүзләренә җырлана торган радио фондында булган язмаларын да эфирга бирүдән тыйганнар. Сәйдәшевнең Галия Кайбицкая, Рокыя Кушловская, Сара Садыйкова, Ситдыйк Айдаров башкара торган күпме җыры радиодан тапшырылмый башлады.

Радио – Салих өчен театр шикелле үк кадерле, радиокомитет аның өчен икенче туган йорты кебек. Радиодан беренче музыкаль тапшыруларны Салих Сәйдәшев башлады бит. Радиостудиягә аны Шамил Усманов чакырып китерде. Усманов белән аларның танышлыгы һәм дуслыгы 1919 елдан ук килә. Шул елда Мәскәүдә интервентларга каршы сугышыр өчен Карл Маркс исемендәге интернациональ батальон оештырыла башлый. Аның Мөселман бригадасын оештыру бурычы 1917 елдан ук большевиклар партиясендә булган, Октябрь инкыйлабын патша армиясендә хәрби хезмәттә каршылаган кызыл комиссар Шамил Усмановка йөкләнә. Бригаданы оештырырга Казанга килгән Усманов аның театраль секциясен оештыруны Кәрим Тинчуринга тапшыра. «Сәйяр» труппасының актив музыканты Салих Сәйдәшев әнә шулай итеп, Беренче Мөселман бригадасының театр төркеме музыканты вазифасында Кызыл Армия сугышчысы булып китә.

Сәйдәшевнең, 1922 елны Казанга әйләнеп кайтканчы, Төркестан фронтында, Оренбургтагы бөтен эшчәнлеге шушы бригада солдаты буларак, Шамил Усманов янәшәсендә узды. Казанга кайтып, Татар дәүләт театрында эшли башлагач та, Казанда радиостудия оештыру эше белән янып йөргән Усмановның чакыруы буенча ул бер үк вакытта радиода музыкаль тапшыруларны оештыручы сыйфатында оркестр оештырып җибәргән иде.

1930 елда Шамил Усманов кинәт кенә радиостудиядәге эшчәнлеген калдырып, тулысы белән язучылыкка чумды, хикәяләр, повесть һәм драмалар язуга күчте. Һәм менә шул кеше, халык дошманы дип аталып, 1937 елны кулга алынган.

Бу ни хәл соң бу?! Инкыйлаб өчен башларын салырга әзер торган большевиклар, егерме елдан соң инкыйлабның дошманнарына әверелгәннәр. Акылга сыймый торган хәл.

Барысы да 1936 елның августында Мәскәүдә Ленинның көрәштәшләре Зиновьев, Каменев, Бухариннарга каршы оештырылган ачык судтан соң башланды. Аларны хөкем иткәннән соң, шунда ук төбәкләрдә Сталинның революция дошманнарына каршы көрәшкә чакыруына җавап итеп, Татарстан Язучылар союзында да корткычларны фаш итүгә багышланган җыелыш булып узды.

– Без бөек Сталинның революцион уяулыкны ныгытырга чакырып ясаган чыгышына җавап итеп язучылар арасында «троцкийчы-зиновьевчы корткычларны» фаш итүдә үз өлешебезне кертергә тиешбез, – диде Кави

Нәҗми үзенең чыгышында һәм үз араларында, имеш, яшертен эш алып баручыларның исемнәрен атады: – Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Мансур Крыймов, Исмәгыйль Рәмиев, Шамил Усманов кебек бәндәләрнең пролетар язучы дигән бөек исемне йөртергә хокуклары юк, – дип, чыгышын тәгәлләде.

Ике көнгә сузылган җыелышта кабул ителгән карарда Шамил Усмановны «үзенең әсәрләрендә милли-буржуаз идеяләрне алга сөрә», «гражданнар сугышы тарихын бозып күрсәтә», «кызыл армиячеләрне томана итеп тасвирлый» дигән гаепләр тагылган иде.

Җыелыш, «Татар Совет язучылар союзын контрреволюцион элементлардан чистартырга», дигән катгый карар чыгарды.

Язучылар җыелышы карарын күтәп кенә торган диярсең, икенче көнне үк «Кызыл Татарстан» газитендә Фатыйх Мөсәгыйтнең әлеге язучыларны буржуаз милләтчелектә гаепләгән мәкаләсе басылып чыкты. Ул хәтта исемлекне тагын да зурайтып җибәргән, аңа яңа фамилияләр өстәгән иде. «Мин аның әсәрләрен марксизм-ленинизм күзлеген киеп укыдым. Коммунизм идеяләре белән чыныккан каләмем очына алып, бу әсәрләрне селкеп-селкеп укып чыктым. Алардан череп таркалган буржуазия исе килә. Аны укыганда укшый башлыйсың», – дип язган иде Мөсәгыйт мәкаләсенең Шамил Усмановка караган өлешендә. Мондый язмадан соң кемне генә иректә калдырсыннар үзенең алга таба да «антисоветчы әсәрләрен» иҗат итәр өчен? Дөрес, башта Фатыйх Сәйфи-Казанлыны кулга алдылар. Аннан соң алты-җиде ай узгач кына – башкаларны. Бер исәптән Кави Нәҗминең үзен дә ябып куйдылар. Ә Кавидан соң бер ай үтүгә – Шамил Усмановны.

Өлкә комитет секретаре Лепа рөхсәте белән кулга алынды Усманов. Совет властен урнаштыруда аеруча зур хезмәте кергән Усманов шикелле фигурага гаеп ягар өчен Лепа дәрәҗәсендәге кешедән алынган санкция кирәк иде, әлбәттә. Сигезенче апрельдә НКВД хезмәткәрләре «Казан» кунакханәсенең Шамил Усманов яшәгән бүлмәсенең ишеген шакыдылар.

Усмановның «Керегез» дигән рөхсәтен ишеткәч, бүлмәгә эчке эшләр хезмәткәре киемендәге биш кеше килеп керде.

– Язучы Шамил Усманов сез буласызмы? – дип сорады керүчеләрнең башлыгы.

– Мин булам, – диде өстәл янында язып утырган Шамил.

– Сез совет властена каршы эчтәлектәге әсәрләр язуда гаепләнәсез, – диде начальник. – Менә сезне кулга алу турында нарком санкциясе. Киенегез. Санкция нигезендә барлык мөлкәтегез конфискацияләнә.

Икенче хатыны Асия Измайловадан аерылып, Мәскәүдән Казанга кайтып яши башлаган әдипнең әллә ни мөлкәте бар дип әйтеп булмый иде. Аның бүлмәсендә тентү ясаганнан соң булган әйберләрен бер капчыкка тутыра башладылар. Алар арасында кәгазьләр белән шыплап тутырылган егерме өч папка, утыз алты дәфтәр, китаплар һәм оборона комиссары исеме язылган револьвердан кала иске портфель белән чемоданнан башка берни дә юк иде. Кулга алучыларның берсе капчыкка озатылган һәр дәфтәрне, папканы берәмтекләп санап, актка теркәп барды.

– Мин язучы гына түгел, мин – 1917 елдан бирле большевиклар партиясе әгъзасы, революцияне шушы кулларым белән ясаган революционер,

гражданнар сугышы каһарманы, Үзәк Мөселман Хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге башлыгы, Төркестан фронты Хәрби-революцион советы әгъзасы, беренче татбригада комиссары, хәрби начальник булган кеше! – диде Шамил. – Бу нindidер ялгышу. Сезнең миңа кагылырга хакыгыз юк!

– Анысын наркоматта тикшерерләр. Безнең эшебез наркомның карарын башкарып, сезне кулга алу һәм тиешле урынга илтеп тапшыру! – диде тентү үткәрүчеләрнең башлыгы.

Аны Черек күл изоляторына илтеп яптылар. Кулга алынган көнне үк сорау алулар башланды. Усмановтан Татарстан НКВДсы идарәсенең дүртенче сәяси бүлегеннән өченче бүлекчә башлыгы Лазарь Ефимович Марголин сорау алды.

– Гаепләнүче Усманов, үзеңнең ни өчен кулга алынуыңны беләсеңме? – диде Марголин.

– Юк, – диде Шамил. – Минем партия һәм совет хөкүмәте каршында бернинди гаебем дә юк!

– Син Троцкий, Зиновьев, Каменев, Бухарин һәм аларның тарафдарлары алып барган совет хөкүмәтенә каршы корткычлык эшләрендә гаепләнәсең.

– Мин бернинди корткычлык эшләре дә алып барганым юк.

– «Легион юлы» дигән әсәрнең авторы синме?

– Әйе, мин. Гражданнар сугышы елларында басмачыларга каршы сугышларда кызыл армиячеләрнең героик көрәшен күрсәткән әсәр.

– Менә шул әсәрегездә троцкийчы хәрби начальник Блюхерның ролен артык зурайтып күрсәткәнсең.

– Матбугатта, киресенчә, Блюхерның гражданнар сугышындагы ролен түбәнәйтеп күрсәтүем турында язып чыкканнар иде.

Шамил Усмановтан сорау алуның беренче өлешендә Марголинның бары тик аның кулга алынуына карата фикерен белү өчен кылларын чирткәләп каравы гына иде. Ул бераздан тоткынга тәмәке тәкъдим итте. Шамил рәхмәт әйтеп, аннан бер сигара алып кабызды. Марголин үзе дә сигара кабызып, сорау алу бүлмәсендә үк тәмәке төтенләп алды. Икенче бүлектә Усмановка белдерелә торган гаепләр тагы да катгыйрак һәм куркынычрак иде. Тәмәкесен тартып бетергәч, ул камерага сержант дәрәҗәсендәге тагын бер хезмәткәрне чакырып кертте.

– Болар әле сиңа белдерелә торган гаепләрнең иң җиңеле генә, – дип башлады ул сорау алуның икенче өлешен. – Син күптән түгел генә Мәскәүдәге троцкийчы-зиновьевчылар оешмасының кушуы буенча аның Казан бүлеген оештырыр өчен җибәрелгәнсең. Оешмагызда тагын кемнәр бар?

Усманов мондый көтелмәгән сораудан аптырап һәм беркадәр югалып калды.

– Мин бернинди дә оешманы белмим. Мәскәүдә дә, Казанда да андый оешма турында ишеткәнем юк, – диде ул, бераздан үзен кулга алып.

– Алдыйсың, кабахәт! – дип акырды Марголин.

Аның бу акыруы кергән хезмәткәр өчен команда булып яңгырады булса кирәк, ул бар көче белән Усмановның касыгына китереп сукты. Кинәт сугудан тыны кысылган тоткын эчен тотып, идәнгә тәгәрәде. Сержант бераздан аны күтәреп торгызды, ләкин элеккеге кебек урындыкка

утыртмады, Марголинның каршына китереп бастырды. Анысы элеккеге кебек үк усаллык белән сорау бирүен дәвам итте:

– Троцкий үзе Мексикада качып ята. Ә аның тарафдарлары Мәскәүдә хөкем ителделәр. Бу хакта да белмисеңме?

– Ишеттем. Ләкин аларны совет хөкүмәтенең дошманнарыдыр дип санамыйм.

– Ах, әле шулаймы?! Аларны яклап маташасыңмы?! Хәзер аңлатырбыз хатаңны!

Марголинның бу сүзләре янә сержант өчен команда булып яңгырадылар. Ул, элеккедән дә катырак кизәнеп, Усмановның эченә китереп сукты. Тоткын тагын идәнгә тәгәрәде.

Беренче көннәрдә Шамил Усмановны гел шул бер үк сорауларга җавап таптырып кыйнадылар. Ул, әлбәттә, үзенең хәрби эшчәнлегендә Троцкийның үзе белән дә очрашкан кеше, күп тапкырлар аның хәрби боерыкларын үтәгәне бар. Зиновьевны да, Каменев белән Бухаринны да яхшы белә, комиссар буларак та, язучы буларак та, алар белән еш аралашты, партия һәм хөкүмәт эшләрен хәл итүдә катнашты. Җитмәсә кайбер иптәшләр белән сөйләшүләрдә НКВД системасының эшчәнлеге куркыныч нәтиҗәләргә китерүе мөмкин дигән фикерне дә әйткәләде. Әле егерменче елларда ук Солтангалиев һәм аның тарафдарларына каршы башланган репрессив чараларга карата үзенең тискәре мөнәсәбәтен белдереп тә чыгышлар ясаганы булды. Менә шулар барысы да хәзер үзенә карата ачылган эшнең сәбәпчесе булуын ул бик яхшы аңлый иде. Шулай да Шамил нык торды, беркемнең дә исемен атамады, берсен дә бу сазлыкка өстерәп кертмәде. Беренче сорау алулардан бернинди нәтиҗәгә дә ирешә алмаган Марголин бераздан аның Татарстан хөкүмәтендәге тамаша оешмалары белән җитәкчелек итү, радиостудия оештыру кебек эшчәнлеге белән бәйле сорауларга, яңа төр дошман эзләүгә күчте. Марголин алдына НКВД җитәкчелеге тарафыннан Татарстанда троцкийчылар оешмасын фаш итү, моны теләсә нинди юл белән башкарып чыгу бурычы куелган иде. Шуңа күрә ул кыйнаулардан, тоткынны гарип калдыру кебек вәхшилекләрдән дә чиркануп тормады.

Бу вакытта башка камераларда Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчуриннардан да шундый ук яшерен троцкийчылар оешмасын фаш итү буенча рәхимсез җәзалар юлы белән сорау алулар барды. Әлбәттә инде, палачлар төзегән һәм сорау алынучы бары тик раслап кул гына куярга тиешле исемлекләрнең барысында да шул берүк исемнәр теркәлгән иде. Сигез ай буе беркемне дә сатмаган, бернинди дә исемне атамаган һәм бернинди дә яшерен оешма булуын да танымыган, бу вакыт эчендә кыйналып, имгәтелеп һәм ач тотудан шыр сөяккә калган Шамил Усманов, ниһаять, катгый бер карарга килде: «Оешма барлыгын расласам-расламасам да, бу палачлардан бер генә нәрсәгә өмет итәргә була – үлемгә! Гаделлек беркөн барыбер өскә чыгар. Бу палачлар җир өстеннән себереп түгелер. Ләкин минем халкым алдында тапланмаган исемем, башкарган эшләрем калачак!»

Өченче декабрь көнне иртән ул, Марголинны шатландырып, троцкийчылар оешмасында торучылар исемлегенә кул куярга риза булуын әйтте һәм исемлек белән бергә каләм һәм кара китерергә сорады.

– Менә бит, күптән куярга кирәк иде инде кулны. Кайчаннан бирле карышып маташасыз, – дип, палач сез дип сөйләшүгә күчте. Ләкин ул «дошман табу» өлкәсендәге бу эшенең үзенә карата да хөкем карары чыгаруы икәнен әле белми иде.

Палач өстәл тартмасыннан, тоткын исемнәрен әйтмәсә дә, инде күптән төзеп куелган исемлек язылган кәгазьне чыгарды һәм корыч каләмле ручка белән кара китереп куйды. Түземсезлек белән тоткынның исемлек астына кулын куйганын көтә башлады. Кәгазьдә кемнәрнең фамилияләре язылганын озаклап укуына эче пошып:

– Бар да таныш исемнәрме? – дип сорап куйды.

Бу минутларда Шамил Усмановның күз алдыннан утыз тугыз гына еллык, әмма бәхетле матур тормыш кору өчен аяусыз көрәш һәм фидакарь хезмәт белән үткән гомер юлы узды; аның башында шундый авыр көрәшләр белән яулап алынган җиңүләрне пыран-заран китереп, халыкның иң батыр улларын халык дошманнары дип атаган Сталинга һәм аның юк итү аппаратына әйләнгән НКВД хезмәткәрләренә карата нәфрәт хисләре кайный иде. Ләкин ул бу аппаратка каршы барырга көчсез иде инде.

– Бар да таныш исемнәр, – диде Шамил Усманов һәм каләмен карага манасы урынга, кинәт торып басты һәм кулын сузып җибәрде дә айканып, уң күзенә китереп кадады. Күзеннән чәчрәп, каны чыкты һәм таш идәнгә егылып җан бирде.

Аның бу хәрәкәтеннән коты алынып, агарынып калган палач, нәрсә эшләргә дә белмичә, идәндә яткан тоткынны күтәреп, урындыкка утыртты...

1898 елның 26 декабрендә туган, тагын егерме өч көннән 39 яше тулырга тиешле Шамил Усманов үлеме турында НКВДның санчасть начальнигы Л.И.Шелутко: «Йөрәк параличы нәтиҗәсендә кинәт вафат булган», дигән Акт тутырды.

НКВД хезмәткәрләре бөтен ерткычлыкларын яшереп калырга теләсәләр дә, төрмәдә кайсы тоткынның нинди хәлдә икәнен, кемнең нинди җәзага хөкем ителгәнен яисә палачлар кулыннан һәлак булганын белеп торалар иде. Усмановның да үз-үзенә кул салуын яшереп кала алмадылар.

Тагын бер елдан СССР НКВДсы башлыгы Ежов урынына билгеләнгән Берия, Дәүләт куркынычсызлыгы комитетындагы башбаштаклыкларны фаш итеп, оешмада гаеплеләрне җәзага тартулар башлагач, Казанда тоткыннарны кыйнап үтерү белән шөгыльләнгәне һәм уңай нәтиҗәләргә ирешмәгәне өчен Шамил Усмановның һәм тагын берничә кешенең гомерен өзгән Марголинга карата җинаять эше ачыла. 1939 елның 16 октябрендә, шулай ук кырык яшендә генә булган палач, хезмәттәшләренең сорау алулары вакытында «кинәт йөрәге туктау нәтиҗәсендә» вафат була.

*(Ахыры киләсе санда.)*



Гөлнур
Айзат

# СЫНАУЛАР БИРӘ РАББЫБЫЗ...

## Бөркет

Бөркет булып, көчле бөркетнең дә
Бер көн килеп, сайлар чагы җитә:
Көрәш аша үрләргәме күккә,
Мескен булып үләргәме читтә?

Сайлый бөркет бары биеклекне,
Үскән тырнакларын чукып ала.
Түзә бөркет – биек кыялардан
Бармак саен бәгырь каны тама...

Яшәү өчен көрәш дәвам итә,
Таш кыяда – канлы томшык эзе!
Бөтен тәне әрнеп сызланса да,
Гел биекне барлый бөркет күзе!

Авыр булып үскән канатларын
йолкып ата – түзсә түзә йөрәк!
Биеклеккә кабат җитәр өчен
Яңа чыккан яшь канатлар кирәк!

Эләктерер өчен үз корбанын
Үсеп чыгар тырнаклары кабат.
Нигә әле бөркет була торып,
Яшәсен ул мескеннәргә карап?!

Таш кыяны чукып яргаланган
Томшыгы да үсәр – үсми тормас!
Өзгәләнгән озын канатлары
Кабат ныгыр – бөркет мескен булмас!

---

Гөлнур АЙЗАТ (1960) — *шагыйрә; «Күз яше ачы була», «Өч мизгел», «Әманәт» исемле китаплар, күпсанлы җырлар авторы. Буа шәһәрендә яши.*

Тормыш дәвам итәр шул чагында:
Йә көрәш син, йә кит дөньядан!
Бөркет булып син керденме төшкә –
Сорау алам менә уйлардан...

## Тамчылы төш

Таңнарда сәлам юлладың,
Күңелем тынып калды.
Сине сагыну хисеннән
Күзләрдән яшьләр тамды.

Минем яшьләргә кушылды
Иртәнге таң чыклары.
Бер минут та хәтеремнән,
Исләремнән чыкмадың.

Син сөйгән яран гөлләрдән
Тамчы бөртеге тамды.
Эндәшкән күк булдың үзең,
Ут камап алды җанны.

«Моңлы син, кызым, шуңа да
Түзәсең сабыр гына.
Сынаулар бирә Раббыбыз
Иң, иң, иң сабырына...»

Яранның да яшен сөрттем,
Якын сүз төште телдән:
«Сәламең төш булган икән,
И Әни, Әни генәм!»

## Тараф

Үлән булып үлән урап уза
Юлындагы дивар-киртәләрне.
Минем уйлар тукталышта һаман,
Әллә көтә нурлы иртәләрне?!

Мин торганчы төне буе саклап
Ул уйларым янәшәдә яткан.
Кайберләре ачу китергечтер,
Кайсылары матур, якты, аклар...

Уйлар белән тагын юлга чыктым.
Ничә тараф көтә: берме, өчме?
Уй-максаты булган кеше генә
Табар киртәләрне узар көчне.

## Диңгез ярында

Әй, серле син, диңгез! Тынгысыз да!
Дулкыннарың кочып басып торам.
Син сулыйсың гүя, тирән итеп,
Мин дә дулкынланам синең тыннан.

Диңгез! Диңгез! Син хатын-кыз сыман!
Мәхәббәтле үзең, бик матур да!
Нинди уйлар белән яшисең син
Калкан-кыяларның артларында?!

Шундый тере бит син! Шундый көчле!
Ирләр кебек гайрәтле син, чыдам.
Синең дулкыннарда ярсып йөзәм,
Мин алардан көчләр алып чыгам.

Зәңгәр күкләр, Кояш сиңа чума.
Елмаясың, диңгез, син аларга.
Могҗизалы тормыш белән тулы,
Бер хәзинә бит син дөньяларда!

Энҗе сипкән сыман балкыйсың син,
Алсулана йөзең таң аткanda.
Мин гашыйкмын сиңа, горур диңгез,
Ярларыңа киләм яратканга.
Яратканга!

## Таңда уйлану

Биш катлымы синең корган йортың,
Исе китмәс аңа Ходайның.
Шул йортыңда күпме кешеләргә
Ачык булды икән чыраең?

Меңнәр йөрсен синең зур кесәңдә,
Миллионнар – Алла кулында!
Ничек таптың икән һәр тиенең,
Дус булдымы намус юлыңда?

Кәнәфиең биек, дәрәҗәле
Булдымы дип Ходай сорамас...
Ничек кылдың һәр гамәлең, Кеше,
Шул мөнбәргә менеп уралгач?!

Дусларыңның саны мөһиммени,
Син соң үзең кемнең чын дусты?
Авыр чакта иңең куйдыңмы син? –
Ахирәттә зарур шунысы!

Дус-туганнар белән ничек яшәп,
Ничек зурладың соң аларны?
Искә төшердеңме хаталарың?
Искә алдыңмы син Алланы?

Сырхауларга бирдеңме син сәлам?
Хәлен белдеңме син мохтаҗның?
Өлеш чыгардыңмы җылысыннан
Йөрәгеңдә йөрткән ут-таҗның?

Үз-үземә шундый сорауларны
Бирдем, җавап эзләп үземнән.
Гомер җебе озын, ә үзендә
Күпме сорау-төймә тезелгән.

## Туган телне сөеп яшә!

Теле татлы булганнарның дуслары күп.
Дуслар белән яшәү матур, җиңел(е)рәк.
Бер яхшы сүз мең яраны төзәтә ул,
Ташларны да эретә тел, җырлый йөрәк.

Үз телемә һәрчак киңдер күңел түрем,
Әнкәемнән олы бүләк – туган телем.
Теле барның юллары бар, асыл эше –
Туган телне сөеп яшә, газиз Кешем!

Туган телдә акыллы сүз шундый кыйммәт!
Гөлбакчалар кебек телем гүзәл бизәк.
Туган телдә халкым моңы – җанга дәва,
Әйткән сүздән тула күңел, өзелә үзәк.

Теле барлар халык булган, данлы булган,
Дөньяда иң татлы нәрсә – ул тел, туган!
Җиде кат җир астыннан да юллар тапкан,
Туган телне юлдаш иткән һәрчак уңган.

Үз телемә һәрчак киңдер күңел түрем,
Әнкәемнән олы бүләк – туган телем.
Теле барның бардыр юлы, күркәм эше.
Туган телне сөеп яшә, газиз Кеше!

## Дивар

Ни ул Үлем? Җиңел, авырмы ул?
Җавап эзлим бүген Тормыштан.
Үлем барлыгын бит һәркем белә
Тәкъдир язылган ул тумыштан.

Кеше яши. Еллар уза тора.
Хата – ялгышлар да кылына.
Кем соң белә: бүген, иртәгәме
Үлем түшәгенә егыла?!

Үлем авыр, диләр. Юк, килешмим!
Авыррак тормыш иткәндә!
Үлем – Дивар сыман! Котылгысыз!
Чагыштыра алмыйм бүтәнгә.

Дивар алды – без тудырган байлык,
Дивар арты – бары Җан гына.
Кем соң сорау биргәне бар икән
Яшәгәндә шушы Җанына?!

Дус-туганны белми, хөрмәтләми
Телен сата күзе тонганнар.
Әйтерсең лә алар гел үлемсез,
Бакыйлыкка күчми торганнар...

Дене ни дә аңа, Ватаны ни?!
Тормыш бүләк иткән Анасы?!
Бәдрәфенең алтын тоткасыннан
Кулын алмый, кирәк яңасы...

Байлык арткан саен, йөрәгендә
Мәрхәмәтлек кими, намусы...
Шул Диварга борын төртелгәчтән
Нинди булыр – килә карыйсы.

Артта – Кеше корган таш сарайлар,
Кеше корган зәһәр тозаклар...
Айнытырга адәм балаларын
Үлем дигән Дивар-йозак бар!

Алда Дивар. Аның аша тик Җан
Юлын ала бакый галәмгә.
Күкрәк кагып йөргән Кеше бер мәл
Тузан бөртегенә әйләнә.

Дивар күргәч, кемдер, ашыга-ашыга,
Төзәтергә тели хатасын.
Тормыш өлеше ул, Үлеме соң
Нигә гөнахларны акласын?!

Күпме якыннарны югалтабыз,
Алар өчен яшьләр түгелә.
Газизләребезне җуйган көнне
Күзәтәдер безне Үлем дә.

Сабый чакта зур буласы килә,
Яшүсмердә – урта буласы!
Өлкәнәйгән саен якыная
Җавап тотар чакның Кыйбласы.

«Яшәп калыйк, имеш, янып калыйк!»
Синнән торамы соң гомерләр?!
Аяк астындагы боз юкара,
Шул боз сыман гомер үзе дә!

Гел яхшылар, юмарт, акыллылар
Китә тора – Үлем сайламый.
Үлем дигән шул нык бу Диварны
Урар юлны беркем табалмый.

Син китсәң дә аннан, мин китсәм дә,
Тормыш бар ул! Мәңге калачак.
Үлем-мизгел! Минут! Секундтыр ул! –
Үз корбанын барыбер табачак.

Качып кала алучылар юктыр!
Бар гомернең башы, чиге дә!
Кеше булып яшик! Баш хәрефтән
Шул санаулы гомер чигендә!


## Кешелеккә сорау

Наданнар дөньяга хәзер булды баш,
Күз чыгаралар ясыйм дип асыл каш.
Алтын, якутларга төренеп кенә
Булмастыр алар, булалмас асылташ!

Китап укымый бар китап язганнар,
Вәгазь сөйләүчеләре дә азганнар.
Намуслы булып күренгәннәр җирдә
Вөҗданны сатарга хәтта базганнар!

Ата-ана оныта бара гамәлен,
Кызыксынмый баласының хәлләрен.
«Тәрбия» дип авыз суы кортулар
Үзгәртәлмәс кайгыртуның мәлләрен.

Кешелек!
Ни калыр бездән соң җирдә?
«Киләчәк» дип
Уйланмыйбыз ник бер дә?!



Вакыйф
Нуриев

ХИКӘЯЛӘР

# НӘБИ ДӘҮЛИ ЙӨЗ КЫЗАРТА

Берсендә шулай «Яшь ленинчы» газетасы редакциясенең әдәбият һәм сәнгать бүлеге бүлмәсенә, кыюсыз гына ишек шакып, язучы Нәби Дәүли килеп керде. Бүлмәдә без шагыйрь Госман Садә белән икәү идек.

– Әйдүк, Нәби ага, түргә уз! – диде Садә.

– Рәхмәт! – Кунагыбыз кыяр-кыймас кына узды. – Мин сезне ресторанга чакырырга килдем. ЭмЦыга! Юл аша гына чыгасы бит!

– Ресторанга! Нинди вакыйга уңае белән?

– Сезне сыйлыйсым килә. Шул гына. Эшләрегез бик тыгыз булмаса, әйдәгез. Эшегез булса, көтеп торам, йә башка вакытта киләм.

Олпат әдип, легендар Нәби Дәүли сине ресторанга чакырып торсын әле. Кырык эшеңне кырык якка ташлап барырсың. ЭмЦының, ягъни Яшьләр үзәге ресторанының да дәрәҗәле чагы.

Киттек!

Ресторанга килеп кергәч, Нәби ага кырт туктап калды. Урамнан кергән шәпкә ордым-бәрдем залга узмады. Без дә төртелдек. Каян күреп өлгергән, яныбызга урта яшьләрдәге ялтырап торган кара чәчен йөзенә килешле итеп кистергән бер гүзәл зат килеп басты. Ул Садә белән миңа таныш. Монда кергәләгән бар. Ресторанның баш администраторы.

– О-о-о!.. Нәби абый, безгә килгәнсез, – диде ул күптән көткән кунагын каршы алгандай. – Рәхим итегез!

Шунда ук безне үз артыннан ияртте. Залда кеше күп. Нәшриятка якын булгангадыр, бу ресторанны язучы-журналист халкы үз итә. Заманы шундый бит, зур булмаган хезмәт хакына да рестораннарга кереп, рәхәтләнеп ашап-эчеп утырырга мөмкин иде. Администратор безне түргә

---

Вакыйф НУРИЕВ (1958) *— язучы; ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Фатих Хөсни, Абдулла Алиш исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Бүре кадәр бүрек», «Җиденче палата», «Ни хәлең бар, балам?..» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

үк алып китте. Нәби Дәүли зал аша узганда, кашык, чәнечке, пычакларның тәлинкәгә тиеп китүеннән чыккан тавышлар тынып торды.

Официант кыз да җәлт килеп җитте. Алдыбызга ялтырап торган тышлыгына төрледән-төрле ашлар, ризыклар төшерелгән «Меню» куйды. Кухня бай: берничә төрле салат, токмачлы аш, борщ, итле бәрәңге, бифштекс, антрекот, өчпочмак, вак бәлеш, тавык итеннән өлеш, чәй эчәргә гөбәдия, кош теле... Администратор да безнең янда әле.

– Кайсын телисез, Нәби ага? – диде ул.

– Чахохбили юкмы? Шуны авыз итеп карыйсы килә иде. Сугышта бер грузин үтереп мактады шуны, – диде Нәби ага йөзенә, тавышына самимилек билгеләре чыгарып.

– Бездә аны пешергәннәре юк, – диде официант кыз.

– Ярар, пешермәгәч – кирәкми.

– Туктале, – диде баш администратор, – кухняга кереп чыгыйм әле.

Кереп киткән иде – байтак торып чыкты. Шатлыклы хәбәр белән чыкты.

– Нәби ага, сезнең өчен пешерергә булдылар. Тик сәгать-сәгать ярым көтәргә туры киләчәк.

– Көтәбез! Шулай бит, егетләр!

– Әлбәттә, Нәби ага!

– Хәзергә аш ашый, салатлар капкалый торырбыз.

Мае өстенә чыккан токмачлы аш белән алсу-кызыл винегретны шунда ук китерделәр. «Ркацители» шәрабын да. Аны бераз уртлап, капкалап алгач, тамырлардагы кан кызурак ага башлады шикелле. Әйбәт! Табын түрендә дошман әсирлегендә газап чиккән, аннан качып, чормаларда ач яткан Нәби ага балкып утыра! Бәлешнең төбе, чананың түре сиңа, Нәби абый! Йөзенә бик текәлеп караганым юк иде, бүген әдипнең ике яңагыннан өстән аска сузылып төшкән тирән эзләрне искәреп алдым. Бу эз туры гына төшә дә туктый. Аларның очына читтән тагын бер эз килеп кушыла. Беренчесе – әсирлек, икенчесе – туган илгә кайткач, сорау алулар, нахакка кимсетүләр, эшсез интектерүләр сызган буразналардыр. Нәби Дәүлинең йөрәк яраларын яңартмаска иде. Моны Госман Садә дә, мин дә яхшы аңлыйбыз. Әдипнең без йотлыгып укыган «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион»нарын телгә алмадык. Әңгәмәгә дөрес юнәлешне олпат язучы үзе бирде:

– Редакцияләрдә эшләгән язучы-журналист халкының бәхете бар инде.

Без Госман абый белән бер-беребезгә карашып куйдык. Нинди бәхет икән ул?

Нәби ага сүзен дәвам итте:

– Бауман урамындагы Матбугат йорты каршында «Ёлочка» кафесы бар иде. Язучы, журналист халкы шунда кереп очраша, хушланып утыра иде. Декабристларда – ЭмЦы. Икесенә дә юл аша гына чыгасы. «Ёлочка» турында минем шаяртып язган шигырем дә бар бит:

Матбугат йорты каршында
Бар бер йорт – «Чыршы» йорты.
Үзе кечкенә булса да,
Матбугат йортын йотты.

Кайберәүләр, очрашу-күрешүләрдән «хискә артык бирелеп китеп», ул кафедан чыга алмыйча да ята иде.

Матбугат йорты каршында  
Бар бер йорт – «Чыршы» йорты.  
Үзе кечкенә булса да,  
Матбугат йортын екты.

«Йотты», «екты» – шәп, Нәби абый!

Официант кызның исеме Илүсә икән. Нәби Дәүли аңа «Эльза» дип эндәште. Аннары гафу үтенде. Кызның исемен бүтән әйтмәде. Бу җәһәттән бер хәл искә төште. Мөхәммәт Мәһдиев белән Нәби Дәүли, сәфәргә чыгып, авылларда халык белән очрашып йөриләр икән. Очрашуларны Мәһдиев алып бара. Һәр авылда Дәүлигә сүз бирә. Залда шигырь яңгырый:

Сальвадор Эленде,  
Син җирдә юк инде.

Бер җирдә – Эленде. Икенче җирдә – Эленде. «Альенде», дип әйт», – ди Мәһдиев. «Әйтермен. Син мине «шагыйрь» дип әйт», – ди Дәүли.

Мәһдиев әйтә. Нәби Дәүли чыга. Чили лидерына багышланган шигырен дәртләнеп сөйли башлый:

– Сальводор Эленде.

Очрашулар беткәнче, «Эленде» булып кала Нәби Дәүли. Ресторанда боларны да көлешеп искә алдык.

Күрше өстәлдә ике кыз икый-чикый килә. «Аларның иһаһай да миһаһай чаклары», – дип куйды Нәби Дәүли.

– Нәби ага, сиңа күп кызлар гашыйк булгандыр, – дим. – Хатын-кызны гашыйк итә торган сөйкемле сөягең бар бит синең.

– Юк ла инде.

– «Син кайда идең?» дигән җырыңа байтак кызлар дәгъва кыла, диләр. Һәркайсы үзенә багышланган дип әйтә, имеш.

– Юк ла инде.

– Алайса, кемгә багышланган җыр икән соң ул?

Син кайда идең,  
Кайларда йөрдең?  
Ничек мин сине  
Күрмәдем икән?

– Хәләл җефетемә, әлбәттә.

– Ай-һай, аңа гына микән...

– Аңа инде, аңа! Тагын кемгә булсын?! – Н.Дәүли артка яткырып таралган куе-калын чәчләрен сыпырып куйды.

«Шигъриятеңне яратам мин синең, Нәби ага» – диде Госман Садә, серле генә елмаеп. Өстәлгә тагын бер «Ркацители» килеп кунаклады. Администратор хәлебезне гел белешеп торды.

Нәби Дәүлинең мине ишкәк түләтүдән коткаруы исемә төште. Хатын

белән өйләнешкән ел. Җәйнең матур бер көнендә Аккош күленә көймәдә йөзәргә киттек. Йөзәбез. Бөтен җиһан безнең тирәдә әйләнә. Күл сай. Комга-ләмгә эләгеп, баралмый азапланам. Черәшә торгач, ишкәк тә сынып чыкты. Базага кайткач түләргә кушалар. Егетләр зәһәр! Кысалар. Түләсәң – яшь кәләш алдында беттең. «Шул күгәреп беткән иске калай өчен түләп тордың», – диячәк. Егетләр түләтмичә җибәрергә уйламый да. Шунда берсе «Яшь ленинчы» редакциясе корреспонденты» дип язылган таныклыгымны тагын бер кат ачып карады да «Нәби Дәүлине беләсеңме?» – дип сорады. Өмет кояшы чыгарга торганын сизенеп: «Беләм!» – дидем. «Дустым», – дип тә җибәрдем әле. Түләтмәделәр. Нәби агага шуларны сөйләдем. «Ишкәк өчен түләгән ишәк булып калудан коткардың», – дидем. «Мин җәй буена шунда бит, Аккош күлендә», – диде ул, тыйнак кына елмаеп.

Җанга якын кешеләр белән утырганда, галиҗәнап вакытның узганын сизмисең дә. Чахохбили әзер икән бит. Китерделәр. Бер караганда гади генә икән ул. Вак кына турап кыздырылган ит. Тәмле үзе. Әмма зәһәр. Күздән утлар чыгара. Безнең ашказаны мондый ризыкка күнекмәгән. Шулай да ашадык. Бер-ике кабабыз да шәраб йотабыз. Нәби ага безнең кызарып чыккан йөзләребездән көлә, үзен күрми әле. Рестораннан чыкканда, зур көзгегә карасак, өчебезнең дә йөзләребез бурлаттай кызарган. «Менә сиңа – чахохбили! Менә сиңа иске корсак – яңа аш!» – диде Нәби Дәүли һәм кесәсеннән тартмасы белән «Казбек» чыгарды. Тартмакчы иде – тартмады.

Урамга чыккач, күктәге кызыл кояш та кызыл йөзләребезгә үз итеп карады. Нурларын безгә генә койды.

Тагын редакциягә кайтып утырдык. Кояш баеганда, Ослан таулары артына качарга ашыкмады. Казаныбыз урамына тәгәрәп төшкән күк булды. Без утырган бүлмәгә юл сузды. Туп-туры, якты юл! Саумы, кояш! Нурларыңны тансыклап йөргән көннәрдә безгә кунакка килдеңме? Нәби Дәүлигә рәхмәт әйтәсең киләдер. Чулпан турында нинди матур җыр язды бит. Анда син дә бар, кояш!

Йолдызлар сүнде, төн узган инде,
Бер йолдыз калды, ул Чулпан иде.
Кемне көтәсең таң саен ялгыз,
Әйт әле миңа, әй, шаян йолдыз?
Һәм әйтте Чулпан дөньяга сүзен
Күрәсем килә кояшның үзен...

И кояш, кояш! Син дә кызыл, без дә кызыл! Әллә безне тиң күреп, үзең кунакка чакырырга килдеңме?

Килербез, кояш. Килербез! Юлны беләбез бит!

Рәхәтләнеп көлештек.

# КАРА ИПИ ҺӘМ САРЫ МАЙ

Хикмәти Хода, кибеткә ипи алырга кергән җирдә тамашага тап буласым ике ятып бер төшемә кермәде. Ипине Казанның Фучик тукталышындагы кечкенә генә пыяла кибеттән алам. Өченче икмәк заводыныкы ул. Өе биек булмаса да, өйрәсе сыек түгел. Ак ипи, кара ипи (без кечкенә вакытта авылда арыш икмәген шулай дип йөртә идек), күмәчләр... Тагын әле чәкчәк, бавырсак, кош теле, печенье, кекс, коржиклар... Икмәк мичтән яңа чыккан. Йомшак, җылы, мамыклы!

Мин кергәндә, кибеттә бер кеше дә юк иде. Сатучы белән сөйләшеп торганда, кемдер арттан аркама «массаж ясап» узды. Узды да минем алга чыгып басты. Кечкенә генә бер әби. Дөньяны йотарга теләгән ашкынулы, ярсулы дәрт ташып тора үзендә. Нишләве инде, ә?! Һи, бәренгән нәрсә ич бу! Күрә торып кеше өстенә менә язды.

– Бир минем йөз егерме җиде сум акчаны! – Әбинең сатучы кызга кычкыруыннан кибет киштәләре селкенеп куйган кебек булды. – Бөкремдә җыйган акчамны алып калгансың.

– Нинди акча сорыйсың син, әби? – дип сорап куйды аптырашта калган сатучы, җилкәсен кашып.

– Бая мин синнән ярты ипи, бер батон алдым. Алар өчен илле дүрт сум акча түләдем. Телефоннан карасам, син тагын йөз егерме җиде сум алып калгансың. Урлагансың, короче. Шуның белән баемакчы булдыңмы?!

– Әби, сүзеңне үлчәп сөйләш!

– Бир акчаны!

– Нишләп тик торганда, мин сиңа йөз егерме җиде сум акча бирим.

– Шуны бел, мин моннан акчаны алмыйча чыгып китмим.

– Кем биргән әле аны сиңа?!

– Бирерсең!

Ул арада чират җыелды. Бүген гадәти эш көне. Төш турысы. Шуңа чиратта гел әби-чәбиләр. Аларның: «Безне торкарлама!» дип, гыйсьянчы карчыкка дәгъва белдерүләрен көткән идем. Әбигә әйбер әйтүче юк. Барысы да бу тавышның ахыры ни белән бетәр, дип көтә.

Бушлай тамаша!

Әбекәй акча «урлату» кайгысын чираттагылар белән дә уртаклашып алды. Ул сумкасындагы ярты ипи белән батонны барысына да тантаналы төстә, вәкарь белән күрсәтеп чыкты. Чыннан да, анда бүтән әйбер юк иде. Кая киткән соң йөз егерме җиде сум?! Халык әбине якларга тотынды.

– Талыйлар пенсионерларны!

– Караклар талый!

– Бандитлар талый!

– Мошенниклар талый!

Сатучы кыз да каядыр югалды.

Качты.

Димәк, гаепле.

Әбиләр арасында пәһлеван буйлы бер карт басып тора. Килеш-килбәтенә караганда, заманында урында эшләгән булса кирәк.

Галстук таккан. Галстук, димәсәң, хәтере калыр, кыска, сыер теле озынлыгындагы, чәчәкле чүпрәк кисәге. Менә карт каударлана-каударлана кесәләрен капшый башлады. Минекенә дә тимәделәр микән дип, акчасын тикшерәдер инде. Юк, телефонын эзли икән. Тапты. Шалтыратты.

– Алло! Полицияме? Срочно килегез. Бер карчыкның акчасын талаганнар. Кайдамы? Фучикта. Ипи кибетендә. Нәрсә? Остановка Фучика.

Шул мизгелдә сатучы кыз пәйда булды. Ул чүгәләп, чүп чиләген актара икән. Чек эзлидер инде. Безгә күренми. Полиция сүзен ишетүгә, сикереп торды.

– Сез ни эшләгәнегезне аңлыйсызмы соң? Кем кемне талаган әле монда?!

– Син талыйсың, – диде карт. – Хәзер полиция килә.

– Ой, дурдом! – Кыз тагын юкка чыкты. Тагын чиләк актара, күрәсең.

Чират кибеткә сыймыйча, урамга чыкты. Аның койрыгына таякка таянган бер абзый килеп басты. Әнә ул, таягын болгый-болгый, ишеккә таба килә. Бер адым атлый да чиратта торучыларга чекерәеп карап тора. Гаскәрне барлап чыгучы генералмыни?! Менә ул, күзен бүлтәйтеп, ерып йөргесез кибеткә килеп керде. Керүгә: «Маңгаегыз – сары май!» – дип кычкырды. Полиция дә килеп җитте. «Озак йөрисез!» – дип орышты «Керле галстук» погонлыларны, гәрчә тиз килеп җитсәләр дә. «Маңгаегыз – сары май!» – диде таяклы адәм. Чират сузылганнан-сузыла барды. Ипи алыргамы? Нинди ипи?! Беренчедән, чират кешене үзе ымсындыра. Совет заманы галәмәте. Икенчедән, полиция кызыксындыра! Нәрсә булган? Нишләгәннәр?

Сатучы тагын торып басты. Бу юлы ул кулына кечкенә генә кәгазь кисәге тоткан иде. Димәк, чекны тапкан.

– Менә бу нәрсә? – диде ул, кәгазь кисәген әбинең күзенә терәп. – Менә синең йөз егерме җиде сум акчаң! Кара борыч.

– И –и –и... Алдым бугай шул. – Әби җәт кенә сумкасының эчтәге кесәсен ачты һәм аннан бер пачка борыч тартып чыгарды. – И-и –и... Хәтер юк шул...

Карчык кибеттән шыпырт кына чыгып тайды.

Полиция дә китеп барды.

Ул чыгып китүгә, бая үзен кызгандырган әбигә теләктәшлек белдергән чират халкы шунда ук нахакка гаепләнгән кыз ягына авышты. Сатучыны мактадылар, әбине эттән алып эткә салдылар. Карчыкның кыздан гафу үтенмәве барысының да ачуын чыгарды.

Без сатучының тынычланганын көтеп торганда, бая буза куптарган әби кибеттә тагын пәйда булмасынмы?!

– Мине гафу ит инде, балакаем. И-и-и... Бигрәкләр дә юк инде хәтерем. Тиле мин, тиле...

Чират халкы телсез калды. Хәзер инде ул шелтә-сүгешләрне ни сатучыга, ни әбигә әйтерлек хәлдә түгел иде. Тынлык озакка бармады. Гаеплене тиз таптылар. Кем ул дисезме? Ипи белән борычны бер кибеттә саттырган, сумканың эченә бер кирәкмәгәнгә кесә тектерттереп куйган, хәтерне яхшырта торган дару уйлап чыгармаган хөкүмәт! Һай, сөйләшеп тә күрсәтәбез инде! Һай, әйтеп тә карыйбыз инде! Бу ыгы-зыгыда «Маңгаегыз

– сары май» өстен калды. Ул ни сатучыга, ни әбигә бәйләнмәде. Хөкүмәткә дә тел-теш тидермәде. Аның сүзләре адрессыз иде.

Тукта әле, мин кибеткә ипи алырга кергән идем бит. Онытылып басып торам икән, ярый әле сатучы үзе эндәште. «Сез беренче идегез», – ди. И-и-и... минем дә хәтер... Алдым ярты буханка кара ипи һәм ашыкмый гына чыгып киттем. Артымнан теге таякка таянган абзый: «Маңгаең – сары май!» – дип кычкырып калды.

## ИСЕМЕМ ЛАЛӘ, ДИДЕ УЛ

Татарстан Язучылар берлегендә эшләп йөргән чагым. Берсендә шулай тәвәккәлләп, Иделнең аръягында яшәүче яшь язучыларны җыйдык. Буа мәдәният йорты каршына Тәтеш, Кама Тамагы, Апас, Кайбыч, Чүпрәле районнарыннан маңгаена «Дети» дип язылган сары автобуслар килеп тезелде. Җитмешләп бала. Монда килгәнче аларның әдәбият дөньясына керергә ымсынып язганнарын укып чыккан идек инде. Буада сөйләшү көн буена барды. Казаннан килгән язучылар, яшь иҗатчылар язган бер генә хикәя-микәяне дә, бер генә шигырь-мигырьне дә читкә куймыйча, ачыктан-ачык сөйләделәр, күбесен каты бәрелмичә генә сүттеләр, кечкенә генә табышны да сөенә-сөенә укыдылар. Кичкырын эшне тәмамлап, яшь шагыйрьләрнең зур сәхнәдә узачак шигырь бәйрәменә керергә торганда, яныма ак кофта, кара итәк кигән бер кыз йөгереп килде.

– Минем хикәям чыкмады, – диде ул сулыгу аралаш. – Ләлә минем исемем.

– Ничек чыкмады?

– Мине телгә дә алмадылар.

– Хикәяңне җибәргән идеңме соң?

– Нишләп җибәрмәскә! Иң беренче мин җибәрдем.

– Хикәяң ничек атала?

– «Сары лаләләр».

– Кая китте икән инде ул?! Кайткач тагын җибәр әле! Укырбыз. – Шулай дидем дә кызның күзләрендә яшь күреп уйланып калдым.

Тукта әле, бүген бу кыз Буага барырга дип, әче таңнан торып чыккандыр (хәтерем ялгышмаса, Кама Тамагы районыннан иде бугай ул). Көн буена үзенең исемен әйтүләрен әсәрләнеп көтеп утыргандыр. Хәзер якташлары белән кайтасы да бар. Барысы да шат, ә аның күзләре яшьле. Иҗатка кереп барганда, күңеленә саксыз кагылып, рухын сүндермик, гайрәтен чигермик тагын.

Юк, ничек тә табарга хикәяне! Көнозын балаларның, үсмерләрнең язганнарын тагын бер кат күздән кичереп арган-талчыккан булсам да, Ләләнең югалган «Сары лаләләр»ен эзләргә утырдым. Кәгазь тавын берәмтекләп-бөртекләп актарам. Күчне тузгытып бетергәндә генә таптым хикәяне! Бер файлда бер повесть астына качып калган.

Шигырь бәйрәменә соңга калып кердем. Хикәяне үзем белән алдым.

Шунда күз йөгертеп чыгармын. Беренче җөмләләрен шудырып җибәрүгә, туктап калдым. Яңадан укыйм. «И әни! Белмисең һәм мәңге белмәячәксең сине ничек сагынуымны. Истәлегең булып бакчабызда лаләләр чәчәк ата. Сары лаләләр. Син аларның нәкъ менә сарыларын ярата идең. «Җирдәге кояш» дип әйтә торган идең аларны».

Хикәяне укыйм. Сәхнәгә дә күз төшереп алам. Анда малайлар, кызлар үзләре язган шигырьләрне сәнгатьле укырга тырышалар. Бер мәлне кәгазьгә карап тагын уйга калам. «Әнием! Син бик оста тегүче идең. «Кызым, Сабантуйга яңа күлмәк тегеп бирермен. Якасы басып торган, иңбашлары күпертмәле озын күлмәк. Акка чәчәкләр төшерелгән күлмәк. Их, ул чәчәкләр сары лаләләр дә булса...» – дигән идең. Насыйп булмады, әнием, ак күлмәк тә, аңа төшерелгән сары лаләләр дә...» Җөмлә тәмамланган урында саргылт таплар-тамчыларны искәреп алдым. Нинди тамчылар соң?.. Болар Лаләнең күз яшьләре түгелме соң? Һәрхәлдә мин шулай кабул иттем. Димәк, кыз елый-елый язган.

«Өй каршында чәчәк аткан лаләләр бакча башындагы инеш аша чыгып, үргә менеп, кабереңә синең үрмәли, әнием. Сары лаләләр. Сары сагышка чумып утырган кабер.» Җаныма проза белән шигърият берьюлы бәреп керде.

Шигырь бәйрәменнән чыгуга, Лалә тагын йөгереп килеп җитте.

– Укыдым, – дидем. – Син үзең турында яздың мәллә?

– Әйе, абый, язмышымны яздым.

Лаләне юатасым, мактыйсым килде, беравык сүз таба алмый тордым.

– Яз, Лалә! Яз, туктама! Өметле оеткы бар.

– Рәхмәт, абый! Бүгенге сөйләшүдән соң, мин хикәямне тагын да көчәйтергә булдым әле.

– Дөрес эшлисең. Камиллекнең чиге юк. – Шулай дидем дә иртән безнең өстәлгә куелган чәчәкләр янына килдем. Ал, кызыл лалә чәчәкләре! Араларында сарылары да бар. Аларны өч литрлы банкадагы судан тартып чыгардым да Лаләгә суздым. «Рәхмәт!» – диде кыз. Чәчәкләрне кочаклап алды да күкрәгенә кысып торды.

Урамга чыктык. Майның соңгы көннәре. Җиһан җәйгә җыена. Сары автобуслар китеп беткән. Берсе генә калган. Ул Лаләне көтеп тора. Кыз сикерә-сикерә автобуска таба йөгерде. Утырыр алдыннан, борылып, миңа кул болгады. Кулындагы чәчәкләрнең ялкынлы яктысы кофтасының кардан ак төсенә кушылып, гаҗәеп балкыш хасил булды.



*Люция Әблиева исеме ана телебездә даими матбугат укып баручылар өчен, мөгаен, таныштыр. Аның хикәяләре, парчалары, лирикасы һәм юмор шигырьләре төрле газета-журнал битләрендә күренгәләп тора. Берникадәр лирикасы моңарчы журналыбыз сайтындагы «Каләм тибрәтүчеләр» сәхифәсендә дә басылганы бар, парчалары «Печән базары» юмор сәхифәбездә дә дөнья күрде. Ә менә лирик шагыйрә буларак, журналыбыз битләрендә урын алуга ирешкәне моңарчы юк иде әле.*

*Люция ханым 1962 елның 21 августында Башкортстанның Чакмагыш районы, Тозлыкуш авылында туа. Югары белемле хокук белгече буларак, гомерен Дәүләт күзәтчелеге органнарында хезмәт итүгә багышлый. Балачактан иҗатка тартыла. Тәүге шигырьләре район газетасы битләрендә дөнья күрә. Ул «Сөюемнең Тәнрәсе» исемле шигырь, «Гөнаһ шомлыгы» исемле юмор-сатира, «Соңлап тотылган җавап» исемле хикәя китапларының да авторы.*

Люция
Әблиева

# ҖИДЕ НОТА ГЫНА ҖИТМИ ИКӘН...

## Шигърият дөньясында

Өндәүләрдән торган шигырьләрне
Кабул итәсеңме, замандашым?
Затлы имезлеккә төреп биргәч,
Икенчерәк тәме, беләм, ашның.

Сорау куя торган очракта да
Кирәкме соң өндәүләргә бикләү?
Бу бит, миңа калса, бармакларны
Авырттырмый, җайлап кына бөкләү.

Шөһрәт гөмбәзенә күтәрелер
Миссияне үтиме бу билге?
...Күңел көтә иҗат мәйданына
Сөлге буып чыккан ныклы билне.

***

Августның салкынча һавасы,
Тирәләп тик йөри, җибәрми.
Ә күге – зәп-зәңгәр, ичмасам,
Чеметем болыт та тибрәлми.

Августның көне дә, төне дә
Ни дисәң дә инде – зәвыклы!

Җәй әле! Азагы булса да,
Чәчкәләр сулырга ашыкмый.

Күңелем тулышкан, йа Раббым!
Никадәр гүзәллек, чибәрлек.
Августның тавышы иркәли:
«Сөюне үткәреп җибәрмик...»

## Ышанмасаң...

Шигырь калыбына сыеп бетми,
Яши-яши мин дә үзгәрдем.
Сөюмне роман итеп язам,
Иң-иңнәрен сайлап сүзләрнең.

Килеп чыкмый... Төсләр эзлим менә,
Кулларымда уйный пумала.

Мольбертымда әзер сюжет ята...
Юк, минемчә түгел... уала.

Күңел түрләреннән ургып чыккан,
Моң бирәлер, бәлки, аңлатып?
...Җиде нота гына җитми икән,
Ышанмасаң... кара яратып.

## Тоташ – яктылык!

«Нарат урманында иртә»[1] –
Сихри бер тынлык.
Монда дөнья шау-шуына
Мыскал урын юк.

Беленер-беленмәс кенә
Томан тарала.
Кояшның нурлары үткән,
Нәни акланга.

Рәссам узган давылны да
Оста яшергән.

Яшел хәтфә үләннәрне
Бизәп төшергән.

Аю балалары уйный,
Рәхәткә чигеп.
Табигать үзе аларны
Курчалый кебек.

Таң исе аңкый бар җирдә,
Бөркелә сафлык.
Караңгы урман эчендә
Яктылык, аклык.

***

Мин сине күзләрдән яшердем,
Алтыннан булса да төсләре.
Җәлләдем буярга асылга,
Ямь-яшел яз тулы хисләрне.

Һәм сине күзләргә кертәсем
Һич килми... Үзең дә беләсең.

Күңелем сизәдер, күрәсең.
Җилләре бәгырьне теләсен.

Мин сине җәйләрдә калдырам,
Әйләнеп ул кире кайтачак.
Җанымда иркәле карашың:
«Уртак таң, берсүзсез, атачак!»

## Калмасын үкенече...

Каен ышыгында торам.
Күл өстен туный яңгыр.
Кем белсен, бәлки, сулыкка
Берәр ачуы бардыр.

«Шап» та «шоп» килеп бәрелә,
Тамчылары дәррәүләп.
Читтән генә күзәтәбез,
Каен белән икәүләп.

[1] И.И. Шишкин картинасы.

Күл чайкала, күл тибрәлә,
Түзә инде, нишләсен?
Салкын күзге яңгырларның,
Белә ич бер үтәсен.

Бу дөньяда бар да үтә,
Син дә, мин дә – үткенче.
Чыландым яңгыр астында,
Калмасын үкенече...

***

Җил-юньсез! Иртәдән йолкыйсың
Юп-юка күлмәген каенның.
Иртәрәк бит әле, тугызы
Нибары октябрь аеның.

Беләм бит, син назлап, иркәләп,
Кирәксә, талгын да исәсең.
Ник бүген хисләре тулышкан
Каенның бәгырен кисәсең?!

Чак кына мөмкинлек бир, сөмсез!
Аңлыймын, тугрысың күзеңә.
Тикмәгә ул алтын камчысын
Элмәгән канатлы иңенә.

Ишетте әллә җил? Туктады.
Тагын бер ыргылып алды да.
Ә мин ни... Таптанып торамын,
Түшәлгән яфраклар алдында.

***

Мин сине ишетәм, ишетәм...
Комачау түгел җил уллары.
Төйнәпләр бирсәң дә сереңне,
Янәшә – чишелү юллары.

Мин сине күрәмен, күрәмен...
Саф-садә күңелем – күземдә.

Арада күренмәс җепләрдән
Күперләр челтәрләп тезелә.

«Мин сине сөямен, сөямен...»
Беләмен, беләмен, беләмен...
Каршылык булса да, ачыла,
Сәгате сукты исә келәнең.

## Жәл...

Йолдызлар яңгырын күзәтү
Язмаган... Нишлисең, бик тә жәл.
Хыялда тәкыя кем үрми?!
Булгалый, була ул андый мәл...

Бөркетләр үз иткән кыяга
Чакырдың... И үзең бер сабый!

Кирегә, җирләргә каерып
Көчләрнең барлыгын уйламый…

Күземнән күзеңне алмаган
Вакытны кайтарам төсмерләп.
Кызганыч, әле дә тоямын
Тәннәрем киткәнен чемердәп.
Жәл...

## Хәтер

Ярату хисләре йөрәкне
Үзенә мәңгегә бикләде.
Очынып яшәдем, һәр көнне
Ишетеп чакыру: «Кил әле!»

Янәшә булсам да янында,
Эндәшә идең гел: «Кил әле!»

Таңнарым, кичләрем, төннәрем,
Булдылар сәгадәт-сөюле.

Күкләргә ашсаң да, кадерлем,
Мәхәббәт ул – үтә хәтерле.
...Яңгырап киткәндәй тавышың:
«Әлегә килмәвең хәерле...»



Әнисә
Зәйнуллина

# ОЧРАШУ

хикәя

Мине очрашуга чакырдылар.

Дөрес, «очрашу» дип аталган кичә-мәҗлесләр күп булды тормышымда. Күбесенә эш өчен кирәк булганга, кайсыларына «бармау яхшы түгел» дип йөрелгән. Андый ыгы-зыгылы бәйрәмнәрне яратып бетермим. Ардыра. Ә монысын ашкынып көттем. Ни әйтсәң дә, утыз ел күрешмәгән укучыларым белән очрашам бит!

...Укытучылык һөнәрен сайларга уйлаганым да юк иде. Ул авылга очраклы гына килеп эләктем. Иремне юллама белән бирегә җибәрделәр – шәһәребездәге хәйран абруйлы адвокатлар конторасына эшкә урнашып өлгергән идем, шуны ташлап, аның артыннан китәргә мәҗбүр булдым. Чоры шундый иде – мәктәптә миңа да дәресләр табылды. Кемнән нинди предмет артып кала, шуны бирделәр. Тел-әдәбият та, тарих та, биология белән география дә эләкте. Һич кенә дә күңелемә ятмады бу, билгеле. Үземне шундый «күпкырлы» укытучы итеп тою бик авыр булды. Алай гына да түгел, бишенчеләрнең класс җитәкчесе итеп тә куйдылар әле.

Тик боларның берсенә дә укучылар гаепле түгел бит! Алар сиңа олы кеше итеп, ышанып карый. Беренче тапкыр каршыларына кереп баскач ук аңладым мин моны. Берсеннән-берсе сөйкемле йөзләр, мөлдерәп торган кызыксынучан күзләр. Аларны ничек алдарга мөмкин, ди, инде! Шуңа күрә яңа эшемә чытырдап ябыштым. Педагогика, психология буенча китаплар алдырттым. Төп «предметниклар»дан киңәш сорап, йөдәтеп бетердем, туеп беттеләр бугай алар миннән. Дәрескә әзерләнгәндә, төннәр буе утырдым: эшләсәң, җиренә җиткереп эшлә, юк икән, тотынма – монысына минем үз укытучым өйрәтте. Тотынмый нишлисең, эшең булмаса, ашың да юк бит инде! Ә класстан тыш эшләр үзем өчен дә кызык булды, балалар белән бергә ихластан күңел ачтым. Яшь чак бит, мөгаен, үзем дә балалыктан чыгып җитмәгән булганмындыр.

Мәктәпне тәмамлагач, укучыларым кайсы кая таралышты. Үзебез дә авылда артык тоткарланмадык – «отработка» срогы да күптән чыккан, үз балаларыбыз да аякка баскан иде. Шуның белән юлларыбыз аерылды – кемнең ничек яшәве, нинди уңышларга ирешүе турындагы хәбәрләр ишетелгәләп торса да, берсе белән дә якыннан аралашырга туры килмәде.

...Бүгенге очрашу шәһәребезнең «Карлыгач» кафесында буласы икән. «Ни өчен нәкъ менә шуны сайлаганнар?» дигән соравыма җавап соңрак табылды.

Үзем әзерләнәм, үзем моннан дистәләрчә еллар элек булган вакыйгаларны күз алдына китерергә тырышам. Дулкынланам – укучыларым алдына беренче тапкыр кереп басачак мизгелләр кабатлангандай була.

Машинадан җиргә төшеп басуым булды, шунда ук бер төркем олы гәүдәле, җитди чырайлы ирләр, мөлаем йөзле чибәр-чибәр ханымнар уратып алды. Башлап, кайсы белән исәнләшергә белмим – күңелләр якынлыгын йөрәгем белән тоям, танып бетереп кенә булмый. Утыз ел аз вакыт түгел бит!

Аннары акрынлап, күңел үз урынына кайтты. Аралаштык, аңлаштык, тирә-юнь көлешү-шаярышу авазларына тулды. Моннан утыз-утыз биш ел элек булган истәлекләр берәм-берәм баш калкыта башлады.

Зәвык белән бизәлгән аш өстәле янында Гәүһәр үзен хуҗаларча тотты. Һәр ризыкны тәкъдим иткәндә, «бик тәмле» итеп аның тарихын сөйләп алды.

– Бишенче класста сез безгә «Йорт эшләре» дәресеннән дә керә идегез, апа, хәтерлисезме? (Алар һәммәсе дә бала чакларындагы кебек миңа «апа» дип кенә эндәште.) Аш пешерергә, камыр куярга өйрәттегез. Бәлешләрне ничек матур ясый идек, әйеме? Шул бер дә күңелемнән чыкмады инде. Мәктәпне тәмамлагач, кулинария техникумына кердем. Башта кечкенәдән башлаган идем, тора-бара зуррагына ирештем...

«Зуррак» дигәне шул – Гәүһәр күптән инде «Карлыгач»ның хуҗасы икән.

– Минем таныш-белеш монда әбәткә йөри, бик яраталар, – дип, сүзгә кушылды өстәлнең теге башында утыручы Рамилә. – Гәүһәр бөтенләй остарып беткән, сез аның клиентлары белән сөйләшкәнен ишетсәгез! Тегеләре шунда ук эреп китә инде...

Анысына ышанам, ә алда сөйләгәннәренең күбесе дөреслеккә туры килми. Аш-суга осталыгым да, ул өлкәдә укучыларымнан артык җирем дә  юк иде, моңа үзем дә алар белән бергә өйрәндем. Интернет заманы түгел, Юныс Әхмәтҗанов китабы бик популяр иде, шуннан файдаландык. Кайберләрен кызлар әниләреннән сорашты. Тормыш итәргә укучыларым мине үзләре өйрәткән булып чыга бит!

Рамилә үзе хуҗабикә «профессиясен» сайлаган – биш бала анасы. Ире эшмәкәр икән, шәһәр читендә зур йорт салып куйганнар.

– Берәү булса, иренә аркаланып, рәхәттә генә яшәр иде. Юкса, андый тормыш алып баручыларның дистәләгән «ярдәмчеләре» була. – Бусын тыныч тигез тавыш белән җитди чырайлы Вазыйх сөйли. – Ә Рамилә – юк! Бөтен эшне үз җилкәсенә алган. Шундый зур хуҗалыкны берүзе сөйрәп бара дисәң дә була.

– Берүзем түгел инде, нишләп алай булсын! – дип каршы төште Рамилә.

– Гаиләдә бөтенебез эшли, юнәлеш биреп торучысы, әйе, мин инде. Апа, хәтерлисезме, чыгарылыш кичәсеннән соң кызлар белән генә җыелышып, сөйләшеп утырган идек. Тормыш коргач, иреңнән алда чабарга кирәкми, дигән идегез. Үзең теләгән нәрсәне ул уйлап тапкан дип ышандырырга кирәк, дип көлешкән идек. Хәйләсез дөнья – файдасыз. Менә шулай җайлашабыз инде...

– Ә сез Хаммурапи патшаның кем икәнен онытмадыгызмы әле? – дип, сүзгә кушылды Вазыйх. – Тарихны шуннан ярата башладым мин, апа. Шулкадәр матур итеп сөйли идегез, Хаммурапиның үзен күргәндер бу, дип уйлый идем...

Вазыйх укыган да, югары уку йортында укыткан да, бүген инде тарих фәннәре буенча докторлык диссертациясе якларга җыенып йөри икән. Тик мин үзем бу фәнне яраттырырлык нинди белгеч булыйм, ди, инде! Нинди кызык нәрсә табам, шуны түкми-чәчми җиткерергә тырышканмын, шул гына!

Розалия исә гаиләсе белән бергәләп, тоташ бер фермер хуҗалыгы тота икән.

– Утыз баш сыер, йөз баш сарык, әллә күпме кош-корт асрыйбыз, ничәдер гектар җиребез, тагын умарталыгыбыз бар, – ди.

– Ничек өлгерергә кирәк барысына да? – дип аптыравыбызга ул ансат кына җавап бирде:

– Эше барның ашы бар... Ник, апа, эшләп үскән буын бит без. Көз җитте исә, колхозга бәрәңге алырга чыгардылар, хәтерлисездер. Безнең класс үз бураснасын гел беренче булып бетерә иде. Ник дигәндә, ял итәргә күбрәк вакыт кала, шул арада без сезнең белән көлгә бәрәңге күмеп ашарга өлгерә идек. Алай гынамы, нинди дә булса кызыклы китап сөйли идегез шул чакта, аны иң дулкынландыргыч җирендә өзеп куя идегез. Икенче буразнаны чыкканда, шуның дәвамын тыңларга дип, тагын ашкынабыз...

Исемдә... Анысы да үзем өчен рәхәт иде инде аның. Беренче буласы килү теләге дә зур иде. Гел үзем кызык эзләп яшәгәнмен, ахры, мин ул чорда...

– Ә география дәресләре? Кайларда гына «булып кайтмадык» бит без сезнең белән! Эльбрус тауларына да «мендек», Абхазиядәге Афон мәгарәсенә дә «төштек», Гавай утрауларында да булдык... Шуннан гашыйк булдым инде мин бу фәнгә. Илләр гизү теләге дә шул чакта уянды. Кайларда гына булмадым! Сезгә рәхмәтле мин моның өчен, апа!

Бусы – Илгиз, ул шулкадәр дәртләнеп, рухланып сөйли, аның артыннан һәммәбез дә дөньяның төрле почмакларын айкап кайткандай булдык. Илгиз хәзер шул үзе укыган, мин укыткан мәктәптә егерме елдан артык мәктәп директоры булып эшли икән. Минем үземдә дә кабат шул якларны кайтып күрү теләге уянды. Илгиз җитәкләгән мәктәп тегенди-мондый гына түгелдер! Малай чактан ук бөтен нәрсәне белергә тырыша иде, сорашып, төпченеп, үзәккә үтте дисәң дә дөрес булыр. Аның сорауларына җавап бирү өчен төннәр буе энциклопедия актарып утырырга туры килде. Үзем дә тәмам географ булып бетә яздым...

Идрис исә әлегә сүзгә кушылмый, авызын ера төшеп, иптәшләрен тыңлый. Күзләрендәге шаян очкын нәкъ әүвәлгечә. Тагын нинди «этлек» эшлим икән дип уйланып утыра шикелле. Аның белән хәйран азапланырга

туры килде ул чакларда. «Идрисең тагын клубка кичке сеанска чыккан...» «Синең Идристән ферма хуҗалары зарлана, бер атны сорамый алып чыгып киткән. Кайда йөрткәндер, тәмам хәлдән тайдырып кайткан...» «Тагын шул Идрис! Прәме мәктәп ишегалдында кечкенәләрдән көрәш оештырган! Ата-аналар зарлана, пычракка батып кайтканнар...» Аның белән сөйләшүләрнең иге-чиге булмады. Нәрсә әйтсәң дә: «Һи, нәрсәсе бар инде аның!» – дип кенә җибәрә иде. Үзе математикадан башка бер фәнне дә танырга теләмәде. Әйтә башласаң: «Нәрсәгә кирәк алар миңа!» – дип кенә җибәрә иде. «Соң институтка бер фәннән генә имтихан биреп кермиләр бит инде!» – дигәч: «Нәрсәгә кирәк миңа институт!» – дип кенә җибәрде. Берсендә, аптырагач, утырып елаганым да хәтердә... Ә чагырылыш кичәсендә Идрис миңа үзем кадәр чәчәк бәйләме күтәреп килде: «Бу сезгә, апа, миңа түзгәнегез өчен!» – диде. Хәзер аны бик зур кеше булган дип сөйлиләр. Төзелеш институтын бетергән, йортлар төзү буенча үзенең шәхси оешмасы бар икән.

– Һи, нәрсәсе бар аның!

Барысы да, кызык эзләп, Идрискә таба борылды.

– Без бит авыл балалары, эштән курыкмыйбыз, шулай бит! Җитәр, мактанышып утырмыйк, җырлап алыйк әле! Апа, әйдәгез, теге смотр концертында өйрәнгән җырыбызны сузабыз:

Без кичә алмаган юк кара урман,
Без җиңә алмаган дошман тумаган...

Кафе эче гөр килеп торды, үтеп-сүтеп йөрүчеләр урамнан башларын тыгып-тыгып карады.

Тагын... «Аҗаган» спорт уеннары, табигать кочагына походка чыгулар, төнге учак тирәсендә ачыктан-ачык сөйләшүләр, туган телгә багышланган шигырь сөйләү конкурслары, авыл клубында концерт программасы белән чыгыш ясаулар... Берсе дә искә алынмый калмады. Иң кызыгы шул: алар фикеренчә, боларның бөтенесен дә мин оештырганмын икән ләбаса! Ә иң сөенечлесе – укучыларымның һәрберсе тормышта үз урынын тапкан, берсе дә югалып калмаган, үзебезчә әйтсәк, кеше булган! Шуның өчен миңа рәхмәт әйтүләре генә аңлашылып җитмәде...

...Мәктәптән киткәч, кабат үз эшемә – адвокатлар конторасына кайтып утырдым. Утыз елга якын вакыт эчендә рәхәтен дә, михнәтен дә күп татырга туры килде. Тырыштым. Ә мөгаллимлек иткән елларымны, төп профессиямнән читтә булгач, тормышымның «төшеп калган чоры», әрәмгә үткән вакыт дип исәпләп яшәгән идем. Нык ялгышканмын икән! Бүген укучыларым аша үземне бөтенләй икенче яктан ачтым...



*Бикә Колынчакова (1946) – ногай язучысы, шагыйрә, драматург, публицист һәм тәрҗемәче. Ногай һәм рус телләрендә егермеләп китап авторы. Дагстанда ногай телендә чыгарыла торган «Байтирәк» альманахының редакторы. Дагстанның халык язучысы. Тәрҗемәче буларак, ногай язучыларының әсәрләрен башка телләргә, Кавказ халыклары язучыларының әсәрләрен ногай теленә тәрҗемә итә. Журналыбызда басыла торган бу хикәясе белән ул татар укучысына беренче тапкыр тәкъдим ителә.*

Бикә
Колынчакова

# ҮКЕНЕЧ

хикәя

Автобустан төшкәч, Канитат күпкатлы биек йортлар яныннан үтеп, кибеткә керде. Ашарга бер-бер нәрсә алырга дип, азык-төлек бүлегенә тезелгән озын чиратның койрыгына килеп басты. «Никадәр күп вакыт узачак бу чиратта торып, – дип көрсенде. – Бу вакыт эчендә диссертациянең ун табагын язып өлгерткән булыр идем. Әле өйгә кайткач аш пешерергә, шуның арасында кер юып алырга кирәк. Бүлмәләрне Амзатка җыештырттырыр идем. Амзат булыша булышуын, тик ул хатын-кыз түгел шул инде, – дип куйды. Шунда ул як-ягына каранды да чиратның башында ук авылдаш күршесе Патиматны күреп алды. Канитат күршесенең кызы Назирә турында уйлады. – Патимат бар эшләп тапканын кызына биреп бара. Оныгын карый, ашарларына әзерли, җыештыра... Өйдәге бар эшне башкара, ә Назирә белән ире киногa, театрга йөриләр, ай буена ял итәргә диңгезгә китәләр. Кемнең эше аз, Аллаһы Тәгалә, күрәсең, шундыйлар турында күбрәк кайгырта. Назирәнең, әнисе ярдәм итмәсә дә, өйдә эше юк. Ә минем һәр минутым кадерле, беркемнән дә ярдәм көтәргә түгел», – дип көрсенде Канитат, кибеттән чыгып баручы Патиматны карашы белән озатып калып. Аның кулларында әйбер белән тулы ике зур сумка иде.

«Их, рәхәт яши Назирә! Минем дә әнием бар югыйсә. Әле Патиматка караганда да эшчәнрәк. Тик минем өчен тырышмый, үзенең ялкау киленен күбрәк кайгырта...» Канитатның күз алдына кояшта йөзе каралган, ябык, бер минут та тик тормый торган әнисе килеп басты. Салият биш бала

анасы булганга, илле яшендә үк пенсиягә чыккан иде. Әмма өйдә ял итеп ятып буламы, кызлар кияүгә чыгып, уллары өйләнеп – үз учакларын булдырганнан гына хатынның тормышы җиңеләймәде. Салият улы Яхъя белән тора иде. Алар килене белән кышлауда эшләделәр, шунда куна-төнә яшәделәр. Ә балалары Салият белән авылда тордылар. Яхъяның хатыны үзе караган сарык кебек, бала артыннан бала табып торды. Аларны берничә ай гына күкрәк сөте белән имезде дә каенанасына тапшырып барды. Берсеннән-берсе бәләкәй шул дүрт баладан башка да яшелчә бакчасын, тавыклар белән сыерны карау Салият өстендә булды. Шунлыктан аның бер көнгә генә булса да, башка балалары янына барып кайтырга һичбер вакыты юк иде. Канитат әнисенә: «Миндә генә яшә. Ирем акыллы, балабыз да берәү генә, сиңа бездә яшәве кыен булмас», – дип, бер генә тапкыр әйтмәде. Салиятнең мондый сүзне ишетәсе дә килми иде.

– Нишләп әле үз улым була торып, мин чит ир йортында яшәргә тиеш? Авылдашлар: «Улы була торып, кызының кияве кулында тора», – дип әйтсеннәр дисеңмени? Ят ата баласына карап, бер сүз әйтергә куркып яшәргәме? Кунак булып бара алам, бөтенләйгә килә алмыйм... Үпкәләмә, кызым.

Канитат белә, сәбәп монда гына түгел, дөрес, йола йола инде, картлар аны бозарга теләмиләр. Улы булган бер генә ана да, килене белән эт белән мәче шикелле яшәсә дә, улын калдырып, кызы янына яшәргә китмәячәк. Салият шуның өстенә каланы яратмый. Ул кызының үз теләге белән калада яшәвен аңлый алмый. Дала иркенлегенә, аның үлән исе аңкып торган саф һавасына күнеккән кеше буларак, шәһәрдә тыны кысыла, күңеле болгана. Кызын сагынып килсә дә, «Монда яшәү тоткынлыкта яшәү белән бер. Үзегез кайтыгыз авылга, нәрсә бар шушында?» – дип, тизрәк кайтып китәргә ашкына.

Анасын каланың тарлыгына күнектерүе авыр икәнен Канитат яхшы аңлый. Эш тарлыкта гына түгел. Салият башка бер авылда да яшәмәячәк. Ул үз авылына, даласына тамыры белән береккән. Әгәр карт агачны урыныннан кубарып, башка урынга күчереп утыртсаң, аның яңа җирдә үсеп китәсен беркем дә әйтә алмый. Карт агачның тамырлары бик тирәнгә киткән, тармакланган, аны зарарландырмыйча гына казып алуы мөмкин түгел.

Ярар, бөтенләй торырга килмәсен дә, ди. Һич югы сирәк кенә булса да килгәләп, ярдәм иткәләсә дә, яраган булыр иде. Канитатка хәзер аның ярдәме бик кирәк. Диссертациясен тизрәк язып бетереп котылыр иде. Аспирантурада укыганда, ул районнарга, авылларга йөреп, үзенә кирәкле материалларны туплады. Кайтса, өен тузан баскан, кызы авырып киткән. Барысына да төкереп, укуны ташларгамы икән әллә дип тә уйлады. Ләкин йөрәгеннән бер кисәк итне өзеп ташлаган күк булыр дип курыкты. Ничек итсә итте, укуын ташламады. Менә хәзер институтта эшләү белән диссертация һәм өй арасында чабып үтә гомере.

Кибеттә бер сәгать вакытын югалтып, ул тулы сумка белән өенә кайтып керде. Биш катлы йорт ишегалдындагы эскәмиядә хатыннар утыра иде. «Мин кызым бәләкәй вакытта да шулай утырып торырга вакыт тапмадым», дип, Канитат эченнән ачуланса да, йортташлары белән җылы исәнләште дә өенә кереп китте.

Ишекне ачкан гына иде, алты яшьлек кызы Альбина каршына йөгереп килеп чыкты.

– Әни, әни, безгә дәү әни килде, тәмле катлама һәм тавык ите алып

килде! – дип кычкырды кызы, сөенеп. – Миңа күлмәк тә тегеп алып килгән, тик озын булган. Үскәч киярсең, диде дәү әни.

Канитат тиз генә күтәрелеп, өйгә керде, өй эче чиста итеп җыештырылганын күрде һәм телевизор карап утыручы иреннән:

– Әни кайда, кайчан килде, ничә көнгә килгән? Өйне син җыештырдыңмы? – дип сорады.

– Мин кайтканда, әни ишегалдында утыра иде, – диде Амзат. – Икәүләп чәй эчтек, аннары өйне җыештырып алдык. Әле әни аш бүлмәсендә аш пешерә. Ничә көнгә килгәнен белмим.

Канитат аш бүлмәсенә кергәндә, әнисе токмач кисә иде. «Менә әнинең файдасы», дип уйлап куйды кызы.

Ашап-эчкәннән соң Канитат әнисе белән аш бүлмәсендә ялгыз калдылар.

– Син ничә көнгә килдең? – диде ул, көлемсерәп. – Бу юлы сине тиз генә җибәрмәячәкмен. Язылася эшләрем күп, ярты ай чамасы торырсың.

Бу сүзләрне ишеткән Салият дәшмичә калды. Канитат әнисенең янына килеп, аны муеныннан кочаклап алды.

– Яхъяның ялкау хатынын кызганган кебек мине дә бераз кызган. Төннәрен туйганчы йоклауны да оныттым. Синең килененең бер төн йокысыннан калса, шуны атна буе сөйләр иде.

– Шулаен шулай да. Тик мин бу юлы тиккә генә килмәдем, – диде анасы уйчан йөз белән. – Ике-өч айдан бирле авырыксынып торам, йөрәгем әледән-әле туктап алгалый. Ашказаным да күптән начар эшли.

Салият сөйләгән саен кызының чырае үзгәрә башлады һәм ул анасының яныннан читкә китеп, урындыкка утырды. «Үзләренә кирәк булганда, мине искә төшерәләр. Берсе дә мине кызганырга теләми. Яхъяның да бер дә оялы юк, сау чагында әнине эшләтеп, чирли башлагач, кызы карасын дип, миңа китереп ташлаган», дип уйласа да, Канитат дәшмичә калды.

– Минем белән йөрергә бер кеше кирәк. Синең дә вакытың юктыр, – диде әнисе, читенсенеп.

– Минем вакытым юклыгын белә торып мине борчыйлар, – дип кызды Канитат, әнисенең йөзенә карамыйча гына. – Узган айда Әминәт улын җибәргән миңа, институтка керергә булышсын, дип. Минем атамнан калган институтым бар дип белгәндерме. Шушы көннәрдә генә Бәрият килгән баласы белән. Авырый, яхшы доктор табып булмасмы, дип сорый. Амзатларның килене авыру анасын ияртеп килгән, хастаханәгә салырга сорап. Җитмәсә, кулында яшь баласы бар. Төне буе елады, язу түгел, йокларга урын тапмадым. Берсенең дә калада яшисе килми, әмма барысы да минем янга чабудан кыенсынып тормыйлар. Ни өчен Яхъя үзе алып килмәгән сине? Син аның балаларын карыйсың бит!

Салият дәшмичә генә тыңлап утырды да соңыннан арган тавыш белән:

– Минем белән йөрергә вакытың булмаса, китәрмен, нишләп сине борчып йөрим, – диде.

Шул вакыт Канитат әнисенә текәлеп карады һәм аның чырае бозылганын күрде. Шулай ямьсез сөйләп утырганы өчен үзенә ачуы чыкты. «Кем инде мин? Башкаларга вакыт тапканда, тудырган анама ни генә әйтеп бетермәдем», – дип, үзен тиргәде.

– Ни дә булса уйлап табарбыз. Хастаханәгә урнашу да кыенлаша елдан-ел, – диде Канитат. – Син бар, ял ит, мин язйым бераз.

Әнисен яткыргач, язарга утырса да, башлый алмыйча, көрсенеп торды. Бер яктан әнисе белән дорфа сөйләшкәненә үкенде, икенче яктан үзен кызганды, барысына да ачуланып, уйлары чуалган иде. Канитат бу төнне дә озак утырды.

Әнисен залда яткырганлыктан, аш бүлмәсендә язды.

Салият төн уртасында су эчәргә дип, аш бүлмәсенә керде.

– Ни булды, авырыйсыңмы әллә? – диде аңа кызы, борчылып.

– Йөрәгем чәнчеде бераз, – диде хатын. Үзе кызын кызганып, аның кәгазьләренә карады. – Йокыңны калдырып, һаман утырасың. Нигә кирәк сиңа бу язу? Авылдагы яшьтәшләрең синнән яхшырак яшиләр. Тамаклары тук, өсләре бөтен. Баладан да калмыйлар. Синдә бары бер кыз.

– Шулай шул, – дип ризалашты Канитат. Әмма көлемсерәп куйды. – Миңа шундый тормыш ошый. Бу кәгазьләрне язып бетергәч, Мәскәүгә җибәрсәм, хезмәтләрем әрәмгә китмәячәк. Зарлануларым да, йокысыз төннәрем дә онытылыр.

– Алла кушып, шулай булсын, – диде анасы.

Канитат табиблар артыннан ике көн йөреп арыса да, әнисен хастаханәгә яткыра алды. Инде көн дә барып, хәлен белеп торырга кирәк иде. Күбесенчә хастаханәгә ирен җибәреп, үзе ашамлыклар артыннан чапты, базардан барып, җимешләр сатып алды. Әмма әнисе янында озаклап утырырга, матур сүзләр белән аның хәлен җиңеләйтергә вакыт тапмады. Анасы хастаханәдә егерме көнләп ятты. Шул вакыт эчендә авылдан дүрт баланың берсе дә килеп бакмады. Яхъя таныш шофёрдан бер сарык итен җибәргән иде. «Дөньяны колачлап, байлык артыннан куып үләләр инде. Әниләрен килеп күрергә дә вакыт таба алмыйлар», – дип уйлады Канитат алар хакында, тәмам икенче яктан аларның килмәгәненә сөенә дә иде: «Килеп ни эшләрләр иде, өйне пычракка батырып, вакытны алудан башка бер файдалары да булмас!»

Хастаханәдән чыкканнан соң да Салият кызында икенче җомгага хәтле торды.

– Әнкәй һаман уйланып йөри. Ни булган икән? – дип сорады беркөнне Амзат.

– Авылдан берсе дә килеп, хәлен белмәгәнгә үпкәләгәндер, – диде Канитат, яза торган кәгазьләреннән башын күтәрмичә генә.

Әмма Салиятне автобуска озатканда, йөрәге бераз чәнчеп алды. Әнисенең чырае һаман да борчулы иде. Буйга да чүккән кебек күренде. Аны дәвалаган табибның әйткән сүзләре исенә төште. «Әниегезнең йөрәге сау түгел. Санаторийга илтсәгез, авыруы бераз җиңеләер иде, бәлки», – дип әйткән иде ул. Санаторийга тиз генә юллама табуы җиңел түгеллеген яшь хатын аңлый иде, шуңа күрә берни дә дәшмәде. Әлбәттә, Яхъя совхозында шуның хакында сүз кузгатса, алдагы елда табарга мөмкиндер. Агасы берничә елдан бирле алдынгы куйчы, Салият үзе дә совхоз эше өчен аз көч түкмәгән. Әмма бу сорауларны күтәреп, кемдер армый-талмый юллама артыннан йөрергә тиеш.

Автобус киткәннән соң да Канитатның йөрәге урынына утырмады. «Киләсе язлыкта үзем илтермен санаторийга. Юллама булмаса, башка бер әмәлен эзләрмен», – дип уйлады ул.

Акрынлап, аның күңеле тынычланды. Ул диссертациясен язып бетерде. Авылга кайтып килергә дип уйлаган иде дә, Амзат аңа бераз ял итәргә киңәш

бирде. Кәгазьләрен Мәскәүгә җибәргәч, эштән соң икәү бергә кинога, театрга барып, үзләренә кунак чакырып, үзләре кунакка барып, Канитат авылга кайтырга дигән уен да онытып җибәрде. Шулай бер көнне таң алдыннан авылдан бер машина килде. «Салият авырып тора, агаң сине алып кайтырга кушты», – диде шофёр. Канитат ни уйларга да белмәде. Машинага иренә дә утырырга кушты. «Үлгәндер, шулай булмаса, аны алып кайтырга машина җибәрмәсләр иде», дип уйлады. Машина туган-үскән җирләренә якынайган саен йөрәге ашкынып тибә башлады. «Чынлап та әнием үлгән булса» дип, бизгәк тотып курка ук башлады. Ишегалларында күп кеше җыелып торганын күреп, Канитат биле кузгалгандай, бөгелеп үк төште. Аның хәле бөтенләй бетте. Ул машинадан ире ярдәме белән көчкә генә чыга алды. Йола кушканча, кычкырып елап җибәрде.

Әниләре вафат булган иде. Аны җирләр алдыннан балаларына күрсәттеләр. Ул якты дөнья белән риза-бәхил булып хушлашкандай, әйтерсең лә, йокыга киткән кебек тып-тыныч йөз белән ята. Мәет озату эшләре башкарылып беткәннән соң, аны ишегалдыннан алып чыгып киттеләр. Яхъяның өе дә, ишегалды да буп-буш булып калды. Канитат авыр төштән уянгандай, әнисенең юклыгына ышанмады. Бүлмәдән бүлмәгә кереп, ишегалдына чыгып, Салиятне күрергә теләгәндәй, як-ягына каранды. «Әле кайчан гына тере булган адәм бүген бу дөньяда бөтенләй яшәмәгән дә кебек юк булды», дип гаҗәпләнде ул.

Канитат үскәндә, кайгы күрмәде. Әтиләре балалар кечкенә чагында ук үлде. Ул вакытта Канитат икенче класста укый иде. Кайгы кызның йөрәгенә кермичә, яныннан узды. Шуннан бирле өйләреннән мәет чыкканы булмады. Ике-өч елдан соң ире Амзатның анасы, озак авырудын соң җан биргәндә, Канитат аның янында иде. Әмма йола буенча аны озатканда елап, йөрәгендә авырлык сизмәде.

Инде Канитат җанында бер авыр хис туганын аңлады. Авылдан ул әнисенең үлгәнлегенә ышана алмыйча китте. Калага килгәннән соң да җанына тынычлык тапмады, көн дә уйлары йөрәген телгәләп, ачы хисләргә әйләнә иде. Әнисе белән сөйләшүләр, үзенең авылда узган еллары, әнисенең үләр алдыннан калага килеп яшәве – барысы да бергә искә төшеп, Канитатның күңеленә инде башкача булып күренәләр иде. Тик бер нәрсәгә гаҗәпләнде: «Ни өчен алдан аңламадым әниемнең тормышын? Ни өчен аны җиңеләйтер өчен тырышмадым? Ирсез калып, биш баланы аякка бастырыйм дип яшәде. Авыр елларда нинди яхшылык күрде бездән?» Хастаханәдә ятканда, әнисен дәвалаган табиб әйткән сүзләр исенә төште Канитатның. «Яшьли ирсез торып калган авыл хатыннарына тормыш алып баруы кыен. Тормыш иткәндә генә түгел, саулыгын да ала ул. Йөрәгенең авыртуын шуннан күрәм...» – дигән иде табиб.

«Яңадан кияүгә барырга уйламады да әниебез, – дип көрсенде Канитат. – Бөтен уйлаганы балалары турында булды. Аның берәр көн матур итеп киенгәнен, берәр көн ирләр турында уйлаганын күргәнем булмады».

Канитат гаиләдә дүртенче бала иде. Шуңа күрә әнисенең ничек яшәвен туганнарына караганда күбрәк күрде. Әминәт белән Бәрият калада укып йөргәндә, Яхъя өйләнеп, хатыны белән авылга киткәндә, Канитат һәм энесе Арслан өйдә иделәр. Салият җир сугару бригадасының бригадиры иде. Таң белән чыгып китеп, кич кенә кайтып керә иде өйгә. Ә Канитат белән

Арслан, мәктәптән кайтуга, өйдәге бөтен эшне башкарып куялар. Бер дә вакыт юк дип тормадылар, көн дә әниләрен өй эше белән изаландырмаска тырыштылар. Аңа кыен булганын аңлыйлар иде. Әниләре аз гына акча тапса да, кызларын киендерергә тырышты, шуларны күреп, үзе киенгәндәй сөенә иде. Тапкан акчасын күбесенчә Әминәт белән Бәрияткә биреп барды.

«Сөелеп, бер яктан да кимчелек күрми үскән апаларым кияүгә чыктылар да әниләрен оныттылар. Бар кайгылары – үз балалары булды. Баласы авырганда, ничек йөгерде Бәрият. Әниебез хастаханәдә ятканда, берсе дә дөньяларын ташлап, аның янына килмәде», – дип уйлады Канитат, авыр көрсенеп. – Ә мин нинди изгелек кылдым?! Мине дә укытты бит ул институтта. Кияүгә чыкканчы бар ишеткәнемне-күргәнемне кайтып, аңа сөйли идем, нинди генә планнар кормый торган идек бергәләп. Иргә чыккач, үз казаным – үз кайгым дип, ничек тиз оныттым шуларны».

Шундый көннәрнең берсендә Канитатның әнисе белән булган бер хәл исенә төште. Шулай бервакыт, кызына кунакка килгәч, Салият аның сандыгында ачык рәсемле кримплен күлмәклек күрде. Ул елларда кримпленны яшьләр дә, картлар да яратып кия иде.

– Төсләре ничек ачык, бизәге матур, – диде Салият, сокланып.

Канитат әнисенә гаҗәпләнеп карады.

– Сиңа нигә кирәк булды андый күлмәклек? Картаеп барганда, ачык рәсемле күлмәк кимәкче буласыңмы?

– Шундыйны киеп йөрүчеләрнең миннән кай җирләре артык? – дип, Салият үпкәләде. – Туйларга баргач, хатыннар өстендә күргәнем бар.

– Син яшь чакта алай дип әйтми торган идең, – диде кызы, тагын да гаҗәпсенеп.

– Үзем киенсәм, балаларыма җитмәс дип дәшми торган идем. Кайсы хатын матур киенергә яратмый, барысы да ярата.

Шул чакта күлмәклекнең берсен Канитат әнисенә бирергә дип уйлаган иде дә, әмма кызганды. Аларны авыл хатыннарыннан кулдан, ике бәясен түләп, үзенә яки эштәге хатыннарга булыр дип алган иде. Үпкәләмәсен дип, әнисенә кемгә дип алганын да әйтте.

– Инде бер акчалы булсам, сиңа да, үземә дә алырмын, – дип сөендерде. Әмма алмый калды.

Инде үкенеч йөрәгеннән бер дә китмәячәген аңлады. «Күлмәклекләр дип, күпме ят адәмгә бүләк иттем, ничә кешенең үтенечен канәгатьләндердем, әмма үз әниемнең бердәнбер теләгән үти алмадым, – дип, хатын түшәгендә әрле-бирле килеп борсаланып ятты. – Кемгә охшаганмын мин? Әниемнең тормышыннан матур тормыш кайда бар иде? Нигә мин башкача яшим? Кайда ялгышканмын? Институтка үзем кереп, үзем аны кызыл дипломга тәмамламадыммы? Соң!..»

Ялгышлыклар шуннан соң башланды. Аспирантурага керер өчен белем түгел, танышлыклар кирәк булып чыкты. Сайлаган юлдан тайпылмас өчен Канитат күп ишекләрне ачты, күп адәмнәр алдында баш иде. Институтта эшләгәндә дә, шундый хәлләргә күп калды. Канитатның бик белемле һәм талантлы икәнен аның белән укыган һәм эшләгән адәмнәр тиз сизделәр. Шушы хаталар исенә төшкәндә, йөрәге тагын да ярсыды: «Дөрес яшәр өчен дөрес кешеләр белән аралашырга кирәк, – дип көрсенде. – Ә мин

җил очыртып алып киткәндәй, башкача яшәргә керешкәнмен. Инде кайгы минем күземне ачкач кына үкенәм».

Авылдашлары исенә төшкәндә, әнисе турында уйлап тагын да ныграк кыйналды. «Ничек шулай намусым җитте минем тудырган анам белән шулай дорфа сөйләшергә? Барыгыз да мине әрлисез, миңа ачуыгыз килә! – дип, үзен-үзе ачуланды. – Әниемне бары мин генә кимсеткәнменмени соң? Кайсы ананың баласына зыян ясыйсы килсен? Ничек кенә яманлык итсәк тә, безне кичергән кеше әни түгелме? Ниемә дип шулай ашкынып, ул диссертацияне яздым? Быел куеп торып, бер-ике елдан бетергән булсам, җирнең асты өскә килгән булыр идеме икән? Җир дә җимерелмәгән булыр иде, әниемнең саулыгы турында уйлаган булсам, үлмәс тә иде. Картлыгын да күрми калды, бахыр. Ни була иде, бөтен эшемне ташлап, хастаханәдән чыккач, санаторийга алып китсәм?! Тырышып эзләгән булсам, юлламасы да табылган булыр иде».

Үзен шундый уйлар белән кыйнаган саен инде күп нәрсәгә башкача карый иде Канитат. Авылдашларының берсе, җитмеш биш яшьлек Җарият, әле дә сау-сәламәт, үзе ялгыз яши. Ире күптән үлгән. Авылдашлар аны нигәдер сөймиләр. «Нигә кызганасың син аны? – ди иде алар Канитатка. – Гомер буе ресторан буфетында эшләп, акчадан кимчелек сизмәгән. Авыр елларда бер коштабак он өчен алтын-көмеш алган, берсен дә кызганмаган. Сугыштан соң күпме бала ятим калган, нигә шуларны алып үстермәгән? Җиңел яшәп, картлыгын уйламаган. Инде аз гына авырса да, яллап өен җыештырттыра».

Башта Канитат бу сүзләргә бер дә мәгънә бирмәгән иде. Кортка берәр яры китсә, сөйсә-сөймәсә дә, өен карады, авырса, аңа аптекадан дару алып кайтты. Әмма инде үзенең анасы үлгәндә, Канитат башкача уйлады.

Җарият белән минем әнием арасында нинди зур аерма булган. Ул кигән киемнәрне, ашаган ашларны, күргән курортларны, калаларны безнең әнкәй күрдеме?! Сугыш елларында ачлык та, ялангачлык та күреп килгәнгә, яшьли ирсез калып, һичбер тапкыр тормышыннан зарланмады, җиңеллек эзләмәде. Җарият исә, йөрәгенә нинди дару кирәген, нинди витаминнар суыктан саклавын, баласыз яшәүнең гомерне озынайтуын бик яхшы белә. Безнең әниебез беркайчан да уйлап карамады мондый нәрсәләр турында. Уйлаган булса, без тормышта авырлыклар кичергән булыр идекме?»

Әнисе үлгәннән соң, Канитат Назирә күршесенең тормышына да башкача карый башлады. Нигә дип ул күршесеннән көнләште икән? Ул бит яшь, чибәр хатын, өендәге бөтен авыр эшне карт анасы җилкәсенә салган. Канитат хәзер генә Патиматның ничек итеп авыр атлавын сизде, күрәсең, аяклары шешкән... Шулай бервакыт, Назирә кызы белән урамга чыккач, Канитат тәрәзәдән карап, аны чәй эчәргә чакырды. Ул аңа берни дә яшермичә, үзенең әнисе турында сөйләде. Назирә аны бик кызыксынып, башын түбән иеп тыңлады.

– Мин дә синең хәлгә калмасам ярый инде, – диде ул соңыннан. – Балалары шәфкатьсез булган аналар, күрәсең, тиз үләләрдер...

*Ногайчадан* **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәсе.*

# ШАГЫЙРЬ ГОМЕРЕ

Равил Фәйзуллинның Сайланма алты томлыгына[1] һәм «Яңа гасыр иртәсе»[2] китабына кергән ике мең шигыре, бер дистә поэмасы аның поэтик егәре – иҗат фидакарьлеге, кабатланмас индивидуаль-шәхси үзенчәлеге яшәештәге бәхәссез лидерлыгы хакында сөйли. Басылып чыккан йөзләп публицистик язма-рецензия-бәяләмәсе, алтмыш елга сузылган иҗтимагый эшчәнлеге гражданлык активлыгын күрсәтә. Аның әсәрләрен анализлап, меңнән артык милләттәшенең әдәби-гыйльми мәкалә язуы[3] – киң җәмәгатьчелекнең автор иҗатына булган олы ихтирамы. Соңгы ярты гасыр татар әдәбияты үсешенә ул, һичшиксез, иң якты эз салып килүче әдипләрнең берсе. Моңа өстәп, биредә поэзиябезгә алып килгән сыйфат яңалыгын, бу жанр үзгәрешенең Бөтенроссия масштабында да танылу алуын, 27 яшендә ике йөз томлык «Бөтендөнья әдәбияты китапханәсе»ндә урын алган унҗиде классик шагыйребезнең берсенә әверелүен дә ассызыклап үтәргә кирәктер.

Үткән гасырның алтмышынчы елларында татар шигъриятенә үзенчәлекле поэтик сулыш алып килгән яңа буын вәкиле Р.Фәйзуллин әсәрләре әдәби тәнкыйтьтә шактый кызу бәхәс, мәдәни мохиттә шау-шу кузгатты. Иң мөһиме: өйрәнчеклек чорын ул, барча олы талантларга хас булганча, тизләтелгән темпларда узды. Шуңа күрә басылып чыккан бу шигъри тәҗрибәләрдә һәртөрле бәя-карашларга да сәбәп җитәрлек иде. Аның шигырьләре ул чорда милләт зыялылары, бигрәк тә иҗади яшь каләм ияләре рухи дөньясында җил-давыллы үзгәреш дәрте тудырды. Яңалыкка, ихласлыкка, шәхес ирегенә нык сусаган күңелләр тарафыннан һәр китабы көтеп һәм хуплап каршыланды. Яшьтәш-курсташы Рәфикъ Юныс соңрак бу хакта «Фәйзуллин шартлаткан «бомба...» мәкаләсендә: «1965 елның ноябрендә «Казан утлары»нда Равил Фәйзуллинның «Нюанслар иле» дигән кыска (2, 3, 4, 5 юллык) ирекле шигырьләр тупланмасы чыкты. Шуннан соң купкан шау-шуны күрсәгез! 22 яшьлек Фәйзуллиныбыз тиз арада иң күп макталган һәм иң күп сүгелгән, ягъни иң популяр шагыйрьгә әйләнде дә куйды!»[4] – дип яза.

Әлбәттә, каләмдәш-курсташының «бомба шартлату»ны бер Фәйзуллинга гына кайтарып калдыруын биредә мәкалә исеме мантыйгыннан чыгып аңларга, бу чорга бәя биргәндә исә әдәби процессны шактый тарайтып күрсәткән һәм артык кискен яңгырашлы әлеге метафораны беркадәр йомшартыбрак, киңәйтебрәк карау кирәклеге соралып тора.

1 Равил Фәйзуллин. Сайланма әсәрләр, алты томда. // 1–3 том: Шигырьләр, поэмалар; 4–6 том: әдәби-публицистик мәкаләләр, иҗат портретлары, әңгәмәләр, юлъязмалар, нәсер-парчалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.

2 Равил Фәйзуллин. Яңа гасыр иртәсе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014.

3 Равил Фәйзуллин. Заман. Иҗат. Шәхес. – Казан: «Мәгариф» нәшр., 2002 (5–412 битләрдә 90 каләмдәшенең язма-бәясе, 425–482 битләрдә аның турында матбугатта басылып чыккан меңгә якын автор-хезмәтнең исемлеге бирелгән; 2013 елның 17-18 октябрендә шагыйрьнең 70 еллык юбилее уңае белән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә уздырылган һәм Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция материаллары тупланган «Равил Фәйзуллин: шәхес, иҗат, заман» басма китабында 92 олпат һәм яшь галимнең фәнни мәкаләсе урнаштырылган.

4 Равил Фәйзуллин: шәхес, иҗат, заман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 268 б.

Татар әдәбият тарихында «Фәйзуллиннар буыны» дигән төшенчә ныклап кереп урнашкан икән, димәк, ул инде үзе генә түгел дигән сүз. Чынлап та, бу заман шигъри фикерләвендә мондый үзгә яңалыкны без аның башка каләмдәшләре иҗатында да тоймый калмыйбыз. Ул чакта шигырь җене кагылган затларга аеруча нык тәэсир ясаучы Рәдиф Гатауллинның 1966 елда дөнья күргән «Гөлләр су сорый», Гәрәй Рәхимнең 1967 елда басылган «Вәгъдә», Рөстәм Мингалимнең «Эзләр» (1968), Ренат Харисның «Беренче карлыгачлар»дагы (1968) шигырьләре, «Кайтаваз» (1969) китаплары әнә шундый, күңелдә яңа «поэтик шартлау» хасил иткән китапчыклар иде. Әмма шунысын да әйтергә кирәк, Р.Фәйзуллинның 1966 елда чыккан «Аҗаган» китабында бирелгән ирекле стиль-фикерләү тәҗрибәләре сәнгати яктан тәмам өлгереп җиткән шигырь үрнәкләре белән бергә аралашып килә. Алардагы сокландырган һәм беркадәр аптырашка да калдырган бөек иҗади сер-каршылык та нәкъ шунда иде булса кирәк.

Егерменче гасыр татар әдәбиятында «поэтик шартлаулар»ларның бу беренчесе түгел. 700ләп татар зыялысын иҗатка илһамландырып[5], шигъриятебезгә бөек Тукай, Дәрдемәнд, Бабичларны дөньяга чыгарган бишенче-унынчы елларны, тагын да янәдән үз чорының күренекле әдәбият галиме Г.Нигъмәти сүзләре белән әйтсәк, халык массаларын энтузиаст хезмәткә, иҗатка рухландырып, «татар революция әдәбияты күгендә биш йолдыз» – Нәҗми, Такташ, Туфан, Толымбай, Кутуйларны[6] биргән социализм төзүгә керешкән күтәренке-катлаулы романтик елларны без яхшы хәтерлибез.

Инде менә әдәбиятыбызның яңа талпынышы: миллионлаган репрессия, дәһшәтле сугыш корбаннары исәбенә ирек яулап алган, дистәләгән классик әдәбият үрнәгенең, тоткынлыктан чыгып, кабат милләтебез рухи яшәешенә әйләнеп кайткан, халыкның исә, ач-ялангачлыктан котылып, аң-белемгә, фәнни-техник революция (ФТР) чорына аяк баскан, чиксез галәм киңлекләренә капка шакыган, меңләгән физик һәм лирикларның бер-берсен узыштан ирекле иҗат бәйгесенә томырылган, «җепшеклек» чорына кинәнеп, илдә сүз-гамәл иреген тойган яшьлекнең «без»дән «мин»гә әверелгән, азатлыкка омтылган эчке «поэтик шартлаулар»ның урамнарга бәреп чыккан, Мәскәү шагыйрьләре Е.Евтушенко, А.Вознесенский, Б.Ахмадуллина, Р.Рождественский, Б.Окуджава кебек талантларның шигъри телдә бушанырга стадион тутырып, халык җыя башлаган яңа чоры!

Биш-алты елга соңарып, ирек дулкыны милли провинция саналган безнең татар мохите үзәге – Казанга да килеп җитте. Татар әдәбиятына алмашка сугыштан соңгы: үлем куркынычын һәм михнәтләрен татымаган, ач-ялангачлык белән изелмәгән, илдәге рухи чикләнүләрне алга таба да ватарга әзер торган, югары белемле, дөнья әдәбиятыннан хәбәрдар – зур дәгъвалы яңа буын килеп керде. Алар берән-сәрән генә түгел, ә бәлки төркем-төркем булып, дистәләп килделәр. 1968 елда басылып чыккан «Беренче карлыгачлар»ның үз эченә берьюлы 14 яшь авторның яңа нәни китапчыгын берләштерүе дә очраклы гына түгел иде бит.

Р.Фәйзуллин тәмамлаган (1965) Казан дәүләт университетының татар бүлеге генә дә 60-70 еллар аралыгында профессиональ иҗатка (сүз «җиз иләккә» әверелгән – Язучылар берлегенә кабул ителү турында бара) ел саен 4-5 яшь әдип өстәп торды. Бу чорда әдәби иҗатка килүчеләр саны «дулкын-дулкын булып» даими артып торды. Алар, бер зур агымга кушылып, 70-80 еллар әдәбият белемендә киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим иткән көндәлек басмада (сүз йөз мең тираж белән басылган матбугат турында бара) «Поэзиябездә Тукай, Җәлил традицияләре» кебек зур, җитди сөйләшүләр чыганагына сәбәпче булды.

[5] Р.Гайнанов төзегән исемлек // Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы). Төзүчеләре З.Рәмиев, Ф.Бәширов. – Казан, 2005. – 4 б.

[6] Галимҗан Нигъмәти. «Безнең юл» журналының 1927 елгы 6-7нче саннары.

***

«Нюанслар иле»нең татар җәмәгатьчелегендә, бигрәк тә әдип һәм галимнәре арасында шундый кызу бәхәс китереп чыгаруы, миңа калса, иҗат процессының төрле баскычын тәшкил иткән бу үрнәкләргә поэтик эзләнү һәм тәмамланган әдәби продукция итеп аерып карамауларында. Әсәрләргә шигъри фикерләү потенциалы һәм поэтик жанр тудырган үзкыйммәт буларак якын килү, бигрәк тә аның төгәл эстетик дәрәҗәсен билгеләү исә мәсьәләгә шактый күп ачыклык кертер иде югыйсә. Бу берочтан жанрның асыл хасиятенә төшенү өчен әдәбият галимнәрен, башка милләтләрдә охшаш жанр чыганакларын эзләп, ерак географик киңлекләрдә[7] адаштырып йөртмәс иде. Хакыйкатьнең үзеге – гомум иҗат процессында, гомум иҗат кануннарында! Ә инде аның милли хасиятләре турында да беркадәр күзаллау тудырасыбыз килә икән – алар күптән ачыкланган: музыкаль әсәрләрдәге пентатоника кебек үк, поэтик фикер йөртүебез, андагы поэтик күзәнәкләр дә үз телебезгә, милли-рухи барлыгыбызга, берничә мең елга сузылган үз әдәби традицияләребезнең еракка киткән тирән тамырына барып тоташа! Әдәбиятның структур-функциональ табигатен искә алып эш иткәндә, моңа төшенү авыр түгел. Иҗаттагы бер-берсеннән аерылгысыз бу ике этапның һәркайсы шагыйрь үзенчәлегенең төрле аспекттагы сыйфатын: беренчесе күбрәк аның башлангыч потенциаль шигъри мөмкинлеген, икенчесе исә сүз остасының конкрет әлеге жанрга бәйле төстә ирешкән композицион уңыш-нәтиҗәсе хакында сөйли. Бу ике төрле ракурстан чыгып карау авторның табигый максат-омтылышын, эзләнүләрен, иҗат сулышын һәм, ниһаять, әсәрдәге табыш-казанышларын, кимчелекләрен бик ачык күрсәтеп тора. Тик аларны бергә кушып бутамаска гына кирәк.

Р.Фәйзуллинның берьюллыкларында поэтик фикерләү һәм жанр таләбе аерылмас бербөтенлек хасил итә, чөнки алар шигъри күзәнәктән аерылып җитмәгән. Аны кайсы яктан күрәсебез килсә, ул шул ягы белән безгә әһәмиятле булып тоела:

*Күңелгә иш – ертык болытлар...*
(Хәсрәтле чакта)[8].

Кешенең бу – табигатьтә эчке үз дөньясы белән аваздаш таныш моң-сурәт табып алып юануы. Ул гаҗәеп табигый – натураль, рухи халәт биредә жанр таләп иткән һәртөрле өстәмә көйләнгән-көчәйтелгән ритм-үлчәм (аһәң), рифмалардан (кабатланган яңгыраш) азат (бер юлда чагылыш тапкан тын алуда аларның һич кирәге юк һәм бу мөмкин дә түгел). Әмма әлеге охшашлык ассоциациясе тудырган дүрт сүзле эстетик берәмлектә поэтик фикерләүнең нигезен тәшкил иткән сәнгати (шартлы) шигъри күзаллау – поэтик микрокүзәнәк инде бар.

Дөрес, автор аңа конкрет исем куеп – логик дәрәҗәгә күтәреп, билгеле бер төгәлләнгән конкрет жанр-әсәр икәнлеген дә искәртә. Әмма поэтик җегәре белән ул барыбер авторның күбрәк эчке шигъри потенциаль фикерләү рәвеше хакында сөйли.

Авторның иң уңышлы берьюллыклары көтелмәгән ассоциатив тойгы уятулары шул ук башлангыч һәм тәмамланган әсәр функциясен башкарулары белән кызыклы: монда шагыйрьнең нечкә психолог һәм рәссамлык талантын сизми калмыйсың – болар сүз-тасвирга күчәр-күчмәс тышка бәреп чыккан табигый кичерешле әзер шигъри картина-этюдлар! Күбесе күңелдә дәвам итүне сорап аваз салган лирик башлангычлар:

*Елады кан Елан елында.* (Сөюсез ел)
*Толымланып салынып төште Күк сагышы.* (Яңгыр)
*Дулкын иңнәрендә кабынды учаклар...* (Иделдәге шәфәкъ)
*Күзләр чагыла яшисе килүдән!* (Кар яктысы)

[7] Татар әдәбияты тарихы, сигез томда. – 6 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 412-433 б.
[8] Равил Фәйзуллин. Сайланма әсәрләр. Алты томда. 1 нче том: Кыска шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.– 29-192 б.

Кайберләре исә бөтенләй исем куюны да артык санаган яртылаш сүзсез аккан фикер сөреше – хикмәтле фәлсәфи хакыйкать!

*Каберләрнең бар – тик туган елы...* (Каберләрнең бар...)

Паремиологик әсәр буларак, бу тасвирлар аткан ук кебек тойгы яисә фикер чаткысы аша максатларына төгәл барып ирешә торган афористик, эффектлы жанр берәмлеге.

Авторның икеюллыклары оригинальрәк, кызыклырак ачышларга тагын да баерак. Аларда да тасвирның поэтик егәре һәм икеюллыкның жанр үзенчәлеге буларак композицион төгәллеге безне бердәй сокландыра:

*Кына тулы кан.*
*Тышында чәчәк сурәте...* (Тарих)
*Өметемнең күзе шундый зур!*
*Керфекләре генә ябылмасын!..* (Очрашкач)

Рухи халәт белән аның тышкы чагылышы арасына сузылган поэтик күпердән укучы биредә әсәрнең исеменә кадәр әнә шундый сынаулы, хикмәтле озын шигъри юл уза.

*Менә ишек ачылыр да хәзер –*
*мине суырып алыр салкын юл...* (Хушлашыр алдыннан)

Шагыйрь чынбарлыкны шулкадәр якыннан торып, халәт-тасвир берлеген шундый сиземле итеп сүзгә күчерә ки, шартлы психологик рәсем, тормыш дөреслеге үзеннән-үзе күңелгә кереп утыра сыман!

Һәр уңышлы табылган икеюллыгында без авторның рәссамлыгы һәм нечкә психологлыгы белән янәшәдә башкалар язмышына гаҗәп сак карашы, милли әхлагыбызның аерылгысыз фәлсәфи атрибуты – кешелеклелеге белән очрашабыз:

*Икәү фотога төшкәнсез.*
*Син – барыбер уртада!* (Үземнеке!)
*Җыерчыкларыңның болары – минем борчулардан...*
*Ә болары – үз бәхетең көннәреннән.* (Карадым да текәлеп...)

Алдагы ике юллык текстта гамәл һәм поэтик очыш тирбәлеше масштаблы эчке халәт кайнарлыгына әверелә:

*Кулыңда чуерташ кына.*
*Ә миндә инде дулкын!* (Кабыну)

Икеюллыкларда еш кына халкыбызның меңьеллык поэтик акылы терелгәндәй була:

*Ил мантырга теләмәсә,*
*халкыннан дошман эзләр.* («Ил мантырга теләмәсә...»)

Шагыйрьнең зирәк фикер йөртү нигезенә дә аның хикмәтле акыл көче салына:

*Гел бер телдә язылган тарих –*
*«Әнисенең уңган кызы!..»* («Гел бер телдә...»)

Бик еш кына кырыс яшәү хакыйкатен авторның газаплы үз эчке тормыш тәҗрибәсе ачып җибәрә:

*Минем хәлгә төшәр өчен*
*Сиңа менәргә әле!* (Бер яшь каләмдәшкә)

Берьюллыклардагыча ук, әлеге икеюллыкларның жанр чыганакларын эзләп тә әллә кая барасы түгел, милләт рухының, татар фикер йөртүенең ул үз табигате кысаларында формалашкан. Нәкый Исәнбәт туплаган өчтомлык мәкаль-әйтем, сынамышлары белән таныш булган кешегә моны раслап-исбатлап торасы юктыр дип беләм. Р.Фәйзуллин икеюллыклары шуларның яңа заманда чагылыш тапкан һәм авторлаштырылган дәвамы буларак кабул ителә:

*Кешенекен урлагансың –*
*Шуңа китек күмәчең...* (Өлеш)

*Ир-ат, егет – бөтенебез –*
*Хатын-кыз ятиме без!* («Ир-ат, егет – бөтенебез...»)

Монда – бер яктан, бар көченә томырылып чапкан Шигърият дөлдөлен иярләп алып, аны заманнан калышмаслык итеп тагын да кызулатып камчылау, икенче яктан, якты яшәү чаткысының нәни ут сыман кабынып сүнүен хәтерләткән тормыш хакыйкате, поэтик җан талпынышы.

Шагыйрьнең өчьюллыклары башлыча чынбарлыкның лирик герой күңелендә кузгаткан шартлы – ассоциатив чагылышына нигезләнеп оеша:

*Торналар китеп бара.*
*Кош канатлары орынгач,*
*Болытларның күңеле тулды.* (Көзге яңгыр)

Беренче юлда нейтраль объектив табигать күренеше тасвирланган. Икенче өлештәге табигать исә – кешеләштерелеп, субъект призмасы аша җанландырылган күңел халәте.

Поэтик фикерләүдә бер-берсеннән шактый ерак тоелган, әмма чынбарлыкта гаҗәп якын күрше булып яшәгән әлеге янәшәлек ассоциациясе микросурәтләре, бигрәк тә аларның өчьюллык белән чикләнгән кыска формалары, чыннан да, японнарның хокку кебек поэтик жанрларын хәтерләтеп куя[9].

*Йолдыз атылды.*
*Сабый бала форточкадан*
*Кулын сузды.* (Омтылыш)

Бүгенге татар шагыйренең дөнья шигърияте казанышларыннан, шул исәптән япон поэзиясендәге бу төр жанрлар белән дә яхшы таныш булуы һич гаҗәп түгел. Шулай да автор иҗатының эволюцион үсеш юлын күзаллап, мин аның табышларын да, кимчелекләрен дә япон поэзиясе кысаларында эзләүдән, «хокку жанрына хас традицион сыйфатларны милли җирлеккә яраклаштырып үзләштерә»[10] дигән бәя бирүләрдән ерак торам. Шагыйрьнең һәр талпынышын үзебезнең милли фикерләү хасияте традицияләрендә күзаллау күпкә нәтиҗәлерәк дип саныйм. Һәрхәлдә, авторның уңышлы табылган поэтик казанышларын бу тышкы жанр охшашлыгы түгел, ә бәлки аның милләте тудырган үз поэтик җегәре билгели. Алда китереләсе мисаллар да моны тулысынча раслап тора.

*Таз эчендә орчык малай.*
*Пар эчендә ата елмаюы:*
*«Арка ышкырга кешем бар!»* (Горурлык)

Моннан соңгы өчьюллыкта без янәшәлек ассоциациясенең автор нерв җепселләрен тагын да киеренкерәк халәткә китергән очрагына тап булабыз:

*Яз җитүгә,*
*Беренче булып*
*Таудагы кабер ачыла.* (Хәтер)

Ә алдагы шигырьдә бу төр ассоциациягә авторның логик фикере килеп кушыла:

*Тын бүлмәдә шәп вазада җикән камыш.*
*Ханым күлмәк салгандагы җил*
*ул бик аз шул...* (Әсир)

Чираттагы мисалда лирик герой халәте, охшашлык ассоциациясе аша трансформацияләнеп, әсәрнең идеясенә – яшәү-тормыш кодрәтен раслауга алып чыга:

*Көнбагышка ябышып үлгән.*
*Ачык күзләрендә*
*икешәр кояш.* (Көн уртасында үлгән солдат)

---

[9] Татар әдәбияты тарихы, сигез томда. – 6 нчы том, Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 412–433 б.
[10] Шунда ук. – 416 б.

Дүртьюллык кыска шигырьләренең татар-төрки шигъриятендә гарәп-фарсы робагыйлары белән үрелеп үскән озын тарихы бар. Әлеге хикмәтле поэтик жанр бик күп татар классик шагыйрьләренең яратып кулланылган шигъри сүзе булып тора. Иҗатында Р.Фәйзуллин да аларны актив фәлсәфи көрәш чарасына әверелдерә.

Шунысын да әйтергә кирәк, авторның дүртьюллыкларында инде тасвир нигездә логик фикерләүгә корыла: шуңа алар рациональ, кискен, кырыс, максатчан булып яңгырый. Логик фикерләүгә корылганлыктан, башка телләргә тәрҗемә итү ягыннан да бу төр микросурәт, шактый җиңеллек тудыра. Моңа өстәп тагын Р.Фәйзуллин дүртьюллыкларының, нигездә, традицион яңгырашлы ритм-рифма чаралары белән дә көчәйтелүен билгеләп үтү мөһим.

Әлеге кыска логик тезис-җөмләләр аша шагыйрь үзенең тулы яшәү программасын тергезә:

*Шатлыкны бик җиңел димә,*
*Кайгыны бик авыр алма.*
*Һәр икәве – олы сынау*
*Кешелеге булган җанга.* (Җиңел димә)

Автор тынгысыз тормышының Олы мәхәббәт белән мәңге аерылгысыз булуын белдерә:

*Нык тораммы, чайкаламмы,*
*Күккә ашаммы, аваммы...–*
*Хурлыгымның ахыры бул,*
*Зурлыгымның дәвамы!* (Яме!)

Гасырлар дәвамында кылыч-хәнҗәр кебек үткенләнгән фикри тасвир чарасы шагыйрьнең көндәлек рухи көрәшендә аерылгысыз төп корал. Алар ярдәмендә ул еракка төбәлгән масштаблы фәлсәфи гомумиләштерүләрен ясый:

*Бөекләр булган җуйганбыз.*
*Гасырлар – ерак ара.*
*Кайта-кайта «Тукай!» – дибез, –*
*Ул шул яңарак яра...* (Әүвәл дә булганнар...)

***

Р.Фәйзуллинның күпкырлы поэтик фикерләү үзенчәлеге аның яшь психологиясе нюанслары белән баетылып, нәниләр өчен язган шигырьләрендә тагын да тулырак булып ачлылып китә. Шунысын да искәртеп китик, авторның Татарстан китап нәшриятында бастырып чыгарган беренче китабы да нәкъ менә балалар әдәбиятына карый[11].

Дөрес, өлкәннәр өчен язылган «Аҗаган» (1966), «Монологлар һәм диалоглар» (1967), «Мәрмәр» (1969) кебек әдәби җәмәгатьчелектә зур җанлану, бәхәс, хуплау уяткан яңа сулышлы китаплары шагыйрьнең нәниләр өчен язылган шигырьләрен беркадәр күләгәдәрәк калдырды булса кирәк. Ә бит үз балачак дөньясының үзенчәлеген гаять нечкә шигъри сурәтләр аша җанландырган бу беренче китабы ук авторның профессиональ осталыгы хакында сөйли.

Сабыйлык дөньясы алга таба да шагыйрьнең иҗатын әйдәп баручы төп көчләрнең берсе булудан туктамый. Нәниләр өчен язылган китапларының дистә еллар буена өлкәннәр шигърияте белән үрелеп баруы әнә шул хакта сөйли. Дәлил итеп аларның кайберләрен атап үтәсе килә: «Рәсем ясыйм» (1965); «Күмәч пешерүчеләр җыры» (1977); «Чәчәкләр үстердем» (1979); «Паласны кем кагар?» (1980); «Якты моң» (1983); «Сәгыйть белән сәгать» (1989). «Газиз китабы» (2005; «Текут, текут реки» (М.: Дет. лит., 1987, 100000 д.).

[11] Р.Фәйзуллин. Рәсем ясыйм. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965.

Әлеге китапларда авторның балалар шагыйре буларак иҗат активлыгы, шигъри фикерләү үзенчәлеге, гомум иҗат үсеше бик ачык төсмерләнә. Иң мөһиме, нәниләр шигъриятенә төбәлгән мәхәббәте аның күңел ихтыяҗы булып калуын дәвам итә: «...Уянып киттем үлән үскән тавышлардан» кебек юллары белән автор үзенең һәрдаим балалар шигъриятендә яшәвен күрсәтте.

Чынбарлыкны хыялый шартлылыкта шулай масштаблы, сиземле, ачык итеп күзаллау бары тик нәниләр шигъриятендә генә мөмкиндер. Ә шагыйрьнең сабыйлыгы исә аның фикерләвенә, җанына, әйтүебезчә, күптәннән – ерак балачагыннан салынган:

*Көнбагыш чәчәге ясыйм,*
*сары карандаш алдым.*
*Эшем бетте, исем китте:*
*кояшны ясаганмын.*

Күрәбез, бу баланың рәсем ясап уйнавы гына түгел. Бу – поэтик сурәтнең туу рәвешен чагылдырган, шагыйрьнең поэтик фикерләү үзенчәлеген күрсәткән шигъри иҗат этюды. Бу – конкретлыктан сурәтле фикерләүгә булган күчеш – һәртөрле шигъри метаморфозаларның башлангычы. Шагыйрьнең сәнгатьле фикерләве үткән юлны нәни бала еш кына шулай уйнап-шаярып, тормышта үзе яшәп үтә.

Сабыйларча сиземле, җанлы итеп уйлауның сәнгатьле фикерләү белән уртаклыгы әнә шунда. Инде моннан соң баланың:

«Үрмәкүч үргән челтәр-бишектә тибрәнә җәй!« – дип, йә булмаса кар баскан урман өстендә уйнаклаган кызылтүшне: «Карлы дугалар өстендә кызыл кыңгырау! Кышкы урман уртасында язгы яңгырау!» – рәвешендә шигъри күрүе гаҗәп түгел.

Әнә, бала йоклагандай, «ай да башын салган болытларның өстенә» («Йокы әкияте»); «Кояш исә болытларның читен ачып, җиде төрле буй сөлгесен иңгә асып», яңгырдан соң саф һавага чыккан («Яңгырдан соң»); тал песиләре, ташулар ярга менгәч, рәхәтләнеп су коена («Быелгы яз»); телефон чыбыгына кунган чыпчыклар исә малай әнисенең кызык сүзен ишетеп «чырык-чырык итәләр» («Чыпчыклар»). Әлеге сурәт-детальләр артында уй-хисләре, кичерешләре – бөтен барлыгы белән бала үзе тора. Аның үткен күзе, предметлы фикерләве, бай фантазиясе бергә кушылып, җанлы тасвирга әверелә. Әнә ул – көчсез, тәҗрибәсез табигать баласы («Барырга кая дип торганда уйланып, беткәнбез чыланып... Ә бал корты исә аптырап калмаган, үлән-яфрак астына кереп поскан); әнә ул – Идел кебек җәелгән инешләргә карап: «Бәлки быел безнең якка аккошлар да килерләр», – дип, татлы, яшерен хыялый өметкә бирелгән («Быелгы яз»); әнә ул – ата-ананың шаян, бәхетле улы: «Шулай да җиләкләр күбрәк табыла әтием янында, әнием янында».

Балалар логикасын тасвирлаганда, шагыйрьнең нәниләрчә фикер йөртә белүе, шигъри гомумиләштерүдәге кыюлыгы тагын да ачыграк күренә: «Карталарда безнең илне буяганнар алсуга. Чөнки кояш иртүк торып, алсу утлы шардай булып, иң башта бездә чыга».

Икенче бер шигырьдә бала тәрәзәдән карап таң атуын күзәтеп тора:

*Башта үзем куркып куйдым –*
*караңгыда күрә алмам.*
*Хәзер тышта якты инде,*
*таң атканын күрми калмам!*

«Паласны кем кагар?», «Ни җитмәгән?» һ.б. шигырьләрендә юмор-көлү, сатира актив тәрбия чарасына әверелә.

Р.Фәйзуллинның шигъри осталыгы деталь-сурәтләрдә генә түгел. Шигырьнең композицион оештырылышында да аның кызыклы гына үз табышлары бар. «Каймаклы чия» һәм «Кызыл кар» шигырьләренең төзелеше үзенчәлекле һәм кызыклы. Каймаклы чия өстәлгә килсен өчен ни кирәк? Бу – шигырьнең шарты, шигъри ачкычы. Җавап исә,

әле чиягә, әле каймакка бәйле төстә үстерелеп, әсәрнең поэтик чишелешенә әверелә. Әлеге шигъри уен – һичшиксез, бала өчен мавыктыргыч һәм файдалы шөгыль.

«Күмәч пешерүчеләр җыры»нда автор табынның кояшы булган гади һәм изге икмәкнең өстәлгә кайдан килүе турында тасвир итә. Икмәк пешерүче кебек гади дә, күрекле дә булган меңнәрчә, миллионнарча хезмәт куючыларның – «кешеләрнең йөзләренә шатлык төшерүчеләр»нең олылыгын нәни укучысына онытылмас шигъри сүз ярдәмендә илтеп җиткерә.

«Сабыйлар елы»ның да укучы алдында хикмәтле ел булуы – аның әти-әниләр елы булуы да, чәчәк һәм күбәләкләр елы да, дуслык һәм бәхет елы булуы да ачылып китә.

Шагыйрь үз укучысын кечерәйтми, аның белән бергә үз тиңедәй итеп фикер йөртә. «Сәгыйть белән сәгать», «Бердәнбер» шигырьләрендәгечә аларны ул еш кына җитди фәлсәфи сөйләшүгә чакыра. Шулай итеп, шагыйрь йөрәк акылын, тормыш тәҗрибәсен үзенә генә хас шигъри тасвир телендә нәни укучысы күңеленә илтеп җиткерүгә ирешә.

***

Шагыйрьнең гражданлык йөзе, һичшиксез, кыска һәм нәниләр өчен язган шигырьләрендә генә түгел, ашкынулы яшьлеге, моннан соң иҗат иткән бөтен тулы форматлы поэтик әсәрләрендә тагын да киңрәк чагылыш таба.

Р.Фәйзуллинның өлкәннәр өчен чыгарылган беренче 72 битле «Аҗаган» (1966) китабына кергән 31 шигырьнең яртысы сәнгать ягыннан инде тәмам өлгереп җиткән югары сыйфатлы әсәр саналырга хаклы. Әйтергә кирәк, әлеге китапчык шагыйрь иҗатының иң көчле тупланмаларының берсе. Аның татар поэзиясенә гаять үзенчәлекле яңа талант килүен хәбәр итүе һәм татар әдәби җәмәгатьчелегендә шундый зур резонанс тудыруы һич очраклы түгел. Иҗатка бер чорда килгән каләмдәшләреннән дә авторны иң әүвәл әнә шушы өлгергән әсәрләргә гаҗәп юмартлыгы аерып тора. Табигый ки, бу әсәрләр ярты гасырдан соң, ягъни бүгенге көндә дә гаять оригиналь һәм өр-яңа булып кабул ителәләр.

Шундый шигырьләрнең берсе 1963 елда язылган «Балыкчы карт» әсәре:

*Иске көймә.*
*Беткән көймә.*
*Җил-яңгырдан типчелгән куп;*
*кычкырсаң да, таралыр күк.*
*Балыкчы карт һаман ярда.*
*Йөзе – сөяк ,*
*ә куллары тамыр гына...*

Тагын да шундый классик шигырьләренең берсе – аның ассоциатив фикерләүгә нигезләнеп язылган «Кер чайкыйлар кызлар...» (1964) әсәре:

*Кер чайкыйлар кызлар.*
*Тезләрендә – Кояш!*

«Эмигрант» (1964) шигырендә дә поэтик фикерләүне шул ук ассоциатив бәйләнешләр хәрәкәткә китерә *(«*Туган илдә сагыш, көзге яфрак кебек – сары төстә генә... Ә монда сагышның зәңгәре, аклары, аллары...»*)*

Әлеге чорда шагыйрь үзе күргән, үзе ишетеп белгән бик күп замандашларының төрле кабатланмас холык-фигылен сүз портреты аша җанландыруга ирешә. Аннан да бигрәк, һичшиксез, үзенең гаҗәеп тынгысыз, күпкырлы, актив лирик героеның күңел кичерешләренә кыю үтеп керә.

Үзәктә – бөек яшәү лабиринты буйлап алга җитәкләп барган хис-тойгы – уй-акыл көрәше, мәңгелек очышка дәртләндергән кодрәтле сөю-мәхәббәт очкыны. Шуңа яшьлегенең һәр мизгеле шагыйрь күңелендә тылсымлы җырга күчеп яңгырый:

*Мин сине ничек яраттым!*
*Мәктәп юллары белә.*

*Синең эзне аера идем*
*мең эздән, (бер?) карау белән*
(«Мин сине ничек яраттым!» 1966)

Китапның серле ачкычы, һичшиксез, оригиналь сюжет-канвалы «Ажаган» (1965) шигыренә яшерелгән. Ул бер үк вакытта серле-романтик *(«Яшьләр үбешә иделәр... / Иреннәр аерылмады. / Керфекләр генә сөйләште: /«Ажаган гына бары, / ажаган гына бары...»), шул ук вакытта шактый ук хәвефле-хафалы нәтиҗәләре – гыйбрәтле бетеме белән истә кала («Булмады быел алмалар – / агачлар кысыр калды. / Әйтте күпләр: «Чәчәген / ажаган гына алды, /ажаган гына алды...»)* Халкыбыз ырым-сынамышы, шул рәвешчә, шагыйрьнең үзәк иҗат магистраленә, төп гомер кредосы – нәтиҗәле-мәгънәле яшәү турында уйлану символына әверелә.

Шунысы характерлы: авторның тулы форматлы, композицияле шигырьләрендә дә тыныч кына бер көйгә аккан поэтик тасвирны без бик сирәк очратабыз. Аларда хис-фикер, гадәттә концентрацияләнеп, энҗе бөртегедәй ялтырап, әсәрнең йөзек кашы сыман, аның шигъри лейтмотивы булып калкып чыга. Әмма аларның һәркайсы үзенчә аерым төсмерле: кайчакта ул күңел төпкеленә яткан иң авыр ташларны кузгатып, лирик геройның бәгырь нечкәлеге булып бәргәләнә:

*«Күзләрдән соң язлар килми,*
*Алда – салкын, ак кышлар.*
*Китәсез дәмени,*
*Китәсез дәмени,*
*Китәсез дәмени,*
*аккошлар?»*
(«Аккошлар», 1971).

Ул да түгел лирик герой хикмәтле философ рәвешен алып, зирәк фикерен белдерә:

*«Философ булмаган әти.*
*Ә минем кирәкне белеп,*
*өйләнгән минем әти.*
*Җырчы да булмаган әти.*
*Ә миңа бишек силәсен*
*зыңлап торганын ясарга*
*өйрәнгән минем әти»*
(«Минем әти», 1964).

Яшәешнең һәр сулышы, һәр вакыйгасы, һәр драматик төенләнеше шагыйрьгә кабатланмас шигъри шартлылык тудыруга сәбәп була. Иҗатның калган өлешен авторның янар таудай көне-төне сүнүне белмәгән шигъри җаны хәл итә, аның әледән-әле вулкан булып, мәрмәр ташны уярлык шигъри сүзгә әверелеп (автор үзенең бер китабын тикмәгә генә «Мәрмәр» дип атамый бит) меңләгән күңелләрне яндырыр кодрәт алып бәреп чыгуы да монда һич гаҗәп түгел:

*Ул елларны инде даулап булмый...*
*Сагынып кына була!*
*Үткән бөеклеккә кайтып булмый, –*
*табынып кына була...*
(«Ул көннәрне инде даулап булмый...» 1968)

Мондый үлемсез шигърият гомерлеккә синең барлыгыңны биләп ала, аның кайтавазы шатлыкта да, кайгыда да – синең аерылгысыз юлдашың, ә еш кына – битараф тынлыкта ул шигъри мәйданнарга чыгып оран сала сыман:

*Яздан аерып булмый Тукайны!*
*Язда килгән, язда ул янган.*

*Язы, киләчәге барлар ничек китсен,*
*ничек югалалсын дөньядан.*
(«Яздан аерып булмый Тукайны!»1971, 3-4 апрель, Әлмәт.)

Ул шигъри кодрәтнең рухы безнең буынның җанына, бөтен яшәү-тереклек итү рәвешенә сеңгән: *«Бездә бераз дуамаллык, / Бераз баламишкинлык» («Син, әлбәттә, бездән акыллырак», 1971).* Әлеге бунтарьлык – безнең канда: *«Син – теләп алган сагышым, / Син – теләп алган ярам. /Туеп кем дә китәр, ә син – / Яратып китеп кара! (1971) «Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык! / Героинялар көтте урамда.../ Шундый тансык бөек тилерүләр / кануннардан каткан дөньяда! («Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык! 1971).*

Шагыйрь безнең буын яшәп узган чорның иң зур фаҗигасен ачып, үзенең иң яхшы шигырьләреннән берсе «Уен» (1971) шигырен яза:

*«Борынгы уен дигәч,*
*ырымлы уен дигәч,*
*ләззәтле, тәмле дигәч,–*
*нигә кермәскә дидем,*
*уенга барып кердем.*
*Авыз ачып калмаска,*
*кешедән калышмаска!»*

Иң фаҗигале өлеше – шигырьнең азагы:

*«Туктыйм инде дип уйлыйм.*
*Үзем уйлыйм, үзем туймыйм.*
*Бүтәннәр юри уйныйлар,*
*мин, юләр, чынлап уйныйм.*
*Барсын беләсе килә,*
*кайчак көләсе килә.*
*Уендашлар шаркылдыйлар,*
*миңа күз яше килә...*
*Бу әллә нинди уен!»*

Әлбәттә, бу – шәхси фаҗига гына түгел, илебездәге Брежнев заманы җәмгыятенең бөтен рухи фаҗигасен, хәер, нигә ул чор гына булсын, шул исәптән безнең заманның да, димәк, кешелек тарихының бөтен фаҗигасен шагыйрь шушы кыска шигыре канвасына сыйдыруга ирешкән!

Бөтен хикмәт шунда, шагыйрь үз шәхесе кысаларына сыеп кына яши алмый. Аның «мин» дип сулаган сулышы да үзенеке генә була алмый.

Шуңа аңа *«Космополит түгел. Шөкер, / халкым да бар, ил дә, Ватан да» дип авыз тутырып әйтү хокукы да («Космополит түгел...» 1969-1970)*, иң тирәндә аккан кичерешләре белән ялгыз калып бер сүз дәшмәү хокукы да бирелгән: *«Монда вәхшәт эзе тирән, / мыскыллаулар – сүздән түбән. / Суда ухылдап чайкала / ярда бәйләнгән көймәм...» («Болгарда төн», 9-10 март 1971, Әлмәт).*

Аның бары тик картлыгы гына үзенеке дип әйтмәкче идем дә... Әлеге юлларны укыгач, тукталып калдым*: «Бәрәкәтсез гомер, аһ, сүтелә!» / Вакыт белән дуэль. Ни чара? / Бу таңнарны күбрәк күргән саен / күңелне ник моң һәм шом сара? / Янарга да, батарга да риза / эштә, өйдә, идеалларда... / Барыбер килә, күзләр аша килә олыгаю, / күзләр аша, – авыр аларга...» («Бер бөтерелеп без дә яшәп алдык...»1971)*

Юк, шагыйрьнең картлыгы да, үлемсезлеге дә, бәхете-бәхетсезлеге дә үзенеке генә була алмый икән ләбаса!

***

Шагыйрьнең җитмеш елга якын сузылган киеренке иҗат гомере, табигый ки, салынган бер эздән, көйләнгән бер моң белән тигез генә акмый. Һәр тарихи чорның үз таләбе, кеше яшәешенең үз ихтыяҗы дигәндәй, иҗат этаплары да бер-берсен

һич кабатлый алмый: һәрберсенең үз хасияте – үз йөзе: үз шатлыгы – үз борчуы, үз табышы – үз югалтуы бар. Р.Фәйзуллин иҗат эволюциясен биредә укучыга шундый аерым өч этап-чорга бүлеп тәкъдим итү урынлы булыр кебек.

Беренчесе – шагыйрьнең кулга каләм алуыннан 1971 елга кадәр сузылган гаять киеренке һәм нәтиҗәле поэтик иҗат чоры. Авторның шигъри фикерләү үзенчәлеге һәм әлеге беренче чор иҗаты әсәрләре хакында алда шактый җентекле анализ ясалды.

Моннан соңгы – 2000 нче елларгача дәвам иткән икенче иҗат чоры шагыйрьнең башлыча киң җәмәгатьчелеккә танылуы белән бәйле. Бу чорда Р.Фәйзуллинның иллеләп китабы, шул исәптән биш томлык «Сайланма әсәрләре» (1992–2001) дөнья күрде. Шуларның дистә ярымы рус телендә. Болардан тыш аерым әсәрләре алман, гарәп, инглиз, поляк, француз, төрек, эстон, үзбәк, грузин һ.б. телләргә дә тәрҗемә ителә. Аның шигырьләре ике йөз томлык «Бөтендөнья әдәбиятлары китапханәсе» сериясендә чыккан томлыкта (180) урын алган.

Шагыйрьнең әсәрләре күп мәртәбәләр төрле дәрәҗәдәге премияләр, аерым алганда: 1970 елда «Мәрмәр» исемле китабы өчен Республика яшьләр оешмасының М.Җәлил исемендәге премиясе, 1973 елда «Дружба народов» журналы һәм 1979 елда «Литературная Россия» газетасы премияләре белән бүләкләнә. 1978 елда ул «Шигырьләр һәм поэмалар» китабы (1976) өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Автор республикабыз шигырь сөючеләр арасында гына түгел, киң җәмәгатьчелектә, союз буенча һәм дөнья күләмендә танылу ала. Биредә шагыйрьнең бу чордагы эчке дөньясын күзалларга ярдәм иткән – безнең алдагы темага турыдан-туры караган бер истәлек-вакыйганы искә төшереп үтик. Ул әдәбият галиме Нурмөхәммәт Хисамов мәкаләсендә чагылыш таба.

Казан университетының татар бүлеге 1969 елда үзенең 25 еллыгын бәйрәм иткәндә, Р. Фәйзуллин исеменнән дә котлау телеграммасы килеп төшә. Анда: «Мин дөньяның кайсы читендә булсам да, кемнәр белән генә аралашсам да, университетның татар бүлеген тәмамлавым белән горурланам», дип язылган була. Галим моңа түбәндәгечә бәя бирә: «Бердәм совет халкы төзибез дип, милли телләрне кысрыклау, татар теленең абруен ясалма рәвештә төшерү еллары иде бу. Карьерасы үргә юнәлгән шөһрәтле җәмәгать эшлеклесенең әлеге сүзләре шул рәвешчә туган телне, халык мәдәниятен яклау булып яңгырады. Бу аның затлы гражданлык гамәле иде. Чөнки ул елларда туган телгә битарафлык карьера чарасына әверелгән иде»[12].

Шагыйрьнең әлеге чор иҗаты һәм эшчәнлеге – Татарстанның суверенитет яулап алган киеренке көрәше елларына туры килә. 1990–1995 елларда Р.Фәйзуллин Татарстан Югары Советы депутаты буларак, республиканың мөстәкыйльлеген, дәүләтчелеген яклауда актив эш алып бара. Бу елларда ул әдәбият, сәнгать, иҗтимагый тормыш мәсьәләләренә, сәясәткә багышланган бик күп әдәби-публицистик мәкаләләр, эссе-уйланулар, новелла-парчалар, каләмдәшләренең һәм сәнгатькярләрнең иҗат портретларын, чит илләргә иҗат командировкалары, сәяхәтләре турында юлъязмалар яза. Үткән гасырның җитмешенче-сиксәненче елларында шагыйрь язучыларның илкүләм узган күп кенә съездларында делегат булып катнаша, берничә мәртәбә СССР һәм РСФСР Язучылары берлегенең идарәсенә сайлана.

Р.Фәйзуллинның иҗат гомере «Казан утлары» журналы белән тыгыз бәйле. Язучыларның әлеге төп журналында ул чирек гасырга якын баш мөхәррир вазифасын башкарып килде.

1999 елда Татарстан Президенты М.Шәймиев Указы белән аңа «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән исем бирелә.

Элеккеге накалда ук булмаса да, әлбәттә, бу чорда әдип шигъри әсәрләр язуын да

[12] Н. Хисамов. Тирән хакыйкатьләр дөньясы // Равил Фәйзуллин. Заман. Иҗат. Шәхес. – Казан: «Мәгариф» нәшр., 2002 –197 бит.

дәвам итә («Кем шакымас толлар ишеген...», 1971, «Яшәсен!», 1972, «Әйләнә сәхнә, әйләнә», 1973, «Иясез шатлык», 1982 һ.б.).

Аның үзенә генә хас үткен һәм афоризм рәвешендә белдерелгән гомумиләштерүләр белән истә калган хикмәтле шигъри энҗе бөртекләре дә әледән-әле ялтырап китә:

*Әнкәләрне санламаучы*
*Сантыйлар да җитәрлек.*
*Бездә шигырь аңлаганга –*
*Башың Себер китәрлек!*
(«Шигырьне укымыйлар... дип...» 1988)

Бу чорда автор үзенең киң катлам укучыларга яхшы таныш булган күләмле «Сәйдәш» (1978–1980) һ.б. поэмаларын яза.

Шагыйрьнең өченче чор иҗаты яңа гасыр башыннан бүгенге көннәргәчә дәвам итә. Шагыйрь иҗатында бу этап Татарстанга мөстәкыйльлек вәгъдә иткән Конституциянең берәм-берәм юкка чыга барган елларга туры килә. Иҗатында әдипнең төп коралы поэзия жанрының торган саен активлаша баруы да очраклы түгел, әлбәттә. Ул шигырьләр авторның «Яңа гасыр иртәсе» дип исемләнгән яңа китабында басылып чыкты[13]. Аларның кайберләренә күз салып узу укучыга да кызыксыз булмас дип уйлыйм.

Менә аның Ахырзаман мөнәҗәте стилендә язылган «Килде бу көн...» (2001) шигыреннән кайбер өзекләр:

*Килер бер көн:*
*Мөтәгаллим «академиклар» йөрер төркем-төркем.*
*Гамәлләрен аңламас беркем.*
*Милләтнең күбәер «ата-аналары».*
*Туган телдә сөйләшмәс балалары.*
*Идарәгә менәр угрылар –*
*Алдап җыйган малга тугрылар.*
*Закон өстендә закон булыр, указ өстенә указлар,*
*Берсен-берсе бетерешеп бугазлар.*

Әсәргә комментарий биреп тору кирәк түгел кебек – яшәп үткән соңгы чирек гасыр көнкүрешебездә мондый типик хәлләрне без аз күрмәдек. Шундый ук таныш хәлләр һәм замандашлар белән авторның башка шигырьләрендә дә очрашабыз. Аерма тик шунда – болары икенче сфера яшәешенә карый:

*«Төшкән тешләр кебек йортлар кимеп бара.*
*Беренче сыйныфта быел ике бала».*
*«...Тыкрык чатында әйтте сәрхуш түтәй:*
*«Авыл – кабыгы сау, эче аккан күкәй...»*
(«Хәлең ничек, авыл?», 2002).

Шагыйрь кайчакта хыялында йөрткән Ватанны «күңелдә янәдән яңарта» («Тыңлап ятам сандугачны», 2014), киләчәккә яңа стратегик планнарын сыза, бүгенге көнгә бәйле кайгы-шатлыкларын барлый, үз лирик героеның мәңгелек белән тоташкан шигъри үлчәм-бөтенлеген күзаллый:

*Әйтер сүзләр әкренләп бетә.*
*Булды заман, әйттек ихласын.*
*...Күз яшьләре кипте... яңгыр булып*
*хәзер инде еллар еласын.*
(« Әйтер сүзләр...»)

**Равил РАХМАНИ,**
*әдәбият галиме.*

[13] Равил Фәйзуллин. Яңа гасыр иртәсе. – Казан: Татар. кит., нәшр., 2014.

*ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов (алгы планда уңнан икенче) Татарстан китап нәшрияты бинасындагы китаплар күргәзмәсендә. Аның янәшәсендә (сулдан уңга): Роберт Миңнуллин, Дамир Шакиров, Равил Фәйзуллин. 2013 ел.*





*Равил Фәйзуллин музей-салонының бер күренеше. Балык Бистәсе районы, Балтач (Юлсубино) авылы. 2023 ел.*



*Музей ачылышына килгән каләмдәшләр. Сулдан уңга: Зиннур Мансуров, Илсөяр Иксанова, Равил Фәйзуллин, Газинур Морат. 2023 ел.*



*Равил Фәйзуллинның туган йортына Чаллы шәһәре язучылары делегациясе килгән. 2023 ел.*



*Равил Фәйзуллин әтисе (уртада) һәм туганнары белән.*



*Оныгы Чулпан дәү әтисенең шигырен укый, улы Газиз саксофонда уйный. Язучылар Үзәк йорты. Мәскәү. 2013 ел.*



*Равил Фәйзуллинның килене Алия һәм улы Алмаз балалары Чулпан, Ильяс, Камил белән. 2015 ел.*



*«Фәйзуллин йөзүләре» быел 45 нче мәртәбә Биектау районындагы Чулпан күлендә үтте.*

*Фотолар Равил ФӘЙЗУЛЛИНның шәхси архивыннан алынды.*

# «УТ БӨТЕРЧЕГЕ»



Татарстанда нефть чыгару яки эшкәртү мәсьәләләренә кагылышлы хөкүмәт уздырган, республика Рәисе үткәргән утырышларда аның чыгышлары, ул тәкъдим иткән ноу-хау технологияләр һәрвакыт зур кызыксыну уята. Фәнни конференцияләрдә ул – гамьле әңгәмәләр һәм бәхәсләрнең, журналистлар игътибарының үзәгендә тора. Әйтик, аның «Базар мөнәсәбәтләренә карамыйча, ничек итеп нефть эшкәртүне файда китерә торган тармакка әйләндерергә» дигән докладазы авыр нефтьне эшкәртүдән калган калдыкларны файдалануга багышланган иде. Галим фикеренчә, җитештерү «ноль сумга» төшә торган «сыек кокс» металл коючылар өчен ташкүмергә альтернатива була ала, ул энергетика өлкәсендә дә зур файда китерергә сәләтле. Галимнең, техник крекинг турында сөйләгәндә, нефть калдыкларының «тере, җанлы» булуын телгә алуы, җайлап кына шахмат терминнарын куллануы – үз эше белән чын мәгънәсендә янып яшәүче, иҗат кешесе булуын күрсәтә. Гомумән алганда, Казаныбызга килгән саен ул Татарстанның – авыр, кушылмалы нефтьләр эшкәртү ягыннан дөньякүләм алдынгы үзәккә әйләнә алачагын сөйли. Бер үк вакытта үзе – Татарстан нефтьчеләренең иң беренче конкуренты да.

Сүзебез – Башкортстан Республикасы нефтехим-эшкәртү институты «Нефтехимэшкәртү» фәнни-сәнәгать оешмасында (НПО) генераль директор урынбасары – фәнни җитәкче Илшат (Эльшад) Гомәр улы Теләшев хакында. Техник фәннәр докторы (1992), профессор (2008), Башкортстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы (2009), Россия Федерациясенең (2014), Башкортстан Республикасының (2006), Казакъстан Республикасының (2010) атказанган фән эшлеклесе, Россия энергетика министрлыгының Экспертлар советы әгъзасы, Россия Нефть эшкәртүчеләр һәм нефтехимиклар ассоциациясе идарәсе әгъзасы, бик күп дәүләт бүләкләре иясе ул.

Илшат Гомәр улы 1956 елның 21 ноябрендә Уфа шәһәрендә туган. Кечкенәдән җитез, зиһенле, үзеннән өлкәнрәк малайларны да үз артыннан ияртергә сәләтле «ут бөтерчеге» Илшатны гадәти булмаган һәр нәрсә үзенә җәлеп итә. Һәр нәрсәнең төбенә төшәргә, сәбәбен табарга омтылганнар гына фәнне сайлый һәм шул юлда зур уңышларга ирешә! Фән юлы исә аңа үз исеменә тугры булып яшәргә мөмкинлек бирә.

Олы улы үскән саен әтисе Гомәр Гариф улы Теләшевнең да язмышы ил йөрәгенә языла, аны нефтьче-галимнәр династиясенә нигез салучы итеп таныта бара.

Гомәр Теләшев 1931 елның 13 декабрендә Башкортстанның Дәүләкән районы Имай-Карамалы авылында – Башкортстанда 1932 елның маенда беренче нефть фонтаны бәргән 702 номерлы скважинадан якын гына урында туган. Төбәкнең нефть республикасы булачагын хәбәр иткән легендар урында яшәп, республикада җәелә барган нефть чыгару һәм эшкәртү процессына кушылмый калу мөмкин булмас иде. Шулай килеп чыга да: кечкенәдән тырыш, кызыксынучан, зирәк малай-егетне Башкортстан җиренә яңа сулыш өргән нефть сәнәгате үзенә тарта.

Ерак бабалары да Идел буеннан Көньяк Уралга буш җирләр кирәккә генә түгел, яңа

дөньялар эзләп күчеп килгәннәр. Нәсел-ыруга атама биргән Теләш баба исеме ике мәгънәви йөкләмәгә ия: борын заманнарда озак көттереп дөньяга килгән ир балага шул исем кушылган, яки мәҗүси чорларда ыруда теләк теләүче – рухи йолалар үтәүче, үз сүзенә ышандыру, үз артыннан ияртү көченә ия нәсел дәвамчылары шундый ат ала торган булган. Теләшевларны якыннан белгән кешеләр икенче версияне яклар. Чын мәгънәсендә якты карашлы, башкаларны да зур эшләргә илһамландыра ала торган, сүзләре белән дә, эшләре белән дә юл ярып баручылардан, тормышны яхшы якка үзгәртү мөмкинлекләрен белүчеләрдән алар.

1950 елда, мәктәпне тәмамлап, инженер-нефтьче булу хыялы белән Гомәр Теләшев Уфага килә, Уфа нефть эшкәртү заводына эшкә урнаша. 1954 елны – оператор, аннары өлкән оператор, АВТМ-1 җайланмасында җитәкче баскычларын уза.

Шулай килеп тә чыга: 1959 елда ул җитәкләгән коллектив җайланманың регламент буенча билгеләнгән ремонтка кадәр эшләү срогын өч айдан – 20 айга җиткерә. Бөтенсоюз рекорды була бу. Гомәр Теләшев инициативасы белән башкарылган технологик җиһазлар реконструкциясе аларның куәтен ике тапкыр арттырырга мөмкинлек бирә. Коллектив исә «Алдынгы комсомол-яшьләр бригадасы» дип атала, соңрак Башкортстанда беренче коммунистик хезмәт коллективы булып танылa.

Аларның уңышлары илкүләм яңгырый, республика данын еракларга тарата. Үзләре дә югары бәя ала: 1960 елның 28 маенда СССР Югары Советы Президиумы Указы белән Гомәр Теләшевка Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә. Бу вакытта аңа – 29 яшь. Кремльдә «Алтын Йолдыз»ны һәм Ленин орденын легендар маршал Семён Будённый тапшыра. Коллективның тәҗрибәсе исә 1964 елны ГДРда нефть эшкәртү заводын сафка тапшырганда, уңышлы кулланыла.

1962 елны Гомәр Теләшев эштән аерылмыйча Уфа нефть институтының технология факультетын тәмамлый. Күпләгән рационализаторлык тәкъдимнәре белән чыга торган, фәнни-тикшеренүгә тартылган ир-егетне ректификация фәнни-тикшеренү лабораториясен җитәкләргә чакыралар. Күп тә үтми, 1967 елдан ул тәҗрибә-тикшеренү цехына рәис итеп билгеләнә. Шушы цех Яңа-Уфа НПЗсының эре фәнни-технологик үзәгенә – Идел-Урал буенда нефть чыгару һәм эшкәртү өлкәсендә иң яңа технологияләр булдыру мәйданына әверелә.

Әлбәттә, бу уңышларда Гомәр Теләшевнең үзенең фән белән шөгыльләнүе хәлиткеч роль уйный. Ул башта – кандидатлык, 1993 елда докторлык диссертациясен яклый. 300 фәнни хезмәт, китап һәм монографияләр авторы, 100 дән артык уйлап табулары авторлык таныклыклары һәм патентлар белән расланган галим укыту, тәҗрибә алмашуга да вакыт таба: УГНТУда нефть һәм газ эшкәртү технологияләре кафедрасында профессор буларак хезмәт куя. Казанышлары өчен Фән һәм техника өлкәсендә Россия Федерациясе хөкүмәте премиясе лауреаты, «Башкортстан АССРның атказанган уйлап табучысы», «Башкортстан АССРның атказанган химигы», «Россия Федерациясенең мактаулы нефтьчесе» һ.б. шәрәфле исемнәргә лаек була.

1998 елны Гомәр Теләшев «ИНТЭКО» нефтехимия инженерлык үзәген оештыра һәм җитәкли. 2004 елдан нефть химиясе буенча Проект-технология институтының генераль директоры була. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул үзе сайлаган юнәлештә эшләүдән туктамый. Гомәр Гариф улы гомере буе ил һәм кешеләр тормышын яхшыртуны кайгырта – иҗтимагый эшчәнлек белән шөгыльләнә: күп тапкырлар җирле үзидарә депутаты була, Башкортстанның ветераннар советында эшли, махсус гыйльми советларга сайлана һ.б. Замандашлары хәтерендә Гомәр Гариф улы – тирән белемле, уникаль белгеч, тынгысыз, тырыш хезмәт кешесе, кешеләргә игътибарлы, ихтирамлы шәхес булып яши. Хатыны Фәвидә Гомәр кызы белән алар 3 ул тәрбияләп үстерәләр. Аларның икесе әтиләре юлыннан китә: нефть химиясе фәнен гомерлек һөнәрләре итеп сайлый. Бүген инде нефтьче-галимнәр династиясенең өченче һәм дүртенче буын Теләшевлары бабалары юлын лаеклы дәвам итә. Аларның алтысы – гыйльми дәрәҗәләр алган галимнәр булуын да әйтергә кирәк.

Озакка киткән сүзебез – Гомәр Теләшевнең олы улы турында иде бит! Илшат исемле

егет, 62 нче мәктәпне тәмамлап, Уфа дәүләт нефть техник университетына (УГНТУ) «Нефть һәм газны эшкәртүнең химик технологиясе» белгечлеге буенча укырга кергән. Һәр җәйне студентларның төзелеш отрядларында эшләгән, спорт, туризм, комсомол эше белән шөгыльләнгән, институттагы үзешчән җыр клубын җитәкләгән Илшат әйтерсең лә «музыка белән химияне» бер уртак юлга әйләндереп барырга омтыла. Ул 1983 елны – кандидатлык, 1992 елны – әтисенә кадәр үк өлгереп – докторлык диссертацияләрен яклый.

«Органик химия» кафедрасында эшкә калып (1979), институтта профессор, лабораторияләр мөдире баскычларына җиткән, Уфа азтоннажлы нефтехимия сәнәгате тәҗрибә заводында (УОЗ МНХП) директор (1997–2004), «Нефтехимэшкәртү» фәнни-сәнәгать оешмасында (НПО) генераль директор (1997–2006) булып эшләгән Илшат Теләшев 2012 елны Башкортстан Республикасы Президентының нефть чыгару, эшкәртү һәм нефтехимия буенча Киңәшчесе итеп билгеләнә. Бу юнәлештә республика сәясәтен билгеләүчегә әйләнә. Уфа шәһәр советы депутаты (2004–2008), Иҗтимагый палата әгъзасы буларак та, әтисе кебек үк, Башкортстан халкы тормышын яхшыртуга үзеннән зур өлеш кертә. Бүген ул – Башкортстан Республикасы хөкүмәтенең  Экспертлар советы әгъзасы.

Илшат Гомәр улы – 650 дән артык фәнни хезмәт, 170 патент иясе. Аның фәнни хезмәтләре нефтьне калдыкларсыз тирәнтен эшкәртү технологияләре булдыру, нефть эшкәртүче һәм нефтехимия предприятиеләренең калдыкларын утильләштерү, полифункциональ технологик ягулык-майлау материаллары булдыру һәм аларны сәнәгать җитештерүенә җиткерү кебек мәсьәләләр белән бәйле.

Татарстан, Башкортстан, Казакъстан, Себер, башка урыннарда табыла торган төрле кушылмалар белән «авырайган» нефть – озак еллар дәвамында чыгарырга да, чистартырга да җайсыз, түбән сыйфатлы җир мае буларак бәяләнеп килә. Әмма табылган «җиңел» нефть күләме елдан-ел кими, бу тармак кушылмалы җир мае чыгаруны арттырганнан-арттыра бара. Нәтиҗәдә җир өстенә күтәрелгән нефть калдыклары да елдан-ел күбәя. Киләчәккә фаразлар Идел-Урал буенда мондый үзгәрешләрнең дәвам итәчәге турында сөйли.

И.Г.Теләшевның күпсанлы фәнни хезмәтләре, төрле дәрәҗәдәге җыеннарда яки конференцияләрдәге чыгышлары исә бер фикерне дәлилләүгә хезмәт итә: әлеге кушылмалар үзләре дә – бик кадерле, бик кирәкле байлык, алар кешегә нефтьнең үзе кебек үк файдалы, халык хуҗалыгының күп кенә өлкәләрендә кирәкле чимал була ала! Алар металл эретүдә дә, ягулык рәвешендә дә, өр-яңа продукция эшләүдә дә арзанлы һәм алыштыргысыз! Аның уйлап тапкан, тәкъдим иткән технологияләре шуны раслыйлар, куллану мөмкинлекләрен күрсәтәләр.

Илшат Теләшев җитәкчелегендә Волгоград, Уфа, Салават, Нарьян-Мардагы эре промышленность үзәкләрендә, шулай ук Румыниядә төзелгән коксны кыздыру, күкерт һәм битум җитештерү, гудроннарны таркату, нефтьне күкертле водородтан арындыру җайланмалары фәннең шушы юнәлеше ачышларын сәнәгатькә – димәк, тормышка, көнкүрешкә – алып керәләр. Бер яктан, бу технологияләр нефть һәм газ эшкәртүдә, бу процесс вакытында моңа кадәр кирәксез саналган калдыкларны файдалануда өр-яңа сүз булып чыгалар. Икенче яктан, алар нефть һәм газ эшкәртүне, нефть һәм газ химиясе сәнәгатен экологик чиста, зыянсыз, калдыкларсыз процесс итеп корырга ярдәм итәләр. И.Г. Теләшевның әлеге гыйльми күзаллавы Башкортстан Республикасы «Нефтехимэшкәртү» фәнни-сәнәгать оешмасын иң алдынгы үзәкләрнең берсенә әйләндерә.

Фәндәге үсеш бары тик фәнни мәктәпләр – тикшеренүләрне дәвам итеп китәрлек дәвамчылар-укучылар булдырып кына тәэмин ителә. Шуны аңлаган галим, гыйльми-тикшеренү һәм җитештерү тармагында тулы көчкә хезмәт кую белән бергә, беркайчан да вузда укыту эшен читкә куймый! Ул – үзе белем алган УГНТУда «Химик-технология институты» директоры, шушы ук вузда «Газ химиясе һәм химик-технологик процессларны модельләштерү» кафедрасы мөдире, Башкортстанның, Казакъстанның, Россиянең аерым төбәкләренең уку йортларында билгеле лектор, яшь белгечләр

әзерләүче фәнни җитәкче дә. Аның кандидатлык диссертациясе яклаган 14 укучысы да шушы фәнни мәктәпне үстерүне дәвам итәләр.

И.Г.Теләшев катнашында булдырылган технологияләр Россиянең нефть эшкәртү предприятияләрендәге 150 сәнәгать объектында кулланыла. Шулар арасында Татарстан сәнәгать оешмалары да бар. Мисалга, Түбән Камада, «ТАНЕКО» АҖдә урнаштырылган иң заманча кокслаштыруны акрынайту җайланмалары ел саен 2 млн тонна җитештерү көченә ия; шул ук предприятиедәге гудрон висбрекингы җайланмасының көче – елына 2,4 млн тонна; шул ук шәһәрдәге окислаштырылмаган (калдык) битумнар эшкәртү җайланмасы, яки «коры» вакуум-тудыручы мазут куалау җайланмасы; майларны катнаштыру, каты май ясау җайланмасы – шәһәрдәге генә түгел, илдәге нефть химиясе тармагының горурлыгы. Нурлаттагы парафиннар сыекчасы булдыру җайланмасы, шулай ук АТ-80, Шөгердәге АТ-100, Түбән Камадагы АВТ-6000 җайланмалары да шундыйлардан.

Гомумән, Илшат Гомәр улының җитезлеге, активлыгы таң калдыра. Мәктәптә укыганда ук класс комсоргы, университетта – студентлар төркеме комсоргы, үзешчән җыр клубы президенты булган егет 1974–1987 елларда студентларның төзелеш отрядларында: А.Матросов ис. «Технолог» отрядында сугышчы, бригадир, комиссар; «Красная гвоздика» интернациональ лагеренда (Павловка) комиссар; «Дружба» интернациональ төзелеш отряды (ГДР, Мерзебург) командиры, «Красная гвоздика» интернациональ лагерь (Нефтекама) командиры баскычларын уза. Бу юл аны коллективта уртак максатка ирешү өчен бердәм һәм бер ритмда эшләү серләренә төшендерә, башкалар өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга өйрәтә, туктаусыз хезмәттә, иҗтиһадта, иҗатта, фикердәшләр арасында кайнарга күнектерә.

Аның Уфада «Белый ворон» авторлык җыры клубын оештыручы һәм аның җитәкчесе (2005 елдан), «Агыйдел», «Малиновый аккорд», «Арский камень» җыр фестивальләрен оештыручы булуын, Башкортстанның гүзәл табигатен, театр һәм җыр-музыканы, китапны, мәдәният-сәнгать тарихын яратучы икәнлеген дә искә алганда, бу шәхескә энергия, көч-куәт, хис-кичерешләр байлыгы каян килә икән дип уйлап куясың! Эстет, энциклопедик белемле галим, талант иясенең, чыннан да, үз рухи-фәлсәфи дөньясында бер-берсеннән бик ерак торган ике өлкәне: технологияләр һәм иҗатны куша, тоташтыра алуы гаҗәпләндерә дә, сокландыра да.

Бәлки, аның җитезлегендә, ташып торган энергиясендә, башкаларны үз артыннан ияртү сәләтендә яраткан гаиләсенең һәрдаим янәшә булуының, эш белән яшәвен аңлап, ярдәм итеп торуының да роле зурдыр. Хатыны Гүзәл Җәүдәт кызы да – техник фәннәр кандидаты, УГНТУ доценты; ул Илшат Гомәр улы белән бер фәнни мәйданда эшли. Ике кызлары бар: Айгөл – укыту, фәнни тикшеренү юлын сайлаган, Диләрә исә – журналист.

Йөзләгән фәнни хезмәтләр язган, ачышлар ясаган, Россиянең нефть тармагында өр-яңа нефть һәм газ эшкәртү технологияләре булдырган, нефть табу һәм эшкәртү объектларына экологик һәм җитештерү куркынычсызлыгын тәэмин иткән методлар уйлап тапкан Илшат Гомәр улының тормышы һәм эшчәнлеге – татар дөньясы өчен үрнәк, горурлыктыр. Мондый көчле нәселләр, мондый затлы династияләр – туган җиребезнең иң олы, җир маеннан да кыйммәтлерәк байлыгы бит!

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы.*

**Редакциядән:** *Илшат Гомәр улы Теләшев Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы итеп сайланды! Котлыйбыз, яңа гыйльми һәм иҗади уңышлар телибез.*

# «КУРАЙ БУЛЫП КАЙТЫРМЫН...»

## РОБЕРТ МИҢНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Әнкәй турындагы күңелгә ятышлы бу җырларны бездә белмәгән кеше юктыр:

*«Әнкәй безне Сөннән алып кайткан,*
*Сөн суында юган иң элек...»*

Яисә икенчесе:

*«Ташлама, әнкәй, ташлама*
*Мине изге догаңнан!*
*Ташласаң изге догаңнан*
*Мин бәхетле булалмам...»*



*Роберт Миңнуллинда кунакта. Казан, 2017 ел.*

Әйе, бу җырларны тыңлап, хәзер инде берничә буын үсте. Мәктәптә укыганда, әнкәй турында нинди җыр беләсең дип сорасалар, тап шуларны хәтергә төшерер идем. Кызык бит ул тормыш. Ул чакта авторы кем дип уйланган да юк иде. Еллар үткәч, шул юлларны язган атаклы замандашыбыз, Татарстанның халык шагыйре, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Роберт Миңнуллин икәнен белеп, үземә зур ачыш ясагандай йөрермен. Алай гына да түгел, Роберт агай белән якыннан аралашырбыз, фикердәш, рухташ булырбыз дип кем уйлаган?!

Роберт агай Миңнуллинны студент чакта ук күрергә насыйп булды. Ул елларда якташыбыз Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе урынбасары буларак, Уфадагы байтак әдәби-мәдәни чараларда катнаша торган иде. Мостай Кәримнең вафатына бер ел тулу уңаеннан Башкорт дәүләт академия драма театрында уздырылган хәтер кичәсенә дә килгән иде. Роберт агайның андагы чыгышын без йотлыгып тыңладык. Сәхнәдән әйткән сүзләре әле дә булса хәтердә:

«Мостай чынлап та хикмәтле исем. Аның төп нигезендә безнең «оста» дигән бик мәгънәле сүз ята. Тел остасы, шигырь остасы! Мостай исеменә «ай» сүзе дә яшеренгән. Аның «Ай тотылган төндә», «Айгөл иле» дигән драмасы да шул сүз белән башлана. Ул үзе дә ай йөзле, ай кебек нурлы булды. Мостай исемендә «тай» дигән сүз дә ыргылып тора. Ул олы яшендә дә тай шикелле ярсу, яшь тай шикелле йөгәнсез һәм иярсез иде. Аңа беркем дә йөгән кидерә алмады, аны беркем дә иярли алмады. Мостай сүзендә «ос» дигән башкорт сүзе дә бар. Аксакалның бөтен гомере очу белән бәйләнгән иде. Бөркетләр кебек биектә очты. Тагы «мост» дигән рус сүзе дә бар. Мост – күпер! Ул иҗаты белән күпме халыкларга, күпме күңелләргә күпер салды!»

Шәп чыгыш ясады шагыйрь! Роберт Миңнуллин сөйләп бетергәч, халык гөр килеп кул чапты! Мин, ул чакта БДУның беренче курс студенты, үткер сүзле якташыбызның әйткәннәрен күңелемә сеңдереп утырдым. Шулай булмаса, хәтердә калыр идеме?!

Ә инде Роберт Мөгаллим улы белән якыннан танышу 2015 елда Казанда булды. Анда

Төрки дөньяның яшь язучылары җыены үткән иде. Чарага төрле республикалардан, илләрдән абруйлы әдипләр дә чакырылган. Шул кунаклар арасында Роберт агайны күреп калдым. Шунда китап сату да оештырылган иде. Форсаттан файдаланып, якташыбызның «Мыек астынан гына...» дигән юмористик китабын сатып алдым да янына йөгердем.

– Агай, мин Уфадан килгән идем. Айгиз Баймөхәммәтов булам. Шушы китапка автограф куйсагызчы...

Роберт агай ихлас елмаеп куйды:

– Ә-ә-ә, Айгиз дигәннәре, димәк, менә кем. Гәзиттән укып барам үзеңне. – Бу сүзләрне ишеткәч, түбәм күккә тигәндәй тоелды. – Ә нигә китабымның шул хәтлем калынын алдың? Уфага алып кайту авыр була бит...

– Роберт агай, сезнең китапларыгыз безнең өчен беркайчан да авыр түгел. – Шагыйрь миңа карап, мут елмаеп куйды:

– Ну, телгә беткәнсең, дустым.

Агай тиз генә теләкләрен язып, китапны миңа сузды.

«Айгиз якташым! Укып барам, шатланам! Яшь чакта язып кал! Иң изге теләкләр белән – Роберт агаң.» Шул очрашуда танышуга канатланып, үземнең беренче китабымны да, матур сүзләр язып, аңа бүләк иттем.

2015 елда Башкортостанның Язучылар берлеге мине Шәехзадә Бабич исемендәге Дәүләт яшьләр премиясенә тәкъдим иткән иде. Шул вакытта «Кызыл таң» гәзитендә Роберт Миңнуллинның минем хакта ихлас язылган мәкаләсе дә дөнья күрде. Халык шагыйре хуплап, тәүге әсәремә карата җылы сүзләрен язган. Бу, әлбәттә, минем өчен көтелмәгән яңалык булды.

«Минем кул артым җиңел ул. Шуңа хуплау сүземне язарга булдым» – диде телефоннан сөйләшкәндә.

Ахырдан шул ук мәкаләне Казанда чыккан публицистик китабына да иңдерде. Нинди генә уңышларга ирешсә дә, кешелекле һәм яшьләргә ихтирамлы булуы белән дә кадерле иде ул.

Белүебезчә, Роберт агай чыгышы белән Илеш районыннан. «Илеш минем туган җирем генә түгел, Илеш – минем бабам да. Әйе, әйе, нәкъ шулай. Тарихи чыганакларга, авылдаш картлар калдырган мәгълүматларга караганда, минем шәҗәрәм Илеш исемле бабамнан (Илеш авылына нигез салучы) башланып китә!» – дип язган иде ул «И газиз якташларым!» китабында.

Роберт Мөгаллим улы, тәү чиратта – искиткеч талантлы балалар шагыйре. Аның кечкенәләр өчен кызык шигырьләре үзенән-үзе ятланып тора, алар җиңел, хәтердә тиз кала. Бу юктан гына түгел. Шагыйрь үзе һәр шигырьне балаларның эчке психологиясен аңлап, аларча уйлап иҗат иткән. Шуңадыр да аның иҗаты совет чорында ук югары бәяләнеп, һәр китабы йөзәр мең тираж белән ил буйлап таралган. Аның китаплары бихисап телләргә тәрҗемә ителүе дә – моңа ачык дәлил.

Янә Роберт Миңнуллинның әнкәйләр турында иң күп язган шагыйрь буларак даны бар. Әйе, аның бик күп үзәккә үтәрлек әсәрләре газиз әнкәсе – Гөлҗәүһәр апага багышланган.

Гөлҗәүһәр апаның язмышы җиңелдән булмаган. Кечкенәдән үзе балалар йортында тәрбияләнгән. Яшьли тол калып, ялгызы биш баланы аякка бастырган. Ялгыз хатын биш бала белән ниләр күргәнен, йокысыз төннәрдә ниләр уйлаганын үзе генә белгәндер. Җырга әйләнгән шигырендә шагыйрь үзе болай дип яза:

*«Без биш бала үстек әнкәй белән,*
*Тик үсмәдек иркә кочакта.*
*Без әнкәйнең биш шатлыгы идек,*
*Биш кайгысы булдык кайчакта».*

Миңнуллиннар гаиләсендәге биш бала да тормышта үз урынын таба. Роберт агай – Татарстанның халык шагыйре, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты дәрәҗәсенә ирешә, күп еллар Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Рәис урынбасары була, Ким Мөгаллим улы – филология фәннәре докторы, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының директоры, Татарстан фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы. Гөлҗәүһәр апаның өч баласы исә – Фән, Рим, Люция – укытучы һөнәрен сайлап, гомерләрен белем бирү хезмәтенә багышлаган.

Шуңа да Роберт Миңнуллинның әнкәсенә чиксез рәхмәте, мәхәббәте – аның бөтен иҗатында төп урыннарның берсен биләп торды.

Роберт агайны ике республика арасында дуслык күперләрен ныгыткан шәхес буларак та беләбез. Үзе әйтмешли, «Уфа–Казан арасын тапап үтте инде гомер».

Бик күп башкорт, Башкортстан язучылары белән дус яшәде, күпләренең китапларын татарчага тәрҗемә итеп, Казанда нәшер итте. Мостай Кәрим, Нәҗар Нәҗми, Әнгам Атнабаевларны – үзенең остазлары дип санаса, Равил Бикбаев, Хәсән Назар, Кадим Аралбай, Ирек Киньябулатовлар белән һәрчак дусларча аралашып, бер-берсенә кирәк чакта шигырь аша җылы сүзләрен әйтеп яшәделәр. Бу җәһәттән олы буын әдипләре безгә, яшьләргә, үрнәк булып тора.

Роберт Миңнуллин – йөрәгендә Татарстан белән Башкортстанны берләштергән олы шәхес. Шагыйрь үзе бүләк иткән «Путешествие с поэтом Робертом Миннуллиным в Уфу и обратно» дигән китап бар миндә. Аның авторы – Удмурт Республикасының халык язучысы Вячеслав Ар-Серги. Ике әдипнең Башкортстанга сәфәргә бару тәэссоратлары нигезендә туган публицистик китап ул. Анда шундый юллар бар:

«Мин үзем татар белән башкорт сәнгате бишегендә үскән кеше. Башкорт моңы, курае, эпосы, кобайырлары... Искиткеч фольклоры бар аның. Үзем татар мәктәбендә укыдым, әмма гел башкорт радиосын тыңлап үстек, шуңа башкорт телен туган телем кебек беләм. Балачактан башкортча укыдым, чөнки өебездә шул телдә гәзит-журналларны алдыралар иде.

...Казанда мине – башкорт, ә Башкортстанда – татар дип исәплиләр. Язмыш шундый инде: әнкәем – татар, әтием паспорт буенча – башкорт».

Бу юлларны китергәндә, әдипнең милли тамырлары хакында сүз йөртергә теләмим. Безнең өчен ул Роберт Миңнуллин булуы белән кадерле. Ике халыкның да яраткан улы, ике халыкның да әдәбиятына, сәнгатенә байтак мирас биргән шәхес. Казанда агайның фатирында булганда, шәхси китапханәсенә игътибар иттем. Башкорт язучыларының китаплары күп булуы сокландырды. Әдәби әсәрләр генә түгел, сәнгать әсәрләре хакындагы альбомнар, тарихи китаплар бихисап иде. Бу, әлбәттә, әдипнең югары мәдәниятле кеше булуы, шулай ук ике тугандаш милләтне дә бердәй якын күрүе хакында сөйли.

«Без бик якын халык. Татар язучылары белән дуслыкта бул. Казанга ешрак кил!» – дип, берничә тапкыр әйткәне булды агайның. Ә инде күрше республикага барсам, Роберт агай белән күрешү үзе бер бәйрәм иде.

«Синең уңышларыңны күреп куанам. Бер туган дустым сыман күрәм үзеңне», – дигән сүзләре әле дә хәтердә.

Бер тапкыр агай фатирына кунакка да чакырды. Клара җиңги пылау пешереп куйган иде. Мин инде Казанны начар белгәнгә күрә, чакырылган вакытка бераз соңарыбрак килдем. Җиңгәбез ашны берничә тапкыр җылытып та өлгергән. Роберт Мөгаллим улы, гадәттә, төрле чараларда гел ялгызы йөри иде, шуңа җиңги белән аралашу форсаты да моңарчы чыкмаган иде. Ә монда бик ихлас аралашып утырдык, күңелле булды. Кайтыр чакта, агай җиде томлык китабын матур сүзләр язып бүләк итте.

Шул мәлдә ике кешенең мәхәббәтен күреп, сокланып куйдым. Һәр ирнең уңышы артында – бөек хатын тора, диләр. Хак сүзләр! Минемчә, Клара апайның акыллылыгы, түземлеге, тыйнаклыгы бик ярдәм иткәндер шагыйрьгә. Иҗат кешесенең күңелен

аңлаучы булмаса, кирәк чакта терәк-таяныч булмаса – агаебыз шундый уңышларга ирешә алыр идеме?!

Әйткәндәй, Клара Миңнуллина – Башкортстан кызы, Илешнеке. Күп еллар матбугат өлкәсендә эшләгән, «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исеме дә бар. Алар Алмаз белән Таңсылу исемле балаларга гомер биргән.

«Моннан берничә ел элек телевидение программасын караштырып утырганда, «Клара һәм Роберт» дигән нәфис фильмга тап булгач, хатыным белән, ничектер, аптырап та, дулкынланып та, сәерсенеп тә калган идек. Туры килүен кара әле син аның! Баксаң, бөек немец композиторы Роберт Шуман һәм аның хатыны Клара турында булып чыкты ул фильм. Кызык бит әй! Кайчан да булса берәр заман тагын да «Клара һәм Роберт» исемле яңа әсәр язылмас дип, кем әйтә ала? Бәлки, ул татар шагыйре Роберт Миңнуллин һәм аның хатыны Клара турында булыр. Белмәссең бу дөньяны!» дип язган иде шагыйрь истәлекләрендә.

Роберт Миңнуллин белән соңгы елларда телефоннан еш аралашып тордык. Аның каты чир белән көрәшүен дә белә идем. Һәрчак йөзеннән елмаю китмәгән теремек агайның күз алдында сүнә баруын күрүе бик кыен булды.

«Хәлемне кешеләргә генә әйтеп бармыйм. Ике ай дәваханәдә яттым, дүрт операция кичердем. Терелеп киләм...» – дигән иде бер сөйләшкәндә. Кызганычка, әҗәл көчлерәк булып чыкты.

*«Курай булса – борынгыдан*
*Күңелләргә кайтыр моң...*
*Туган якка мин үзем дә*
*Курай булып кайтырмын!»*

дигән шигъри юлларын укып, дертләп куйдым. Шагыйрь туган җиренә бар мәхәббәтен, эчке кичерешләрен, уй-хыялларын шушы юлларга салган түгелме?..

Роберт Миңнуллинның безнең арадан китеп баруына еллар үтеп китте. Бик сагынабыз, юксынабыз сине, агай! Синең акыллы сүзләреңне ишетәсе, ягымлы итеп шигырь укуларыңны тыңлыйсы, сәхнәдән төртмә телле чыгышларыңны күрәсе килә... Үлемсез җырларың, үзәккә үтәрлек шигырьләрең генә юата безне.

Башкортстан җирендә курай моңы тынганы юк, тынмас та! Шулай булгач, Роберт агайның рухы да һәрчак туган җирендә.

Шагыйрьнең күрәзәчелек кебек язган юллары һәрчак колакта чыңлап тора:

*«...Курай булып кайтырмын да,*
*Моңнар булып тулырмын.*
*Курай күрсәгез – тыңларсыз,*
*Ул курай – мин булырмын...»*

**Айгиз БАЙМӨХӘММӘТОВ,**
*Башкортстан Язучылар берлеге рәисе.*

# СӨББУХ РӘФЫЙКОВ ЯДКЯРЕ

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

## Авылдашлар

Норильск сөргененнән кайткан Сөббух Рәфыйков Казанда үзе кулга алынганчы хезмәт куйган китап нәшриятында авылдашы Саимә Ибраһимованы очрата. Аны Зөләйха апасына охшатып, үзе килеп күрешә. Саимәнең монда матур әдәбият бүлегендә тәрҗемә буенча мөхәррир булып эшләгән чагы була. Алар шулай танышалар. Ике авылдашның сөйләшеп сүзләре бетми. Язучы абыйсы (яшь аермалары унбиш ел) Саимәгә Зөләйха апасының газета-журнал битләрендә мәкаләләре бик еш басылуын, ул вакытта үзенең Казанда «Кызыл яшьләр» газетасы редакциясендә бүлек мөдире булып эшләвен әйтә. Зөләйханың тормышы, язмышы турында сорый. Саимә авылдаш абыйсына түбәндәгеләрне бәян итә. 1934 елның декабрь санында «Азат хатын» (1991 елдан – «Сөембикә») журналының тышлыгында апасының матур портреты басылып, шуның астына фабрикада эшләүче алдынгы бригадир кыз Зөләйха Ибраһимованың еллык планны 7 ноябрьгә сыйфатлы итеп үтәве һәм шәһәр советына депутат итеп сайлануы турында язылган була. Авылдашлары шуны күреп алалар да, фотосы өстенә «Бу кулак кызын нишләтеп йөртәсез монда?» дигән нахак сүзләр язып, Казанга җибәрәләр. Җитәкче урыннарда эшләгән Ибраһим абыйны күралмауларын алар шулай белдерәләр. Шул сүзләргә ышанып, Казанда кызны эшеннән дә, комсомол сафларыннан да куалар. Саимәгә апасы белән булган бу вакыйганы ул үсеп җиткәч сөйлиләр. Ләкин аның апасы югалып калмый: шәфкать туташы булыр өчен белем ала, Бөек Ватан сугышы елларында тәүлекләр буе госпитальдә эшли, яралы сугышчыларга, донор буларак, канын бирә, тыныч тормышта да хезмәт уңышларына ирешә...

Язучы Сөббух абыйсына «халык дошманы» мөһере сугылгач, аның якын кешеләренә дә якты көн беткән икән. Әнисе Мөһривафа апа, бала кайгысыннан таушалып, ашказаны чиреннән 1942 елда 59 яшендә вафат булган.

Үзе аклануга ук, туганнары хакында белергә теләп, Сөббух авылга хат юллый. Кимсетүләргә чыдый алмыйча, Хәерлебанат апасы авылдан – Үзбәкстанга, энесе Самат Сахалинга чыгып киткән икән. Бу хәбәрне һәм башка яңалыкларны аңа элекке укучысы, авыл укытучысы Таһир Шәрәфетдинов үзенең җавап хаты аркылы җиткерә.

Ике авылдаш – Сөббух белән Саимә – туган авыллары Зур Нөркәйне дә озак итеп искә алалар. Заманында волость идарәсе урнашкан атаклы авылда туган кешеләр бит алар. Җитмәсә, Саимәнең әтисе Ибраһим волость идарәсе рәисе булып эшләгән. Волость идарәсе нотариаль оешма вазифасын да үтәгән, волостька кергән авылларның архивы да шунда сакланган. Ибраһимга писарьлык эшен дә үзенә башкарырга туры килгән.

Сөббух та үзенең хезмәт юлын кайчандыр данлыклы волость үзәге ролен башкарган, туган авылындагы мәктәптә укытучы булып башлый. Иң элек авыл мәктәбендә укып, аннары унике яшеннән Чаллыда һәм Алабугада тырышып белем алганнан соң, унҗиде яшьлек егет, хуҗалыкта әнисенә ярдәм итү ниятен дә күздә тотып, төп йортка кайта.

---

*Ахыры. Башы узган санда.*

Ачлык елны әтисе вафат булгач, сигез яшеннән кул арасына кергән Сөббух авыр физик эшләрне бик яшьли җигелеп тарта башлый, шуңа күрә аның тәҗрибәсе зур. Укытучы егет авылдагы тормышын «үзе әнисенең терәге булырга тиеш» дип күз алдына китерә.

Саимәне авылга бәйләнешле үткәндәге тормышы белән бераз таныштыргач, Сөббух үзе мәктәпкә эшкә кайтасы 1930 елны авылдашларын тетрәндергән хәлгә туктала. Илдә коллективлаштыру башлануга, «кулак» тамгасы сугылган урта хәлле крестьяннарга гына түгел, дин әһелләренә дә турыдан-туры каныгу көчәйгән. Халык Комиссарлары Советы тарафыннан 1918 елның 23 гыйнварында кабул ителгән Декрет нигезендә дәүләттән аерылган мәчетләрнең биналарын җимерергә, муллаларын читкә сөрергә уңайлы форсат та чыккан. 1929 елның 8 апрелендә теркәлгән «Дини оешмалар турында» дигән карар дин әһелләрен юридик хокуклардан тулысынча мәхрүм иткән. Һәм алар күпләп-күпләп төрмәгә ябылган. Шул шаукым вакытында Зур Нөркәйдә 1930 елның 8 мартында авыл мулласы Мөхәммәтҗанов Габдуллаҗан кулга алынган һәм лагерьга озатылган. Габдуллаҗан мулла кебекләрнең бәхетеннән, шул елның май аенда ВКП(б) Үзәк Комитетының махсус карарында Татарстанда дингә каршы көрәштә чамадан тыш тырышлык күрсәтелүе кимчелек дип бәяләнә. Бәхетенә күрә, Зур Нөркәй мулласына шул чакта исән калып, кире әйләнеп кайту насыйп була. Тик Казанда Сөббух кулга алынырга бер атна вакыт калгач, 1937 елның 12 октябрендә Габдуллаҗан икенче тапкыр кулга алына һәм төрмәгә озатыла... Репрессия шаукымы Сөббухлар нәселеннән Гатаулла улы Салихка бик каты орынган. Сөббух Саимәгә бу хакта да сөйли. Авылдашлар турында авылдашыңа сөйләмичә, тагын кемгә сөйлисең инде? Зур Нөркәйдәге өч мәчетнең берсендә имам-хатыйп вазифасын башкаручы җитмеш биш яшендәге Салихны, «халык дошманы» дип, 1938 елда кулга алганнар һәм Минзәлә төрмәсендә атып үтергәннәр. Чөнки 1938 елның башында ВКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы кулга алынырга һәм атып үтерелергә тиешле кешеләрнең өстәмә, яңа нормаларын билгеләгән, шул сәбәпле репрессияләрнең күләме арткан. Кулга алынганнан соң, гаепле дип табылганнарның яртысын атып үтергәннәр. Шул көчле ташкында Салих Таишев та һәлак ителгән...

Беренче сыйныфка үз авылының мәктәбенә укырга керсә дә, Саимәгә белемне башка мәктәптә (хәзерге Актаныш районы Пучы авылында) алырга туры килгән. Чөнки волость бетерелеп, авылда ЗАГС бүлеге башлыгы булган Ибраһимны яңа оешкан кулланучылар кооперациясе-берләшмәсе рәисе итеп куйганнан соң, алга таба аны гел күчереп йөрткәннәр. Ул район үзәкләрендә заготскот, потребсоюз кебек җирләрдә җаваплы вазифаларны башкарган. Саимәнең хәтерендә туган авылы сокланырлык гүзәл табигате, шунда башланган балалык еллары белән, онытылмаслык хатирә булып, әле дә саклана икән. Тоткынлыктан иреккә чыгарылган Сөббух та күңеле белән иң элек ямьле Минзәлә елгасы буенда утырган туган авылы Нөркәйгә омтыла. Туган авылы һәркемгә дә кадерле шул, чөнки анда иң мөкатдәс, мөһим вакытлар – балачак һәм яшьлек еллары узган. Әнә Саимә, дулкынланып, Зур Нөркәйгә бары тик 1943 елда гына, анысында да паспорт алу өчен туу турында таныклык кирәк булганга гына кайтуын сөйли. Авылга көнен генә кайтып килергә бик җитди сәбәп тә чыккан. Кавказ фронтында шәфкать туташы буларак катнашып, сугыштан кайткан Шәмсеруй апасына авыл советыннан таныклык алырга кирәк була. Алар, Нурлыһода апаның өч кызы, Мөслимнән авылга кадәр юлны җәяүләп атлыйлар. Рәхимә апасы, юлдаш булып, болай гына ияреп бара. Аның белән дә авылдашлары рәхимсез кыланганнар. 1939 елда Алабуга педагогия техникумын тәмамлап, Мөслим районындагы Вәрәшбаш авылы мәктәбенә укытырга кайткач, авыл советы рәисе исеменә «Кулак баласының укытып йөрергә хакы юк!» дигән катгый карар белән хат җибәрәләр. Ярый әле, рәис ул хатны Рәхимәнең үзенә генә күрсәтә...

Документ юллап кайткан «кулак» балаларына ул көнне, нишләптер, «урта хәлле крестьян гаиләсендә туган» дип таныклык бирәләр.

Шул көннән гайре Саимәгә туган авылына кайту насыйп булмас. Танылган журналист һәм оста тәрҗемәче Саимә Ибраһимова гомер буе Зур Нөркәйне сагынып яшәр. Ул 2001 елда язган «Күңелем тәрәзәсе, яки Тарих мең дә тугыз йөздә...» исемле мәкаләсен: «Нурия ханымның хаты мине тора-тора куандыра, тора-тора сөенәм, хәзер эчемә җылы кергән сыман. Атам-анамны тапкан сыман тоелам. Нөркәйне кайтып күрәсем, урамнары буйлап йөрисем, өйләрен кулым белән тотып карыйсым килә башлады...» дип тәмамлаган...

Сөббух Рәфыйков белән Саимә Ибраһимовага бик тә кадерле булган Зур Нөркәй авылы киләчәктә дә данлыклы булыр. Аның биләмәсенә Кече Нөркәй авылы кушылыр. Ике авыл арасы бары тик бер чакрым, аларны Минзәлә елгасы гына аерып тора. Алар электән үк бер авыл кешеләре кебек яшәгәннәр... Зур Нөркәйдә табылган мамонт сөякләре Сарман районында иң борынгы табылдыкларның берсе булыр. Ул 1989 елда сигезенче сыйныф укучылары Габдрахманов Марат һәм Фәхертдинов Гинар тарафыннан табылыр. Алар аны сыйныф җитәкчеләре, география укытучысы Хәдичә апалары Хуҗинага тапшырырлар, ул исә бу искиткеч тарихи истәлекне үзе оештыра башлаган музейга куяр... Мәктәптә якташ язучылары Сөббух Рәфыйковка багышланган музей да барлыкка килер. Ул 1996 елның 27 апрелендә үзенең ишекләрен ачар. Тантанада язучының якын кешеләре дә катнашыр. Алар үзләренең фикер-теләкләрен дә язып калдырырлар. Текстның эчтәлеге түбәндәгечә булыр. «Безнең яраткан һәм кадерле әтиебезнең музее ачылу көнендә аны оештыручыларга чиксез рәхмәтебезне белдерәбез. Әлеге музей Нөркәй авылы тарихы музее да булсын иде. Авылдашыгызның истәлеген яңарту өчен башкарган хезмәтегезгә сокландык. Музей алга таба да аның турында яңа материаллар белән тулыланыр һәм һәрберебездә изге хисләр тәрбияләр дип ышанабыз. Тагын бер мәртәбә зур рәхмәт. Ихтирам белән, Сөббух Рәфыйков балалары-кызлары, оныклары: Әлфия, Сания; Эмилия һәм Айнур. 27.04.1996 ел».

Сөббух исә туган авылы белән һәрвакыт элемтәдә яши. Төп йортның ишеге һәрвакыт ачык булу да үзенекен иткәндер. Саимәләрнең Зур Нөркәйдә йортлары юк, алар кая кайтсыннар?!. Күрше-күләнгә бер генә кайтасың, әниле йортка көн дә кайтырга мөмкин. Авылда яшәргә дигән уй белән, үз һөнәрен бик яратып, укучыларын әдәбият дөньясына әйдәп эшләп йөргән Сөббухка да уку елын тәмамларга туры килми. Аны ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Җир эшләре халык комиссариаты органы булган «Колхоз газетасы»на әдәби хезмәткәр итеп эшкә алалар. Чөнки шул газетаның күчмә редакциясе 1931 елның 1 мартыннан 10 маена кадәр Сарман районында «Колхоз газетасы» – чәчүдә» исеме астында үз газеталарын чыгара. Мөхәррир Шакир Рәмзи (Рамазанов) җитәкчелегендә газетаның егерме сигез саны дөнья күрә. «Колхоз газетасы»ның кулы җиңел булып чыга: Сарманның үзендә дә «Комбайн» газетасы оештырыла.

«Колхоз газетасы»нда эшләп алганнан соң, Татар педагогия институтына укырга керү теләге белән, «өйрәнмичә, белем йокмас» дип, Сөббух Казанда институт каршындагы эшчеләр факультетында белемен тирәнәйтә. Югары уку йортының филология факультетында татар бүлеге студенты булу бәхетенә ирешкән егетне тиздән ВЛКСМ өлкә комитеты Сарман районы газетасына мөхәррир урынбасары итеп җибәрә. Сөббух, укуын читтән торып дәвам итәргә тиеш булып, яңадан тагын туган җир туфрагына аяк баса.

Яңа оешкан редакциянең, әлбәттә, башта үз бинасы булмый. Ул МТСта, контораның бер бүлмәсендә урнаша. Сөббух бер көнне, газетада эшли башлаган 1932 елның истәлеге булыр дип, җаваплы сәркатип Яхъя Вәлишин белән фотосурәткә дә төшеп ала.

Район үзәге булган Сарман авылы белән Зур Нөркәй арасы ундүрт чакрымлык юл. Язылачак мәкаләләренә материал туплау өчен ул чакта Сарман районы составына кергән Чуар Абдул, Югары Баграж һәм башка авылларны да аркылыга-буйга йөри Сөббух. Кыскасы, хәрәкәттән бәрәкәт-муллык ясый. Җае чыкканда яисә җаен китереп,

төп йортка кайтып кунарга тырыша. Аена йөз егерме биш сум хезмәт хакы алып эшли ул. Мөхәррир Тәкый Яхинныкыннан егерме биш сумга гына ким. Кайткан саен әнисен күчтәнәчләр белән сөендерә.

Редакция журналистлары да, типография хезмәткәрләре дә хөкүмәт кешеләре дип саналалар бит, ягъни алар – рәсми төстә район тарихын язышучылар. 1934 елның кояшлы март аенда, бердәм коллектив булып, янә фотосурәткә төшәләр. Анысы да район тарихы өчен инде. Алга, озын эскәмия куеп, типография мөдире Ислам Солтановны, мөхәррир Тәкый Яхинны, мөхәррир урынбасары Сөббух Рәфыйковны һәм җаваплы сәркатип Габдессәлам Иштирәковны утырталар. 1933 елда Яхъя район җир бүлеге мөдире вазифасын башкарырга күчкәнгә, аның урынында Габдессәлам эшли башлый. Фоторәсемгә төшкәндә, арткы рәттә басып торучылар: газета басучы Хәсән Минһаҗев, хәреф җыючылар Нурдидә Әхмәтшина, Газиз Нуриев. Барый Вәлиев, Таһир Абдуллин һәм Мансур Солтанов та хәреф җыючы булып эшлиләр.

Август аенда Сөббух Казанга китә. Анда ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты органы булган «Кызыл яшьләр» газетасына эшкә урнаша. 19 август көнне фоторәсемгә төшә. Рәсем артына: «Әни, Самат! Сагынганда карарсыз. Сезгә Казан бүләге. Кечкенә истәлек булыр. Алыгыз. 19.VIII. 1934», дип яза һәм Зур Нөркәйгә җибәрә.

Китап нәшриятында тәүге очрашулары вакытында Сөббух абыйсы Саимәгә үзенең тоткынлыкта күргәннәре турында өстән-өстән генә әйтеп уза. Сорау алгандагы вәхшилекләрне, канга батырып кыйнауларын, тырнак астын каезлауларын, Себердәге рухи һәм физик авырлыкларны нигә сөйләп торырга?! Җитмәсә, ул хакта беркайчан беркемгә сөйләмәскә ант итеп, йөз җиргә кул куйган кеше бит ул... Һәм ул сүзне иҗат темасына күчерә.

Саимәгә тәүге шигырьләр китабының «Үсү җырлары» исеме белән, кырык тугыз битле булып, өч мең данәдә, Мәскәүдә СССР халыклары үзәк нәшриятында 1932 елда басылуын, җыентыктагы шигырьләре колхоз авылының беренче көннәре турында булуын әйтә. Саимә бик бирелеп тыңлап тора. Сөббух абыйсы үзенең иҗаты белән таныштыруны дәвам итә. Шул ук елны Казанда «Соңгы талпыну» исемле хикәясе аерым китап булып басылган, ә үзе кулга алынасы 1937 елны «Үсмерчак» исеме белән шактый калын хикәяләр җыентыгы дөнья күргән. Ни кызганыч, шул ук елны нәшриятка әзерләп тапшырган «Зәңгәр гөрләвек» повесте һәм «Ап-ак каен янында» исемле шигырьләр җыентыгы, билгеле инде, басылмыйча кала. Сөббухны кулга алучылар кулъязмаларны да үзләре белән алып китәләр. Ул Себердә вакытта «Ак төннәр» исемле шигырь китабын да, «Беренче яз» романын да кулъязмада тәмамлаган икән инде. Менә шуларны китап итеп бастырып чыгарырга уйлый.

Киң маңгаенда җыерчыклар эз салган, күзләрен тирән моң сарган, чәчләре сирәгәя төшкән язучы абыйсына Саимә үз итеп, яратып, сокланып карый. Ул да кайчандыр Сөббух абыйсы белем алган институтка филология факультетының рус бүлегенә укырга керә. Студент чагында бервакыт укытучысы, йомыш кушып, аны китап нәшриятына җибәрә. Төргәгенә «Бу студент кыз – нәкъ безгә кирәкле кеше» дип язган кәгазьне дә кыстырган була. Тәрҗемә бүлегендә эшләүчеләр Саимәне шул вакытта исләрендә калдыралар. Институтны 1950 елда тәмамлаган егерме ике яшьлек кыз, мәктәптә «тиешле еллар»ын эшләп үткәргәннән соң, китап нәшриятының матур әдәбият бүлегенә мөхәррир вазифасын башкарырга кабул ителә.

Саимә шунда эшләгәндә, 1953 елның 25 апрелендә Мәскәүдә «Литературная газета»да шагыйрь Илья Френкель тәрҗемәсендә Муса Җәлилнең фашистлар әсирлегендә иҗат иткән шигырьләре басылып чыккач, Матбугат йортындагы газета-журнал редакцияләрендә, китап нәшриятында, полиграфиядә эшләүчеләр һәм бөтен язучылар Тукай клубында митинг үткәрәләр. Күңелгә онытылмаслык булып кереп калган шул вакыйга турында Саимә Сөббух абыйсына да сөйли. Әйе, митингны шигырь секциясенең җитәкчесе Сибгат Хәким ачып җибәрә. Фронтовик шагыйрь үзенең кереш

сүзеннән соң, Җәлилнең дусты буларак, берничә вакыйганы исенә төшерә. Ул Муса белән Әминә яшәгән Зур Галактионов урамындагы 17 нче йортның 28 нче фатирында күп тапкырлар булганын, дүртенче катка күп мәртәбәләр күтәрелгәнен һәм Гадел Кутуй, Гази Кашшаф, Нәҗип Җиһанов, Әхмәт Исхаклар белән «түгәрәк өстәл әңгәмәләре»ндә катнашуын, 1940 елның июнь аенда бер төркем язучыларның Васильеводa Язучылар берлеге җитәкчесе Муса Җәлил белән бергә ял итүләрен әйтә. Гази Кашшафка сүз бирелгәч, әдәбият галиме һәм Җәлилнең якын дусты шагыйрьнең бай иҗаты турында сөйли, икесенең һәрвакыт яратып шахмат уйнауларын искә ала. Депутат була торып та, шагыйрьнең бары тик коммуналь фатирда гына яшәвен, өч бүлмәнең икесе генә Җәлилләр карамагында булуын мисалга китерә. Мусаның сугыш башлангач та икенче көнне үк, хәрби комиссариатка барып, үзен фронтка җибәрүләрен сорап, сугышка үз теләге белән китүен, шулай башкаларга үрнәк күрсәтүен әйтә. Аннары Моабит төрмәсенең элекке әсирләре Нигъмәт Терегулов һәм Андре Тиммерманс тырышлыгы белән туган илгә кайтып җиткән кул яссуы зурлыгындагы ике куен дәфтәрен митингка җыелган халыкка күрсәтә һәм шуннан берничә шигырьне укый. Чыгышын 1943 елның 20 ноябрендә язылган «Ышанма» исемле шигырь белән тәмамлый.

Шагыйрьнең ниндилеге шигырьләреннән беленә. Хак икән!

Кызганычка күрә, 1946 елның мартында Муса Җәлилнең гарәп хәрефләре белән алтмыш шигыре язылган беренче дәфтәрен һәм Абдулла Алишның куен дәфтәрен Язучылар берлеге рәисе Әхмәт Ерикәйгә тапшырган Нигъмәт Терегулов Черек күл подвалында атып үтерелгән...

Гази Кашшафтан соң трибунага Язучылар берлеге идарәсенең сәркатибе Әнвәр Давыдов күтәрелә. Ул Мәскәү газетасында Константин Симоновның кереш сүзе белән басылган Җәлил шигырьләрен русча тәрҗемәдә укып бирә.

Илья Френкель Җәлилнең «Кичер, илем!», «Сугыштан соң», «Ышанма», «Имән», «Алман илендә» һәм «Яңа ел теләкләре» дигән шигырьләрен тәрҗемә иткән.

Шул елны 24 майдан 4 июньгә кадәр Мәскәүдә үтәсе Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә күргәзмәгә Габдулла Тукай китаплары, Таткнигоиздатта басылып чыккан «Татар поэзиясе антологиясе (1956) һәм «Антология татарской поэзии» (1957) янәшәсенә Муса Җәлилнең ике куен дәфтәре урнаштырылачак. Аларны тапшыру мизгеле фотосурәткә алыначак. Әлеге фоторәсемдә без Казандагы Максим Горький музее директоры Мария Елизарованы һәм Муса Җәлилнең кызы, М.В.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының филология факультетында өченче курста укучы егерме яшьлек Чулпанны күрәчәкбез. Шулай ук Таткнигоиздатның матур әдәбият бүлеге мөдире Абдулла Гомәрне һәм радиотапшырулар комитетында эшләүче Зәкия Бәдигова-Рәсүлеваны да күрербез... Кулына диплом алганнан соң, Чулпан Җәлилова «Художественная литература» нәшриятында, рус классика редакциясендә сынау срогы-стажировка үтеп, шунда эшләячәк һәм баш редактор дәрәҗәсенә күтәреләчәк... «Моабит дәфтәрләре» 1958 елдан рус, немец, чех, корея, гарәп, белорус, инглиз һәм башка бик күп телләргә тәрҗемә ителәчәк. 1966 елда Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулу тантанасында Андре Тиммерманс Җәлил дәфтәрен саклап, совет илчелегенә тапшырганы һәм фашизмга каршы көрәштә күрсәткән батырлыклары өчен «За отвагу» («Батырлык өчен») медале белән бүләкләнәчәк...

Җәлилнең шигырь дәфтәрләре кайтып җиткәнче үк, аның Моабит төрмәсендә чакта бер китап битенә язган хат кисәге очраклы рәвештә совет солдаты тарафыннан 1945 елның 29 апрелендә табыла. Табылдыкны Мәскәүгә Александр Фадеев исеменә җибәрәләр. Шагыйрь турында иң беренче хәбәр шул була.

Митингта нотык сөйләргә чират Саимәгә дә җитә. Ул үзенең чыгышын: «Фашист тоткынлыгында да Муса Җәлил бөек пролетар шагыйрь Маяковскийның «Я хочу, чтоб к штыку приравняли перо...» дигән чакыруын тормышка ашыргандай, дошманның үз өнендә дә югалып калмыйча, кулындагы каләмен аның күкрәгенә төбәгән!..» – дип

тәмамлый. Ә берничә көн үтүгә, редакция мөдире, Муса Җәлилнең яшьтәше һәм якташы Абдулла Гомәр Саимәне үз бүлмәсенә чакырып ала да: «Менә без монда уйлаштык та Муса Җәлилнең «Моабит төрмәсендә язылган шигырьләр» китабына нәшрият редакторы сез булырсыз дигән карарга килдек. Махсус редакторы Гази Кашшаф була. Эшләгез!» – ди. Шул көннән Саимә ике ай дәвамында Муса Җәлилнең Германия әсирлегеннән кайткан аерым-аерым ике дәфтәрендәге шигырьләрне кәгазьгә төшерү һәм машинкада бастыру эше белән мәшгуль була. Яратып, үзендә зур җаваплылык тоеп башкарганда, эш шома бара. Эшне тиз арада төгәлләп, июнь ахырында җыярга тапшыралар. Октябрь ахырында китапны басарга кул куела. Һәм ике йөз алты битле әлеге китап, Гази Кашшафның анализлы кереш сүзе белән, сигез мең данә булып, Таткнигоиздатта басылып та чыга. «Язган сүз булыр илгә». Менә шагыйрьнең язганнары да үз иленә насыйп булган!.. Әйе, сүз бит ул күз җитмәгән урынга да барып җитүчән.

Саимә 1954 елда 24–26 июнь көннәрендә язучыларның чираттагы III съездында катнашуын да искә ала. Җыелыштан соң үзе, Гөлшат Зәйнашева, Ләбибә Ихсанова, Мирза Мәхмүтов, Риза Ишморат, Салих Баттал һәм Баян Гыйззәт бергә фоторәсемгә төшүләрен әйтеп, икенче очрашуда аны Сөббух абыйсына күрсәтергә вәгъдә итә. Шул елны Анна Зегерсның хикәяләрен татарчага тәрҗемәдә китап итеп бастыруын, ә быел Мирза Мәхмүтов белән икесе Дәрҗия Аппакованың сайланма әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итүләрен һәм ул китапның бик калын килеп чыгуын, «Илдус» һәм 1945 елда Татар академия театрында куелган «Тапкыр егет» пьесалары үзенең каләме аша үтүен әйтеп ала. Бер ел элек Балтыйк буе Хәрби округындагы Рига шәһәрендә инглиз теленнән тәрҗемәче булып эшләгән Мирза, үзе теләп, Казанга күчеп килгән. Хәзер университетта гарәп теле укыта.

Ике авылдаш, ике каләмдәш әлеге дустанә җылы очрашуда иҗат дулкыннарында да тирбәлеп, яңадан шулай күрешүләрен теләп саубуллашалар[1]...

## Иҗат офыклары

Норильскига гаиләсе янына кайткач та, Сөббух Казанда алган тәэсирләр белән яши. «Кайтырга, кайтырга, туган якка кайтырга кирәк!» Ул күңеленнән гел шуны кабатлап йөрергә гадәтләнә. Татарстан – хатыны Хәлимә өчен дә туган як бит ул. Красноярск краенда Ошма дигән татар авылында туса да, аның әтисе Миңнәхмәт Кукмара ягыннан. Дәүләтшиннар, «кулак» дигән мөһер сугылгач, туган якларыннан китәргә мәҗбүр булганнар.

1956 елның 9 маенда тулысынча аклану алган Сөббух очар коштай иректе булганга, кичекмәстән туган ягына кайтып төпләнү турында гына уйлап йөри. Аның Казаннан

[1] Култамгалы бүләк китаплар арасында минем өчен бик кадерле булган «Моабит дәфтәрләре»нең татарча, русчага тәрҗемә һәм факсимиль басмасы, ягъни төп-төгәл фотокүчермәсе бар. Татарстан китап нәшриятында сувенир форматта бастырылган ике йөз кырык битле ул китапларны миңа «Рухие Фахразиевне с искренней симпатией и благодарностью Чулпан Залилова. 9.08.2019 посёлок Джалиль» дип язып, Муса Җәлилнең кызы бүләк иткән иде. Ул елны Чулпан Җәлилова кызы Татьяна һәм оныгы Елизавета белән, «Җәлилнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе оешуга 60 ел тулу уңаеннан, хөрмәтле кунак итеп чакырылган иде. Муса Җәлилнең Казандагы музей-фатиры мөдире Нәзирә Фәттахова да алар белән бергә иде. Ул китапларны алтмыш яшьлек юбилеема истәлекле бүләк дип кабул иттем. ...Саимә апа Ибраһимова белән шактый еллар дәвамында аралашып яшәдек. Аның белән танышлыгым 2012 елның көзендә Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Җырлы чишмә» исемле китабымны, Сарман районы Зур Нөркәй авылында туган язучы дип, аңа бүләк итүемнән башланды. Беренче очрашуыбызны ачык хәтерлим. Үзем белән: «Мин – Сарман ягыннан», – дип таныштыруыма, ул бик нык каушады, хәтта бер мәлгә нәрсә әйтергә дә белмичә югалып калды. Җәлил бистәсеннән икәнемне белеп алгач, ул бераз тынычланды. Мин моның сәбәбен күп еллар үткәч кенә аңладым. Ул мине Зур Нөркәйдән килгән дип кабул иткән булса кирәк. Шул очрашуыбызда Саимә апа миңа бүләккә Марк Твенның үзе тәрҗемә иткән «Том Сойер маҗаралары»н һәм үзе төзегән «Сөембикә-ханбикә» исемле китапны автограф белән биргән иде. Тәрҗемәче хезмәтенең гаять авыр булуын белгәнгә, Саимә апаны шул яктан ачасым килеп, аның турында язарга теләгән идем. Ләкин тартылып-сузылып йөри торгач, мин ул изге ниятемне тормышка ашыра алмыйча калдым: мәкаләм язылмады. Аңа багышланган «Милләт гаме» исемле шигырем өчен ул, әлбәттә, рәхмәт әйтте. Автор.



*Шәхес культы елларында төрмә-сөргеннәрне кичкән татар әдипләре.*
*Сулдан уңга: Сөббух Рәфыйков, Хәсән Туфан, Ибраһим Салахов.*
*Озак еллар үткәч, Тукай клубында очрашу. 1956 нчы ел, октябрь.*

әйләнеп килүенә шактый вакыт үтсә дә, 1957 елның 15 июлендә генә (20 июньдә туса да, ул документларда 15 июльдә туды дип язылган), нәкъ Сөббухның туган көненә туры китереп, ниһаять, озату кичәсе үткәрергә планлаштыралар. Дуслары, танышлары, Хәлимәнең әтисе саубуллашырга җыелалар.

Менә, ниһаять, августта Казан вокзалына кайтып җитү. Кунар урын тапмагач, вокзалда кунулар. Казанда вакытлыча яшәп торыр өчен фатир тапмагач, Васильево посёлогында бер бүлмә «снимать» итү. Иң әһәмиятлесе: «Совет Татарстаны» (1960 елдан – «Социалистик Татарстан») газетасында Зәй һәм Ширәмәт районнары буенча үз хәбәрче булып эшкә урнашу. Казанга кайтып, бер ай вакыт үтүгә, коммунистлар партиясенә керү өчен гариза бирүе. Бераздан мөхәррир Галим Мәҗит улы Рябковның Сөббухка яшәү урыны итеп Зәй яки Ширәмәтне сайларга тәкъдим итүе. Көз көне Зәйгә күченеп, башта кунакханәдә яшәүләре. Һәм, ниһаять, аларга үзләренчә, үз көйләренә яшәү өчен Островский урамында урнашкан 18 нче йортны бирүләре. Дөрес, бу йорт ике гаиләгә исәпләнеп төзелгән. Тик шунысы әйбәт: һәр гаиләнең ишеге аерым. Һәрхәлдә, коммуналь фатир түгел инде.

Җиденче сыйныфта укыганда ук, кулына каләм алып, хикәяләр һәм повестьлар яза башлаган Сөббух вакытын бушка уздырмас. Иртәнге дүрттән торып, гаиләсе йокыдан уянганчы язар да язар. Аның исеме Сөббух бит. Исеменең мәгънәсе «олылау, данлау, мактау; таңнар» дигәнне аңлата. Күчерелмә мәгънәдә – «иртәчел кеше» дигән сүз дә әле. Сөббух ундүрт ел дәвамында иртүк торыр, кешеләрне данлап, очерклар, мәкаләләр һәм әдәби әсәрләр язар.

1957 елда Казанда Таткнигоиздатта «Ак төннәр» исеме белән шигырьләр җыентыгы басылып чыккач, Сөббухның күңеле тагын да күтәрелә. 1937 елда дөнья күргән «Үсмерчак» исемле китабы белән әле яңа нәшер ителгән җыентыгы арасында егерме елга сузылган тоткынлык еллары ята. Кызганыч, әлбәттә. Шуңа күрә вакытның кадерен белеп, аңа шул егерме еллык бушлыкны тутырырга туры киләчәк.

Сөббух Зәйне һәм аның халкын яратып яши. Кешеләр дә аны хөрмәт итәләр, яраталар. Ул – Яңа Зәй посёлогы советы депутаты да. Нечкә күңелле язучы бервакыт көзге суыкта туңган бер ярлы кешегә үзенең өстендәге яңа пальтосын салып бирә. Моны кешеләрне кызганучы, бигрәк тә Себер салкыннарын үзе кичергән кеше генә эшли ала дыр. Игелекле, мәрхәмәтле кеше генә.

Язучы халык белән еш аралаша. Үзе белән һәрвакыт куен дәфтәре һәм каләм йөртеп,

көн дәвамында алган тәэсирләрен, әңгәмәләрен теркәп бара. Кайберләрен «Көндәлек дәфтәренә» дә яза. 1958 елның май аенда партия сафларына кабул ителүен ул шунда билгеләп куячак.

Сөббух Зәй белән Казан юлына тузан кундырмый. «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә эш буенча еш булырга туры килә аңа. Шигырь яисә хикәяләрен башка газета-журналларда да калдыра.

Китап кибетенә кергәч, Сөббух киштәләрне тутырып тезелеп торган китапларга хәйран калып, хозурланып карап тора. Менә ике телдә басылган шигырь антологиясе китаплары. Аларда Кол Галидән башлап Гамил Афзалгача siксән тугыз шагыйрьнең үрнәк шигырьләре тупланган икән. Ике җыентык та сигез мең данәдә басылган. Бәяләре 22 сум 50 тиен. Татарча басмасы 1956 елда нәшер ителгән. Русчасын 1957 елның 31 гыйнварында җыярга тапшырганнар, 16 февральдә басарга кул куелган. Эшне тиз тотканнар. Кыскасы, китап Мәскәүдә үтәчәк декадага басылып өлгергән. Бик шәп булган. Афәрин! «Татар поэзиясе антологиясе»нең русча басмасын әзерләүчеләр Михаил Львов (Рифкать Маликов), Сибгат Хәким, Николай Сидоренко, Борис Дубровин, Рувим Моран, Леонид Хаустов һәм Юрий Окунев икән. Сөббух 1956 елда Тукай клубында очрашуларын исенә төшереп, бик кызыксынып, Туфан шигырьләрен карый. Кыскача гына биографиясеннән соң, 365–373 нче битләрдә шагыйрьнең унбиш шигыре урнаштырылган.

Казан язучысы Геннадий Паушкин, Леонид Хаустов тәрҗемәләрендә.

Аһ, нинди могҗиза! Аһ, нинди самимилек, садәлек! Әйе, Туфанның шигърияте алдында баш иярлек... Еллар үтәр. Һәм 1978 елда рус совет шагыйре Михаил Дудин да, баш иеп: «Хәсән Туфан – поэзиядәге сирәк очрый торган, гаҗәеп, уникаль күренешләрнең берсе. Ул – татар поэзиясенең горурлыгы. Кадерен белегез аның, саклагыз аны!» – диячәк. Үзе дә репрессия газаплары кичергән Рувим Моран – татар телен өйрәнгән шагыйрь – Туфан шигырьләрен дә русчага тәрҗемә иткән. Леонид Хаустов белән икесенең тәрҗемәләре 1958 елда Мәскәүдәге «Советский писатель» нәшриятында «Стихотворения» исеме белән, 170 битле булып, 5000 данәдә басылып чыгачак.

Туфанның моң тулы шигырьләре музыка телендә дә яңгыраячак әле.

Гаҗәеп нәзакәтле, йомшак тембрлы тавышка ия булган Фәридә Кудашева тормыш иптәше Бәхти Гайсин көйләр язган «Кайтырсың шикелле», «Юксындырсаң, нишләрмен» җырларын яратып башкарачак. Шулай ук «Киек казлар» (Марс Макаров көе), «Әйткән идең...» (Әнвәр Бакиров көе), «Тургай» (Заһир Исмәгыйлев көе) җырларын ихлас күңелдән, тирән хис белән тыңлаучы хозурына җиткерәчәк. Киң диапазонлы, үзенә бертөрле түбән тембрлы тавышка ия булган Нәфисә Васильева «Киек казлар» җырын үзәкләргә үткәреп башкарачак.

Драматик тенор тавышка ия булган, хәтта Отелло партиясен иң югары дәрәҗәдә башкару осталыгына ирешкән, татар халкының җыр хәзинәсенә әйләнгән бөек җырчысы Хәйдәр Бигичев «Әйткән идең...», «Тын сукмакта тал тирбәлә» җырларын сәнгатьнең алтын фондына кертәчәк.

Җырчының вафатыннан соң җиде ел үткәч, хәләл җефете, җырчы Зөһрә Сәхабиева, Татарстан хөкүмәтенең матди ярдәме белән, 2005 елда «Аксу» студиясендә «Тын сукмакта...» дип исемләп, аның дискын чыгарачак. 2016 елда Татарстан китап нәшриятында басылачак «Җырлы гомер – гамьле гомер» исемле китабында (107 нче биттә) аның: «Хәйдәрнең Хәсән Туфанны ни дәрәҗәдә тирән аңлавы «Тын сукмакта тал тирбәлә» җырын башкаруыннан да күренеп торадыр, мөгаен», – дигән сүзләре булачак. Контральто тавышка ия җырчы үз репертуарына «Казан кичләре» (Сара Садыйкова көе), «Әйткән идең...» җырларын кертәчәк. «Чаган» (Резеда Ахиярова көе) җырын беренче башкаручы булачак.

Баритон тавышлы, мең елга бер генә туган даһи җырчы Илһам Шакиров

«Ромашкалар» (Фәтхерахман Әхмәдиев көе) җырын сөекле халкы алдында күзләрдән яшь китерерлек итеп башкарачак.

Җырларны сәхнәләштерү талантына ия булган Зифа Басыйрова (ул – Хәсән Туфанның кодагые да бит әле) «Кояшта тудың микән...», «Исле гөл» (татар халык көе) җырларын тамашачыга бүләк итәчәк. Шушы җырны лирик сопрано тавышка ия Рабига Сибгатуллина иҗади рәвештә гәүдәләндереп башкарачак, ягъни интерпретация ясаячак. Туфанның исемсез шигыренә музыканы аның тормыш һәм сәхнә иптәше композитор, музыкант Фәрит Хатыйпов язачак һәм исемен «Синең нурың» дип атаячак.

«Агыла да болыт агыла» (Марс Макаров көе) җырын җырчылар Рөстәм Закиров та, Вил Усманов та тыңлаучы онытмаслык итеп башкарачаклар.

Репрессия гарасатыннан туган якларына исән-имин кайтып ирешүе белән шагыйрь Хәсән Туфан үзе дә әйтеп бетергесез бәхетле. Аның үзләре үк көй сорап торган лирик шигырьләре дә, һичшиксез, татар җыр сәнгатен баетачак әле.

Сөббух Казанда, беренче чиратта, Саимәне очратып, аның белән сөйләшергә тырыша. Саимә дә язучылар съездларында үзенә иптәш, киңәшче булыр дип сөенә, Сөббух абыйсына зур ышаныч белән карый. Саимә аны Зөләйха апасының фатирына да алып бара, үзләренә дә чакыра. Зөләйханың ире Гали Бөек Ватан сугышында һәлак булган икән. Саимә, Зөләйха һәм Сөббух чәй табыны артында иркенләп сөйләшеп утыралар. Казанга килгән саен Сөббух Саимәне һәм Зөләйханы күрергә тырыша. Алар белән очрашкач, күңеленә ял була. Туганнарын да искә алалар. Сөббух энесе Саматның хатыны Тамара белән Сахалинда, Оха уртавында яшәвен, ике кыз бала тәрбияләп үстерүләрен әйтә. Үзеннән өч яшькә өлкәнрәк Хәерлебанат апасының да, Самат гаиләсенең дә Зәйне бик ошатуларын өстәп әйтеп куя.

Сөббух Казанда озаграк тоткарланса, Зәйгә өйдәгеләргә бер-бер артлы хатлар язып сала. Хатта, һәрберсенә аерым мөрәҗәгать итеп, хәлләрен сораша, киңәшләрен бирә. Әнә, Сания белән Нәфисә икесе дә төс-бит ягыннан Сөббухның үзенә охшап үсеп киләләр, озын буйлы буласылары хәзердән үк сизелеп тора. Әлфия, олы бала буларак, аларга һәрвакыт күз-колак инде. Сөббух шуңа күрә «командировка»дан алып кайткан күчтәнәч һәм бүләкләрдән аңа өлешне күбрәк чыгара. Мондый балалар турында бераз хыялланып алсаң да зыян итмәс: Әлфия тормышта ныклы итеп, үз урынын табар; Сания, югары уку йортын тәмамлап, илебез өчен кирәкле белгеч булыр; Нәфисә Зәйдә «Дуслык байрагы» газетасында дубляжда татар телен бик яхшы белүче корректор булып эшләр, аны коллективында «аяклы энциклопедия» булганга да хөрмәт итәрләр. Нәфисә белән бергә эшләгән хезмәттәше Рәзинә Хаҗиәхмәт кызы Ахунова (Вәлиәхмәтова) аның дусты булыр, күп еллардан соң аның турында истәлек-хатирәләр дә сөйләр әле...

Сөббух, 1961 елда «Социалистик Татарстан» газетасына штаттан тыш хәбәрче булып күчкәч, «Беренче яз» дип аталган беренче романын камил рәвешкә китереп тәмамлый. Әсәр киләсе елда 475 битле калын китап булып, унбиш мең данәдә Таткнигоиздатта басылып та чыга. Үзе кулга алынасы елны нәшриятка әзерләп тапшырган ике китабын санамыйча, биш китап һәм зур роман авторы Сөббух Рәфыйков – 1962 елның 25 маеннан СССР Язучылар берлеге әгъзасы. Язучылык билеты аңа шул елны 20 июньдә (фактик туган көнендә) тапшырыла.

Шагыйрь Галимҗан Латыйп 1963 елны «Социалистик Татарстан» газетасының 11 июль санында басылган «Гел юлда, гел хәрәкәттә» исемле мәкаләсендә Сөббухны тәҗрибәле журналист һәм чарланган каләм остасы буларак ачып бирә.

«Беренче яз» романы китап булып басылып, өч ел вакыт үткәч, тәнкыйтьче Флүн Мусин, «соң булса да, уң булсын» дигәндәй, 1965 елның 18 июлендә «Социалистик Татарстан» газетасында «Үткәннәр эзеннән» дигән рецензиясен бастыра.

1966 елда «Авыл иртәсе» исеме белән Сөббух Рәфыйковның икенче романы да

Татарстан китап нәшриятында дөнья күрә. 359 биттән торган китап шулай ук зур тираж белән басыла. Яза-яза, Сөббух язу остасына әйләнә бара. Язучы каләменең туган тел сакчысы булуын тойган хәлдә, ул үзенең иҗатында тел байлыгын мул итеп кулланырга тырыша. Аның зур күләмле романнары татар милләтенә рухи тәрбия бирергә тиеш. Чөнки язучы кеше – халыкны иярткүче дә бит әле.

Сөббух Рәфыйковның яңа романы буенча Сарман мәдәният йортында китап укучылар конференциясе үткәрелә. Зәйдә яшәп иҗат итүче автор анда үзе дә катнаша. Соңыннан Дамир Гарифуллин аның ата-бабалары кемнәр булуын сораштыра. Язучы үзенең нәселе чалмалылардан һәм чалмасызлардан гыйбарәт булуын, үзенең чалмасызлардан икәнен әйтә... Күп еллар үткәч, Дамир, Казан һәм Уфа архивларында казынып, Сөббух Рәфыйковның шәҗәрәсен төзиячәк. Таиш – Габдерәфыйк – Мифтахетдин – Мөхәммәтвәли – Мөхәммәтһади – Габделсөббух...

Сөббух ике романын да колхоз тормышына багышлый. Беренчесендә 1930 елдагы аерым хуҗалыктан күмәк хуҗалыкка күчү вакытларын тасвирласа, икенче романында шул элек төзелгән колхозларны 1960 елларда эреләндерүнең катлаулы яклары белән таныштыра ул.

Хак икән: бөркетнең канаты очканда ныгыса, язучы яза-яза остара. Сөббух шунысын да белә: ташка басасы әйберне язганда, һич ашыгырга ярамый, аны кат-кат эшкәрткәндә дә, бик таманга туры килә әле. Дөрес, беренче тапкырында ук берәгәйле итеп язарга тырыша ул. Чөнки кулың белән язган әйбер өчен башың белән җавап бирәсең. Читтән карап торганда, бәлки, язу эше бик ансат шөгыль булып та тоеладыр. Физик эш түгел бит: күтәрәсе юк, төшерәсе юк. Әйе, илһам килгән мәлләрдә, аның кулындагы каләм ак кәгазь битеннән йөзеп кенә бара, әйтерсең бии. Сөббух «аны язам, моны язам» дип, алдан шаулап йөрми: уйлый, планлаштыра һәм шуны үти. Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән бер өлеш талантына тугыз өлеш тырышлыгын өстәп, үҗәтләнеп иҗат итә. Чөнки аның (ничәнче тапкыр шулай уйлавы инде!) егерме ел язмый торган бушлыкны һич кичекми тутырасы, үз сүзен әйтеп-язып калдырырга өлгерәсе бар...

Сөббух үзенә яшәү һәм иҗат итү өчен Зәй посёлогын сайлап дөрес эшли. Беренчедән, язучы һәм журналист өчен иң мөһим трибуна, әйтергә кирәк, монда әзме-күпме иҗат мәйданы булган «Кызыл Зәй» район газетасы редакциясе эшли. Ул 1935 елның маенда ВКП(б)ның Зәй район комитеты һәм хезмәт ияләре депутатларының Зәй район советы буларак оешкан. Җитмәсә, 1957 елдан газетаның күләме арта, дүрт полосалы, ягъни басма текст дүрт битле булып чыга. Ләкин 1963 елның 1 февралендә Зәй районы таркатылып, территориясе Әлмәт һәм Чаллы районнарына бирелгәннән соң, «Кызыл Зәй» газетасы чыгудан туктаячак шул... Шулай да 1972 елның 1 ноябрендә Зәй районы яңадан торгызылып, икенче елны 7 июльдә район газетасы «Дуслык байрагы» исеме белән рус телендәге «Знамя дружбы» газетасының дубляжы буларак, нәшер ителә башлаячак. 1990 елның 9 июненнән «Зәй офыклары» исеме белән мөстәкыйль татарча газета чыга башлаячак...

Зәйне сайлавының икенче сәбәбе нигезлерәк, әлбәттә. Чөнки Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәгендә нефть чыгару сәнәгате колач җәеп үскәнлектән, күп күләмдә электр энергиясе таләп ителә. Шуңа күрә СССР Министрлар Советы 1955 елның 17 маендагы күрсәтмәсендә Зәйдә Дәүләт станциясе төзергә дигән фикерне терки. Һәм бер елдан ГРЭС Дала Зәе елгасы буенда төзелә башлый. Аның белән бер вакытта Зәй (Иске Зәй) янында Яңа Зәй энергетиклар посёлогы төзелә. Чөнки ГРЭС – шәһәр барлыкка китерүче предприятие. Зәйдә яшәүче Сөббух, гаиләсенә өстәмә керем булсын дип, ГРЭС төзүчеләренең тулай торагында тәрбияче булып эшкә урнаша. Эшчеләр белән аралашып, алар турындагы күләмле очеркларын республика газетасында бастыра. Очерк жанры авторның үз күзе белән күргәнне тасвирлауга гына корылса да, персонажның һөнәре җитештерү тармагы белән бәйле

булганлыктан, Сөббухка, куна-төнә дигәндәй, ГРЭС төзелешендә булырга туры килә. Чөнки Зәй төзүчеләре һәм монтажчылары ел саен икешәр энергия блогын файдалануга тапшырып торалар. Төзелеш гөрли, эш кайный. Сөббух аларның эш урыннарында гына түгел, ялгызаклар яшәгән тулай торакта һәм гаиләләләр торган баракта да булырга вакыт таба. Ул үз персонажларының эш-хәрәкәтләрен, уй-фикерләрен, хәтта үзара мөнәсәбәтләрен дә алгы планга куя. Очерк коры фактлардан гына тормасын өчен ГРЭСның директоры һәм баш инженеры Владимир Иванович Бутин кабинетына кереп, производствога кагылышлы мәсьәләләр буенча «дәресләр» дә алып чыгарга туры килә аңа. Төзүчеләрнең һәм энергетикларның хезмәтен эчкәрәк кереп, төптәнрәк алып сурәтләргә омтыла. Чөнки йөрәктән чыкмаган йөрәккә керми. Шуңа күрә ахырда җиңел булсын өчен Сөббух һәрвакыт иң элек авырын эшләп куя. Һәр язганында мәгънәле, мөһим сүз кирәк. Буш сүз язып, вакытын әрәмгә үткәрү һич ярамый. Дөрес, ул күп яза, ләкин фикерләре тыгыз булып оеша. Күтәрә белмәгән күп күтәрер, диләрме әле? Юк, монысы Сөббухка кагылмый. Ул тоташ язмаска тырыша. Көн белән төнне бутамый. Иртән торып, башы авыртмаганда, күбрәк итеп язып кала. Баш авыртуы бертуктаусыз уйлануларыннандыр. Әйе, ул очерк персонажлары белән «яши» бугай инде. ГРЭС төзелешендә дә берөзлексез эш кайный. ГРЭС директоры Николай Александрович Баныкин да үзенең бөтен көчен куеп җитәкчелек итә. Зәй ГРЭСының соңгы уникенче энергия блогы да 1972 елда сафка бастырылачак. Электр станциясе проектта каралган 2400 МВт егәрлегендә эшли башлаячак. Алдынгы хезмәткәрләр дә, һичшиксез, мактауга лаек. Сөббух менә шулар турында яза да инде. Ул очеркларны бергә туплаганда, үзе бер калын китап булыр иде. Сөббух, шулай әкрен генә, өченче романына да материал туплый. Ниһаять, 408 биттән торачак «Тын елга буенда» китабы язылып тәмамлана. Роман башта, гадәттәгечә, язучылар журналы булган «Казан утлары»нда 1971 елның 2–6 нчы саннарында басылып, укучыларның игътибарын үзенә җәлеп итә.

Шушы журналда Сөббухның Ибраһим Салахов турында «Үрләргә кыю атлап» дигән мәкаләсе август санының 90–91 нче битләрендә басыла. Репрессия тоткынлыгының кеше чыдамаслык газапларын кичергән дустына 30 августта алтмыш яшь тулачак. 1956 елның көзендә Казанда бергә очрашкан вакытта Ибраһим үзенең Колымада күргәннәрен язарга җыенуын әйткән кеше бит. Беркемгә дә сиздермичә язып, ышанычлы кешедән өч нөсхәдә машинкада бастырып, һәрберсен төпләткәннән соң, берсен – Казанга, икенчесен Уралдагы ышанычлы дусларына сакларга җибәрәчәк, ә өченчесен, кат-кат төреп, тимер әрҗәгә салачак һәм алмагач төбенә күмеп куячак ул. Әлбәттә, вакытлыча...

Сөббухның өченче романы журналда басылып, дүрт ай үткәч, язучы Фатих Хөсни «Тын елга буенда...» дигән рецензиясен шул елның 10 ноябрендә «Социалистик Татарстан» газетасында бастыра. Әгәр дә ул ун-унбер көнгә соңарган булса, Сөббух аны беркайчан да укый алмас иде, әлбәттә...

Татарстан китап нәшрияты, 1972 елда китап итеп бастырып чыгару өчен язучының әлеге романын үзенең эш планына кертәчәк. Мәртәбәле китапка авторның портретын да урнаштырачаклар. Һәм Рафаэль Мостафин 1977 елда Татарстан китап нәшриятында чыгачак үзенең тәнкыйть мәкаләләре тупланган «Алга барышлый» дигән китабында Сөббух Рәфыйковның шушы соңгы романына этрафлы тирән анализ бирәчәк. «Тема һәм аның чишелеше» исемле мәкалә 100–105 нче битләрдә урын алачак. Алга таба да газета-журналларда төрле авторларның Сөббух Рәфыйков турында хатирәләре басылып торачак. Зәй шәһәрендә бер урам, Үзәк китапханә аның исемен йөртәчәк. Ул 1957–1971 елларда яшәгән һәм иҗат иткән йортка язучының истәлеген мәңгеләштерә торган мемориаль такта куячаклар. 1991 елда Зәй районы администрациясе башлыгы карары белән Сөббух Рәфыйков исемендәге премия булдырылачак. Язучыны

каләмдәшләре сагынып искә алачаклар, «исеме һәм эше яши» дип сөенәчәкләр. Үзбәк шагыйре Алишер Нәваинең: «Исеме онытылмаган кеше – иң бәхетле кеше», дигән сүзләре нәкъ Сөббух Һади улы Рәфыйковка туры килә дә кебек...

## Соңгы сүз урынына

Тормышта шулай була бит: Сөббух абый Рәфыйков Сарман районында туган, Зәйдә гомер иткән. Мин, киресенчә, Зәй районы Имәнлебаш авылында туган кеше, Җәлил посёлогында мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләдем һәм хәзерге вакытта шунда яшим.

Дамир Гарифуллинның «Норильлаг тоткыны» китабында Сөббух абыйның чынлыкта туган көн датасы 20 июньдә дип язылган урынны укыгач, безнең туган көннәребез дә бер вакытта булуына исем киткән иде.

Минем бу язмам кулына эләгеп, шуны укып чыккан укучы, бәлки, Сөббух Рәфыйковка кагылышлы материалларны, шулай ук истәлек-хатирәләрне бергә туплап язарга алынуымның сәбәбен белергә теләр.

Чыннан да, сәбәп нәрсәдә?

Мин, мәктәптә укыганда ук, иҗат кешеләре белән кызыксына идем. Асия Гыйниятуллина төзеп, Татарстан китап нәшриятында 1970 елда басылып чыккан «Писатели Советского Татарстана» белешмә китабында Сөббух Рәфыйковның портретын күргәч, иң беренче мин аны телевидение дикторы Рөстәм Нәбиуллинга охшаттым. Монда киресенчә язсам, анысы дөресрәк буладыр, мөгаен. Шул китаптан Сөббух абыйны Сарман районы язучысы дип белеп калдым. Татар телендә 1958 елда нәшер ителгән белешмә китапны күргәнем булмады. 1986 елда Рәис Даутов белән Нәзәһәт Нуруллина төзегән «Совет Татарстаны язучылары» дигән белешмә китапта Сөббух абыйның Зәйдә яшәп иҗат итүе турында язылган иде. Күп еллар үтте. Тора-бара аның язучы Саимә апа Ибраһимовага авылдаш булуы ачыкланды. Аннары Дамир Гарифуллинның «Норильлаг тоткыны»н, ә аңа кадәр Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре»н укырга туры килде. Быел үземнең авылдашым, Зәй районы газетасында 1978–1997 елларда корректор, 1997–2000 елларда редактор булып эшләгән Рәзинә апа Ахунова миңа Хәлимә апа һәм кызлары, бигрәк тә Нәфисә турында бик күп мәгълүмат бирде. Нәфисә белән бер коллективта эшләгәнлектән, Рәзинә апа Сөббух абый яшәгән һәм иҗат иткән йортта булган. Хәлимә апа, ачык йөзле һәм кунакчыл хуҗабикә буларак, аның килүен бик яраткан, Нәфисә белән дуслыкларын хуплаган. Тиз генә чәй табыны көйләгән, салмак кына, рәхәт итеп кенә сөйләшкән. Рәзинә апа әйтүенчә, Әлфия әнисе кебек уртача буйлы, ә Сания белән Нәфисә, әтиләренә охшап, озын буйлы булганнар. Әлфия яшәргә Чаллыга күчкән. Сания үзенең гаиләсе белән гел Зәйдә яшәгән. Аның тормыш иптәше, Зәй тимер-бетон корылмалар җитештерү заводы директоры булып, җаваплы урында эшләгән. Сания шул заводта баш технолог булган. Бөгелмә шәһәрендә туып үскән Рәшит Закиров, 1974 елда Казан инженер-төзүчеләр институтын «инженер-төзүче-технолог» белгечлеге буенча тәмамлап, юллама белән Зәйгә эшкә җибәрелә. Башта мастер, начальник, баш технолог баскычларын үтә. Аның рационализаторлык таланты ачылып, җитештерелгән продукциянең сыйфаты күтәрелә, эшчеләрнең хезмәт шартлары яхшыра. 9 ел баш инженер вазифасын башкарганнан соң, Рәшит Зәкуан улын үзе эшләгән Зәй тимер-бетон корылмалар җитештерү заводына 1988 елда директор итеп билгелиләр...

Нәфисә, әтисе кебек, редакцияне үз иткән. Ул тирән һәм күпкырлы белемгә ия булган. Хезмәттәшләре нәрсә турында сорасалар да, шунда ук җавабын әйткән. Нәфисә Сөббух абыйның да иң яраткан кызы булган. Пөхтә, төгәл Нәфисәнең бөтен нәрсәсе тәртиптә икәне эш барышында нык сизелгән. Ул һәрнәрсәнең идеаль булуын теләүче

максималист кеше булган. Кул эшләрен аеруча яраткан. Рәзинә апа белән икесе бергә гөмбә җыярга да еш барганнар. Нәфисә әтисе үзләрен шулай урманга алып барганын искә алган. Тик артык күп укып, күп белүдән аның башына көч килгән. Ул, авыру сәбәпле, яраткан эшеннән киткән. Аннары Сәвәләй авылы егете Михаил белән яшәргә дип, алар Чаллы шәһәренә күчкәннәр. Эшкә батыр гаилә башлыгы Нәфисәгә дә калкан кебек җил-яңгыр тидермәгән. Кызганычка күрә, Нәфисә вафат булган...

Сөббух абый турында материал туплаганда, аның турында бик күп мәгълүмат белдем. Зәй шәһәре Үзәк китапханәсе мөдире Сәрия Батыршинага һәм «Зәй офыклары» газетасының мөхәррире Энҗе Әгъләмовага, Зур Нөркәй авылы мәктәбендәге Сөббух Рәфыйков музее хезмәткәрләре Ләйлә Шәйхеразыева һәм Зөлфия Зариповага да үтенеч белән чыгарга туры килде. Минем үтенечемне кире какмадылар, барысы да булдыра алганча ярдәм иттеләр. Сөббух абыйның дәвамчылары турында да бик беләсем килә иде. Шул хакта сорашкач, Зур Нөркәй мәктәбе директоры Ләйлә Назыйм кызы миңа Айнур Закировның исемен әйтте. Мин үз чиратымда Сәрия Миңнегалиевнадан язучының оныгы Айнур Закировның телефон номерын белештем. Һәм Айнур белән сөйләшеп, менә нәрсәләр белдем.

Хәлимә апа 1918 елның 9 маенда туган булган икән. Нинди туры килү! Сөббух абый 1956 елның нәкъ 9 май көнендә реабилитацияләнгән.

Кызлары Әлфия 1942 елның 26 июнендә туган. Ул, югары белем алып, Чаллы шәһәрендәге мәктәптә немец теле укыткан. Тормыш иптәше Шәфкать белән ике ир бала тәрбияләп үстергәннәр. Ренатка алтмыш яшь. Ул сәүдә вәкиле булып эшли. Тормыш иптәше Равия белән Владимир һәм Тимур исемле ике ир бала тәрбияләп үстергәннәр. Маратка илле ике яшь. Ул – «Автосервис» хуҗасы. Тормыш иптәше Лилия белән Вероника һәм Виктория исемле ике кыз бала тәрбияләп үстергәннәр. Бибишевларның икесе дә Чаллыда яшиләр. Шәфкать вафат булгач, Әлфия Евгений белән гаилә корган.

Мин телефон аркылы сөйләшкән Айнурның әнисе – Сания Сөббуховна, әтисе – Рәшит Зәкуанович. Икесе дә 1949 нчы елгылар. Казан инженер-төзүчеләр институтында югары белем алганнар. Айнур үзе 1987 елда туган, Зәй шәһәрендә автоэлектрик булып эшли. Аның тормыш иптәше Зөлфия 1990 елгы. Ул – маникюр ясау остасы. Уллары Әмирхан 2012 елда туган, аңа быел унбер яшь. Ул, әтисе янында йөреп, техника серләренә өйрәнә икән. Кызлары Айлинәгә быел 2023 елда биш яшь тула, ул киләсе елга бию түгәрәгенә йөриячәк. Айнурның апасы Эмилия 1974 елгы, гаиләле. 2015 елдан – Кырымда, 2018 елдан Мәскәүдә яши. Ул – «ЗВИ» заводында хезмәт иминлеге буенча белгеч. Аның тормыш иптәше Игорь МЧСта эшли.

Нәфисә белән Михаилның кызлары Таня Чаллыда яши. Ул тормыш иптәше Виталий белән дүрт бала тәрбияләп үстерә. Таняга кырык биш яшь.

Айнур миңа хәтта шәҗәрә төзерлек тулы мәгълүмат бирде. Рәхмәт аңа, рәхмәт.

Мин язмамны репрессия давылы кагылган язучыларга багышладым. Аларның барысының да теге яки бу дәрәҗәдә Сөббух Рәфыйков белән юллары кисешкән. Янәшәсендәге кешеләр янында Сөббух абый төрле яклап ачыла. Бусы да бик мөһим.

**Рухия АХУНҖАНОВА**

**Төзәтү.** *Узган санның (2023 ел, июль) 157 нче битендәге «Сөббухның тоткынлык газаплары Казанда Кремль астындагы Пләтән төрмәсендә башлана» дигән җөмләне «Сөббухның тоткынлык газаплары Пләтән төрмәсендә башлана» дип укырга.*

# КҮҢЕЛ КУШУЫ

*Хат язарга яратмыйм. Әмма үземә каян да булса хат килеп төшсә, конверт ачкандагы билгесез рәхәтлек мизгеле гомер буена кабатлана килә.*

*Ни кызганыч, бу гасырда инде кулга каләм-кәгазь алып, сырлап-чуклап хат язулар бөтенләй бетәр, ахрысы. Кайчандыр хат язганнар бит тәмләп, иркенләп дип, яңа буын яшьләре йә мыскыллап, йә кызыгып искә алырлар безнең дәверне.*

*Узган гасырлардагы классикларның том-том хатларын кулга аласың да... шаккатып куясың: булган бит дәверләр!*

*Атлы заманнан чыккан хатлы заман.*

*Әйе, Вакыт – ат тизлегеннән алга ыргыла алмаган. Шәм утлары күзне чагылдырып янмаган. Каурый каләм бармакларны ашыктырмаган. Салмак-сабыр яшәү рәвеше, ел фасылларына карап көйләнгән уй-тәэсирләр мәңгелеккә табыну бизмәнендә тирбәлгән.*

*Билгеле бер яшькә җиткәч, әдәби әсәр укып, матур алдану тәэсире үтмәсләнә, язучының көндәлекләрен, хатларын күбрәк йотылып укыйсың. Анда – тере тормыш. Әдип хатларында үз табигыйлегендә кала: үзеннән көчлерәк тә булып күренми – ничек бар, шулай!*

*Кеше белән кеше арасын бәйләүче, ерак араларны якынайтучы кош-хатларның тәүге мәртәбә каурые йомыла башлавы – телеграф-телефон уйлап чыгарылып, гамәлгә кергән заманнарга туры килә. Хәзер инде электрон почталар, кесә телефоннары, компьютерлар заманында – бөтенләй башка. Кыскалык, ашыгу, тиз генә фикереңне җиткерергә тырышу, җылы кәгазь урынына салкын экран – телдәге хисне, тәэсири сүз куәтен, шагыйранә тойгыларны бөтенләй йолкып ташлады. Һәр сүз артында акча чылтыравы ишетелеп торганда, нинди хис булсын, ди. Кыскалык, кыскалык! Бардым, күрдем, җиңдем. Йотып җибәр шундый хәбәрне. Информация дип атала ул. Утырып уйлар уйлар өчен үсмәгән буең.*

*Әйе, әллә нинди техникалар гамәлгә керә, ерак планеталарга сәяхәтләр күзаллана, могҗизага тиң ачышлар ясала. Ә тере кешенең асылы, холык-фигыле, яшәү рәвеше камилләшәме? Студент чакта мин Энгельснең «цивилизация шундый бер ноктага җитәр, аннары кире кайту процессы башланыр» дигән фикерен укып шаккаткан идем. Җәя тоткан неандерталецка таба кайтып баруыбыз күз алдыма килгән иде. Әллә соң без чынлап та кайтып барабызмы?.. Телдә хәбәр бирүче сүзләр генә калыр да... без җәнлекләр кебек күз карашы, койрык селкетү, йон кабарту кебек хәрәкәтләр белән кыска гына арада аңлаша башламабызмы?..*

*Чехов кебек том-том хатлар язган әдипләр дөнья классикасында шактыйдыр. Андыйлар янәшәсенә бездә Аяз Гыйләҗевны гына куеп була. (Аның бүген дә түш киереп йөрүче кайберәүләрне салып таптаган, үз заманы вакыйгаларын кайнар фикер иләге аша үткәргән хатларын матбугатта чыгарырга әле дә җөрьәт итә алмаган редакторлар шактый).*

*Үтә бер тәм белән, килештереп хатлар язучы берәүне генә беләм: Рәдиф Гаташ. Редакциягә кайчан килеп кермә, башын кыңгыр салып, дога укыгандай онытылып, сәҗдәгә китеп хат юллары тезеп утырган мәле була иде аның.*

*«Хат язардай шәхесләр бетеп бара...» – ди Гаташ, моңсуланып. Үз чорында Ауропа әдәбиятын төбенәчә «эчеп» тәрбияләнгән шагыйрьнең табыну яссылыгы башка шул...*

*Менә мин, нәүмиз-моңсу уйларга бирелеп, архивымны актарып утырам. Катлы-катлы какланган хатлар. Бер-бер артлы ачам, укыйм. Хәтер уяна, таныш йөзләрне*

*күрәм, тавышларын ишетәм. Кайберләрен кичә генә язып салганнардыр кебек, югыйсә авторларының бу дөньядан киткәннәренә дә шактый еллар узган шул инде. Бу – саргайган хатларда әкрен генә суына барган кадерле сүзләрне кабаттан уятасым, дөньяга чыгарасым килә икән, димәк, үзең хәл ит, боларга – син хуҗа, дип, күңел шулай куша, фатихасын бирәдер.*

**Марсель ГАЛИЕВ,**
*Татарстанның халык язучысы.*

## Мостай Кәрим хаты

Хөрмәтле Марсель! Күп сәлам сиңа. Китабың, игътибарың, җылы сүзләрең өчен рәхмәт.

Шаукымлы, җилле китап язгансың, үзең болай шаталак *(тиктормас, тынгысыз – **М.Г.**)* булсаң да, иманлы, әдәпле китап язгансың. Үзеңнән дә шәбрәк, үзеңнән дә акыллырак булырга тырышмагансың. Тәүдә актаргалап утырдым да, бара торгач, Хуҗа Насретдинның картузы шикелле, бөтенләй укып бетердем.

Китапның ни өчен Кипр аша килүен дә аңладым. Синең даның белән җылынып, горурланып, Кипрда яшәүче поклонникларыңа – төрекләргә һәм грекларга алып баргансың да аны, ул утрауда поклонникларың булмагач, миңа җибәргәнсең. Шулай итеп, бүрем улады минем.

*(Бер төркем галимнәр белән Кипрның төрек ягында сәяхәт кылган чакта Уфа галиме Песәнкин аша Мостай агага юллаган идем ул китапны. Бераз шаяртып, Россия почталарына ышанмау сәбәпле, ындыр артына чыгып, Кипр аша җибәрергә булдым китабымны дигән кебегрәк сүзләр дә язган идем. Мостай аганың шуңа ишарәсе. – **М.Г.**)*

Күңелгә ятып җитмәгән ике генә нәмә очрады. Муса Галинең чак кына хәтерен калдыргансың. Бусы бер. Икенчесе шул: Р.Гамзатов, М.Кәрим, К.Кулиев, Д.Көгелтиновларны узып, алга чыгарга кем дә кыймый иде, дисең. Ниндәй аламалар! Алга чыгармайлар! Ә бүтәннәр, бахырлар, шундый юашлар. Алга чыгарга оялалар... Акыллы башың белән ахмак сүз сөйләйсең. Әдәбият ул мәчеттәге җомга намазы түгел лә – кемгә беренче рәт, кемгә бишенче рәт тәгаенләмәгәннәр.

*(«Кыймый иде...» диюем, йомшартып, киная белән әйтелгән иде. Мостай аганы тынычсызлаган фикерләр түбәндәрәк булгандыр бәлки. Әлеге исемнәрдән соң китабымда мондыйрак фикерләр теркәлгән иде: «Алар каршына дан һәм бүләк бирү баскычлары эзлекле чиратка куелган, шул ноктага килеп җиткәндә, «дөрес» әсәр, «дөрес» мәдхия уку мәҗбүриятеннән азат була алмыйсың. Кремль җылы куенында юкка гына асрамый, партия чираттагы бүләкне сузган саен манежда бер шакмак шикәр өчен саллы гәүдәсен селкетеп биегән аю кебек реверанс ясарга тиешсең. Ни хәл итәсең, җәмгыяте шундый, нәфсе җепләре хакими көч кулында, шуны тартып, кеше белән уйныйлар. Толстой кебек «икенче патша» дәрәҗәсендә йөрү өчен граф титулы гына җитми, бәйсезлек биргән биләмәң-байлыгың да булырга тиеш. Бер акыллысы: «Әгәр Толстой коммуналь фатирда яшәсә, Салтыков-Щедрин булыр иде...» – дигән әнә. – **М.Г.**)*

Ни өчен мин моңа игътибар иттем? «Перестройка» башлангач, «Советская культура» газетасында бу мәсьәлә буенча тач синеңчә итеп, синнән дә зирәгрәк Ямил Мостафин дигән берәү язып чыккан иде. Аннан соң безнең Башкортстанда да бу турыда син китергән схема буенча зарланучылар булды. «Һәр халыктан бер корифей...» Минем аңлавымча, иҗат дөньясында шушы 4-5 мең елда корифейларны әмерләр яки фәрманнар белән тәгаенләмәгәннәр. Гомерлар, Дантелар, Һётелар, Пушкиннар, Тукайлар... Бу инде син санаган исемнәрне әлеге халык йөзәр, меңәр ел

үзенең корифейларын раслый. Бу безнең карамакта түгел. Кипр төрекләре әйтмешли: «Аңлата белдемме?».

Китабың – күзәтүләрең, фикерләрең мавыктыргыч. Афәрин, Марсель!

Акыллы кешегә мөрәҗәгать итәсе килгәндә, сине сагынам да үземне уйлаем.

Кочаклап калам.

*Мостай Кәрим.*
*15 декабрь, 1999 ел.*

## Кояш Тимбикова хаты

И Марсель!

Хава Сафинаның 800 битлек өр-яңа романын уку «ләззәтеннән» зиһеннәрем тәмам чуала дигәндә, күк капусы ачылгандай булды – бүлмәгә синең саф кышлы урман куеныннан җибәргән хатың иңде. Рәхмәт.

Шулай да ике адым җиргә китеп, тыштан ялтырарга тәмам өйрәнеп җиткән халыкларга мөкиббән булып, Казанны әллә нинди гөнаһларда гаепләргә маташа башлавың ошап җитмәде. Хәер, син аны юри генә язгансың бугай: хатыңның 99,9 %ы Казанның бөеклеге, аның берсеннән-берсе кыйммәтрәк кешеләре турындагы фаразлардан тора лабаса.

Мондагы чын хәлләр болайрак: минем бүлмәдә Абдулла *(Сәләхетдинов. – **М.Г.**)* Дом прессы ишеге төбендә таеп егылып, аягын сындырып, кабат больницага керде. Солтан *(Шәмси. – **М.Г.**)* әле һаман больницада. Мөдәррис Вәлиев «больничныйда» иде дә партиягә керү җыелышына терелеп чыкты. Аны кандидат итеп алганнар. Мин ул җыелышка бармадым, минемчә, ул көнне түр башында синең гариза ятарга тиеш иде. Ярый, анысы минем эш түгел, күрәсең, синең фикер башкачадыр. Мин үземнең беркатлылык белән генә адым саен сине димләп йөрим, җүләр, ә синең ул мәсьәләгә карашың бәлки бөтенләй башкачадыр. Нигә бәйләнергә кешегә? Бер карасаң, тиз генә эшләп ташлый торган нәрсә түгел бит ул партиягә керү, шул ук иман бит инде ул. Партҗыелышка бармагач, күп яңалыкларны кешеләр аша гына ишетергә туры килде – Мәскәү ягына ук язып җибәрерлек фикер чыкмаган, ахрысы.

Роберт Миңнуллинның квартира мәсьәләсен Ләбибә апа ерып чыккан, алганнар, тик Роберт үзе Зәки абыйга *(Зәки Нури. – **М.Г.**)* үпкәләп, аннан рөхсәт-фәлән дә сорап-нитеп тормыйча, 12 көнгә Буага китеп барган. Миңа: «Китәм, белеп тор!» – дип кенә әйтеп китте. «Ул бит безгә үпкәләгән, Зәки абый», – дигән идем, Зәки абый да ризалашты бугай.

Рәдиф Гаташ – Чирмешәндә, яшьләргә шигъриятнең үзенә дә билгеле булмаган серләре турында доклад сөйләп, әсәрләренә анализ ясап йөри. Ул бөекләр шайкасында мин дә булырга тиеш идем дә, Зәки абый җибәрмәде. Редакциядә кеше юк. Сезнең бүлмәдә Рәшит Гәрәй хакимлеге рәхәт чигә. Ринат *(Мөхәммәдиев. – **М.Г.**)* Чирмешәнгә бармады, аның бер минут та буш вакыты юк: әле Мансур Хәсәнов үтенече буенча Совминга бара, әле ОК КПССка кереп, Мирзаһит Фәтхиевич *(Вәлиев – КПСС Өлкә комитеты өченче секретаре. – **М.Г.**)* белән киңәш-табыш итешеп чыга.

Язучылар Союзында Фәрваз абыең әле һаман үз властен җәеп җибәрә алмыйча азаплана, иртә якта шактый батыраеп тотына, төштән соң авызын ачкан гына була, тәгәрәп, Гариф Ахунов килеп төшә. Кичә Гариф абый съездга китте. Кыш бабайга сәлам әйтергә кушкан идем, онытмаса ярый инде.

Сине гашыйк иткән Мостафа *(Мостай Кәрим. – **М.Г.**)* абый да съездга киткәндер, мөгаен. Менә күңелсез булып калгандыр инде. Ничего, түзәрсең, аңа гашыйк булып өзгәләнүчеләр бер сез генә түгел, шактый күп алар, тик берсе дә егылып үлмәде.

Шигыреңнең «...яшь кар җылысы» дигәне әйбәт, аннары соңгы строфасы шәп. Синең ул бөек шәхесләр белән мавыгу чирең кайчан үтәр икән, Мәскәүдә берәр даруын

таба алмассыңмы? Гадиләргә игътибарлырак була башлар идең бәлки, бер-ике төймә дару кабып җибәр.

3 нче санның корректурасы килде. Миргазиян Юныс тавышсыз-тынсыз гына үтте. Шөкер. Тик ул автор университет студентлары алдында безнең редакцияне хурлап чыгыш ясаган дигән хәбәр ишеттем дә җен ачуым килде. «Шедевр язган идем, редакция ...ук итеп чыгара», – дип сөйләгән, имеш. Әй, кадалып китсен даһилыгы, шулай да ул әсәрнең дөнья күргәненә инде тәмам ышангач, җанга рәхәт булып китте.

Син, төрле хәйләләр корып («...аерылуы кыен, фәлән-төгән»), повестеңны язып бетермичә кайтырга чамалап ятма, яз, тәмамла. Шомартуы-фәләне монда да, бичара Казанның кары кара урамында йөри-йөри дә эшләнә аның. Симеон Бикбулатович крепосте кебек үк булмаса да, Казан бер дә төшеп калган шәһәр түгел, Руза урманының Азнакай урманнарыннан хозуррак булуы, *вообще*, адәм көлкесе. Ул сүзне башка кешегә әйтмә, оятлы булырсың, ә мин бер юлга, ишетмәмешкә салышып үткәреп җибәрермен. Яме?

Да! Гәрәй Рәхим керде. Себер бае кебек очраган бер кешегә кесәсеннән чыгарып, бүләк өләшеп йөрде – пиш.машинка лентасы. Баюы чиктән ашкан. Башында – мәче теле хәтле генә кепка, өстендә – күн бишмәт, вельвет ыштан, марсианин дип торырсың. Көлеп җибәргәч кенә, үзебезнең керәшен икәнен таныдым. Белмим, тагын бер ел Мәскәүдә торса, бетәр ул, көлүе дә бетәр, үзе дә.

Синең отпускада икәнеңне белделәр, ахры, ишекне ватып кереп, минем сигаретлар коллекциясен алып чыгып киттеләр. Тәмәкеңне ташлап кайт!

Разилгә *(Разил Вәлиев. – **М.Г.**)* сәлам, йоклап ятмасын, ул болай да тутырган тавык кебек. Чаңгыда йөрисезме соң?!

Ярый, хәзергә җитәр. Казанның һәр кешесе турында том-том хәбәр язарлык, мин генә ерып чыгалмам. Хуш, сау бул.

*Кояш.*
*20.02.81.*

## Нәҗар Нәҗми хаты

Марсель!

«Догалы еллар»ыңны рәхәтләнеп укып чыктым. Күпме күзәтү, күпме осталык – сокландыргыч! Миңа таныш, мин белгән кешеләрне үзеңчә ачу бик зур тәэсир калдыра.

Мин дә шуның шикеллерәк, синеке шикеллерәк әйбер өстендә эшлим, әмма минеке синеке кебек шәп булмаячак, чөнки синең фикерләүләреңдә яшьлек очкыны чәчрәп тора.

Соклануларым турында матбугатта да язып чыгар идем дә, гафу ит, картайдым, эшләве авырайды. Яңа әйберемне дә бик авырлык белән язам. Врачлар эшләргә кушмасалар да, аларны тыңлаган юк.

Язасы сүзләрем шул иде. Яңадан-яңа зур уңышлар телим сиңа!

*Нәҗар абыең.*
*3.04.98.*

*Асия Измайлованың тууына – 120 ел*

# ТӘҮГЕ ЙОЛДЫЗ



Татар профессиональ җыр сәнгатенә нигез салучыларның берсе, җырчы һәм педагог, Татарстанның халык артисты Асия Измайлованың (1903–1993) тууына – 120 ел.

Милли сәнгатебез күгендә якты эз калдырган шушы күренекле шәхесне тулырак итеп күз алдына китерү өчен без Татарстанның халык артисты Рафаэль Ильясовның «Тәүге йолдыз булып кабынды» исемле мәкаләсенә мөрәҗәгать итәрбез («Шәһри Казан» 2013 ел, 16 июль). Мәкаләдән юллар:

«Асия Сембер шәһәренең тимер юл станциясе машинисты Сафиулла ага гаиләсендә дөньяга килә. Буйга җиткәч, туку фабрикасына эшкә керә. Авыр тормыш шартлары Асиядә булган талант очкыннарын сүндерә алмый: аның чишмәдәй чылтырап аккан саф тавышы көннән-көн ныгый бара һәм үзенә киңрәк мәйдан таләп итә башлый.

Бәхетенә, 1919 елда Сембердә татар драма театры оештырыла. Үсмер кыз шушы театрның артистына әверелә. Ул Гражданнар сугышының ахырына кадәр фронтта булып, туган каласы Сембергә кайта. Тиздән Мәскәү дәүләт филармониясенә эшкә алына.

Казандагы беренче чыгышы 1920 ел ахырында була. Халык яшь җырчыны яратып кабул итә. Газиз Әлмөхәммәтов, Асия Измайлова уңышларына шатланып: «Синең саф чишмәдәй моңлы, көчле тавышың, тыңлаучыны сихри дөньяга алып китә, аларда дәрт, рухлану тудыра», – ди. Күренекле рус язучысы А.М.Горький, А.Измайлованың җырларын ишетеп, җырчының дәфтәренә: «Свобода любит красоту, а красота свободу», – дип язып бирә».

Асия Измайлова 1927 елдан Казанда эшли башлый. Нәкъ шушы елда Татарстан радиосы оештырыла. Аның тавышы беренчеләрдән булып эфирга чыга. 1934–1938 елларда Мәскәү консерваториясе каршында оештырылган опера студиясенә укырга керә. Бу елларда ул Муса Җәлил белән тыгыз иҗади элемтәдә яши.

1939 елда Казанда татар опера театры оештырыла. Бу тарихи вакыйга да Асия Измайлова исеме белән бәйле. Ул 1944 елга кадәр шушы театрның төп җырчыларыннан берсе була һәм «Галиябану», «Зәңгәр шәл», «Энҗекәй» кебек музыкаль драмаларда төп рольләрне башкара.

Дәһшәтле сугыш елларында Асия Измайлова фронтта җырчы буларак катнаша, госпитальләрдә җырлый, театрдагы хезмәт хакының яртысын фронт файдасына тапшырып килә. Озак еллар дәвамында Мәскәүнең П.И.Чайковский исемендәге консерваториясендә аерым җырлау классы алып бара, үзенең белемен һәм еллар буена тупланган бай тәҗрибәсен яшьләргә тапшыра.

Асия Измайлованың язмалары Татарстан радиосы фондында бик аз сакланган. Аның сәхнә иҗаты чәчәк аткан елларда тавыш яздырып алу җиһазлары әле булмаган шул. Шуңа күрә без граммофон тәлинкәләреннән күчереп алган җырлар белән эш итәбез. Хәер, техник яктан сыйфаты кайтышрак булса да, шушы язмалар да җырчының кабатланмас тавышын һәм башкару осталыгын бәяләргә мөмкинлек бирер дип уйлыйбыз. Игътибарыгызга Асия Измайлова башкаруында халкыбызның «Сибелә чәчәк» җыры тәкъдим ителә.

*Ләбибә Ихсанованың тууына – 100 ел*

# МИЛЛӘТ БАКЧАСЫ ТӘРБИЯЧЕСЕ



Татар балалар язучысы, прозаик, тәрҗемәче, публицист Ләбибә Фәез кызы Ихсанованың (1923–2010) тууына – 100 ел.

Татарстан Язучылар берлегенең рәсми сайтына күз салсак, булачак әдибә Киров өлкәсенең Нократ Аланы районы Түбән Шөн авылында укытучылар гаиләсендә туып үсә. 1943 елда Казан университетының география факультетына укырга керә. Студент елларында каләм тибрәтә башлый. Соңгы курсларда укыганда, беренче күләмле әсәрен – «Көмеш елга» исемле повестен иҗат итә. Әсәр нәшриятта басылып чыгу белән балалар яратып укый торган китапларның берсенә әйләнә.

1948 елда университетны тәмамлагач, Л.Ихсанова үзен тулысынча әдәби иҗат эшенә һәм журналистикага багышлый: 1948–1978 елларда, ягъни утыз ел дәвамында көндәлек матбугат һәм мәгълүмат чаралары оешмаларында – Татарстан радиокомитетында, Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты бүлегендә, «Ялкын» һәм «Казан утлары» журналы редакцияләрендә җаваплы вазифалар башкара. Шул рәсми хезмәт еллары агышында аның әдәби иҗат хәзинәсе дә яңадан-яңа әсәрләр белән байый бара: «Җир астында җиде көн», «Якты уйлар», «Нияз», «Нияз мәктәптә», «Тал бөгелә», «Робинзоннар лагеренда», «Саралан малайлары», «Ана көндәлеге», «Очкын», «Гөлләр кояшка карый», «Наил, Фаил һәм башкалар», «Ил кызы», «Милиционер малае», «Тузганак» һ.б. повестьлары языла, «Сөйләнмәгән сер», «Тау чәчәге» кебек хикәя җыентыклары басылып чыга.

Ләбибә Ихсанованың Татарстан радиосы фондында да саллы мирасы бар. Аның әсәрләренә нигезләнгән радиоспектакльләр 1970 елларда ук эфирга чыга башлый. Алар арасыннан «Космонавтлар урамы» (сценарий авторы – Юныс Әминов), «Җир астында җиде көн», «Сугыш чукмарлары» дип исемләнгән радиотамашалар безнең көннәрдә дә балалар өчен тапшыруларда актив кулланыла. 1990 елларда Ләбибә ханым безнең радиода балалар һәм яшүсмерләр өчен «Әдәпле булу җиңелме?» дигән тапшырулар циклы алып барды. Ата-анага, әби-бабайларга хөрмәт, туган телгә, туган илгә карата мәхәббәт темаларына багышланган бу чыгышлар хәзер дә актуальлеген югалтмаган.

Журнал укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган язмада исә 2008 елның 20 августында эфирга чыккан тапшыру тәкъдим ителә. Ул әдибәнең 85 яшьлек юбилее уңаеннан әзерләнгән иде. Әңгәмәне тапшыруның авторы, язучы һәм журналист Дания Гайнетдинова алып бара. Бу – Ләбибә Ихсанованың радиодагы иң соңгы язмасы. Әңгәмәдән соң аның «Күз алдымда – якты йолдыз» дигән китабыннан бер өзек Тәлгать Хаматшин укуында тәкъдим ителә.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире*
**Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ФЕДЕРАЛЬ САБАНТУЙ

Кемеровода XXIII Федераль Сабантуй булып узды. Аны Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән Кемерово өлкәсе губернаторы Сергей Цивилёв ачты. Р.Миңнеханов Кемерово татарлары милли-мәдәни оешмасына «Газель» микроавтобусы бүләк итте. Сабантуй уздырырга Татарстаннан 350ләп кешелек зур делегация килде. Бәйрәм Лениногорск осталары тарафыннан әзерләнде. Төп татар утарын да, халык уеннарын да алар оештырды. Мәйданда татарча көрәш бәйгесе, Татарстан сәнгать осталары концерты уздырылды. Кемероводагы Федераль Сабан туенда баш батыр булып Татарстан егете, 2023 елгы дөнья чемпионы, Россия чемпионы Радик Сәлахов калды. Аңа «Лада» автомобиле, 57 мең сум акча һәм, әлбәттә, тәкә бирелде.

### Г.ДЕРЖАВИННЫҢ ТУУЫНА – 280 ЕЛ

Республикабызда бөек рус шагыйре, күренекле дәүләт эшлеклесе Гавриил Романович Державинның тууына 280 ел тулуны зурлап билгеләп үттеләр. ТР мәдәният министры Ирада Әюпова, ТР прокуроры Илдус Нәфыйков, Россия һәм Татарстан Язучылар берлекләре җитәкчеләре, ТР Юстиция министрлыгы, милли-мәдәни берләшмәләр, киң җәмәгатьчелек вәкилләре, әдәбият-сәнгать әһелләре, галимнәр, республикабыз кунаклары Казанда Державинның Лядской бакчасындагы һәйкәленә чәчәкләр салдылар.

Бәйрәм Лаеш районы үзәгендәге Державин мәйданында дәвам итте. Монда Гавриил Державин исемендәге республика премиясе тапшырылды. Быел бу олы бүләк «Очерки истории казанской журналистики (1758 – 1918)» китабы өчен шагыйрь, журналист, документаль телефильмнар авторы Айрат Бик-Булатовка бирелде. Аны ТР Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева тапшырды.

* * *

Г.Р.Державинны Санкт-Петербургта да искә алдылар. Аның музей-утарында чаралар үткәрелде. Монда Татарстан Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь, прозаик, драматург Ркаил Зәйдулла белән шагыйрә, тәрҗемәче Алёна Кәримованың иҗат кичәсе дә булып узды.

### ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТЫНА БАГЫШЛАНА

Төркиядә нәшер ителә торган «Кардәш каләмнәр» әдәби журналының июль саны татар әдәбияты классигы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый иҗатына багышланган. Әлеге басмада татар язучыларының һәм галимнәренең Г.Исхакый турындагы язмалары урын алган.

### ЯЗУЧЫ ДӘРЕС БИРӘ

Бер төркем язучылар Казан арты милли кадрлар әзерләү үзәге – Г.Тукай исемендәге педагогия көллияте базасында оештырылган «ТатАрчаҖәй» төбәкара җәйге ял аланында балалар белән очраштылар. Бу чара «Язучы дәрес бирә» проекты (ул моннан берничә ел элек шушында гамәлгә куелган иде) кысаларында үткәрелде. Арчага Россиянең төрле төбәкләреннән олимпиадаларда җиңү яулаган актив балалар җыелды. Ял аланының максаты татарча аралашу мохите булдыру, иҗатка омтылыш тудыру иде. Балалар белән очрашуда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, язучылар Ринат Мөхәммәдиев, Газинур Морат, Камил Кәримов, Сания Әхмәтҗанова, Вакыйф Нуриев, Айсылу Имамиева, әдәбият галиме Ләйлә Минһаҗева катнашты. Башта алар кабинетларда 45 минутлык дәрес бирде. Аннары зур залда дәресләргә йомгак ясалды. Кунакларны һәм балаларны көллият директоры, бу эшне оештырып йөрүче Гөлнара Гарипова сәламләде. Соңыннан язучылар шушы уку йортындагы «Әлифба» музеенда булдылар. Музей мөдире Дамир Таҗиев экскурсия үткәрде.

### «МЕДИА-САБАНТУЙ»

Быел «Медиа-Сабантуй» Питрәчтә узды. Бәйрәмдә катнашучыларны «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков, Питрәч муниципаль районы башлыгы Илһам Кашапов сәламләде. Республика матбугат һәм массакүләм комму-

никацияләр агентлыгы җитәкчесенең сәламен аның урынбасары Эльвира Әхмәтова ирештерде. Агентлык җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев соңрак үзе дә килеп кушылды һәм чыгыш ясады. Ул «Медиа Сабантуй»ның журналистларга аралашу мәйданы булуын искәртте. Бәйрәм күтәренке рухта узды. Журналистлар төрле ярышларда көч сынашты. Сабантуйның күрке булган көрәштә баш батыр булып «Мамадыш-информ»нан Илдар Хәсәнов калды. Командалар арасында да беренче урынны «Мамадыш-информ» алды.

* * *

«Татмедиа»да «Медиа-Питрау» бәйрәме дә булды. Әлеге чара «ТАТМЕДИА» АҖнә – 15, керәшен татарларының «Туганайлар» газетасына 20 ел тулу уңаеннан оештырылды. Татарстанның атказанган артистлары Вадим Захаров, Олег Фазылҗанов, «Бәрмәнчек» дәүләт фольклор ансамбле, Алинә Давыдова, Татьяна Ефремова, яшь җырчылар Виктор Агапов, Кирилл Спичков һ.б. бәйрәмне ямьләделәр. «Медиа-Питрау»ны Олеся Дмитриева белән Вадим Шрыков алып барды.

**ЧИШМӘ АЧУ**

Башкортстанның Кушнаренко районы Гомәр авылында чишмә ачу тантанасы булды. Бу – Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ балачакта суын эчеп үскән «Башкорт чишмәсе». Ул Рәдиф аганың тырышлыгы һәм матди ярдәме белән төзекләндерелде. Әлеге бәйрәм Р.Гаташның бертуган абыйлары, игезәкләр Рәшит һәм Рәфит Гатауллиннарның тууына 85 ел тулган көнне узды. Тантанада Кушнаренко районы башлыгы Марат Әхмәдуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, Башкортстанда яшәп иҗат итүче шагыйрәләр Нәҗибә Әминева (Гатауллина), Халисә Мөдәррисова, Лилия Булгакова, «Татарстан» радиосы хезмәткәре Дания Нәгыйм, «Кызыл таң» газетасы хезмәткәре Ләйсән Якупова һ.б. катнашты. Чишмә ачу тантанасы Гатауллиннарның туган авылы Марста шигырь кичәсе булып дәвам итте, соңыннан Рәшит һәм Рәфит Кәшфулла уллары рухына дога багышлау белән тәмамланды.

**МӘХӘББӘТ НИЧӘҮ БУЛА?**

«ТАТМЕДИА» бинасындагы «Әдәби кафе»да язучы Шәмсия Җиһангированың «Казан утлары» журналы китапханәсеннән сериясендә басылып чыккан «Мәхәббәт ничәү була?» китабын тәкъдим итү булды. Анда «ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков, язучылар Марсель Галиев, Нәбирә Гыйматдинова, Рәдиф Сәгъди, Алмаз Хәмзин, Асия Юнысова, галим Марсель Бакиров, «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе, китапның редакторы Ландыш Әбүдәрова, «Болгар» радиосы хезмәткәре Эльвира Камалетдинова, Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары мәгариф бүлегенең милли мәгариф эшләре буенча методисты Илгизә Ильясова, Арча районы Курса Почмак авылы китапханәчесе Вәсилә Мотыйгуллина һ.б. чыгыш ясады. Үзенең китап бәйрәмен Шәмсия Җиһангирова җыр белән тәмамлады. Чараны «Казан утлары» журналының проза бүлеге мөхәррире, язучы Рафис Корбан алып барды.

**ЯЗУЧЫЛАР ЯЗА ДА, ЙӨЗӘ ДӘ**

Биектау районы Олы Кавал авылы янындагы Чулпан күлендә «Фәйзуллин йөзүләре» булып узды. Ул 45 нче тапкыр уздырылды. Мәдәният һәм спорт бәйрәме Олы Кавал мәдәният йортында әдәби очрашу белән башланып китте. Кунакларны Биектау районы башкарма комитеты рәисе урынбасары Ринат Сабирҗанов сәламләде. Залда утырган китапханәчеләр, китап сөючеләр алдында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла (ул үзешчән каләм ияләренә Рәхмәт хатлары да тапшырды), аның урынбасары Илсөяр Иксанова, Татарстанның халык шагыйрьләре Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Равил Фәйзуллин үзе, алар белән бергә Азәрбайҗаннан килгән «Яшьлек» татар җыр һәм бию ансамбле чыгыш ясады. Күлдәге ярышларда йөзү осталыгын Равил Фәйзуллин, аның улы Газиз, «Татарстан – Яңа гасыр» телекомпаниясе баш мөхәррире Данил Гыйниятов, «Безнең мирас» журналының җаваплы сәркатибе Ленар Гобәйдуллин һ.б. күрсәтте.

2023 елның 1 июлендә 74 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә, популяр җырлар авторы **Нурия Халит кызы Измайлова** вафат булды.

Мәрхүмәнең җәсәде Америкада җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман-эссе Р.КУРБАНА «Лишние люди», роман Г.ГИЛЬМАНОВА «Искушение дьявола», рассказы В.НУРИЕВА; стихи Р.ФАЙЗУЛЛИНА, Р.СУЛЕЙМАНОВА, Г.АЙЗАТ.*
*«Новые имена»: стихи Л.АБЛИЕВОЙ.*
*«Литературный конкурс «Учитель – прекрасный человек на земле!»: рассказ А.ЗАЙНУЛЛИНОЙ «Встреча выпускников».*
*«Литература родственных народов»: рассказ Б.КУЛУНЧАКОВОЙ «Сожаление».*
*«Литературная критика»: статья Р.РАХМАНА, посвящённая 80-летию Р.Файзуллина.*
*Фотоархив.*
*«Наука»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«Память»: статья А.БАЙМУХАМЕТОВА, посвящённая 75-летию Р.Миннуллина.*
*«Публицистика»: документальная повесть Р.АХУНЗЯНОВОЙ «Память Суббуха Рафикова».*
*«Памятные письма»: письма М.Карима, К.Тимбиковой, Н.Наджми М.Галееву.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 120-летию А. Измайловой и 100-летию Л.Ихсановой. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: мечеть «Ирек» г.Казани. Фото И.АБРАМОВОЙ; писательница Рухия АХУНЗЯНОВА.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel-essay by R.KURBAN ,»Superfluous people»; novel by G.GILMANOV «The Devil's Temptation», stories by V.NURIEV; poems by R.FAYZULLIN, R.SULEYMANOV, G.AYZAT.*
*«New names»: poems by L.ABLIEVA.*
*«Literary contest «Teacher is a Wonderful Person on Earth!»: story by A.ZAYNULLINA «Alumni meeting».*
*«Literature of kindred peoples»: story by B.KULUNCHAKOVA «Regret».*
*«Literary criticism»: article by R.RAKHMAN dedicated to the 80th anniversary of R.Fayzullin.*
*Photo archive.*
*«Science»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*«Memory»: article by A.BAYMUKHAMETOV dedicated to the 75th anniversary of R.Minnullin.*
*«Publicity»: documentary story by R.AKHUNZYANOVA «Memory of Subbukh Rafikov».*
*«Memorial letters»: letters by M.Karim, K.Timbikova, N.Najmi to M.Galeev.*
*«Priceless voices»: articles for the 120th anniversary of A.Izmailova and the 100th anniversary of L.Ikhsanova.*
*The rubric is led by N.AKMAL.*
*Diary of public and cultural life.*
*On our covers: «Irek» mosque, Kazan. Photo by I.ABRAMOVA; writer Ruhia AKHUNZYANOVA.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* «Ирек» мәчете.

*Тышлыкның икенче битендә:* Лобач тавы (Кама Тамагы районы). *И.АБРАМОВА фотолары.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы Рухия АХУНҖАНОВА.